# Казан утлары

4
АПРЕЛЬ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**4**

АПРЕЛЬ
1974


## Бу санда


**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Бу беренче пароходлар. Шигырьләр . . . 3
**Х. КАМАЛОВ.** Һәркемнең гомере бер генә. Роман . . . 12
**Ф. ЯРУЛЛИН.** Яңгыр. Шигырьләр . . . 61
**М. НАСЫЙБУЛЛИН.** Телсез шаһитләр. Повесть . 65
**Г. БАКИРОВ.** Балалар дөньясы. Парчалар . . . 107
**И. ТУКТАР.** Җөмләләр . . . 108

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Х. ГАЙНЕТДИНОВ.** Май яңгыры. Шигырьләр . . 109

ОЧЕРКЛАР

**КамАЗ** елъязмасы . . . 111

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**А. ХӘСӘНОВА.** Япония... нинди ул! . . . 113

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.** Кояш тотылганда табылган хәзинә . . . 132

ӘДӘБИ МИРАС

**Т. ГЫЙЗЗӘТ.** Чордашлар, каләмдәшләр . . . 148

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ
VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**А. ӘХМӘДУЛЛИН.** Заман героен эзләү юлында 153
**Ф. ХАТИПОВ.** Җаваплылык . . . 163

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Ф. САФИУЛЛИНА.** Тел байлыгы — халыкта . . . 172

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**А. ШАПИРО.** Сәхнәдә бүгенге көн темасы . . . 179



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ГАЛИЕВ.** Җилкәннәр бирешмәс әле . . . . 182

**Ә. ДӘМИНОВ.** Учак урыннары . . . . . . . 185

САМАТ ШАКИРГА 50 ЯШЬ

Һаман да тынгысыз . . . . . . . . . . . . 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

*Редакциянең адресы: Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 4/I-1974 ел. Басарга кул куелды 18/III-1974 ел. ПФ 04032. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 89.000 экз. Заказ Ю-4. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары». 1974 ел.

## Равил Фәйзуллин

* * * *Бу беренче пароходлар...*

Иделдән бозлар китүен
миндәй кем көтә икән?
Бу беренче пароходлар
ник бик җилкетә икән!

Апрельләр җитте исә,
җаным ашкына, шаша.
Бозлардан арынып, дулкын
үтә күңелем аша.
Ник алай? Үзем дә белмим —
диңгезче түгел ласа!..

Быел нинди пароходлар
затонда калган икән?
Штурвалда торучылар
танышмы, яңамы икән?

Быел ничә баллы дулкын
ярларны юар икән?
Туган яктан киткәннәрне
кайларга куар икән?

...Су өсләрендә гудоклар
үзәкне өзәр инде!
Маякчы кызы аръякта
ничекләр түзәр инде...

Палубадан күренеп торыр
безнең якның ярлары.
Әй, онытылып бара торган
яшьлек пристаньнары!

Акчарлаклар кабат кайтты
Иделенә — Иленә.
Бу беренче пароходлар
искә төшерми ни генә!

*1972—73*

** * * Иделгә карап бер уйлану*

Су саеккач атауларда,
калкып чыкты имән төпләр.
Комда ята тамырлары —
сигезаяк кебекләр...

Үлән әле бик тиз шытмас,
туфрак өсләп ләм утырган.
Элек гөл-чәчәкле җирдә
хәзергә әле комлы буран.

Адашкан күке кыйгачлап
очып китте атау өсләп.
Ял иткән нарат башларын
килгән микән әллә эзләп?

...Фәкать картлар хәтерендә
бу якларның болыннары.
Дулкын юган, җил тараткан
зиратларның урыннарын.

Аңлы-аңсыз тия кеше
Табигатьнең теңкәсенә...
Су чигенгән җирдә йөрим
басып балык тәңкәсенә.

Еракта яр. Чын яр. Чыр-чу.
Яшьләр. Уен. Сөю-гыйшрәт...
Адәмнәр ни кылсалар да,
Җиргә кыен,
Җиргә хәсрәт.

*1973*

** * * Әйләнә сәхнә, әйләнә...*

Баш исәк тә даһи җанның
сәнгатьтәге көченә,
тик ул да каршы торалмый
сәхнә әйләнешенә.

...Күренешләрне алыштырып,
әйләнеп кереп китә.
Гомерләрне, бәгырьләрне
кискәләп, телеп китә.

Менә шушы әйләнештә
кемнеңдер соңгы роле.
Соңгы алкышлануы,
иң соңгы алган гөле.

Кемдер Зөһрә, кемдер Таһир,
кем әле Хәлил бүген.
Ә сәхнәдән киткәннәрнең
үз хәле хәлдер бүген...

Әйләнә сәхнә, әйләнә,
сибелеп кала еллар.
Сибелеп кала язмышлар,
режиссерлар, геройлар...

Сибелә... Әйләнә сәхнә.
Булмый каршы торып.
Изге җиргә була икән
табынып тик, баш орып.

Тоела кайчак, сәхнә ул
агачтан түгелдер күк.
Күз яше белән юылган
күзгедер, күңелдер күк.

Анда иңләп йөрүчеләр
илаһи затлар кебек.
Алар гаҗәеп якын да
һәм бераз ят та кебек.

...Әйләнә сәхнә, әйләнә,
шуышып кереп китә.
Гомерләрне, бәгырьләрне
кискәләп, телеп китә.

*1973*

* * *

Түбенә төшеп уйлап баксаң,
бер нәрсә дә куркыныч түгел.
Туу-үлү дигән ике чикне
котылгысыз үтү һәркемгә.
Мәңгелекнең, фанилыкның да
мохтаҗы юк безнең хөкемгә.
Ахыр чиктә
бер нәрсә дә куркыныч түгел,
бер нәрсә дә...

*1970*

* * *

Яңгыр юктан бар җир кипте, корды.
Дөньяның йөзе саргайды.
Коткән болыт килеп койды... суга.
Аңа карап
Идел сырты калынаймады.

Җанны сыгып язган җырларымны,
шул болыт күк,
мин дә түктем яшь бер йөрәккә.
Ул — тоймады, үзгәрмәде дә.
Ә мин — беттем,
калдым өрәккә...

*1973*

* * * *...гә*

Җир җимермәк идек!
Күкләр ватмак идек!
Мәңгелектә балкыр
утлар якмак идек!

...Күзгә сагыш иңгән.
Исәп башны игән.
Балкыр чыра сүнгән
тамчы яңгыр белән...

*1970*

* * * *Чит җирләрдә йөргән чакта*

Барсы үзеңдә — эчтә. Яна...
Ни мәгънә эндәшеп тә!
Ни дошман юк, ни дус... Булмый
җан атып та, көнләшеп тә.

Бөркетме син, бер чебешме?
Беркем барыбер тоймас.
Бар да чит шул. Танышлардан —
Зөһрә йолдыз, Ай да Кояш.
Ичмасам, кайчак аларга
җанны бушатам бераз...

*1971*

* * * *Бер мәҗлестә*

Бу йөзләрнең күбесе онытылыр,
гел хәтердә тормас бу табын.
Тик онытмам Сибгат Хәкимнең мин
«Туган тел»не җырлаган чагын.

Башын чөйгән бераз. Әйтерсең лә
көткән бәхет кошын ул тоткан.
Чын барлыгы белән җырга кереп
фани борчуларны оныткан.

Бөтен халык бергә җырлаганга
күңеленә шатлык, нур тулган.
«Туган тел» шул безнең барыбызны
берләштерә, итә бертуган.

Сибгат Хәким җырлый. Кемдер бәлки
ишетмидер аның тавышын да.
Тойган тояр, аның моңы баса
җырчыларның монда барсын да.

Җырчы шагыйрьне син аңла гына,
хисләрен той, төшен гаменә.
Уе киткән аның халкыбызның
үткәненә, киләчәгенә.

Җырында ул әйтә: халкыңны сөй,
Тукайны син минем күк сагын...
Сынау катыш өмет күзе белән
карап ала без — яшьләр ягын.

...Байтак мәҗлестәшләр онытылыр.
Гел хәтердә тормас бу табын.
Тик онытмам Сибгат Хәкимнең мин
«Туган тел»не җырлаган чагын.

*1972—73*

* * * *Бу — хис Иле*

Бу — сәясәт түгел.
Сөю — бер йөзле.
Бер утта янганның
барын тигезли.

Бу — хис Иле. Монда
кануннар үзгә.
Монда көчсез — Акыл
көйләгән бизмән.

Монда кызганмыйлар
һәм баш имиләр.
Рөхсәт сорамыйлар,
рәхмәт димиләр.

Гамәлгә кермәгән
дәрәҗә, даннар.
Мәхәббәттә һәркем
үзенчә янган.

Бәхетлеләр хәтта
сүзсез аңлаша.
Яшәүне данлыйлар
җан һәм тән аша.

Бу — үзгә Ил. Монда
ләззәт, хис — өстә.
Юк монда яз-көзләр,
юк иртә-кич тә...

Сөю — хезмәт түгел.
Норма, тариф юк.
Уйлап баксаң, ансыз
Җирдә Тарих юк!

*1972*

* * *

Нишләр идем әгәр дә мин
диңгездә туган булсам!
Тәпи йөргән эзләремә
акчарлак кунган булса?..

Болай да ярсу йөрәккә
диңгез шау биргән булса,
ирекккә шашкан күңелгә
давылын өргән булса?..

Далада тусам да, җаным —
диңгезгә шундый охшаш:
я булам мин зәңгәр сагыш,
я булам дәһшәт — тоташ.

Күрәсең, тәңре әйткәндер:
болай да хисле бала —
диңгез түгел, далалардан
сабырлык кирәк аңа...

...Нишләр идем әгәр дә мин
тауларда туган булсам!
Кыя башларына менеп
бөркетләр куган булсам?..

Күрәсең, тәңре әйткәндер:
болай да текә башлы,
үссен күреп болыннарны,
үзәннәрдәге ташны.

...Туган илне үзе сайлап
алалмый адәм-инсан.
Нишләр идем туган җирдә
туа алмаган булсам!

*1973*

* * * *Дәрдмәндкә тәкълидән*

Нинди мәхшәр!
Кайдан бу ут?
Җилкәннәр дөрләп яна.
Дулкын шаша.
Каек тулук, —
Кайда ул, кайда ана...

Кораб баткан.
Каек эзсез.
Нинди ярдан аңгырык?
Кайсы якта
илсез, күзсез
кемнәр йөри каңгырып?..

*1968*

* * *

*Аклыны бирдисәң,*
*ак яра җанда.*
*Каралыны бирсәң —*
*карасы...*

Ах, аеклык! —
Бар да аныклык!
Кешеләр — аксым, матдә, җисем.
Җирдә аек акыл ташса, әй Күк үкси:
«Сөю әмер үтәп йөрсен...»

Ах, исәрлек!
Күк шаркылдап көлә!
Җирдә — уйнаш, сугыш, рия...
Кара көя Җир,
тетри
һәм оятыннан
асыл акылларны җыя
туфрагына кире...

*1968*

* * *

Сау булыгыз, күз күргән илләр!
Дәрья-диңгезләр,
шәһәрләр,
йөзләр!
Сау булыгыз!
Сау булыгыз...

Очрашам да,
сәламлим һәм саубуллашам.
Очрашам да,
сәламлим һәм саубуллашам...

Гел шулай.
Бу илләргә,
бу җирләргә
әллә килəм бүтән...
Бу йөзләрне
әллә күрәм бүтән...

Таңда — төннең башы.
Туу — үлем башы.
Кабат күрә сирәк
комсыз адәм башы.

Сау булыгыз, күз күргән илләр!
Инде янә күрә калсам,
(сөенечтән ул чак бәлки яшь тә чыгар) —
хушлашудан элек
сәламләрмен башта.
Чын күңелдән.
Әүвәл күргән кебек.

Ә хәзергә —
сау булыгыз...

*1973*

# Кыска шигырьләрдән

* * * *Этюд*

Күл төбендә йоклыйдыр төн.
Төнбоеклар тора сакта.

Кемдер таба, кемдер югалта...

Кемдер фейерверк чөйде
йолдыз атылган чакта.

* * * *Кыенрак*

Кызыктырамы!
Читләр куйган балдактагы якут шәп ул!
Үз туфрагың җәүһәрләрен
ком аралаш күрү кыен.

* * * *Сынау*

Аз вакыт та безне тетте!
Аҗаган булып килдең дә
тычкан уты булып киттең...

* * * *Төш кенә*

Премьерлар, уенчыклар, сөйгән ярлар,
режиссерлар — бар да искерә...
Торган саен матурая бара
бала чакта күргән төш кенә.

* * * *Бер чараң юк...*

Куркак дустан
усал дошман яхшырак.
Дошман өчен корал була,
хыянәтенә якыныңның
бер чараң юк.

* * * *Кем тыя ала!*

Уйламагыз, кошның канатларын кискәч инде
туктар дип ул, күккә табынудан.
Син онытсаң да, мине кем тыя ала
яратудан сине, сагынудан!

* * * *Неруда ватанын уйлап*

Йөземнәр пешеп тулган.
Төрмәләр шыплап тулган.
Алмалар эрмәкләнгән.
Йөрәкләр чәрдәкләнгән.

* * * *Бәлки...*

Биек очкан кошка Кеше:
«Әй, могҗиза! Ничек оча,
күз дә иярми!» — диде.
Булса канатсыз, аны бәлки
хәшәрәт дияр иде...

* * * *Бу дөньяда...*

Теле, иле булса — шагыйрь үрли.
Укучысы булса — шәбәя.
Бу дөньяда күпме хисле жаннар
ук атмакчы сынган җәядән...

*1972—73*

## Хисам Камалов

# ҺӘРКЕМНЕҢ ГОМЕРЕ БЕР ГЕНӘ

РОМАН

8

Немец һөҗүме вакытында Алексей Баранов батареясына әллә ни зур каза килмәсә дә, бүтән батареялар бик каты кыршылган иде, шуңа күрә дивизионны яңа көчләр белән тулыландыру өчен икенче эшелонга күчерделәр. Алексейныкылар әйбәт кенә бер урманчыкка урнаштылар. Орудиеләрне сугышчан тәртипкә куйдылар, траншея һәм блиндажлар казыдылар. Тикшерүче, өйрәтүче, отчет сораучылар күбәеп китте. Теге оперуполномоченный да исән икән әле. Бер көнне блиндажда Алексей бер үзе калгач кына ул килеп керде.

— Синең гаебең юк, ахрысы, капитан,— диде ул ышандырырлык тавыш белән.— Син безгә ярдәм ит. Ничек булган, барча нечкәлекләренә кадәр искә төшереп, безгә язып бирсәңче, ә? Ул кушмый, ә үтенә иде.

— Әллә сызымнар дошманга эләккәнме? — дип шаккатып сорады Алексей.

Вәкил ирен очлары белән генә «нинди беркатлы син?!» дигән кебек елмайгандай булды һәм дипломатларча дәшми торды, тик барыбер җавап кайтармады. Шулай да теләге үтәләчәк икәнен капитанның чыраеннан сизеп, канәгать булып чыгып китте. Алексей бу кеше калдырган ак кәгазь битләренә карады, озак кына уйга чумып утырды. Барысын да искә төшереп булырмы? Кырык беренче елның канлы җәе иде, ә бүген кырык дүртенче елның июнь башы — нәкъ өч ел узган. Алексей ул вакытта отделение командиры — сержант, Көнчыгыш Пруссия чигеннән өч йөз чакрым тылдагы хәрби шәһәрчектә хезмәттә иде. Әх, яраның кутырларын куптару никадәр авыр икәнен үз башына төшкән кеше генә белер!

...Иртәгә сугыш башланачак ул көнне өйләдән соң ук бөтен комсостав җыелышка киткән иде. Тоташ эре чыршылык эченә урнашкан хәрби шәһәрчек, бушап, кешесез өй шикелле булып калды. Сержант Баранов үзенең отделениесе белән штабта каравылда тора иде. Шәһәрчекнең кайсы почмагындадыр бер эт җанны талап улый да улый, шомлы

Дәвамы. Башы өченче санда.

тавышы белән күңелне өзеп-өзеп ала шикелле тоела. Телефонда исә бернинди тавыш юк. Һәммәсе тыныч, парольләрне әйтешәсең дә трубканы куеп торасың. Алексей икенче бүлмәдә ял итүче кызылармеецны уятты һәм үзе аның урынына ятты. Ярты көн узды, ә җыелышка киткәннәр һаман юк. Нишләп болай соңгардылар икән, мөгаен, кино күрсәтә торганнардыр дип уйлады сержант һәм йокыга китте. Яктырып килгәндә, ул кинәт коточкыч шартлау тавышына сикереп торды. Һавада унлаган самолет гүли, алар бөтен тирәне бомбага тоталар иде. Күзләре мангаена менгән, чиксез куркынган кызылармеец Алексейга килеп орынды.

— Нәрсә бу, сержант? — дип, беләгеннән тарткалады.

Алексей:.

— Дошман провокациясе! Постны ташламаска! — диде дә телефонга килде һәм шалтыратырга кереште. Парольне күпме генә кычкырса да, аңа җавап бирүче булмады. Ә тышта бомбалар шартлый, мәхшәр, ишегалды бөтенләй күренми иде, кинәт тәрәзә пыялалары коелып төште, ә кайсылары рамнары белән очты. Кемдер ишегалды ягыннан штабка таба йөгерде.

— Хыянәт! Хыя-нәт! — дип, ямьсез, йөрәк өшеткеч тавыш белән кычкырды. Алексей нишләргә белмәде, читлектәге арыслан шикелле, бүлмә буйлап чабулады. Кемнәрдер атлар җигеп, каядыр чыгып чабалар. «Штабны ташларга ярамый!» — дип, үз алдына сөйләнде Алексей. «Ничек инде бу?! Нәрсә бу?!» дигән мең-мең шик җанын тигәнәк кебек чәнчә-чәнчә сырып алды. Тагы телефонны боргаларга кереште. Күзенә берни күренмәде, күз алдында бары тик куркынган һәм каушаган кызылармеецлар гына буталыштылар. Нишләргә?! Командирлар кайда?! Шул вакыт безнең чик буендагы орудиеләр атканы ишетелеп китте. Алексей сугыш башланган дип уйларга да, уйламаска да белмәде. Самолетлар каядыр безнең тылга таба очалар иде... Бер минут тынлык урнашты, һаваны тутырган балчык кисәкләреннән, тузаннан көн кинәт караңгыланып китте. Көтмәгәндә бусагада комиссар Калмыков пәйда булды. Аның шул хәтле тыныч кыяфәтле булуы таң калырлык иде. Иреннәре кысылган, күзләре эчкә баткан, йөнтәс кашлары тырпайган, үзеннән одеколон исе аңкып тора. Алексей аңа өрәккә караган кебек текәлде. Комиссар, исәнләшеп тә тормыйча, өстәлдәге дежур китабын алды, укыды, аннары әллә нинди бер кош тавышы белән кычкырып җибәрде. Алексей шунда гына комиссарның, артык нык тартылган кыл кебек, киеренке халәтен тойды.

— Сержант Баранов?

— Есть! — диде Алексей, ниһаять, бу билгесез, коточкыч хәлдән котылу чарасы табылганына сөенеп. Чөнки комиссар нинди булса да приказ бирәчәк. Комиссар борылып кесәсеннән ачкычларын алды, сейфны ачарга тотынды. Сейф тиз генә ачылмады. Алексей да барып сейф ишегенә тотынды, ниһаять, авыр ишек ачылып китте, сержант бер адым артка чикте. Комиссар аннан әллә нинди йомшак күн тышлы папкалар чыгарды, үзе Алексейга таба шикләнгән шикелле, икеләнебрәк карап алды. Йөзеннән күренгәнчә, аңарда бу сержантка ышану һәм ышанмау тойгысы көрәшә иде бугай. Менә ул, катгый бер карарга килгән кебек, тураеп басты.

— Сержант, бу секретный пакетны баш штабка тапшыр! Штаб биредән өч йөз чакрымдагы Соколка станциясенә урнашкан, син аны белергә тиеш! — дип, ул Алексейның күзләренә карады, һәм тагы аның чыраенда икеләнү шәүләсе пәйда булды, бер мәл аска карап торды, тешләрен кысты. — Яңа сынала торган яшерен коралның техник данныйлары! — дип сүзен дәвам иттерде. Сүзләре ысылдап чыкты, әллә тамагына суык тидергәнме, әллә кинәт башка төшкән бу фаҗигадән һаман исенә килә алмыймы, аның яңаклары күгәргән төсле, тавышы да беткән, көчсезләнгән кебек иде.

Комиссар Алексей янына килде, папканы аңа тоттырды.

— Менә пакет, менә башың! — дип, сөякчел бармаклары белән Алексейның маңгаена төрткәләде. Аннары, китәргә кирәклеген аңлаткандай, читкә карады һәм йомшый төшеп: — Мин ышанам сиңа, улым!! — диде. Шул вакыт тагы бөтен тирәне коточкыч гүләү авазы күмде, якында гына бомба шартлады, кирпеч ватыклары тузаныннан һава кызыл сироп төсенә керде. Алексей папканы капчыгына сала-сала чыгып чапты. Аның дежурда бирелгән пистолеты бар иде, ул шуңа канәгать булып, капшап куйды. Казармалар артыннан үткәндә, кемдер нәкъ кинодагы матрос шикелле кычкыра-кычкыра аңа таба чаба иде.

— Полундра, хыянәт! Хыянәт!..

— Сугыш, анаңны сатыйм, нинди хыянәт булсын! — дип акырды аңа Алексей.— Тукта, паникага бирелмә! — Теге кеше карап та тормады, күзе тонган, каядыр кычкыра-кычкыра чабып китте. Алексей нәрсә уйларга да белмәде, «миңа приказ бирелгән, мин шуны үтәргә тиеш!» дип үзен юата-юата йөгерде. Хәзер шоссе юлына чыгарга кирәк, анда машиналар булмый калмас дигән фикергә килде. «Ә яралансам?» — дип чиксез куркып уйланды ул. «Пакетны нишләтергә?» Аннары шушы фикернең дәвамы буларак: «Ә үлсәм?!» — дигән тагы да коточкычрак уй килде. «Юк, юк!» — бу уйны тизрәк башыннан куып җибәрде. Бомба шартлаулар, гүләүләр ачыграк ишетелгән саен, шул җан өшеткеч уй аның күңелен били бара иде. Бу пакетның үз җаныннан кыйбатрак икәнен тоя ул, ләкин икърар итәргә күңеле базмый. Аннары өмет белән үзен-үзе тынычландыра: бу хәл фәкать дошман провокациясе, чөнки Германия белән Советлар Союзы арасында килешү пакты бар. Мин Соколкага җиткәнче үк барысы да үз урынына кайтыр!..

Ул, хәлдән таеп, бер агач төбенә ауды, бик нык сусаган, су эчәсе килә иде. Хәрби шәһәрчек ягына карап торды, аннан куркыныч кара болыт кебек булып төтен күтәрелә иде. Складларга да ут капты микәнни? Бик каты шартлаулар, гөрселдәүләр, җир селкенүләр тагы кабатланды. Алексей, буыннары оеп калудан куркып, капылт кына торып юлга кузгалды. Дошман самолетлары агач башларына тия-тия диярлек узып, кайдадыр алда бомба ташлап, кире чик ягына очтылар. Нәрсә булыр бу?..

Икенче көнне таң беленгәндә Алексей бер хуторга килеп җитеп, шунда тамак ялгап чыкты. Өйгә дә кереп тормады, бер чүлмәк сөт сорап алды да күтәреп эчте, күпмедер акча калдырып, алга ашыкты. Тегеләр дә сорашмадылар, Алексейның таушалган кыяфәтеннән барысын да аңладылар. Ул, күңеле нидер сизенгәндәй, олы юлдан читтәрәк барырга тырышты, чөнки гамәл күрсәткәнчә, самолетлар юл уңаена очалар, юлны бомбага тоталар. Анда безнең көчләр киләдер. Тупланалардыр.

Бара торгач, ул үзенә игътибар итмәсеннәр өчен, каешындагы пистолетын алып, кесәсенә салды, ә кабурасын атып бәрде. Пакетны да капчыкта йөртү куркыныч шикелле күренде, кая яшерергә дип һаман баш ватты. Шул төнне ул нинди дә иске салам эскертендә кунды. Үз-үзенә ачуы килүдән, җанны кайчы кебек телгәли торган уйлардан йөрәге әрнеде...

...Сагаеп кына бер чаукалыкны чыгып килгәндә, кинәт хәрби киемле кеше очратты. Алексей шундый сөенде, гүя ул аның якын туганы! Эчтә дөрләп янган бөтен утын, бөтен газапларын аңа бушатасы һәм акрыпакрып туйганчы елыйсы килде. Алексей аңа ачык чырай белән якынлашты, бу таза, мәһабәт кешенең старшина икәнен белде. Тик старшинаның йөзе гаҗәп кырыс, салкын иде. Ул ашап утыра, капчык авызында берике телем икмәге бар иде. Алексейның гаҗиз йөзенә өмет нуры чыккан иде. Ул көзгегә караган шикелле үзенең ничә көннән бирле кырынмаган икәнен белде, Ияген капшап торды.

— Ну, герой, нәрсә? — диде старшина шактый озак, сыный карап торганнан соң. Алексей станциягә юнәлүен әйтте, үзенең буыннары көчсезләнә баруын бу кеше алдында ачык сизгән кебек булды.

— Анда немец өченче көн үк десант төшергән! — диде старшина бер дә ачылмыйча, түбән караган килеш. Һәм саубуллашып та тормыйча, капчыгын төйнәп җилкәсенә асты да китеп барды. Алексейны ул өметсез кешегә санады бугай!

Алексей шуны сизде, аңа тагылмады. Каккан казыктай басып калды. Бу фаҗига, бу билгесезлек станциягә җиткәч бетәр дип өметләнгән иде, шул өмете һаман үскән, ныгыган иде, менә ул өмет хәзер аның миендә бомба кебек шартлады. Кая барырга, нишләргә? Әгәр пакет булмаса, берәр частька барып кушылыр иде дә тынычланыр иде. Куе үләннәр арасында ул уйланып утырды, үзенең изрәп төшеп, йоклап киткәнен дә сизми калды. Күпме яткандыр, бик нык өшеп уянды, өстендә шинеле булмавын хәзер генә абайлады. Таң аткан, бөтен җир чык суына чыланган. Алексей бер басу юлына төште, берәр авылга алып барыр, дип исәп итте. Ләкин кемнәрнеңдер аңа кычкыруын ишетте. Алексей колакларын торгызды, каршы як юлда атлар җигелгән бричкага баскан кызылармеецлар аңа дәшәләр иде.

Алар берничә бричкага төялеп көне буе бардылар. Бу чолганышта булган частьның сугышчылары икән. Ключи станциясенә чигенергә приказ килгәндә, тылга немец десант төшереп өлгергән. Болар флангларДан кечкенә группалар рәвешендә чигенергә мәҗбүр булганнар. Алексейның эченә беразжылы керде, ни булса, шул дигән фикергә килде ул. Солдатлар сөйләшмиләр, һәммәсе дә моңсу һәм киеренке, таркау кыяфәттә иделәр.

Бер шоссе юлы буенда аларны туктаттылар.

— Туганнар, хәзер үк цепькә! Немец биредән прорыв ясарга килә, аның борынына сугарга кирәк! — дип ачынып аңлатты комиссар. Аның чырае качкан, үзе ашыга, кабалана иде. «Кухняга барып ашарга алыгыз!» диде дә китеп тә барды.

Солдатлар команданы сөенеп каршы алдылар. Чөнки билгесезлек белән җаннары өтелеп бетә язган иде. Бик яхшы ашаттылар, һәркемгә кисәк-кисәк ит бирделәр. Аннары юлның бер очындагы вак урманлы түбәгә алып барып окоп казырга куштылар. Анда бик күп сугышчы траншеялар казып урнашып маташалар иде, болар исә иш янына куш кына булдылар. Алексей командирга барып, үзендә яшерен пакет барлыгын әйтергә бик кызынган иде, ләкин немецларга булган ачуы аны тыеп калды. Ул һаман да сугышның рәхимсез чынбарлык түгел, ә очраклы бернәрсә булуын өмет итә, бу мәхшәр бүген-иртәгә бетәр шикелле тоела иде аңа. Немецларны үз күзе белән күрәсе, кеше кыяфәтендәге ерткычларның берсен генә булса да теге дөньяга озатасы килде.

Башта зур тузан баганасы күренде, аннары алда немецлар пәйда булды. Алар мотоциклларга төялгәннәр, бишекләренә пулемет куйганнар иде. Тачанка кебек дип уйлады Алексей. Сигез йөз метр чамасы алда, тирән чокыр аша салынган күпер булган. Ләкин күпер сүтелеп куелган иде. Немецлар шунда туктап калдылар, мотоциклларыннан төшеп, каранып йөрделәр. Сул як текә, тик уң яктан сөзәкләнеп төшкән бер җирдән барып кына чокырны читләтеп үтәргә мөмкин. Немецлар, нидер сизенгән шикелле, каскаларын киделәр һәм мотоциклларга төялделәр. Беренче бишекле машина сөзәк юлга төште, бүтәннәре аның артыннан тизелде. Нәкъ шул чак безнең цепь залп бирде, кул пулеметлары ата башлады. Берничә немец бишектә утырган килеш тынсыз калды. Буталыш китте, мотоцикллар бер-берсенә бәрелешеп бетте, берсенең тәгәрмәче ычкынып, сөзәклектән чокырга хәтле тәгәрәп килде. Каушаган немецлар кая керер тишек таба алмыйча өзгәләнделәр, сүтелгән күпер астына сыендылар. Кайберләре мотоциклларына утырып кире элдерделәр. Коточкыч

буталыш булды. Зәңгәр киемле гәүдәләрнең юлда аунап ятулары безнең солдатларга көч бирде. Димәк, туры һәм җаен белеп атканда, немец пулядан бик шәп үлә икән!

Кич булып килгәндә, гигант мөгезборыннар шикелле булып, тузан эченнән танклар килеп чыкты. Безнең кырык бишле туплар ток-ток аттылар, әмма танклар коточкыч тавыш чыгарып һаман үрмәләделәр. Гранаталар әзерләргә команда булды. Танклар, сөзәклектән төшеп, клевер җире кырыеннан шуышалар иде. Ләкин шул чак дәррәү бөтен җир яна башлады, баштагы өч танк тоташ ут эчендә калды. Бу тозак иде, командир сөзәк җир белән клеверга ике цистерна керосин һәм автол сиптергән. Танклар шунда керү белән, яндыргыч снаряд атып, шул төшкә ут элдерделәр. Караңгылык фонында ут ялкыны тагы да җетерәк, зуррак булып күренде. Немец тарафыннан әзәрлекләнеп килгән сугышчыларның йөзләрендә канәгатьлек нурлары биеде.

— Менә шулай кыйнарга кирәк ерткычларны! — диештеләр.

— Немец та тимердән эшләнмәгән икән, ә?

— Әйе, әйе! — диде Алексей.

— Ник без контратакага бармыйбыз? — дип кычкырды кайсыдыр солдат. Аның тавышы ачынулы иде.

— Чынлап та, иптәш сержант, ә? — дип баягы солдат эләп алды аның батыр ниятен. — Контратакага барсак, берничә танкны плен алырга була иде, әх!

Алексей нәрсә дип тә җавап кайтара алмады, чөнки бу уй аның башына да килмәде. Шул чак цепь буенча приказ ишетте:

— Яңа рубежларга чигенергә! Тавышланмаска, ут кабызмаска!

Тыл хуҗалыгына килеп, машиналарга һәм арбаларга төяләделәр дә тагы юлга чыктылар. Кичке дымлы салкын аркаларны өшетте, ләкин арыганлык, йончыганлык арбага утыргач үзен тагы да каты сиздерде. Керфекләр юл тузаны кунудан гына түгел, йокы килүдән тимер капкач булып авырайдылар.

Алексей тиз генә йоклап китә алмады. Бу көннәр аның гомер җебен бик күп кисәкләргә тураклап ташлады. Шул өзекләрне бергә кушарга азапланып карады, ләкин алар берничек тә кушылмады. Ә артта немецлар ракета чөяләр, ул ракеталар ут күбәләкләре шикелле булып офыкка куналар һәм шунда сүнәләр. Ниндидер сагыш йөрәкне чеметеп-чеметеп ала. Югалту сагышы, үз башың кайгысын каплап, өскә чыга һәм өзлексез җанны әрнетә. Йөрәкнең ниндидер бер өлеше әле артта, дошман басып алган җирләрдә кала кебек иде.

Төне буе шулай бардылар. Таң атып килгәндә, ниндидер бер күпер күренде, аннары кургаш тасма кебек елга да ялтырады. Күпер янында милиционер тора, регулировщик булырга тиеш иде. Барысы да юлны сорарга кирәк, ул белер дип өметләнделәр. Ләкин бераз якынлашу белән теге автоматыннан ата башлады. Юлның икенче ягыннан берничә автомат аңа кушылды, йокымсыраган солдатлар төшәргә өлгергәнче, яраланган атлар коточкыч кешни-кешни дулап чабарга тотындылар, берничәсе котырган көч белән күпер аркылы чыгарга да өлгерде, берничәсе бу якта буталып калды. Кызылармеецларның исәннәре төрлесе төрле якка сибелде. Алексей маңгае белән бик каты җиргә барып төшкәч кенә исенә килде һәм шунда ук немец засадасына эләккәнлеген аңлады. Икенче минутта атларның егылуларын һәм торырга маташып сикеренүләрен күреп калды. Алексей җиргә иелә төшеп, бер урманлыкка таба чапты да чапты, тирә-ягында пулялар «выжт-выжт» итеп торды. Ул бик озак йөгерде, урманның теге ягына чыккач, иген кырлары башлана иде, Алексей тирән-тирән итеп су ярган чокырларны чамалады. Ул биек үләннәр белән капланган кызыл ярлы чокырга төште һәм үзенең хәлсезләнүен, аягын нәрсәдер бик каты чәнчүен тойды. Ату тавышлары хәзер ишетелми иде. Әллә яраландыммы дип, Алексей аякларын чишенде. Юк,

яраланмаган икән, тик бармак араларыннан кан саркый, чиләнеп, суелып беткән. Нишләргә? Юарга су юк. Алексей утырган җирдән генә ак әрем яфраклары җыйды, аларны учында уды, бармак яраларына япты. Әрнетеп әчеттерә башлады, шулай да рәхәт иде. Ул җиргә ятты, үз хәлен тагы уйларга кереште. Ничек вещмешокны кулдан ычкындырмаганмын?! Башына шул фикер килгәч эсселе-суыклы булып китте. Юк, болай ярамый, бер часть штабын табарга, пакетны шунда тапшырырга! Башка чара юк! Ә каян табарга ул частьны?! Мин үзем ахмак, мина башта ук тимер юлны кararга кирәк булган, ничек тә тиешле частьны таба алган булыр идем. Частьлар бит юл тирәләренә тупланалар. Бу кырда нинди часть булсын?! Соколка станциясе янынннан ук мина унга борылырга, тимер юлга төшәргә кирәк булган. Эх, тиле баш, болай минем бөтен тормышым бер үкенеч ахмаклык кына булачак бит! Юк, үкенеч кенә булып каласы килми. Приказ үтәлергә тиеш, шунсыз күңел тынгы тапмаячак, антка хыянәт иткән шикелле җанны өшетеп торачак.

Аяклар, әрнүдән туктап, рәхәт: кызыша. Болай ятсаң, йоклап китүең дә бар дип, куркып уйланды Алексей. Әрем яфраклары җыйгалап, шуның белән тагы аякларын уды да әрнешкән бармакларына ыштыр урады, күн итекләрен киде. Иген басуы булгач, берәр хутор ерак түгелдер дип, зиһене алдан йөгерде. Башта чокыр эченнән атлады, аннары басу юлыннан барды. Бер җан иясе күренми иде. Күктә тургайлар, ниндидер кошлар чыр-чу килеп сайраша. Исәбе бу юлы ялгышмады, тау астында кечкенә генә авыл үзенең салам түбәле аркасын кояшта җылытып ята иде. Немецлар бармы анда, юкмы? Адым саен күңелдә шул сорау кабатлана. Каядыр еракта, сул яктарак немец самолетлары очкан тавыш ишетелә. Алексей иң якындагы өйнең бәрәңге бакчасына керде һәм ишегалдында берәрсе күренмәсме дип, посып, күзәтеп ятты. Авыл бик тын, немец аягы әле бирегә килеп җитмәгән булырга охшый. Бераз яткач, ул сукмактан абзар читәненә килде, ишегалдын яхшылап күзәтте. Бәйләгән бозау бар, тавык-чебешләр йөри, чучка балалары мыркылдаша. Арт капкадан ишегалдына керде, өй алды баскычына килә башлады. Тәрәзәләр түр якта иде. Кинәт ишек ачылды, Алексей юл сорарга, ашарга юнәтергә кирәк, эрсезләнмичә булмас дип ният иткән иде. Ләкин баскыч өстендә пәйда булган хатын-кыз, учын маңгаена козырек итеп куеп, аңа текәлде, ул ни уйларга да өлгерми калды. Алексей үз фамилиясен ишетте.

— Сержант Баранов? — Хатынның тавышы әллә ничек гадәти түгел, каушаган, төерле иде. Хатын баскыч култыксасына тотына-тотына төште, ә үзе нәрсәгәдер елмая иде. Алексей хәтерләргә тырышты: бу хатынны кайда күргәне бар соң? Хатын аның күзләренә туры караган килеш килә, өстендә алгы төймәләре эләктерелмәгән ирләр пинжәге, үзе ничектер таныш кебек тоела, чыннан да?!

— Әллә танымыйсыз? Ә мин сезне таныдым.

— Каядыр күргән кебек булам, — диде Алексей, хатын аның учына үзенең кечкенә йомшак кулын салгач. Үзе һаман хатынның чыраеннан таныш чалымнар эзли, әмма таба алмый изалана иде.

— Санчастьны хәтерлисезме, ә? — диде хатын, ягымлы тавыш белән. Йөзенә нигәдер гаепле елмаю чыкты.

— Ә-ә, Фира Касыймовна, шулаймы? — Алексей да чиксез сөенде, туган частьның кемен генә очратса да зур шатлык иде.

Фира да үзенең чиксез шатлануын бөтен кыяфәте белән аңлатты.

— Сез ничек биредә? — дип, икенче минутта исенә килеп сорады Алексей.

— Ә сез соң ничек? — Фираның йөзе күңелсезләнеп китте.

Бу көтелмәгән очрашу тыштан шатлыклы тоелса да, эчтән моңсу һәм пошаманлы, фаҗигале иде, икесе дә шуны тойдылар. Фира йөзен читкә борды, бите буйлап борчак шикелле эре-эре күз яшьләре тәгәрәде.

Алексей үзен көчсез сизде, хатынны бу хәвефтән коткарасы, яклыйсы килде. Фираның чарасыз-гаҗиз йөзе һәм нәфислеге аны бу мәхшәр эскәнҗәсеннән йоларга өнди иде. Фира, күзләрен учы белән сөртеп, Алексейга карады.

— Интендант Таминдаровны беләм, әйе, — диде Алексей, Фираның ире белән таныш булуын белгертеп.

Тик Фира аны тыңламый, дикъкате бүтән нәрсәдә иде, ул кинәт Алексейны бүлдереп:

— Немецлар! — дип кычкырып җибәрде, Алексейга килеп тотынды, хатын ниндидер сигнал белән шартлы рефлекска өйрәтелгән җәнлек шикелле алга талпынды, ишек төбе баскычындагы төенчеген әләктерде дә капкага атылды. Алексей аның артыннан иярде, шул чак кайдадыр мотор тавышлары тырылдаганы ишетелде. Өйгә кереп чәй эчәргә ымсынганы исенә төште, ярар, тагы булмады инде дип кул селтәде Алексей.

— Мин юлны беләм, — диде Фира, тынын көчкә-көчкә алып, Алексейга су буе таллары эченнән бара торган тар сукмакны күрсәтте.

Алар куркыныч биек басмадан ярның икенче ягына чыктылар. Анда сөзәк тау һәм сирәк урманлык башлана иде. Алексей, Фираның тыны ешайганын күреп, төенчеген алды. Тау түбәсенә менеп җиткәч, туктап, авылга карап тордылар. Авылның теге як тавында, гүя томан эчендәге кебек, мотоцикл шәүләләре күренде, һәм шул хәлне раслаган сыман автоматтан аткан тавышлар һаваны ярды. Алексей, Фираның алдан сизеп өлгерүенә хәйран булып, сөенеп куйды. Немец тырнагына чак эләкми калдык бит, дип уйлады. Фира иң элек ике кулы белән җиргә таянды, аннары ничектер бик иплә кенә чирәмгә утырды, шунда кулларын баш очына куеп кырын ятты, бер колагы белән җирне тыңлаган кебек тынып торды. Тик шунда ук кузгалды.

— Һаман киләләр, — диде ул тыныч кына. Каушаусыз, түзем рәвештә Алексейга карады һәм алдан китте.

Фираның озын аяклары, төз гәүдәсе ничектер бик үк табигый түгел кебек күренде. Ул кызу-кызу атлый, ирләр пинжәге киң җилкәләренә килешеп тора иде. Алексей аның көчле һәм мәһабәт булуын күреп барды.

— Биредән йөз чакрымнарда тимер юл стансасы,— диде Фира, Алексейга якынлашып.

— Берәр авылдан ат юнәтеп булмасмы, шул хәтле юлны ничек үтмәк кирәк?

Алексей Фираның авыр атлавына дикъкать итте. Хатын исә дикъкатьне бик тиз сизде, минем хәлне аңлый, ахры, мине кайгырта, нинди әйбәт кеше, бәхетем бөтенләй юк түгел икән әле дип куанды.

— Ай, шәп булыр иде,— диде хатын, Алексейның хыялын хуплап.

— Чик ерак калды бугай инде,— дип, Алексей сүзне икенчегә борды.

— Ерак, ерак! Без башта машиналар белән бардык. Немец бомбага тотты, көчкә котылып калдык. Машиналар янды.

— Ирегез белән идегезме?

— Кая! Кичтән җыелышка киткән иде, кайтмады, мине юлда таныш шофер утыртты. Уф!.. — Хатын, иренең язмышын белмәгәнгә, тирән көрсенеп көенде.— Бу нинди хәл, һич аңлашылмый?!

— Аңлашыла! — диде Алексей, хатынны үчекләргә теләмичә.

Кинәт бүген кайсы ай, кайсы число икәнен беләсе килде, хәтердә барысы да буталып беткән, асты өскә килгән. Чама белән ул июльнең сигезләре тирәседер дип уйлады. Бигрәк тә бу билгесезлек авыр иде. Ә билгесезлектә кеше ихтыярын җуя башлый, зилзилә агымында билгесез бер йомычка кебек булып калуы мөмкин. Алексей шуны аңлагандай булды, үзен-үзе ябышкак көчсез фикерләрдән арындырырга теләгәндәй, сүзен дәвам иттерде.

— Фира Касыймовна, бик бетерешмәгез әле! — диде һәм үзен дә

шуңа ышандырырга тырышып өстәде: — Барысы да вакытлы гына!..

— Әй, шулай булса, хәер бирер идем. Ә сез белмисезме, безнең часть кайда икән?

— Эх, белсәм, болай каңгырып та йөрмәс идем.

— Барысы да харап булдылар микән инде? Ирем бер дә үзен саклый торганнардан түгел.

— Бәлки исәннәрдер, немецны тоткарлап сугышалардыр, я булмаса чигенәләрдер.

— Шундый приказ бармыни соң? Нигә чигенәләр?

— Күрәсең, бар, — диде Алексей һәм моннан өч-дүрт көн элек ничек немецларның борыннарына сукканлыкларын, берничә танкны яндырганлыкларын сөйләп барды. Сөйләгәндә үч алудан туган шатлыгын яшерә алмады, хатын алдында аның көчле буласы килә иде, ләкин Фираның күз сирпүендә: без сүздә көчле анысы дигән киная сизгән кебек булды һәм тынып калды. Сүзнең гамәлгә туры килмәгәнен менә алар ничә көн инде үз җилкәләрендә татыйлар. Кешене уйга төшерү өчен бер бәла дә җитә, диләр бит. Күпме сөйләндек без, күпме күкрәк кактык? Киноларда безнең көчләр нинди кагылмаслык дәһшәтле иде! Юк, боларны хәзер уйлау файдасыз, болай уйлау гаебенне бүтәннәр җилкәсенә аударырга маташу шикелле! Кеше үзен түгел, бүтәннәрне гаепләргә бик оста. Ник без шулай икән?!. Алексей үзенә комачау иткән кебек тоелган бу уйларын башыннан куып җибәрде. Ул уйлар аны ач кигәвеннәр кебек сырып алалар һәм әнәләрен җанга кадыйлар, каната лар, әрнетәләр иде.

Алда ниндидер чиркәү гөмбәзе күренде. Димәк, зур гына авыл. Юлчыларны шул рухландырды, арыган буыннарына көч өстәгән кебек итте. Өметләрне кабындырды, күңелгә бик күп өмет тулды, хыяллар уңыш канатында очынып, авылга бардылар, кире кайттылар. Бигрәк тә Фираның хәле авыр иде. Ләкин барган саен, авыл чигенә барган кебек тоела, көн эссе, тамак кибә, иреннәр ярыла иде.

— Бүтән бара алмыйм,— диде Фира һәм юл буендагы бер зирек төбенә утырды.

Алексей, су эзләп, алгарак китте, анда бер тирән чокыр күренә иде. Фира, нәүмизләнеп, карап калды, Алексейның нәрсәдәндер канәгать булмавын һәм ачуы килүен ул аның кыяфәтеннән сизде. Нишлим инде, мин аңа бәла генә шул дип уйлады. Туфлиен салып куйды, күлмәк путасын чишеп, тир белән пешеккән тәненең ачытуын тойды. Пинжәген үләнгә җәеп, кырын ятты. Шул чак карынындагы икенче җан, үзенең барлыгын белгертеп, тибенеп куйды. Фира үзенең срокларын инде ничәнче кат санарга кереште: җиде ай да өч көн булган икән. Алексей әле минем хәлне белми бугай, әйдә, белмәсен, юкса, тагы да ныграк куркыр. Болай да мине очратуына әчтән генә үкенә булыр... Миннән ничек котылырга белми булыр! Нишләмәк кирәк, көчсезләнгән һәм искәрмәстән чыгырдан чыгарылган күңелгә гел кире уйлар гына тулучан...

Алексей чокырдагы сазлыктан, бик үк чиста булмаса да, баклашкасына су тутырды. Үзе юынды, аякларын чишенеп суга тыгып торды, бармаклары һаман каный иде. Кайдадыр, күк күкрәгән тавыш таратып, немец самолетлары оча. Бүген көн артык җете кояшлы түгел, сүрәнрәк; сыек болытлар аша кояш алай ук каты көйдерми, тик җил булмаганга, бик бөркү, һава тыгыз, дымлы, авыр. «Бүген тагы унбиш чакрым кайта алсак, әйбәт булыр иде», — дип уйлады Алексей. Ул килгәндә Фира берни булмагандай йоклап ята иде. Хатын Алексейның аяк тавышыннан шунда ук уянды, торып утырды, чәчләрен рәтләде, озын ачык муены матур булып күренде, ә толымы аның тагын да матур, икегә бүлеп үрелгән, бал төсле саргылт — үзенчә мәһабәт иде.

— Күп эчмәгез, юкса, бара алмассыз, — диде Алексей аңа, баклашка сузып.

Фираның кулларына дикъкать итте: мәрхәмәт нуры таратып торалар

кебек. Нинди гажиз алар! Кызганудан анык йөрәге сулкылдап куйды. Тик ни майтара ала ул? Әнә житкән сакалы да эчен пошыра, ләкин кырынырга ихтыяр көче юк бит.

— Инде сез килмисез дип торам, — диде Фира, баклашканы кире биреп.

— Һе, ничек инде? — дип елмайды Алексей, кояш ашап чуендай каралган, сакал баскан бите уртасында ак тешләре жетеләнеп күренде.

— Куркудан ниләр генә башка килми, миңа ачуланмагыз инде, Алексей, яме!

— Нигә ачуланыйм, мин үземне-үзем ачуланам.

— Үзегезне дә ачуланмагыз! Ачу ул хәтәр, ачу ул иясендә генә туктап калмый, бүтәннәргә дә барып кагыла! — Хатын кузгалды, китеп баручы Алексей артыннан калышмыйча атлады.

— Бу ни исемле авыл әле? — диде Алексей, сүзне икенчегә борып.

— Ипатово булырга тиеш! — Фира унлап авылны теге йортта чагында язып алган булган. «Каян зиһененә килгән?» — дип, Алексей моны Фираның уңганлыгына юрады. Куркәмлекнең, эчке сафлыкның да, ахры, тәэсире бар. Алексей хатын янында шуны тойган кебек булды.

Авыл зур гына, ул калкулык өстенә урнашкан. Аңа керә торган юллар урманга чиктәш. Юлчылар килгән жирдән дә кайбер урамнар күренә. Нигә бер дә моржалардан төтен чыкмый? — дип күзәтте Алексей һәм шунда ук күзләре ялгышуын аңлады.

— Бәхет бармы безнең, Фира, юкмы, ә? — диде Алексей, хатынны дәртләндерергә теләп.

— Чү, чү, бәхетне куркыта күрмә! — дип, Фира да өметкә зур ышаныч баглавын белдерде.

Алар икесе берьюлы туктап калдылар.

— Әллә кичне көтикме? — диде Алексей, ара ике чакрым чамасы калгач.

Нәкъ шул вакыт авылның төньягындарак тузан баганасы күтәрелде.

— Эх, тагы булмады, немецлар бугай?! — диде Фира, гаять борчылган, еламсыраган тавыш белән.

Алексей ни уйларга белмичә торганда артта машина тавышлары ишетелде. Икенче бер мизгелдә юлдан авылга таба элдерүче мотоцикллар күренде. Алексей Фираны тиз генә кулыннан алды да юл буендагы киндер жиренә алып кереп китте. Кешедән дә биек булып үскән киндер аларны яшерде. Караңгы төшкәнче тордылар. Алексей нәрсә дип исәп итәргә дә белмәде, өметләре тагы юкка чыкты. Бу нинди эш инде? Аңа вөждан үзенең тырнаклары белән яңадан ябышты. Фира каршында Алексей үзен бик уңайсыз итеп тойды, ничектер оят иде. Инде нишләргә? Ләкин тере жан һич тә өмет өзми икән, һаман ышана һәм хәрәкәтләнергә куша иде.

Таң атканда алар бер хуторга килеп чыктылар. Монда бик тыныч иде, шунлыктан беренче йортка ук керделәр. Бик илгәзәк кешеләр туры килде. Ашарга, эчәргә бирделәр. Хужа хатын Фираның йөкле икәнен сизенеп, Алексейга таба ияге белән ымлап:

— Бу иреңме? — дип кызыксынды.

Фира:

— Әйе, — диде, Алексейга күз кырые белән карап алды. Хатын Алексей савытына сөт өстәгәндә, иелебрәк елмайды да:

— Арту көтәсезмени? — дип уфырып куйды.

Алексейга да:

— Әйе, — дип баш кагудан бүтән чара булмады. Башында уйлары йөгереште: әйтәм аны, Фира үзен сәер тота иде, мин, ахмак, шуны белмәгәнмен дип, бик нык гажәпкә калды.

Юл, ориентир сорап, рәхмәт әйтеп, юлчылар тагы кузгалдылар. Бик озак бер сүз дәшмичә бардылар. Житеп килгән арышлар, өлгерүдән

агарган борчак басулары һәм сөт кебек ак чәчкәгә күмелгән карабодай жирләре артта кала барды. Шундый мул, гажәп байлыкның кара күмергә әйләнүенә ышанасы килми, күңел әрнешә. Барысын да үзең белән алып китәсе, ниндидер могжиза белән хәвефтән коткарасы килә.

Берничә көннән Фира хәлдән тайды. Бер утыргач яңадан кузгала алмады. Шунда кунарга булдылар. Алексей яфраклар, үләннәр жыеп, Фирага урын әзерләде. Фира Алексейнын дәшмәвеннән курыкты, төнлә калдырып китмәгәе дигән уй яңадан күңеленә килде.

— Аркам өши, Алексей, миңа арканны куеп ят, — диде Фира, нык калтыранып. Алексей тыңлады, уңайсыз булса да, кырыена ятты.

— Ничек соң бу болай? — дип сорап куйды.

Фира жанланып киткәндәй булды. Алексейнын нәрсә хакында соравын шунда ук аңлады.

— И-и, шундый күңелем тартмаган иде, иремне тыңлап менә... Казаннныкы без, ул кунакка кайтты да үзе белән алып китте, башымны әйләндерде, уйларга да бирмәде. Үзе гажәп көнчә!..

— Мин татарларны беләм, бергә уйнап үстек.

— Әллә син дә Казаннанмы? — диде Фира, куанырга әзер тавыш белән.

— Мин Самарадан, — дип, Алексей сүзен дәвам иттерәсе килмәгән кебек тынып калды.

— Анда туганнарыгыз бармы?

— Ерак бер апа бар, әти-әни егерме беренче елны үлгәннәр.

— Син ике яшьлек булып калгансың.

— Әйе, каян белдең?

— Төсеңнән, йөзеңнән. Ничә яшь икәнен исәпләп чыгардым.

— Йөзгә яшь язылганмыни? Белми идем.

— Дикъкать итсәң, авыр мәсьәлә түгел. Бер билгесезле генә тигезләмә. — Фираның тавышында шаянлык чаткылары сизелде.

Алексей калак сөякләре белән хатынның йомшак аркасын тойды, аңарда бернинди хис тә уянмады, Фираның кәефе күтәренке булуына гына гажәпсенде.

— Һе, мин карт инде, — диде Алексей, хатынның кәефен төшермәскә тырышып.

— Сиңа әле яшисе дә яшисе! — Фираның чәчләре Алексейнын муенын кытыклады, чәчләрдән кояшта көйгән тәмле ис килә иде. — Хатының кайда соң?

— Кемнеңдер мич алдында күмер ашый, — диде Алексей, шулай ук шаяртып.

— Алайса, әле синең тормышның пичәте дә алынмаган.— Фираның тавышы тагы да шаянрак чыкты.

— Әйе, пичәте дә кубарылмаган! — Алексейның тавышыннан моның киресен аңларга кирәк иде, Фира шулай сизенде дә тынып калды.

Таң белән торып, кулларына берәр телем икмәк тоткан килеш, тагы кузгалдылар. Һава тын, кошлар сайрый, гүя дөньяда бернинди хәвеф юк, гүя беркемнең күз яше коелмый, ә яңа чыгып килгән кояш нурларында алланып, үлән яфракларыннан чыклар гына коела. Юлчылар көне буе диярлек атладылар. Фирага бик авыр иде, ул Алексей аңардан бизмәсен, өмете өзелмәсен өчен бөтен көченә тырышып атлый. Урманны чыгып, басу юлы белән киткәндә, якында гына автоматтан аткан чытырдавык тавыш яңгырады. Фира белән Алексей житкән арыш янынннан баралар иде. Карасалар, урманнан ике немец чыгып килә.

— Кач, Алексей! — дип кычкырды Фира.

Юл кинәт чокырга борылды, тегеләр күмелде. «Күрделәрме, юкмы?» — дигән шик Алексейның башына чүкеч белән суккан кебек бәрде. Ул иген эченә качарга теләп йөгерә башлады, Алда елга икән,

яр астында көтү туплауда бугай. Ике хатын-кыз күренә, көтүчеләр булса кирәк. Алексей алар янына чабып килеп төште.

— Немецлар, качырыгыз! — дип пышылдады.

Тегеләр куыш янында утыралар иде, кинәт хәрәкәткә килделәр. Ләкин качар җир юк иде. Ярлар биек, теге ягына чыгып өлгермәячәк. «Менә капкынга эләктем», — дип уйлады Алексей һәм теге хатыннарга ачу белән карады. Әллә биштәрне генә яшерергәме? Юк, пакет! Эх, пакет! Әрле-бирле сугылды. Фира да килеп җитте, аңа хатыннар иске бишмәт кидерделәр, туфлиләрен кычыткан эченә аттылар.

— Безнең кыз дип әйтербез! — диештеләр.

Нишләргә белми үрсәләнгәндә, Алексей куыш авызында толып күрде, ни булса ул дип, алды да, йонлы ягын тышка калдырып, шуны өстенә ябынды һәм таллар күләгәсендәрәк яткан сыерлар һәм сарыклар арасына барып, имеш, сарык кыяфәтенә кереп, җиргә ауды. Сарыклар бөгәлчәннән куркып, борыннарын яр балчыгына төртәләр, пырх-пырх итеп әле болай, әле тегеләй йөренәләр. Шул чак көлешә-көлешә немецлар килеп җитте. Алар бик шат, нинди дер кызыктан авыз ералар. Куыш янына килделәр:

— Золдатен, золдатен?! — дип кычкырындылар, берсе куышны карады.

Алексей толып тишегеннән бер күзе белән күзәтеп ята. Тегеләр маллар яткан җиргә таба килә башладылар. Алексейның күзен кинәт караңгы сарды, бөтен дикъкате, көче, нервысы бер ноктага тупланды: хәзер үк пистолетны алып, аларга каршы кутәрелергә! Иң элек берсен атар, аннары берәү генә кала. Тик аларны үзеңнән көчсез дип санау да ахмаклыктыр. Йөрәк дөп-дөп тибә, юк, килеп тапканчыга кадәр түзәргә, атарга өлгерер.. Тегеләрнең аяк тавышлары тынып калды, немецлар туплау өеменә текәлделәр. Шул минутта кинәт Алексейга кемдер бик каты итеп китереп типте. «Беттем!» дип уйлады Алексей, бөтен җире кинәт тиргә батты, торырга дип пистолетын кысты, толыпның бер кырыен ачарга да атарга дигән уй энә шикелле башын чәнчеде. Ләкин шунда тагы аңа төрттеләр, Алексей ачык сизде: бу аяк белән тибүгә охшамаган шикелле тоелды һәм бер минутка аны шул тоткарлап калды. Шул чак «тибү» тагы кабатланды, юк, бу аяк тибүе түгел?! Пистолет тоткан кулын суза башлагач кинәт кире алды һәм берни тоймый ята бирде... Әллә юри үчеклиләрме? Барыбер эләкте, дип, әллә шулай көләләрме? Алексейның ачуы, үче чигенә җитте, пакетны Фирага бирәсе калган, бәлки ул исән кала алыр иде?!

Ә немецлар бер минут карап тордылар да ярдан менеп киттеләр. Тагы кычкырып көлештеләр.

Бераздан көтүчеләрнең яшьрәге яр өстенә менде, тегеләрнең киткәнлекләрен күзәтеп төште. Өлкәне аңа ышанмады, үзе барып тикшерде һәм шуннан соң гына Алексей янына барды.

— Киттеләр, тизрәк әлдерегез! — диде.

Алексей толыпны ачып ташлады һәм янында зур, спираль мөгезле олы миренос тәкәсе басып торганын күрде һәм «тибүче»нең кем икәнен шунда ук аңлады, көләсе килде, ләкин көлә алмады. Аның өне качкан, йөзендә тәмам кеше чырае калмаган, куллары калтырый, иреннәре сүзсез үзләреннән-үзләре хәрәкәтләнә, ләкин сер бирмәскә кирәк иде. Ул арада Фира да агарынып килеп җитте.

— Уф, йөрәгем туктады, инде бетүебез дип торам,— диде ул, өзек-өзек итеп. Өлкән хатын берни булмаган кебек кызыксынды:

— Иреңме?

— Ирем, ирем,— диде Фира, нәрсә әйткәнен үзе дә белештерми.— Безгә юл өйрәтегез, ашарга бирегез!

Алексей да, исен җыеп, иркен сулап куйды, гаепле һәм кырыс елмайды. Ул үзенең куркуыннан бик нык оялды. «Болай ярамый!» дип, үзен әчтән кисәтте.

Көтүче кыз аларны шактый юл озата барды. Немецлар авылда кичә генә пәйда булганнар. Тик үзләрен бик ышанычлы тотмыйлар, безнекеләр кысрыклый, ахры, аларны, дип аңлатты кызый. Мин дә сезнең белән китәр идем, өйдә авыру әнием бар дип, еламсырап юл уртасында басып калды.

Икенче көнне кич алар бер тимер юл тупигына килеп чыктылар. Фира бөтенләй арыды, атлый алмас булды.

— Алексей, мине ташлама! — дип, ялварулы тавыш белән әйтте Фира утырган җирдән. Битләре бүрәнкәләнеп әчкә баткан, күзләре болганчыкланган кебек, җетелеген җуйган иде. Алексей ничек аны юатырга белми торды: «Нигә ул минем турыда шулай уйлый, әллә төсемә ачу, ризасызлык, авырсыну билгеләре чыктымы? — дип пошып куйды ул. Аннары Алексей тимер юлда күренгән ике вагонны барып карарга ниятләде.

— Әле барма, бераз күз бәйләнсен! — диде Фира.

Ул Алексейны югалтудан, янсә аңа берәр нәрсә булудан бик курка, үзенә-үзе ышанмый, чөнки хәле һаман авырая бара. Ә Алексей берничек тә ярдәм итә алмаудан гасабиланып уйлана иде.

— Юк, юк, курыкма.

Фираның аны да кайгыртуын егет аңлап җитмәде бугай. Алексей нишләргә белми аптырады, тәмәке тартырга итте, Фира тагы уфылдый, ыңгыраша башлагач, аның янына килде.

— Кит, кит! — диде Фира куллары белән һаваны көрәп. Ул тешләрен шакырдатып кыскан, кычкырмас өчен бар түземен туплаган, көчкә тыелып тора.

Алексей тимер юлга таба чапты, ул су табып булмасмы дип өметләнә иде. Пассажир вагонының берсендә буш әрҗәләр, шешәләр аунап ята иде, эзли торгач ике-өч бөтен шешә дә табылды. Аннары икенче вагонта керде, анда өстәлләр, шулай ук шешәләр, ватык табак-савыт идәнне тутырган иде. Бер почмактагы йомычканы актарып караса, анда тагы берничә бөтен шампанский шешәсе. Тизрәк Фира янына йөгерде. Инде караңгы төшеп килә иде. Ни күрсен, Фира нишләргә белми изалана, аны чиксез нык тулгак тота, ул үрсәләнә, чалкан яткан килеш, башын әле бер якка, әле икенче якка ташлый, тешләрен шыгырдата.

— Су, су! — дип ыңгыраша, иреннәре кара көйгән, күз кабаклары кара кабырчык кебек булганнар. Алексей, шешәне ачып, кружкага чемердәп торган сыеклык сала, Фираның башын бер кулы белән күтәрә төшеп, икенче кулы белән шәрабне эчертә. Хатын зур йотымнар белән голт-голт итеп йота, муенында мускулы хәрәкәт итә. Күкрәкләре тулышып йоту тырышлыгыннан тирбәләләр.

— Кит, кит! — дип пышылдый Фира. — Мин табам, ахры. Кит, кит, рәхмәт!

Алексей нишләргә белмичә, читкәрәк китә, агач артына утыра да күзәтә.

— Нәрсә кирәк, Фира?! — дип, ишетелер-ишетелмәс эндәшә.

Үлә генә күрмәсен дип, йөрәге чәнчешә. Фираның газаплануын җиңеләйтергә үзендә көч юклыктан нишләргә, кая барып бәрелергә белми өзгәләнә. Хатынның ыңгырашуы бәгырен пычак белән телгән кебек итә.

— Алексей, Алексей?! — дип, бер минуттан дәшә Фира. Алексей йөгереп барып җитә, кружкага шәраб салып иреннәренә куя. Хатын бер-ике йоткан итә дә:

— Кит, кит! — дип, тагы аны куа башлый. Аннары тагы. — Алексей, Алексей! Син мине ташлап калдырмассың, мин ышанам. Кит, кит! — ди.

Алексей әле болай чапкынлый, әле тегеләй йөгерә. Нишләргә? Алексей җиргә тезләнә, башын ике учы белән кыса, колакларын томалап тора, тик алай да чыдый алмый. Шундый шәхси газапта кеше ялгыз, бергә-бер булып кала икән!

— Үләм! — дип уфылдады Фира, тәмам хәлсез тавыш белән.

Алексей аның баш очына барып чүгәләде. Шәрабле кружканы ирен-нәренә тигерде. Фира куллары белән эчен уа, ыңгыраша, исен җуйган кебек сөйләнә. Авыртудан кашы-бите сынгалап җимерелгән, күзләре йомылган. Ул аякларын җиргә чәнчеп киерелә, аннан тагы тынып кала.

— Кит-кит! — ди Фира, ыңгырашып.

Алексей тагы агач артына поса, ләкин хатынның газап чигүе аның аякларын атлатмый. Бераздан үлә башлаган тавыш тагы Алексейны бирегә тартып китерә.

— Мә, кис! — дип пышылдый Фира икенче мизгелдә. Кайчы ялтырап китә. Алексей кайчыны эләктереп ала, хатын уңайсызланып кына юбка-сын өскәрәк сыера, үзе озын-озын итеп сулыш ала.

Кинәт бала елаган тавыш ишетелде, тагы бер минуттан караңгыда баланың гәүдәсе яктырып күренде. Фира хәлсез калды, күкрәкләре тир-бәлүдән туктаган кебек булды. Алексей аның кулына тотынды, кулы пешерерлек дәрәҗәдә кайнар иде. Бала көчлерәк кычкырып җибәрде. Фира, кулларына таяна-таяна, ярым яткан килеш башын күтәрде.

— Кис, кис! — дип боерды.

Алексей тәгаен эш нәрсәдә икәнен аңламыйча, нишләргә белмичә, кайчы тоткан көе, хатын гәүдәсе янында мүкәләп йөри иде. Фира бөтен көчен җыеп, үрмәләгән кебек итте, аякларына таба иелеп, Алексейга каян кисәргә икәнлекне күрсәтте. Караңгыда Алексей нәрсәнедер кайчы япьләренә эләктереп өзде. Бала тагы да катырак тавыш белән елый башлады. Фира торып утырды һәм аяклары арасыннан баланы алып, ак җәймәгә төрде, алдан әзерләп авызына капкан җеп белән әлмәкләп, баланың кендеген бәйләде. Ләкин шунда хәле бетеп чалкан ауды. Алексей аның шәрә тәненә әйбер ябарга базмады, тик шәрабле кружканы авызына китереп башын кулы белән күтәреп торды. Фира берни белештермәгән шикелле, чиксез сусаудан йотлыгып-йотлыгып эчте. Бала да тынып калды. Ана озын-озын итеп сулыш алды, кымшанмыйча ятты, йөзенә аз гына җан чаткылары кайта башлаган кебек булды. Ул, ахры, йокыга талды, тын алуы тигезләнде, тәмле итеп мышный башлады. Алексей да кинәт эчендәге киеренкелеге йомшарган кебек сизде һәм аңын ниндидер рәхәт томан сарганын тойды. Ул бер минуттан бала тавышына уянып китте, Фира да уянды, баланы алып, күкрәген аның зур ачылган авызына каптырды, үзенең ялангач аякларын япкандай итте, чәчләрен маңгаеннан сыпыргалады. Инде таң атып килә иде, бәхеткә каршы, иртә бик җылы, тымызык иде. Черкиләр дә бимазаламады.

— Малаймы, кызмы? — диде Алексей.

— Малай, — диде Фира, яктырып китеп, гүя аның эчендә кинәт ут кабынды. Алексей да елмайды, ниндидер билгесез, моңарчы һич тә булмаган, таныш түгел шатлык биләп алды аны.

Шешәләр кичә бушап беткән иде, соңгысын ачып, Фирага бирде дә үзе теге вагоннарга ашыкты. Яңадан берничә тулы шешә, әллә ничә пачка акча табып килде. Кассага тап булу бигрәк тә гаҗәп иде.

— Малай бәхете! — дип шаяртты Алексей, шундый бай ганимәткә сөенеп.

Фира торган, үзен рәткә китергән иде. Малай белән нәрсәдер мы-

дыр-мыдыр сөйләшә. Бала изрәп йоклый бугай. Ул аны биләп, юлга хәстәрләп маташа.

Бик каты атыш тавышлары аларны бу төштән алга куалады. Фираны бик нык сусау газаплады, әмма шәраб эчәргә шикләнде. Алексей шактый гына эчте, аның кәефе күтәрелеп китте, көч өстәлде, тагын бөтен авырлыкны үз җилкәсендә йөртә торган солдатка әйләнде.

Өйләгә хәтле бардылар. Кичкә таба бала уянып елый башлады. Фира аңа ими каптырса да, бала тынычланмады. Ана нишләргә белми, чарасыздан тагы имчәген аның авызына китерә, нәнинең башын үзенә кыса, әмма малай йөрәк өзгеч аваз белән һаман елый. Тәмам арыгач кына йоклап китә. Фираның күзләре мөлдерәмә яшь белән тула. Баланың ни өчен елавын һич кенә дә белә алмый.

— Имми бит,— ди ул, бала елый башлагач, Алексейдан уңайсызланып.

— Ник?

— Әллә сөтем юк инде? — Фира үз-үзеннән сораган кебек әйтеп куя.

Бераз тын алып торгач, бала тагы еларга тотынды. Фира ниләр генә эшләсә дә, малай елаудан туктамый.

— Чын, сөтем юк бугай.

— Ничек инде алай булсын? — Алексей бик нык гаҗәпкә калды.

Алар кузгалып китә алмадылар. Алексей яфраклы чыбыклар сындырып алып килде, Фираны малай белән җайлап яткырды. Үзе дә шунда баш төртте. Бала еласа да, бераз черем итеп алдылар.

Фира сискәнеп уянды, кояш чыгып килә иде. Имчәген тизрәк балага төртте, теге йотлыгып имде дә имде. Тавышын чыгармады. Фира, чиксез өмет белән тулып, Алексейны юлга ашыктырды.

Бала белән мәшәкатьләнеп, алар куркынычны да, арыганлыкларын да онытып бардылар. Алексей дошман самолетлары очкан тарафтан фронт сызыгын чамалады. Көн урталарында бер самолетның кара төтенгә уралып түбән таба мәтәлүен күзәттеләр.

— Малай бәхете! — дип шатланды Алексей. Баланы кулына алып озак кына күтәреп барды.

— Ни исемле була инде бу? — дип, Фирага карады.

— Мин кыз көткән идем, малай булыр дип уйламадым да! Әйдә, син берәр исем тап! — диде Фира, елмаеп һәм горурланып.

— Мин бит татарча исемнәр белмим, интернациональ исем ярыймы?

— Ярый,— Фира Алексейның малайны яратуына чиксез сөенде, аңа рәхмәт хисләрен карашы белән белгертә иде.

— Марат! Ничек булыр, ә? — Алексейның да шундый ышанычтан авызы ерылды. Фира ул исемне ятатканлыгын әйтеп шатланды, йөзендә нур чаткылары күренде.

Ике көннән соң бер тимер юл karауchыга туктадылар. Шунда сөт юнәтеп, бүтән кирәк-ярак сатып алып, тагы юлга чыктылар. Атыш тавышлары ерагайган кебек булды. Башта моңа ышанмаганнар иде. Кичен безнең частьларның көнбатышка таба баруларын күргәч, куктән бәхет төшкән кебек булды. Бу хәл котылуга булган өметне шундый кабындырып җибәрде, хыялны шунда ук чын итте, бу юлы, ниһаять, өмет аларны алдамады.

Төнлә алар бер станциядән товар поездына утырып киттеләр. Бу чиксез уңыш, бәхет иде. Иртән алар Клин шәһәренә барып төштеләр. Алексей Фираны вокзалда калдырып, үзләренең штабын эзләргә китте. Кичкырын гына әйләнеп кайтты, ләкин штабны таба алмаган иде. Фираны поездга утыртып җибәрим, аннары иркенләп эзләрмен, дип карар

итте ул. Тик карангы төшү белән үк немец самолетлары шәһәрне бомбага тоттылар. Коточкыч мәхшәр купты. Станция тирәсенә бигрәк тә нык әлекте. Алексей Фира белән подвалга төшеп котылып калдылар. Таң алдыннан товар поездына утыртып, Фираны Мәскәүгә озатты. Фираның күзләреннән өзлексез яшь акты.

— Хат яз, хат яз! — дип үтенде һәм өметен өзеп, гаепле елмайган килеш өстәде: — Юк, син миннән туйдың инде. Кая! Язмассың!..

— Язам, язам! — диде Алексей, артык вәгъдә бирмичә, чөнки мондый шартларда берни дә ышандырып була алмавына ул бик нык төшенгән иде инде: сүзләр дә, вәгъдәләр дә, хисләр дә, фикерләр дә, кешеләр дә көне-сәгате белән үзгәрә, бөтенләй танымаслык булалар. Алексей Фирага капчыгын һәм барлык акчаларны бирде.

— Сине ничек итеп бәхилләтермен инде, ә? — дип өзгәләнде Фира.

— Әнә малайны гына сакла! — диде Алексей, аталарча кайгыртып, аңа шулай әйтү күңелле иде...

Поезд китте, шул чак Алексей үзенә Фираның да, малайның да бик кадерле һәм үз булуын аңлады, аларның күңеленә нииндидер җепләр бәйләнгәнлеген сизде. Поездның ерагайган саен шушы бәйләнешне өзгәләвен тоеп ачынды, әчендә кинәт кенә ниндидер өшеткеч бушлык хасил булды. Ул поезд китеп күмелгәнче басып торды, җанының бер өлешен шул поезд өстерәп алып киткән кебек хис итте.

Үзләренең подразделение кешеләрен Алексей икенче көнне генә эзләп таба алды. Бәхеткә каршы, пакет белән кызыксынучы кеше дә табылды. Ул комиссар чинында иде.

— Ничек исән калдың син? — дип, һаман Алексейның исәнлегенә ышанмады, килеп, җилкәсеннән тотты. — Просто ышана алмыйм! — Ул башын селкеп уйланып торды, пакетны күкрәгенә кыскан килеш, әрлебирле йөренде.

Алексей аңламады, баш өстендә үлем минут саен янап, асылынып торганда, нинди коткару турында әйтергә мөмкин?

Аларның часте бетү сәбәпле, комиссар Алексейны Кавтин хәрби лагерена артиллерист итеп җибәрергә теләвен әйтте һәм, шул хакта кәгазь язып биреп, аның белән саубуллашты...

Шуннан бирле Алексей бик күп сугыш танкысы аша үтте, күпме мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз килде, инде беттем, үлдем дигәч, кай төшендәдер җан посып калып, аны тагы терелдерде, дүрт тапкыр госпитальдә генә «ремонтланып» чыкты. Шул өч ел эчендә чины да капитан дәрәҗәсенә күтәрелде. Әле дә булса, көн саен диярлек сират күпере кичеп, үзенең ил каршындагы вазифасын үтәп яткан көне.

## 9

Армия газетыннан килеп, Мурзыевны фотога төшерделәр. «Немец самоходкасын ничек җимерә алдыгыз? Курыкмадыгызмы?» — дип төпченде төшерүче. Мурзыев әллә ни сөйли алмады, чөнки русча бик аз белә иде, рәсемгә төшерүче бер дә канәгать булмыйча, һаман төпченде, батырдан нинди дә булса тәфсил суырып чыгарырга өмет итте. Мурзыев исә «әйе, «юк» дигән сүзләр белән аннан ничек котылырга белмәде.

— Бөтен союзга даның китәчәк бит! — дип сөйләнде фотограф.

Сугышчы исә аны аңламады, кулын гына селекте. Дан нәрсә ул? Нәрсәгә икән ул кешегә? Дан белән нишлиләр соң? Дан өчен җимерделәрмени алар дошман самоходкасын? Әнә нугай Кәбиров башын салды. Дан белән ул нишләсен инде! Дан дигән әйбер Мурзыевка нәрсәгә? Ул тауларда, далада яши иде, үзенең бер көтү куе бар иде, хәзер көтү сирәкләнгән дип язалар өйдән. Далада ач бүреләр бик күбәйгән.

Шау-гөр итеп кемнәрнендер бирегә килгәнлекләре ишетелде. Ишеккә авызы ерылган, ниндидер шатлыктан кызарган йөзле Тәкәнәев күренде. Аның артыннан тагы берничә сугышчы керде. Тәкәнәев старшина белән тылга нәрсәдер алырга киткән иде, шуннан бераз күчтәнәч алып кайткан икән. Сары сукно белән тышлаган баклашкасын биленнән чишеп алды да капкачын борып ачты һәм шул уймак кебек сырлы капкачка ниндидер эчемлек салып, башлап Мурзыевка сузды.

— Вай-вай! — диде эчкәч, авызын яндырганга бүтән сүз әйтә алмыйча.

— Бер тарыдан ботка булмый, — диде Никишин, тагы бер уймак өмет итеп.

Тәкәнәев шактый кәефле иде, барсына бер кат күчтәнәчтән авыз иттереп чыккач, актыгын үзе салып эчте дә баклашкасын бил каешына кигертеп куйды һәм иптәшләренә сөйли башлады:

— Утыз сигезенче елның көзендә өйләндем мин. Казанда бухгалтерлар курсында укучы бер кыз белән танышкан идем. Курсларны тәмамлап, кыз Буа районы үзәгенә эшкә китте. Без хат аша гына хәбәрләшә башладык. Бер-беребезне һаман сынашабыз, бер-беребезгә үпкәләшкән булабыз, тагы татулашабыз. Бирегә кил, бередә өйләнешербез дә аннан Казанга кайтырбыз, минем биредә туганнарым күп, алар шуны телиләр дип яза кыз. Мине чакыра. Ә мин аны чакырам. Өйдә әни карчык авырып ята. Өйләнәсе дә килә, куркам да. Ничек булып чыгар, кешене белеп булмый бит. Гаффә мине үлеп яратуы турында чуклыйчуклый яза. Айның 29 ында көтәм, ди бу һаман. Теге айда да шул числода көтәм дигән иде, бу айда да шулай. Мин шикләнә калдым. Нидән булыр бу? Бәлки ял көннәре шул вакытта туры килә торгандыр дим. Юк, ай саен алай булуы мөмкин түгел! Мин 15 ендә барам дип хат яздым, шунда ук җавап — 29 ында кил, дигән. Шул көнне абый өйдә була дигән. Мин тагы уйлыйм: ниткән тәкъдир язган сан бу?

Беркөнне тәвәккәлләдем — нәкъ майның унбише. Көн салкынча, әллә нинди дымсу җил исә иде ул кичне. Барып төштем. Ульян аша йөрелә иде ул чакта. Гаффә яңа гына эштән кайткан, мине күргәч, нишләргә белми, югалып калды. Сүтелгән чәчләрен үрә алмый маташты. Абыйлары мине чак күтәреп кенә алмадылар, ә Гаффә бик үк шатланмады бугай. Чәче тузган көе — үзе шундый матур, кәттә. Ә ник күңелсезрәк — белмим. Егет чак, дәрт ташып тора. Шулай да эчемдә ниндидер әйбәт булмаган нәрсә бар. Ашадык, эчтек, туганнары белән сөйләшеп утырдым. Болай ягымлы, намуслы кешеләргә охшыйлар. Кич булды, Гаффәнең аерымрак бүлмәсе бар икән. Шунда яттык. Авылда егет белән кызның куну гадәте бар бит. Бернинди дә шахыр-махыр юк монда. Ләкин Гаффәнең абыйсы белән сөйләшү искә төште.

— Өйләнергә диген, алайса, чынлапмы? — диде ул, икебез генә тышка тартырга чыккач.

— Шулайрак иде, — дим. Өйләнәм дип авыз тутырып әйтергә куркам да. Шактый каты сорады бу, минем сеңел белән шаярма, кирәгеңне бирермен, малай, дип аңладым мин аның соравын. Шулай уйланып ятам. Утны сүндереп бераз торгач, мин Гаффә янына үрмәләдем, ул миңа аерым җәйгән иде. Ничек шундый чакта түзеп ятасың инде? Бер-беребезгә сыеныштык. Ул мине ничектер аеруча нык итеп коча, ярата, үзе минем иреннәрдән үбә. Сагынган, ләкин моны тырышып шулай эшли кебек иде ул. Аның мине үбүләре күңелне кайтара иде. Мин инде тегенең биленә тотындым. Миндә шундый чакта була торган кызулык кабынды. Ну, бил үзеңдә! Тәне тимер мич кебек кызу, мине тәмам котыртты. Гаффә минем атакага чак чыдый, үзе ялвара.

— Минә язылышыйк, аннары көне-төне гел синеке булыр, ә хәзер тимә, — дип, кулларны каерып ташлый.

Мин тагын аңа ябышам. Ул тагы миннән ычкынмакчы була. Шулай төне буе «сугышып» чыктык. Таңга таба икебез дә «сугыш»тан арып, йоклап киткәнбез. Иртән тордык, ул эшкә җыена. Мин әйтәм, сорап кайт, дим. Язылышырга барырбыз, дим. Теләмичә генә: «Ярар», ди Гаффә. Ничектер мин аның буе-сыны үзгәрүен сизәм, әзрәк юаная башлаган шикелле тоям. Кешене аны белеп буламыни? Бәлки ул миннән башка биредә йөргәндер? Кем белә! Әллә өйләнмәскәме дип, үз-үземә каршы киләм. Саф кызмы ул, түгелме дигән иблис уй килә бит. Куып җибәрәм шул уйны, тагы килә. Кешедән калганны кабасы килмәү бар бит адәм затында. Миндә дә шулай шайтан баш күтәрә. Башына сугам, барыбер аны белми. Юк, ул саф, әнә төнлә белән мин нык тыгызлый башлагач, ничек чын күңелдән елады. Минем бөтен кызуларым кинәт шиңеп калды!

Гаффә, мин көткәнчә түгел, тик кичен генә кайтты. Язылышырга ул ашыкмый иде, ләкин мин ашыктыра башладым. Я иртәгә язылышабыз, я мин кайтып китәм дип, ультиматум куйдым. Кыз нишләргә белми, һаман ай азагын көтәргә кушып, мең төрле сәбәп табып чыгара. Минем дә җан ачуым чыкты. Кыз ультиматумны кабул итте. Без 17 сендә язылышып кайттык. Абыйсы, туганнары, бөтенесе чиксез шатландылар, минем дә авыз колакта, Гаффә генә серле, моңсу. Кызлар алар каһәр, шул серле моңсулыклары белән тарталар да инде... Тәкәнәев тынып калды, күкрәк турын учы белән угалаштырды, йөрәк чәнчегәндәге кебек чыраең чытып куйды. Әллә ярасы тартышып алдымы? Врач аңа тәмәке тартмаска кушкан, ә ул чынлап та тартуны ташлап маташа. Хәзер аның өзелеп тәмәке суырасы килә, шуңа күрә ул күкрәк турын ышкый, әле муенына тотына иде.

— Шуннан, димәк, өйләнден? — дип сорап куйды кыргыз Үтәш татарчалатып. Ул яшь егет, әмма Әнвәрдән өлкәнрәк булырга кирәк, чөнки сакалын кырып йөри, ә Әнвәрнең әле яңак-иякләрендә бала йоннан башка берни юк.

— Язылышып кайттык та, — дип башлап китте Тәкәнәев, нindидер таблетка авызына капкач, аны шытырдатып чәйни-чәйни,— шул, Гаффә тагы суза, тагы карыша, тагы шул 29 лыны кабатлый. Минем җен ачуым чыкты, мин законный ир ләбаса, ачудан эчке күлмәген умырганымны сизми дә калдым, һаман боргалана-сыргалана. Тик мин аны барыбер сындырдым, куенына кердем...

Шул чак җир селкенде, блиндаж түшәменнән аска җәйгән коры печәнгә шыбырдатып балчык коелды, барысы да тын калып, снарядның кай тарафкарак төшүен чамалап тордылар. Аның уылдап килгән тавышы кинәт сүнеп, каты шартлау пәйда булды. Блиндаждан ерак түгел иде. Икенче снаряд якындагы сазлыкка төште, шартламады, җирне генә селкетте. Сәгать дүрт булырга тиеш, немец обед ашагач, төгәл шул вакытта ата иде. Тәкәнәевнең җанланып сөйләве бер дә сүрелмәде, ул һаман кыза барды, кәефе бик килгән иде аның.

— Керүеннән элек чыгуыңны уйла, дигәннәр.— Тәкәнәев тагы шаянрак итеп сөйләп китте. — Юләргә закон юк, ди. Гаффә саф булмады кебек тоелды бит, гөнаһ шомлыгы. Шундый уй минем башка кусәк белән суккан кебек итте.

— Ничек саф булмады? — дип сорап куйды кайсыдыр.

— Шулай булды, шабаш! — диде Тәкәнәев.— Җанга иблис керде. Аңа сиздермим, уйламыйм, ике кулны баш астына салып, чалкан яткан килеш уйлыйм, ул исә лышык-лышык елап яткан була. Янымда елан яткан кебек, бөтен тәнем ытыргый минем. Ник язылыштым? Кара пичәт белән хәзер аяк-кул бәйләнә. Дурак-дурак дип, үземне тиргим. Татар акылы төштән соң — менә шул була инде. Минем кебек дуракларны чәчеп үстермиләр, алар үзләре үсәләр, дим. Аннары үземне юатып та куям. Хәер, төкерергә дә, чыгарга да китәргә. Таңнан тордым да тартырга

дигән булып киендем, ә Гаффәнең ялангач аяклары күренеп, чак кына тагы үзенә тартып китермәде, ул матур аяклар каһәрдә, көчкә үземне җиндем. Абыйсын уятып чыгардым да әйттем. Гаффә шундыйрак бит, дидем. Абыйсы аптырап калды, нишләргә белми. Чалбар кесәләрен капшый, тартырга әзли, мин тәмәкемне аңа каптырдым, үзем китеп бардым. Теге бер сүз дә дәшә алмыйча, өй алды ишеге яңагына сөялеп калды. Артыма борылып карадым да аны җәлләп куйдым. Ул яшен суккан агач кебек кара коелып төште. Мин стансага чаптым, поездга утырып кайтып киттем. Өч көннән соң бугай, эштән кайтсам, безнең өйдә Гаффә, абыйсы, энесе утыралар. Әни дә торып баскан, өйдә йөри. Мине күрү белән әни миңа тотынды:

— Син нәрсә, нәселдә юкны болай адәм хуры булып йөрисең? Шундый кыз балага ничек син шундый гарасат тагасың? Оял, азрак, оятыңа кил! Нигә аны кеше төсле итеп алып кайтмадың? — Әй, китте, әй, китте! Елый ук башлады. Аңа нәрсә, кыз ни, хатын ни — аңа барыбер! Ник үземнең башларыма бәлаләр алдым? Кешенең үзенә үзеннән күбрәк бәла китерүче юк, дигәннәре дөрестер, дим, үземне тиргим. Башны ташка орып булмый! Гаффә врачтан алган язуын өстәлгә китереп куйды. Мин куркып калдым. Курыкмаслык та түгел, врач язуы бит! Мин, ахмак, үзем ялгышканмын икән, дим, тик ялгышны таныйсым килми әле, неужели каптым икән. Тартырга дип өй алдына чыктык, шул чак кинәт Гаффәнең энесе — әзмәвер кебек таза егет — килеп якамнан тотмасынмы? Башы белән іяккә бик каты итеп сукты бу. Мин дә сдачы бирмәк булам, тик абыйсы кулларымнан тотып алган. Алар икесе дә пәһлеваннар, ә мин алар янында чебеш кенә. Ну, бирәләр, малай!..

— Гаффә апа сафмы? — дип тәкърарлыйлар һәм теге язуны минем күземә үк китереп төртәләр. — Гаффә апа әйбәтме? Әйт, ату, малыңмы, җаныңмы? — диләр болар.

Дәшмичәрәк торган идем, тагы көйдерә башладылар. Сизенәм, болар шаярмыйлар.

— Гаффә апаң саф, саф! — дигән аваз чыкканын үзем дә сизми калдым. Чынлап та сафтыр инде, врач язу бирмәс иде, дим эчемнән, үземне-үзем юатып. Шулай тора башладык, әнигә килен бик ошады. Аңа нәрсә, аш пешерелсен дә идән юылсын. Бер елдан соң Гаффә бер бәби табып куйды. Аңа Марсельеза исеме куштык. Бала тугач, Гаффә гел үзгәрде, шундый усалланды, просто кеше әйтеп кеше ышанмас. Минем эшләгән җиргә килеп, мине профсоюз җыелышына куйдырды: эштән соңгарып кайта, имеш. Акчасын пиво эчеп бетерә, имеш. Аннары безнең директорга, парторгка килеп, миңа җәмәгать эше бирүләрен сорап, тәки үзенекен итте. Мине җәмәгать эшенә күмделәр. Баш чыкмаслык. Көндәм атка бит берничә камыт кигерәләр, диләр. Дөрестер, Гаффә тагы парторгка килеп, мине местком итүләрен үтенгән. Янәсе, ирен үстерә бу? Әгәр аның сүзен әз генә тыңламасаң, өйдә торышлы түгел инде. Пычкы кебек кисә дә кисә. Вәт, малай, кая керер тишек таба алмыйм хәзер. Тәки Гаффә йөреп, мине месткомга тыкты, кеше кайгысын кайгыртып көн-төн чабам. Ләкин өйдә әз генә табак-савыт шалтыраса да, ансыз булмый, шунда ук Гаффә парторгка бара. Хатын-кызга ышаналар. Сигнал булгач, ул инде тикшерелмичә кала алмый. Тикшермәсә, Гаффә парторг өстеннән бара, барыбер мине тикшерттерә. Башкаемны кая куярга белми башладым. Тикшергәндә бит, булмаса да, табалар гаепне, кайберләре миннән йөз мәртәбә начаррак кешеләр миңа акыл өйрәтә. Минә шунысына чыдап булмый инде. Нишләп үз иреңне шулай рисвай итеп йөртәсең? — дип, кайчагында чыгырымнан чыгам. Икенче көнне үк парторгка бара да минем бөтен сүзләремне тегеңә тезә. Ул чак, беләсез, тычкан таяк белән йөри торган чак, куркудан берни эшли алмый идем. Теге, мин сине гаепләп, елатып йөргәннәрнең үчен аласың

инде син, Гаффә, дим. Эндәшми. Анын бер эндәшми үтерә торган гадәте бар.

Әй, ачуны китерә шул дәшмәве белән! Шулай яшәдек, кеше дигәнең теләсә нинди шартка да күнә икән. Бер өйрәнгәч, шулай рәхәт була башлады. Сугышка киттем. Киткәндә икебез дә утырып елаштык. Ул чагында нинди зарланып, карганып яши идек бит! Ахмаклыклар эшли идек, ачуланыша идек. Нигә? Менә мин бит Гаффәне ничек саф түгел син дип мәсхәрәләгәнмен! Нигә? Нәрсәдән? Гаффәнең шундый галәмәтләре булмаса, хәзер бу чаклы нык сагынмас идем дип уйлыйм, эх, бик тә сагынам үзен! Эх, хәзер исән калсам, беркемне дә яманламас идем, тормыш начар дип авызымны да ачмас идем, Гаффәнең шундый эшләренә чак кына да ачуланмас идем!..

Шул чак старшина килеп керде һәм хәзер үк мунчага барырга тезелегез, диде. Мунча ерак түгел иде. Инеш буенда ике зур гына яшел палатка. Шуңа су җылыта торган машинадан торбалар уздырып, душлар куелган. Янында тимер вагон кебек тагы бер машина — анысы жарилка — киемнәрне кыздырырга. Старшина сугышчыларга шырпы тартмасыннан да кечерәк берәр шакмак сабын биреп чыкты. Чишенеп керә башладылар.

Озак су күрмәгән тәнне башта душ шундый нык авырттыра, чыбык белән суккалаган кебек итә, аңа көчкә-көчкә генә күнегәсең. Аннары бер чиркәнчек алгач, суның рәхәтеннән туймый йөдисең. Чистаруның ләззәтен тоясың, тәннәр җиңеләя, бөтенләй яңа кешегә әйләнгән кебек буласың. Өлкәнрәкләр әйтмешли, мунчада бер биш яшькә яшәрәсең.

Кайберәүләр, тагы да рәхәтрәк булсын өчен, чишенә торган җиргә чыгып, тәмәке тартырга тотындылар. Берсе палатканың брезент ишегеннән башын чыгарып тышка карады һәм кинәт кычкырып җибәрде:

— Егетләр, киемнәр яна!

Кайсыдыр сүзнең мәгънәсенә төшенмичә һәм шаярта дип белеп, шаркылдап көлде дә әйтә куйды:

— «Җанвар»лар яна диген!

Барысы да ишеккә өелделәр. Вагон-машинаның ишеге каерылып, бер тупсасында гына асылынып калган, ә эчтән куе кара төтен ургыла иде. Ул арада старшина кычкыра-кычкыра нинди дер кранны борырга маташа, мунча дежуры бугай, бер солдат, ут сүндергеч табып, сиптерергә тырыша, ләкин ул эшләми. Аны ташлап, кабинкадан чиләк алып, суга йөгерә. Шул арада кайсыдыр мунчага су куа торган насосны файдаланырга итеп кычкырына. Икенчесе аңа каршы кычкыра. Ә төтен дулыйдулый чыга, теге шаян әйтмешли, «җанвар»лар шатыр-шотыр килеп яналар. Кайсы шәрә тәнен учлары белән чәбәкли-чәбәкли көлә, кайсы уйчанланып, әйберләрен исенә төшереп, тәмәкесен суыра да суыра. Моның ише генә януны күрмәгәнмени алар!

— Нәрсә исегез китте, күргәнегез юкмы әллә? — дип, солдат берни булмаган кебек кулын селтәде.

— Ну, старшинага бераз баш кашырга туры килер! — дип кинәнде икенчесе.

Үлем белән күзгә-күз очрашкан, үлем белән якага-яка алышкан бу сугышчыларга матди кыйммәтләрнең бәясе арзан иде, шуңа күрә жарилканың януы кызык тоелды, аннары бу сугыш янгыны булмавы да сәер. Дөресе исә, танкларга каршы сугышканда нервы киеренкелеге белән чыгырыннан чыккан җан үзенең элекке халәтенә кайтырга тырыша, шушындый күренешләрдән дә кызык таба, бушана иде.

— Биредә кунарга туры килмәсен әле! — диде берсе, янгынны күзәтүдән пошаманга төшеп. Ул сугышчы нәтиҗә чыгарырга ярата иде бугай.

— Әнә старшина чаба, әнә дежур йокысыннан уянган, ләкин соң шул инде, — дип, яңгыннан репортаж биреп торды кыйсыдыр. Бераздан яңгынга кызык итеп багу бетте, кайберәүләр киемнәрен кызганып куйдылар. Бер сугышчы сүндерүчеләрнең уңмаганлыкларын күреп, сүгенеп торды да, анадан тума килеш, булышырга чыгып чапты. Егет насосның җаен белә идеме, ул баргач, жарилкага насостан сиптерә башладылар һәм тиздән сүндерделәр дә, янып бетмәгән киемнәрне алдылар, алар һаман пыскый иде әле.

Яңа киемнәрне озак көтәргә туры килде. Көн эссе булганга әллә ни туңдырмады. Тагы шаяруга күчтеләр, хатын-кыз турында сөйләнделәр.

— Безнең Тамбов ягында яшьләр, берәрсенең туганнары өйдә булмаса, шунда кичәгә җыелалар. Бәрәңге, ботка пешерәләр. Бервакыт без, шаярып, кызларны көлкегә калдыру өчен, тегеләр күрмәгәндә генә боткага күп итеп тоз салдык. Ботканы пешереп, өстәлгә утырттылар. Ул шыр тоз, кабарлык та түгел. Әй, китте көлеш, шулай, аш пешерә белмәгән кызлардан көләбез. Ярар, ә икенче вакыт алар безгә мунча яктылар. Башта үзләре керделәр. Аннары без — егетләр. Ләүкәле мунча, чыккач, әй тотынды тән кычытырга, һич чыдап булмый. Ничек кирәк алай, хәйлә табып, кичәдән ычкындык. Арттан чыгып, кызлар көлепмекөләләр. Алар чабына торган себеркегә кычыткан куйган булганнар икән...

...Мостафин беркөн үк өеннән хат алган иде, тагы шуны укыды, сагыну хисе, күңелен моңсуландырып, үзенең дулкыннары белән күмеп киткәндәй итте. Матур Ык буйлары, аның таулары, Таткандызда үткән бала чаклары кабат күз алдына килеп, йөрәк маен сыздырып үтте. Ә бүгенге көн тагы да тетрәткечрәк очрашу әзерләп куйган икән...

Немецның әлеге танк һөҗүме вакытында, шул ыгы-зыгыдан файдаланып, безнең якка берничә кеше чыккан булган. Алар сугыш башларында немец әсир алган безнең кешеләр икән. Немец аларны, үзенең көче бетә башлагач, безгә каршы, ягъни үз иленә каршы сугышка әзерләгән. Төрле легионнар оештырганнар, ачлык белән мәҗбүр итеп, әсирләрне шунда туплаганнар. Баш итеп немецларны куйганнар һәм фронт сызыгына китергәннәр. Болар шул төнне немец командирларын үтергәннәр һәм алгы линия аша шуышып безнең якка үтә алганнар. Барысы да безнең шәрык халыкларыннан булганга, алар белән эш итү Мостафинга тапшырылган иде. Төпченә торгач, арада берничә татар да бар булып чыкты.

— Ни өчен бу якка чыгарга карар иттегез? — дип сорады Мостафин өлкәнрәк күренгән берсеннән. Һәммәсе дә бик басынкы — юашлар, күзләрендә чиксез курку чагыла, йөзләрендә үзләрен язмыш кулына тапшырганлык сизелә иде.

— Ничек инде үз кешеләреңә каршы атарга мөмкин? — дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды берсе. — Киселгән икмәк кире ябышмый, диләр дә, безнең күңел киселмәгән бит, күңел белән без монда бит, монда!.. — Йөрәге өзгәләнүдән аның тавышы бүленеп калды. Мостафин моңа ышанмады һәм бу кешегә бик нык ачуы килде. Бу кешенең сүзләрендә дөреслек ятса да, шуны икърар итәргә майорның бөтен вөҗүде каршы иде, чөнки кеше үзенең зур гаебен зур сүзләр белән капларга тырышкан кебек тоелды, аянычхәл артына посып акланырга маташкандай булды.

— Безгә анда да үлем, туган җирдә үлим, нчмаса, дидем. Немецка каршы сугышырга мөмкинлек бирсәгез иде безгә! — диде ак чигәле, кыюрак чырайлысы. Бу җавап Мостафинга ошады. Тукта, бу кеше ничектер таныш кебек. Ул аңа тагы да текәлебрәк карады. Әйе, кайдадыр, бу

кешене очратканы бар шикелле, ләкин кайда? Әллә мине күзләрем генә алдыймы, югыйсә? Юк,ниндидер таныш чалым бар йөзендә? Тик хәтергә генә төшми... Мостафин урыныннан торды, йөренде, бүтән фикерләргә күчеп, һаман хәтерләргә тырышты. «Аларны үз гаепләрен акларлык шартка куярга кирәк,— дип уйлады эченнән.— Ләкин бу бик четерекле мәсьәлә. Андыйларны тылга озатырга дигән приказ бар. Анда озын, авыр юл, кыен тәкъдир булуы ихтимал. Фронтта калдыру файдалы булыр иде дә бит — приказ! Безгә дә файда, аларның да теләге җиргә тапталмас иде... Бу эшләр Мостафиннан гына торса, әлбәттә, бу адәмнәргә үз гаепләрен саф, намуслы бәрелештә үз каннары белән юарга мөмкинлек бирер иде. Тик эш аңардан гына тормый шул. Юк, бу — четерекле мәсьәләдән котылу түгел, бу бәхетсезләр өчен нәрсәдер эшләргә кирәк. Күңелсезлек булыр, әлбәттә. Кеше үз язмышын үзе теләгәнчә итеп йөртә алмый бит. Ләкин хыянәтне аңа япсарып калдырырга ярамый...» Кайбер булачак кыенлыкларны уеннан кичерде дә, үзенең югарыдагы бер ышанычлы иптәшен күз алдында тотып, өмет белән исәп йөртте, соңрак аңа шалтыратып, барсын да хәл итәргә ниятләде. Ул курыкмас, урыны өчен калтырый торганнардан түгел... Аннары сакчыга әсирләрне алып китәргә боерды, монысы хәзергә калсын дип ак чигәлегә төртеп күрсәтте. Тегеләр чыгып киткәч, Мостафин якынрак килде һәм чәнечкеле йөз белән очрашты.

— Сезнең фамилиягез Галиев бит, нигә алыштырдыгыз? — диде, ягымлы булырга тырышып.

— Юк, минем фамилиям алыштырылмаган,— дип, күзгә туры карап, бәреп җавап бирде ак чигәле. Мостафин аңа аркасы белән әйләнде, кыяфәтендә икеләнү чагылды, урынына кире утырды, аннары базымлы караш белән тегеңә төбәлде:

— Сезнең фамилиягез Галиев, сез Баулыда эшләдегез!..— Мостафин шундый нык ышанычлы, кире чигенмәслек итеп әйтте, тегенең тез өстендә ята торган куллары кинәт өскә күтәрелде, биреләм дигән мәгънәне аңлаткан кебек булды. Аннары ул кулларын аска төшерде һәм бөтен күкрәге белән күрек кебек тынын эчкә суырды.

— Әйе, ә сез каян беләсез? Булды шундый чаклар. Фамилиямне нужадан алыштырдым,— диде ул, тирән көрсенеп һәм барысы бетте дигән шикелле җилкәләре салынып төште.

— Ник әсир бирелдегез? — Бу сораудан теге җанланып киткәндәй булды, тик Мостафин шунда ук өстәде: — Яраландым дип акланырга маташмагыз!

— Соң мин чынлап та яраландым, — диде теге һәм фуражкасын салып, башын аскарак иде, бер кулы белән башындагы чәчсез җирләрне капшап күрсәтте.

— Нигә качмадыгыз?

— Өч мәртәбә качтым, өчесендә дә этләр белән тоттылар. Этләр бөтен тәнемне умырып, җәрәхәтләп бетерделәр!

Борчулы тынлык урнашты. Мостафин бу кешегә күңеленнән теләктәшлек итәргә теләсә дә, хисләре кырыслыгын җиңә алмый иде. Ул чактагы бик күп авыр кичерешләре йөрәгенә яра булып уелган. Бала чак хәтере — бик явыз хәтер, бернәрсәне дә онытмый, бигрәк тә кимсетүләрне исеннән чыгарып ташлый алмый. Алар кешегә гомер буе тышау булалар, объектив һәм яхшы булырга комачаулыйлар. Шулай да алардан өстен булырга кирәк, Мостафинның моңа көче дә, дәрәҗәсе, урыны да муафыйк иде. Абзый үзенең әсирлектә күргәннәрен озын итеп сөйли, ә Мостафин үзенекен уйлый. Теге сөйләп туктагач, Мостафин бу кешене ничек тә коткарырга кирәк дип эченнән карар итте, аның сөйләүләрен артык тыңламаса да, теге сизенмәсен өчен әйтте:

— Ышанам, ышанам! — диде.

— Ә сез мине каян таныйсыз? — дип, өмет белән сорап куйды әлеге кеше һәм шуышында ниндидер тотынып нәрсә барлыгын сизенде, йөзендә нур шәүләләре күренде.

— Ә сез өтек хәтерле булмагыз! Утызынчы еллар исегездәдер, шәт? Ә бит без кулак түгел идек, әти Шөгаеп байда тегермәнче булып хезмәт иткән. Бай егерме дүртенче елны качып киткәч, безнең әти шунда эшләп калган. Әти егерме тугызынчы елны шул тегермәннең кырык чөенә кысылып үлде. Утызынчы елны сез безне раскулачить иттегез. Сез оныткансыз, ә мин онытмадым...

Мостафин туктады, ишеккә таба барып, нәрсәдер әйтте, шунда ук, подноска чәйле стаканнар куеп, ординарец керде.

— Эчегез, иптәш Галиев! — диде Мостафин һәм бер стаканны алып, кашык белән бутый-бутый, чәйне суындырып торды. Галиев, башы авырайганнан аска караган килеш, йөзен күтәрә алмыйча, чәйне алды да шопыр-шопыр эчә башлады.

— Хәтерегезгә төштеме?

— Булмагандыр дип әйтә алмыйм, туган! Булгандыр!.. Миңа бит куштылар, мин үтәүче генә идем!

— Кушканны үтәүче кылгаң эшләре өчен җавап тотмый, дисезме?

— Шулайрак килеп чыга.

— Кимсетелү ачысын инде татыгансыздыр, уйланырга вакыт та булгандыр?

— Сез миннән үткән өчен үч алырга ниятлисезме? — дип сикереп торды Галиев, шунда аның үзен гаепле санавы беленде, бу әйбәт билге иде. — Алыгыз, бик уңайлы момент.

— Юк, һич юк,— диде Мостафин, бик тыныч елмаеп һәм бала чак хәтерен кузгатканга эченнән үкенеп: — Мин сезне коткарырга тырышачакмын. Әйе, әйе!.. — дип өстәде.

— Анысына мин ышанмыйм, билгеле! — диде Галиев, кире урынына утырып.

— Алдамагыз, ышанасыз!

— Минем эчемдәге тышымда, ә сез мине риялы дип уйлыйсыз, шул гына!

— Ышанмаска минем күбрәк хакым бар.

— Ә сез минем урында булсагыз нишләр идегез?

— Язмышка буйсынып, барсы да бетте дип ятмас идем! — диде Мостафин һәм эченнән коты чыгып уйлап куйды: «Нишләр идем икән соң? Юк, барыбер соңгы чиккә кадәр язмыш ирегенә бирелмәскә тырышыр идем».

— Юк, язмыштан өстен була алмыйсың. Күп отчайный егетләрне белдем, язмыштан уза алмадылар. Кайсыберләре шундый бөгелеп төште, молотилка барабанына эләккән көлтә кебек...

— Әйе, катлаулы мәсьәлә! — Мостафин аның бу фикере белән бик үк килешергә теләмәде.

— Ә сез минем урында, мин сезнең урында булсам, нишләр идегез? — диде Мостафин шаярулы, ышанычлы тавыш белән арадагы киеренкелекне йомшарту өчен. Галиев уйга калды, аның күз кабаклары салынып төште, аска төбәлгән күз алмалары җавап таба алмыйча төрле якка хәрәкәтләнделәр.

— Мин сезне коткара алмас идем, приказны үтәр идем, — диде Галиев башын күтәреп һәм аңа элекке кыяфәте кайткандай булды. Мостафин шуны күреп, бу сүзләрнең эчкерсез әйтелүенә шиге калмады.

— Дөрес әйтәсез, менә монысы миңа ошый,— дип, Мостафин Галиевнең риясыз була баруына сөенеп куйды. Дөреслекне ул үзенә файда-

лы булмаганда да таный һәм бүтән кешеләрдә дә шундый сыйфатны бәяли, югары куя иде.

— Безнең үзебезне генә түгел, җанны да тәмам җимереп, көл иттеләр. Ә тере кеше үз шәхесен кабат төзергә, расларга тырыша. Кайберәүнең моңа көче дә җитмәве мөмкин. Бар андыйлар,— диде Галиев озак уйланып торганнан соң.

— Ә сезнең көчегез җитәрме? — Мостафинны фәлсәфи сөйләшү кызыктырды, шуңа күрә сүзнең җебен өзәсе килмәде.

— Җитәр дип өметләнәм. Элекке закалка мине һәлакәттән саклап калды бугай.

— Шулай: кешене ике көч йөртә, ике көч аның белән җитәкчелек итә: эчке көч һәм тышкы көч,— дип сөйләп китте Мостафин һәм тәмәке кабызды, Галиевкә дә папирос сузды, ләкин ул тартмый икән. Тирән итеп суырып төтенен чыгарып бетергәч, сүзен дәвам иттерде: — Эчке көч — эчке закон, әйтик,— кечкенәдән тәрбияләнгән, әнә шул хәлиткеч закон.

— Ә солдат өчен фәкать тышкы закон гына, әйе! Ул приказ белән генә йөри, гамәл үти.— Галиев ниндидер йөз яктыруы белән Мостафинга карады, ул һаман да үч алыр бу дип уйлый, ышанмый иде. Әйдә сынасын инде, барыбер!

— Алай ук түгел ул, Галиев иптәш, — диде Мостафин, сүнгән тәмәкесенә карап торды, аның киң, шәфкатьле маңгаенда фикер туплау шәүләләре чагылган кебек булды. — Менә, әйтик, солдат танкларга каршы сугыша. Командир яралана яки үлә, иптәшләре дә... берүзе кала, ә дошман танкысы һаман үрмәли. Мондый чакта аңа үзен саклап калырга да мөмкинлек була, чөнки бер шаһит тә юк. Ә солдат танкка каршы бара, граната белән танкны шартлата, үзе дә шунда һәлак була, аңлыйсызмы?

— Юк, аңламыйм, киресенчә, кеше ничек тә яшәп калырга тырыша...

— Менә яңа факт, беркөнне немецның танк атакасы вакытында сержант Кәбиров самоходканы җимергән, ышанасызмы? Ә бит аңа исән-имин калырга була иде. Әйе, сез аңламыйсыз!

— Ышана алмыйм, чөнки күп мәртәбә кешенең тугры була алмавын күрдем, үз тиресен саклавын сынадым.

— Фактка ышанмыйча ярамый, Галиев! Менә танк белән бермә-бер калып, танкны шартлатканда солдатны нәрсә җитәкли? Эчке закон җитәкли, ил каршындагы бурыч җитәкли! — Мостафин туры итеп тегенә карады һәм үзенең юкка гына сөйләвен, барыбер аның аңламавын белде.

— Мин бит сүзләргә ышанмыйм, күзләремә, колакларыма, үземнең тойгы әгъзаларыма гына ышанам, туган! Минем хакта теләсә нәрсә дип уйлагыз, ләкин башкача була алмыйм! Аның карашында гаҗизлек, мескенлек чагылып китте.

— Авыр, авыр! — диде Мостафин, һәм аларны җайсыз күз карашы очрашуыннан коткарып, телефон шалтырады. «Хәзер үзем барам», — диде Мостафин трубкага һәм урыныннан торды. Блиндаждан алар бергә чыктылар. Урман эченнән барганда Мостафин Галиевкә ягымлы чырае борып әйтеп куйды.

— Теге вакытта мин башта сезгә рәнҗесәм дә, соңыннан рәхмәт укыдым. Менә хәзер дә минем сезгә рәхмәт әйтәсем килә.

— Ничек була инде бу? — дип, Галиев берни аңламаганлыгын белгертте.

— Әгәр безне шул чак Магнитогорскига җибәрмәсәгез, олы дөньяны күрми кала идем.

— Анда сезнең хәлләр ничек булып чыкты соң? — дип сораганын Галиев үзе дә сизми калды, ул бу сорауны бирергә бик курка иде, лә-

кин Мостафин баягы кебек ачулы түгел, ул очрашуга шат, үткәннәр белән үтерергә җыенмый иде.

— Төрлечә булды, шунысына сөенәм, мин русча укырга кердем, әйбәт кешеләр ярдәм итте. Русча белмәсәм, хәзер мин нишләр идем дим эчемнән генә һәм куанып бетә алмыйм. Тел өйрәнү минем өчен зур нәрсә булды. Томана булып калыр идем.

— Тел белү байлык шул, — диде Галиев. «Әллә үч алмаска итте микән?» — дип уйлап, өстәп куйды: — Нинди кеше булгансыз бит, ай-яй?! Тегермәнче малае дип кем әйтер, ә?

Мостафин аның сүзләренә игътибар итмәде, бу кешенең язмышы үзеннән торганлыгын аңар һич тә белгертәсе килми, бая да үткәннәрне искә төшерү бик уңайсыз чыкты.

— Сез мине үч алыр дип уйладыгыз һәм уйлыйсыз да, — дип, Мостафин, ачылып, кыска гына көлеп куйды.

— Юк, мин алай уйламыйм, — диде Галиев ялганлап.

— Уйлыйсыз! Һәркем үзеннән чыгып башкалар турында фикер йөртә!

Мостафин тагы мондый сүзнең авызыннан ычкынганына үкенде: бу үзенең хәлең өстенрәк булуына кешенең башына сугып күндерү кебек килеп чыга. Байтак баргач, Мостафин Галиевне бер сугышчыга тапшырды, тәэминатка алырга, киендерергә әйтте. Галиев рәхмәт укырга да, каһәрләргә дә белмәде. Ул әле Мостафинның аңа яхшылык эшләвенә, асылда аны коткаруына ышанмый иде.

Мостафинны начштаб чакырткан — Яким Зиновьевичны вакытлыча шул вазифага куйганнар иде. Алар бер чинда булсалар да, Яким Зиновьевич үзен өстенрәк итеп хисаплый, моңа зур әһәмият бирә. Көндәлек гамәлдә дә приказ яки күрсәтмә «хәрефләренә » бик нык ябыша. Холкы яисә берәр чыгышы белән шул параграфларга сыешмаганнарның кимчелек ягын капылт кына «кисеп ташлауны» алга сөрә. Әмма һәрбер кеше уңай һәм кимчелекләрдән тора. Ә кимчелеген «кискән» җирдә яра кала.

— Өстән сезгә тел тимәсә, канәгать буласыз, — диде аңа бервакыт Мостафин. Теге шунда ук сынаучан карашын Мостафинга чекрәйтте.

— Әллә сез риза булмыйсыз?

Мостафин бүтән сүз озайтмады, нигә кеше вөҗүденә тукынырга дип уйлады. Яким Зиновьевич болай намуслы кеше үзе, мөнәсәбәттә, сүздә тугрылыклы, шуның өчен аның белән эшләве авыр түгел. Тик менә кайбер мәсьәләләрдә фикерләр капма-каршы була икән, моңа түзәргә туры килә. Аннары Яким Зиновьевичның полк штабында зур абруйлы булуының да эшкә файдасы тими калмый иде. Шуның өстенә ул үзенә бик таләпчән, әхлак ягын да «пөхтә» тота, аның бу сыйфаты бүтәннәрнең хилафлыгын тиз күрергә һәм аларны каты хөкем итәргә аңа нигез бирсә кирәк.

...Айкилдиев Римманы санбатта эзләп тапты. Кызны, булышырга дип, тагы Семен Израилович чакырткан икән. Сергей белән очрашуга бу юлы Римма ничектер шат та иде шикелле. Теге чакта мөнәсәбәтләр тәмсезләнеп, аламаланып очланды, күңелдә борчый торган юшкын калдырган иде. Римма Сергейны ачыну белән генә исенә төшергәләде, ләкин үзен күргәч, тагы якты йөз күрсәтте. Ә Сергей моны кыз күңеленә керергә «яшел ут» дип кабул итте, мөнәсәбәтләр өзелмәгән, фәкать арада аңлашылмау гына булган, шуңа күрә ипләшергә генә кирәк дип уйлады.

— Римма, мин хайван булдым, гаеп миндә?! — дип сүз башлады Сергей гафу сораган, кимсенгән тавыш белән.

— Кирәк түгел, Сережа, ташла!—Римма, аска караган килеш, бая җыйган чәчкәләрен йөзенә китереп, иснәп торды. Шуның белән барысы да бетте инде дигәнне аңлатырга теләде.

— Телисеңме, мин сине бөтенләйгә санбатка кайтарам. Без Семен Израилович белән дә... — дип, Сергей сүзен өзде, чөнки баш врачның аны яратмаганын Римма белә иде, шунда ук серле итеп ым какты да икенче фикергә күчте: — Санбатта куркынычсызрак, телисеңме?

— Юк, теләмим. Батареяда җиңелрәк.

— Яким Зиновьевич миңа этием кебек, чын! Армейский госпитальгә күчерергә була, бөтенләй тылда, ә?

— Юк, юк, батареяда да кеше кирәк бит!

— Ярый, минем эшем бар, — диде ул кинәт кенә һәм яралар бәйләү палатасына таба борылды.

— Римма, туктале, Римма! — дип ялынып кычкырды Сергей.

Кыз аңа эндәшмәде, брезент ишекне сиерып ачты да палаткага кереп китте. Сергей аның артыннан керергә кыймады, чөнки Семен Израилович аны корык белән куачак иде. Ул аңардан, тагы жалоба бирер, начальство алдында йөзне кызартыр, дип курка иде. Теге шелтәсе өчен дә, читләтеп булса да, Семен Израилович сәбәпче булды.

## 10

Эштән кайтканда улы Маратның елаган тавышын ишегалдында ук ишетеп, Фира өйгә йөгереп керде. Әнисе урын өстендә ята, малае салкын идәндә үкерә иде.

— Нәрсә булды тагын? Ник баланы карамыйсың? — диде Фира, тик әнисе эндәшмәде, тирән итеп ухылдап кына куйды.

Фира тиз генә баланы кулына алды, бер тәүлек госпитальдә дежур торып бик нык арыган булса да, аяктан егылганчы йөрде. Өй боз кебек булган, утын алып кереп мичкә ягып җибәрде, балага салкын тигәндер дип, стрептоцид эчереп, ашатты да төреп яткырды. Шуннан соң әнисе янына килде. Сызлавына чыдый алмагач, әнисе өченче көн генә тешен суырттырып кайткан иде. Караса, яңагы, муеннары коточкыч шешеп чыккан, кызарып тора, әллә гангрена башланганмы дип курыкты Фира. Тик әнисенең болай температурасы юк иде. Шуңа бераз эченә җылы керде, әмма ананың хәле авыр әле. Бу ике айда ул бик күп хәсрәтләр кичерде шул.

— Ишегә дә чыга алмагансың инде? — диде Фира, әнисенең шешенеп үзгәргән йөзенә карап. Ул Маратка шикәр комы кушып ипи бирергә ниятләгән иде.

— Мин карточкаларны өченче көн югалттым бит! — дип, әнисе кинәт буылып елап җибәрде. Яткан җирдән аның күз яшьләре түшенә тәгәрәп-тәгәрәп төшәләр иде.

Фира ни әйтергә белмичә катып калды. Ул сүз таба алмады. Мич бик нык тәтенли иде, шуның белән чиләнеп маташты. «Әллә бу әни акылга таманланып бара инде?» — дип шикләнде Фира.

— Көне буе тордым, кичен чиратым җиткәндә карасам — карточкам юк. — Әнисе тәмам вәйран булып, учы белән күзләрен каплады.

— Балага нәрсә ашаттың соң?

Ана дәшмәде, тик җилкәләре генә калтыранды.

— Тукта, әни, елама! — Фира кинәт тагы да хәлсезләнеп, ышанмыйча урындыкка утырды.

Әнисе кызының тиргәвен көткән иде. Кинәт Фираның ачуы төкәнде,

ниндидер гамьсезлек, хәзер инде барыбер дигән хис биләп алды. Кешенең бөтен өметләре өзелгәндә шулай була.

— Берәр дару бирче,—диде әнисе,—башым ярыла!

Фира кинәт хәрәкәткә килде, аңа дару алып бирде, су китерде. Әнисенең хәле авырлыгын ул менә хәзер генә ныклап тойды, ананың күзләрендә ниндидер нурсызлык, өметсезлек иде. Шул чак Марат уянып кычкыра башлады, ул ашарга сорый иде. Бу бала да үзенең адәм рәтле булмаганча үсүе белән Фираның җанын телә. Балага менә ике яшь тулып китте, ә ул бер сүз әйтә алмый, башта ук бала төсле еламады, ниндидер елауга охшаган тавыш кына чыгара иде, тамагы ачса, авызына нәрсә капканын белми, балчык ашап, төрле нәрсә кабып туена. Фира аны үзе эшли торган госпиталь врачларына да күрсәтеп карады, ләкин бернинди файдасы тимәде. Башта аны рахит дип дәвалап маташтылар.

Инде нишләргә? Марат ашарга сорып шыңшый, җанга тия торган аваз чәчә, ә өйдә бер чебен туярлык та азык юк. Кемгә барып сорарга? Фираның тәмам башы түнде, уйламас булды. Бер уй икенче уйны егып таптый, хәлдән ничек чыгу юлын таба алмый. Бала шыңшый да шыңшый, бәгырьне пычак белән телгән кебек итә. Ахырда госпитальдән кесә төбендә ияреп кайткан бер кисәк шикәрне җылы суга болгаткан булып балага эчерде.

Әнисе ухылдый-ухылдый, әкрен генә торып, тышка чыгып китте. Фира учактагы янган утка карап, гаҗизлеккә батып утыра, кисәүләрне ут сарган, алар яна, күмергә әйләнә, күмерләр көлгә әйләнә... Шул чак карават кырында идәндә аунап яткан бер кәгазьгә күзе чалынды, әнисе күз-галганда төшергәндер, әллә карточкамы, югыйсә? Аңа һәрбер кәгазь ипи карточкасы сыман күренә иде. Алып караса, күзләренә ышанмый торды: «Летчик Галиуллин Рәшат командование приказын үтәгән вакытта кире әйләнеп кайтмады. Ватанның батыр улына мәңгелек дан!» — дигән сүзләр язылган иде. Ничек инде бу?! Шул чак кыштыр-кыштыр әнисе килеп керде.

— Әни, нәрсә бу, абый да югалган бит! — дип, йөрәк өзгеч ачы тавыш белән кычкырып җибәрде Фира һәм караватка йөзтүбән авып төшеп үксергә тотынды. Әнисе дәшмәде, тирән итеп уфылдады да уфылдады.,

— Нигә дәшмисең, әллә тагы берәр нәрсә яшерәсеңме? Нигә аны миңа әйтмәдең? — дип, ярсулы-елаулы тавыш белән кычкырды Фира.

Әнисе һаман дәшмәде, юрганын йөзенә каплаган килеш, лышык-лышык үкседе. Аннары ул юрганын ачты да карлыккан тавыш белән:

— Ул исән, исән, мин аның тавышын ишетәм! — диде.

— Ничек тавышын ишетәсең? — дип куркып сорады Фира. Ана юрганын башына каплады да кыймылдамыйча ятты, фәкать күкрәк туры гына бер төшеп, бер менеп торды.

— Әни, ник син алай дип әйтәсең? — дип өзгәләнде Фира. Әни миннән тагын нәрсәнедер яшерә, дип уйлады ул. Ана эндәшмәде, ул берни белмәгән, бернигә катнашмаган кебек тынсыз иде. Фираның бөтен тормыш тәрәкләре кинәт җимерелеп төшкән шикелле булды, гүзәл итеп салынган йорт авыр бомба төшеп җимерелгән кебек, чәлпәрәмә килде. Гүя ул шул «гүзәл йорт» хәрабәләре астында калган да котылырга, сулыш алырга һичнинди чара таба алмый... Хәрабә ташлары аның күкрәген изәләр...

Төнне алар шулай ыңрап уздырдылар. Марат төнлә уянып, ашарга сорап шыңшыды, ләкин аңа әһәмият итүче булмады, ул, шыңшып арыгач, тагы йоклап китте. Иртән Фира бераз аек акылга килә башлады, ничек тә яшәргә кирәк, тереләй кабергә кереп булмый бит. Фира эшкә китте, аның сменасы булмаса да, ул бүген бик кирәк булып чыкты, бер сестра фронтка җибәрелгән иде.

Бу бер гаҗәп госпиталь: биредә авызы, сулыш юлы, тамагы, борыны яраланганнар һәм нечкә җире җәрәхәтләнгән авырулар ята. Еш кына коридорда няге белән кулбашы колбаса рәвешендә «ит үстерү» өчен ялганган кешеләрне күрәсең, һәм биленә шешә тагып сидек исе аңкытып үтүчеләрне очратырга була. Шуңа күрә бу авыруларның холыклары да бик үзгәлекле, аларны дәвалау чаралары да бүтән госпитальләрнекенә охшамаган. Кайбер авызы яраланган авыруларны айлар буе фәкать шланга белән генә ашатырга туры килә.

Госпиталь Галиәсгар Камал урамындагы мәктәп бинасына урнашкан иде. Биредә яхшы теш врачлары һәм теш техниклары эшли, невропатологлар бар. Фира өйләдән соң әнисен госпитальгә алып килеп,белгечләргә күрсәтте. Гайшә апаның тешләре таза булып чыкты, сызлау фәкать нервыдан диделәр. Шулай да тешләрен суыртырга киңәш иттеләр. Гайшә апа үзе тешләрен алдыруны гына теләде, баш чатнавына, күз аллары караңгылануына түзәрлеге калмаганын әйтте. Өшеткеч укол кадап, таза тешен алдылар. Бик авыр булды аңар, үзе кайта алмады, Фира кухня аты белән аны өйгә кайтарып куйды, мең бәла белән госпитальдән бераз ашамлык та юнәтә алган иде, барысын да баласына, әнисенә калдырып, тагы бер тәүлеккә эшкә китте.

Эштә ничектер хәсрәт алай ук бәгырьне кимерми, мәшәкать белән онытылып, кумелеп йөрисең. Абыйсының шулай югалуына Фираның һич кенә дә ышанасы килмәде, аңының кай төшедер ышанырга итмәкче булып иңри, ләкин хисләр ул уйга каршы килеп, аны тере, исән итеп күз алдына бастыралар һәм аның исәнлеген исбат итә торган каршы дәлилләр китерәләр: әгәр һәлак булса, төгәл язарлар иде, димәк, һәлак булмаган, ул берәр бурычны үтәргә киткән дә борылып кайтмаган, бу әле үлгән дигән сүз түгел. Үле хәбәре килгәннәр дә соңыннан исән булып чыгалар!.. Ләкин күпме генә үзеңне юатсаң да, начар хәбәр җанны тырный: шулай ук газиз башкае әрәм булды микәнни дисең, тагы күзләргә яшь тула... Икенче уй дулкыны килә дә: юк, юк, бу мөмкин түгел!—ди.

Фира кайтканда әнисе ишегалдында иде, кызын күрми дә, танымый да кебек, әндәшми, шәл бөркәнгән көе, тирән карга бата-чума йөри.

— Әни, нишләп йөрисең анда юләрләнеп? — диде Фира, тавышын күтәрмичә. Теге ишетмәде, каядыр бакча артына барырга ниятләп, сырындыга менеп бара. Фира, нидер шикләнеп, тизрәк әнисен барып тотты.

— Бу синмени? — диде Гайшә апа, кызын шунда гына танып.

— Нишләп юләрләнеп йөрисең? — дип дәште Фира.

— Рәшатның тавышы шул яктан килә, — диде Гайшә апа.

— Нинди тавыш, тиләләнмә зинһар!

Фира нәрсә уйларга да, моны ни дип атарга да белмәде, кырысрак торып, әнисен тизрәк өйгә алып керде. Марат шыңшып ята иде, ичмаса, бер колакны ярырлык итеп елый да белми дип, улы өчен әрнеп куйды Фира. Әллә авыру, кызганыч булганга, малае аңа әнисеннән якынрак тоела иде. Алып кайткан калдык-постык азыклары белән малаен ашатты, әнисенә дә өлеш чыгарды. Тик әнисе ашамады, авызым кибә дип, су гына эчте, каядыр китәргә җыенган кебек, чишенмичә, киеренке генә кыяфәттә сагаеп торды. Ятканда да, өй суык дип, пальтосын салмый гына ятты.

Төн урталарында Гайшә апа кызын төрткәләп уятты.

— Әсфирә, Рәшатның тавышын ишетәм, ишекне ач, әни дип, дәшә, бар әле?! — дип, үзе ишеккә атылды, Фира да торып, лампага ут элдерде.— Нәрсә булыр? — дип көтеп калды. Әнисе керми дә керми. Чыкса, әнисе тагы көртләр өстендә, бакча буенда йөри, күрше эте өтәләнә-өтәләнә өрә. Бу әни, ахры, чыннан да бераз акылга тәмамланган бугай, дип уйлады Фира һәм әнисен көчкә юмалый-юмалый өйгә алып керде.

— Әни, нишләвең инде бу, нишләп Рашатның тавышы килсен?—диде Фира ачыргаланып. Әнисе эндәшми, гаепле кеше кебек Фираның күзләренә туры карап тик тора. Аннары әкрен генә:

— Рашат мине үз янына чакыра: әни дип, өзелеп эндәшә, — диде.

— Ничек? Я, ярый, юләрләнмә зинһар! Аның тавышын ишетерлек түгел, ул еракта! — диде Фира, балага аңлаткан кебек, бераз ачулана төшеп. Үзе ни кылырга белми куркынып, әнисен чишендерде дә дару эчертеп урынына яткырды. Әнисе бераз тынычланган кебек булды, ләкин Фираны тагы да пошаманлырак уйлар биләп алды.

Беркадәр вакыттан соң Гайшә апа өйдәге эшләрне бөтенләй күрми, баланы да карамый башлады. Аны дөнья мәшәкатьләре һич кызыксындырмый, кайгы-хәсрәтне белми, ишетми, торган саен бар нәрсәгә дә битараф була барды. «Төннәрен Рашат тавышын ишеттем, әни дип, мине чакыра», — дип саташа, еш кына ялан өс кышкы бураннарда чыгып китә, аны төне буе эзләргә, милициягә хәбәр итәргә туры килгәли иде. «Әллә ачлыктан шулай булдымы?» — дип, Фира баш вата, кайгыра, госпитальдә икешәр смена эшләп, ашау ягын җайлаштыра.

Авыр көннәрнең берсендә, көтмәгәндә Алексейдан офицер аттестаты килеп төште. Фира сөенде дә, көенде дә. Горурлыгы чиксез тетрәнде, хәтта рәнҗегән кебек булды. Үзен үлемнән коткарган бу кешегә тагы да үти алмаслык бурычлы булу ничектер авыр да, шатлыклы да, көенечле дә иде. Фираның тарихын күрше-күлән, танышлар белә, Алексейны изге кеше санап, аның турында гыйбрәтле сүзләр сөйлиләр. Аттестат җибәргәч, башта ышанмадылар, кайбер дини карчыклар:

— Мөселмандыр ул, шул чаклы игелекле булмас иде!—диештеләр.

Ә Гайшә апаның хәле начарланганнан-начарлана барды, Фира аны оста белгечләргә каратты, ашавын яхшыртты, ләкин ул авызына ризыкны әз генә каба иде инде.

Чәчләре аксыл сүс кебек тере һәм каты, үзе көннәр буе тәрәзәгә күзен төбәп, чәч тарап утыра, тарый-тарый башын канатып бетерсә дә, үзе шуны сизми иде.

Шулай бер көн кичен Фира лампага ут элдереп маташа иде, әнисе тиз генә киенде дә ишеккә атылды, каян болай җитезләнергә көч таба диген? Аның арка бөкресе ишектән кергән суык бу эчендә күмелде, Фира аны туктата алмый калды, ялгыш кулын пешереп, шуны дәвалап азаплана иде. Ул арада Марат ашарга сорап итәгенә килеп ябышты. Марат сөйләшә алмый, ләкин күзләрендә — мөлдерәмә әйтәсе килгән сүз, ашаугә омтылыш һәм кимсенү. Ничек йөрәгеннән өзә ул Фираның! Тукта, әнисе нигә һаман керми әле?! Тагы теге өянәге кузгалды микәнни?.. Фира улын читкәрәк этеп, тышка йөгерде. Әнисен көчкә тапты. Ул тирән кар ерып тагын бакча артына таба китеп маташа иде. Фира аны көчкә генә тота алды. Тик әнисе ниндидер җитезлек белән аннан ычкынып, алга ыргылды. Фирага әнисен янә туктату өчен шактый азапланырга туры килде. Әнисе бер сүз эндәшми, сораганга җавап бирми, һаман ычкынып китәргә генә тырыша иде. Күп тарткалаша торгач, әнисе дә арыды бугай, карга утырды. Ә кызы исә елый-елый өйгә өстерәде...

Фираның тормышы хәзер менә шулайрак булып китте. Ул ике авыру арасында нишләргә дә белмичә бәргәләнә, өзгәләнә иде.

Фира эштән дә кайчак бик арып, киеренке нервы белән кайта. Авырулар бик бимазалыйлар. Офицерлар палатасында авызы, иягe яраланып, ашый алмый торган кызгылт чәчле бер егет ята. Фира аны резин көпшә белән ашата. Туклыклы бульон әзерли, шуны көпшәгә сала, аның икенче очын авыруның тамагына куя. Егет һәр вакыт канәгатьсез, ачулы, чөнки аның карыны ач, шундый зур гәүдәне мондый мәче ашы гына канәгатьләндерә алмый иде.

— Туйдырсагыз, бер үбәм үзегезне, Фира Касыймовна! —дип шаярткан булды ул башта, кая инде үбәргә, иреннәре, теш казналары берсе дә юк. Аның сүзен дә тырышлык белән генә, күнеккәч кенә аңлап була.

Чын мәгънәсендә кызганыч иде ул, ашыйсы килүдән һәрчак селәгәе агып тора иде.

— Бүген майлы тавык бульоны, сезнең өчен генә! — диде Фира, аның шаяртуының асылын аңлап. Резин көпшәне тамагына җайларга үзенә бирде, икенче башыннан кашык белән шулпа сала башлады. Ләкин кинәт авыруның күзләре шар булды, тамагындагы көпшәне алып атты, андагы шулпа аның өстенә түгелде. Авыру сикереп торып, нәрсәгәдер сүгенә башлады, ләкин сүзләрен аңлап булмый иде, резин көпшәне үзенең нечкә балавыз кебек сары бармаклары белән өзгәли, аяклары белән тибенә. Резин өзекләрен хәтәр кизәнеп Фираның йөзенә ыргытты ул. Фира да бу көннәрнең киеренкелегеннән, җилкәсенә өелгән бәлаләрнең авырлыгыннан тәмам йончыган иде, чыдый алмады, йөзен куллары белән каплап, чыгып йөгерде, баш врач янына кереп, тыела алмыйча үксеп-үксеп елады. Эчтәге бөтен әрнү, киеренкелек, ачу, кимсенүләр барысы берьюлы күз яше белән тышка ташый шикелле иде. Врач аны эшеннән бушатып, өенә кайтарып җибәрде.

Өйгә якынлашканда, ишегалдында берничә кеше күреп, йөрәге дөпдөп тибә башлады. Әнигә әллә тагы берәр хәл булдымы дигән уй башыннан йөгереп үтте. Көн буранлырак, җирдән себереп тора иде.

— Гайшә апа тагы Рашат абыйның тавышын ишетәм дип чыгып китте, мин Маратны ашаткан арада, әллә кая юк булды, — дип, Фираның каршысына тәбәнәк кенә бер кыз килде. Фира күрше кызына бераз тамак хакы биреп, баланы карарга кушкан иде.

— Ишекне бикләп тот дидем мин сиңа!—дип кенә әйтә алды Фира. Гайшә апаның кордашлары да чыкканнар, сукмактан карга керергә куркып сөйләнәләр.

— Көртләр өстеннән китмәгәндер инде, изге түгел лә ул карда батмаска?

— Андый кеше суда да батмый бара, өй кыегыннан да егылмый йөри ди.

— Кая табарак юнәлде икән соң? — дип, Фира өзгәләнеп сорады, тегеләр төрлесе төрлечә әйтеп маташтылар. Кардагы эзне бик тиз буран себереп тигезли, шуңа берни шәйләп булырлык түгел иде. Фира, көрткә бата-бата, бакча артына таба китте. Аннан Идел ерак түгел иде, ташу вакытларында су җәелеп, аларның бакчаларына чаклы килеп җитә. Анда хәзер балыкчыларның бәкеләре адым саен. Фира шуңардан бик куркты. Ләкин күз бәйләнеп килә, буран да көчәйгән шикелле, шуңа күрә Фира ирексездән кире борылды. Бәлки тапканнардыр, бәлки әнисе үзе кайтып өйдә утыра торгандыр инде дип өметләнде ул. Әмма өйдә әнисе юк иде, милициягә барып әйтергә туры килде. Фира елгыррак күрше малайларын, берәр сынык ипи биреп, әнисен эзләргә кушты. Алар милиционер янында чыр-чу килеп йөрделәр. Фира һаман шул бакча артыннан шикләнә иде, бозга чаклы бардылар. Милиционер кар каплаган куркыныч бәкеләрне күргәч, малайларны куып кайтарып җибәрде.

Төне буе эзләсәләр дә, Гайшә апа табылмады. Фира нишләргә белмәде, күзенә ак-кара күренмәде, таң алдыннан бөтен җире манма су булып, тәмам хәлдән таеп кайтып ауды. Эче тулы рәнҗү, әрнү, хәтта еларга да көче калмаган, аны шул күңел тирәнендәге үз-үзенә ачу һәм кимсенү генә дөньяда тотып тора бугай!

— Барысы да шул Рашатның югалган хәбәреннән башланды, әнә бит аналар ничек кичерәләр?—дип сөйләнде хәл белергә керүче күрше хатын. Фира аңа ни дип тә җавап бирергә белмәде, аның тел әйләндерерлек көче юк иде.

— «Рашатның тавышын ишетәм, мине эни дип өзелеп чакыра, нишлим инде?» — ди икәү генә калгач. — Моны Гайшә апаның ахирәте Фатыйма карчык әйтте. — Бер дә аңына хилафлык килгән дип белмәссең.

— Шулай ук Рашатның тавышын ишетә микәнни?

— Ишетә, ишетә, — ди Фатыйма карчык, — гөнаһысына кермә, ишетә! Шул тавыш йөртә аны. Сариям үлгәч, аның тавышын гел ишетә торган идем, и-и, дөньялар диген...

Алар бераз сөйләнделәр дә, Фираның күзен дә ача алмыйча хәлсез ятканлыгын күреп, тизрәк чыгып киттеләр. Фира керфекләрен күтәрә алмаса да, башында мие кайный, баш сөяген чатнатырлык итеп бәргәләнә, суккалана иде.

Гайшә апаны өч тәүлектән соң гына бакча артында Идел буе әрәмәлегеннән таптылар. Ул Рашатның бистә малайлары белән бергә уйнап үскән урыны иде.

Фира тормыш таянычын җуйды, үзен тормышка бәйләп торган нәрсәдән мәхрүм калды. Хәзер аңа тагы барысы да барыбер шикелле тоелды. Эшкә килгәч, аны үзе белән бергә эшләгән сестралар урап алды. Җыелып бер бүлмәгә керделәр, анда бик тыйнак кына табын әзерләнгән. Бу 8 нче Март бәйрәме хөрмәтенә иде. Фира шунда беренче мәртәбә авызына эчемлек капты. Ул башта үзендә ничектер җиңеллек сизде, бөтен кайгылары, җилкәсен, миен баскан авырлыклар кинәт беткән кебек тоелды. Ә бераздан караңгы хәсрәт, авырлыклар тагы да ныграк җанын зынҗыр белән кыскан кебек иттеләр. Моны ул эчемлектән күрде һәм кабат авызына да алмаска үзенә сүз бирде. Дарулар эчеп, көчкә генә әзрәк эзгә килә алды. Әнисенә кайчак артыграк тавыш күтәрүенә, аны җитәрлек тәрбияли алмавына сызланды. Эх, нишләп әнине әйбәтләп хөрмәт итә алмадым?! Әни, дөньяда син бер генә, миңа иң якын кеше булгансың, мине иң нык яратучы, минем өчен иң каты газапларны өстеңә алгансың! Каты шелтәләгән чакларыңда да мине үлеп яратучы син идең. Миңа зур өметләр баглап үстергәнсең, ә өметеңне аклый алмадым, син дөньядан миңа рәнҗеп киткәнсеңдер инде, кабереңдә дә миңа рәнҗеп ятасыңдыр? Ничек итеп сине бәхилләтим икән? Синең белән, әни, минем күңелемнең дә бер кисәге үлде, синең белән кабергә керде! Мин хәзер, әни, күп нәрсәләрне аңладым, синең киңәшләреңне, акылларыңны тотмаганда миңа һәр вакыт бәла килде. Әлек шуны таныргa мин-минлегем кушмый иде. Сине бернәрсә белмисең, артта калгансың дип шелтәләгән, киңәшләреңә каршы төшкән чакларым булды. Нинди ахмак, үзсүзле булганмын мин! Синең кулыңа һәр вакыт шырпы кирә иде, син аны энә очы белән казып чыгара идең, шырпыны чыгара алмаганда, ул үлекләп шешә иде. Ниләр генә тоймаган ул куллар? Әни, син миңа нык рәнҗеп киттеңме? Син Рашатны ныграк ярата идең, аны миннән артыграк күрә идең, минем шуңа ачуым килә иде! Кичер мине, әни! Кичер мине! Мин Рашаттан шуңа көнләшә идем. Шуның белән синең бәгыреңне телә идем. Кичер мине, әни, кичер!..

Яким Зиновьевичның «Син бәлане үзеңә тарта торган магнит кебек» дигән сүзе Алексейны тирән уеп алган иде. Ник мин шулай икән соң? Кимчелеге булмаган кеше юктыр инде ул. Бер философ әйткән ди: «Кешенең үзенә файдалы һәм зарарлы кимчелекләре була», диган. Моны ничек аңларга? Әнә икенче батарея командиры дәшмәүчән, бу сыйфат аңа файдага гына.

Алексей сугышчылар янына барды. Сөенчалин яңа марка немец минасын өстәлгә куеп, үзенчәлеген аңлата иде.

— Бу шариклы мина. Шартлаганда бака кебек югарыга таба сикерә, шарикларны чәчелеп китә, бил тиңентен биеклектәге бөтен нәрсәне кыя. Җиргә ятып кына котылырга мөмкин.

Сөенчалин дәресне бетерде, сугышчылар да талчыккан иде. Эскәмиялэрдән дәррәү торып тартырга эзләнә башладылар. Алексей аларга тулы портсигарын сузды. Сугышчылар чеметеп-чеметеп кенә алып көйрәтеп тә җибәрделәр. Әмма Сөенчалин комбатның бу эшен ошатмады, командирның авторитетын төшерә дип эчтән уйлап торды. Алексей исә бик шат иде, ул күптәнге сугышчан танышы, яңа гына госпитальдән кайткан шофер Мулла янына килеп утырды, дусларча аның иңенә кулын куйды. Гыйльмулла исемле бу егетне Мулла дип йөртәләр. Аның, үлсәң ипи эрәм кала дип, сигез йөз граммны берьюлы ашап бетерә торган кызык гадәте дә бар. Комбат аны уңганлыгы өчен ярата иде.

Курку, курыкмау турында сүз чыкты.

— Адәм затының курыкмый торганы булмыйдыр, — диде Тәкәнәев.

— Куркуның ни икәнен белмәүче башсызлар да була.

— Сугыш өйрәтә ул.

— Юк инде, курыкмый торган җан иясе булмый.

— Сергейны, Мирхасны кая куясың?

— О-о, алар...— Мулла кызыккан кыяфәт белән ияк какты, егетләрнең гаярьлеген сурәтләргә сүз таба алмады. Сергей хакында гадәттән тыш әйберләр сөйлиләр иде. Ә Мирхас яз көне Берлиннан махсус килгән бер снайперны тончыктырды. Ул аны көне буе бозлы суда сагалап яткан. Мирхас үзләренең Чистай ягыныкы булганга күрә, Мулла якташы белән бераз мактана да иде бугай.

— Нервыларын чыныктырганнар, шул гына, — дип, Сөенчалин бу батырларга исе китмәгән тавыш белән әйтте, әмма аның эчтән курыкмаска ничек өйрәнергә дигән чаклары булгалый иде.

— Ул гына түгел, табигатьтән дә килә бугай, — дип, комбат сугышта күргәннәре буенча фикер йөртте.

— Юк, хикмәт үзеңне күнектерүдә генә, — диде Сөенчалин.

— Мин Сталинград янында шундый хәл күрдем, — дип сөйләп китте Мулла. — Бервакыт юлда бик каты бомбежкага эләктем. Машиналардан төшеп, кайсыбыз кая аудык. Ә безгә утырып килүче санитарка кыз кабинкада калган. Самолетлар коточкыч сирена кычкыртып пикировать итә, кыз һич курыкмый, без лайда аунаучыларга тәрәзә аша теш агартып утыра, гүя бу аңа бер кызык. Мин аны тагы берничә тапкыр налет вакытында очраттым, куркуның ни икәнен дә белми иде. Менә гаҗәп. Юк, курыкмый торган кешеләр барлыгына иман китердем мин шунда.

Сугышчылар тынып калды. Мулла сүзен көчәйтүче дә, кире кагучы да булмады. Тәмәкеләрен тартып бетергәч, комбат сугышчыларга төрле эшләр кушты, ә Сөенчалинны үз блиндажына алып китте. Сөенчалин бер буш ара табып, ничек тә Римма янына ычкынырга ниятләгән иде, булмады инде дип, күңелсезләнеп куйды. Кызның йөзе, ягымлы тавышы, сөйләгәндә кашларының тибрәнеп-тибрәнеп китүе — барысы да тансык була башлаган иде. Нидән шулай? Әйтер сүзе дә юк шикелле, әллә ничек шул соргылт күзләр, чәч чылгыен пилоткасына төзәтеп куйгалый торган нәфис куллары белән янәшә буласы гына килеп тора иде.

Комбат аңа әлеге немец һөҗүмендә һәлак булган берничә сугышчыга үлгән язуы тутырырга әйтте.

— Шавлинның биш бала, Нурмановның тугыз. Кәбиров, молодец, өйләнмәгән. — Комбат аларның кенәгәләрен караштырды, тавышы бик моңсу чыкты, яңагында эчтән әрнү шәүләләре йөгерешә.

— Фронт семьялылар өчен начар шул, — диде Сөенчалин, комбатның нечкәрүен аңлап бетермичә.

— Нишләмәк кирәк, эх!..

— Нигә шул чаклы өзгәләнергә, Алексей Егорыч?

— Әйе, файдасыз, аңлыйм да соң.

— Җәлләү әйбәт түгел, диләр бит.
— Анысын да беләм, беләм.
— Командирның каты булуы солдат өчен файдалы. Кайчак солдатны мәҗбүр итмәсәң, окобын тирән казырга да иренә ул һәм шуның аркасында һәлак була. Ә укыганда... соңыннан кемне без рәхмәт хисе белән искә алабыз? Иң каты, кырыс укытучыларны.

Комбат уйланып калды, аннары әйтте:

— Кемгә бер җылы сүз дә җитә, кемгә чыбыркы да аз.
— Юк, кырыслык кирәк, кирәк. Шул рәткә кертә.

Сөенчалин язып бетерде, ләкин тагы сөйләшәсе килә иде. Комбатның чын ихластан ачылуы аңа тәэсир итте.
— Юк, Алексей Егорыч, минем күзәтүемчә, командир үзен солдат дәрәҗәсенә куйса, ул бетте дигән сүз.
— Ничек бетте?
— Солдат аны санга сукмый башлый.
— Юк, моның белән килешә алмыйм, Сөенчалин.

Комбатны дәшеп алдылар. Яңа орудиеләр китергәннәр икән. Шул форсаттан файдаланып, Сөенчалин шыпырт кына чыгып тайды.

## 11

...Алгы сызыкка күчәргә приказ көтмәгәндә генә булды. Приказны Яким Зиновьевич үзе китергән иде. Аның артыннан калмый торган шәүлә шикелле булып Айкилдиев та ияргән. Батареяны яңа позициягә урнаштыруда булышлык итү аларга тапшырылган икән. Бәлки Яким Зиновьевич Мостафинның мактаулы комбатын эш өстендә сыныйсы килгәндер. Батареяда политмассовый эш түбән дигән фикердә тора иде ул. Алексей Яким Зиновьевичны иң булдыклы шофер Мулла машинасына утыртты. Орудиеләрне тагып, расчетлар бөркәүле кузовларга төялде. Көчле студебеккерлар тиз элдерделәр, сазлы җирләрдә дә буксовать итмәделәр. Яким Зиновьевич бик нык ашыктырды. Яктырганчы казынып, яшеренеп өлгерергә кирәк иде.

Байтак баргач, туктап, Яким Зиновьевич кабинкасында карталарны карадылар, юлны аныкладылар. Фронт сызыгы зигзаглы, бормалы-сырмалы булып сузылган.

Тагы бер сәгатькә якын баргач, билгеләнгән квадратка килеп җиттеләр. Бу бер сирәк кенә нарат урманлыгы иде. Безнең разведчиклар, Айкилдиев җитәкчелегендә тагы да ары үтеп, батарея беркетелгән пехота частен белеп килделәр. Пехота ике чакрым алда урнашкан икән. Үндә да, сулда да немец ракеталары чөелә, сирәк-мирәк аткан тавышлар төн тынлыгын умырып-умырып ерткалый да аннан тагы шомлы тынлык булып тарала иде.

Орудиеләрне машинадан ычкындырып алгач, расчет кызу эшкә тотынды. Снаряд ящиклары ташыдылар, ут позициясе казыдылар. Шактый вакыт узды. Инде таң якынлашып килә иде.

Яким Зиновьевич батареяны урнаштыргач, тыныч җан белән дигәндәй, дивизионга кайтып җитәргә тиеш. Ул комбатка һәм замполитка күп кенә күрсәтмәләр бирде. Аның батареяга карата алдан ук фикере кире булган, ахры, тел төбендә шул сизелде.

— Зинһар, орудиеләрне маневрлы итеп урнаштырыгыз. Пехотага ышаныч ул... — дип, сүзен әйтеп бетерми Яким Зиновьевич, аның тавышында шаянлык ишетелә. — Аллага ышан, ләкин үзең дә кымшан, диләрме әле?
— Әйе, аңлашыла, Яким Зиновьевич , — дип, аның уңай ягына сыпырырга тырыша Ваһапов. Һәрберебезгә «чыбыркы» кирәк шул, дигән фикердә тора иде ул, ә безнең өчен «чыбыркы» Яким Зиновьевич инде

дип эчтән уйлап куйды һәм майорның күрсәтмәләрен бик тиешле санады.

— Солдатның сәяси чыныккан булуы кечкенә фактор түгел. Газеталар укуны ешрак оештырырга кирәк. Ә сездә карта уйнау очракларын әйттеләр. Солдат рухын күтәрә торган рычаглардан файдаланмыйсыз.

— Солдатның рухы тамакка бәйле бит, Яким Зиновьевич,— дип шаярырга тырышып әйтте Ваһапов.

— Батареяда замполит кулы сизелми, — диде Яким Зиновьевич, аның сүзен колак артыннан уздырып.

Алексей километрлы картаны алды, иңендәге плащ-накидкасын куышлатып, җиргә чүгәләде. Ваһапов та шунда иелде. Алар карта өстенә иелеп, кесә фонарен кабыздылар. Хәзер туктаган җир оборона сызыгыннан немецларга таба зур бер бүлтәймә капчык кебек кереп тора иде.

— Без дөрес килдек микән соң? — диде Алексей шикләнеп.

— Шушы билгеләнгән уңөченче нокта инде. —Ваһаповның тавышы ышанычлы иде.

— Ә фланглар, фланглар? — Алексейның шомы эченә йөгерә башлады. Аның бу төшне төгәлрәк ачыклыйсы килә иде.

— Дөрес инде, дөрес. — Ваһапов бер дә шикләнмәде. Ә Алексей ни өчен немец ракеталары безнең тыл ягындарак чайкала икән дип эчтән генә баш ватты.

— Пехота белән элемтәгә керергә,—диде Яким Зиновьевич, командирларның баш очында фонарьны сүндереп. Алар торып бастылар.

— Мин хәзер шунда җыенам, — диде Алексей, картасын планшетына куйды.

— Штаб белән бүген көндез рация аша хәбәрләшербез, ә иртәгә элемтә суздыр.

— Рациянең питаниесе юк, китереп җиткермәделәр, — диде Ваһапов, тагы ачулану көтеп.

— Менә мин һәр вакыт әйтәм: сәяси яктан ныксызның эшендә дә шундый дәрмансызлык килеп чыга дип! Ничек инде?..

— Таләп кәгазе өстәлегездә ята! Менә шулай! — диде Алексей, бу мәгънәсез сөйләшүне бетерергә теләде.

Яким Зиновьевич өметен өзгән кебек кулын селтәде һәм машинага утырырга ашыкты. Ул кабинкага утырганда командирларга кул бирде. Айкилдиевка биредә калырга боерды, бер-ике көн немец турында мәгълүмат җый, аннан кайт, диде.

— Уңыш телим! Соңыннан елауга караганда, башта ачулану әйбәтрәк. — Ул дусларча елмайды. Ак тешләре ялтырап китте. Командирларның да күңеле йомшарды.

— Эш өчен тиргәшү — файдалы, — диештеләр.

Чынында да шулай иде: Яким Зиновьевич — эш өчен яна торган кеше, шуңа күрә аның кырыслыгын, каты бәрелүен аңламаучылар гына башта аны чит итәләр.

— Кирәк әйберләрне хәзер үк җибәртермен, — дип, Яким Зиновьевич машина ишеген япты.

— Рәхмәт, — диде Ваһапов. Мулла стартерга басты, студебеккер алга ыргылды.

Разведчиклар батарея беркетелгән пехота командиры белән элемтәгә кереп кайтканнар иде. Комбат хәзер, батарея разведчигы Мирхасны һәм Әнвәрне алып, алгы сызыкка үзе китте. Айкилдиев никтер иярәсе итмәде, ул хуҗасыннан башка ятим бала кебек бөрешкән, юашланып калган иде.

Барганда чокырлар, сирәк урман, ерганаклар аша уздылар. Алексей бу урыннан прорыв ясап китәргә уңаймы, түгелме дигән уй белән исәп йөртте. Төн булса да, позицияне чамалап, зиһен үзеннән-үзе эшли.

Алдан ук часовойны күреп, Мирхас парольне әйтте, теге аны танып алды һәм траншеяга ымлады. Тармакланган траншеяда, бер тупиктарак, блиндаж түшәменә салган агач башлары аксылланып күренде.

Эчтә сукыр ут яна, берничә кеше йокымсырап утыра. Керүчеләргә каршы телогрейка кигән, коңгырт чәчле, тулы йөзле берәү калкынды һәм җилкәсе белән утны каплады.

— Лейтенант Тукташев, — диде ул иелебрәк, чөнки түшәм шактый тәбәнәк иде. Әнвәр Тукташевны шунда ук танып алды. Алексей үзенен кемлеген әйткәч, икесе дә утырдылар.

— Яңа комрот, димәк?

— Шулайрак.

— Әйе. Элеккесе бик яхшы командир иде. — Алексей бүтән сүз таба алмыйчарак торды. Тукташев исә, моңа әһәмият итмәгән кебек булса да, сүзнең мәгънәсен эләктереп алды:

— Әһә, аның аршины белән үлчәмәкчесез? — Тукташев житди төс белән Алексейга карады. Комбат ык-мык килде.

— Юк, мин ул хакта түгел,—диде Алексей әйткән сүзен йомшартыр өчен. Әнвәр Тукташевны дәреслектәге шагыйрь Такташка охшатып, соклanып торды. Тукташевка шалтыраттылар. Ул, трубканы алып, шартлы билгеләр белән сөйләшә башлады.

Мирхас кая гына барса да, берәр танышын очратмыйча калмый иде. Бу юлы якташ дусты белән күзгә-күз туры килде.

— Әллә Мифодий инде? — Мирхас аның янында берниндн приборлары булмаганга гаҗәпсенебрәк сорады. Чөнки Мифодий кайсыдыр штабта топограф булып эшли, һәр вакыт үзе белән нәрсә дә булса йөртә иде.

— Урынны карарга резведкага килдем.

— Ә-ә. Өйдән хат бармы?

— Сезнең авылдан Миңзифага мәҗбүри эш биргәннәр, ди.

— Транспортта йөри иде, икмәк беләндер инде.

— Шулайрак бугай.

Мифодий күрше авыл мукшысы иде, Мирхаслар алар аша базарга йөриләр һәм шунда фатирга төшәләр иде. Бу аралашу буыннан-буынга килгәнгә, ике авыл бер-берсен яхшы белә.

— Чакканнардыр, — Мирхас Миңзифаның ике ат белән Чистайга икмәк ташыганын һәм гаять үткен хатын икәнен хәтерләп алды.

— Атларына солы алган икән, аксак Госман күргән дә... — диде Мифодий.

— Бер-берсеннән күпсенү инде.

Алар блиндажга кергәләп-чыккалап йөрүчеләргә дә дикъкать итмәделәр.

— Мирхас, шуны әйтәм әле, сездән мәҗбүри эштә унҗиде кеше икән, ә бездән берәү дә юк.

— Әйтәм бит, тар күңеллеләр дип.

— Гаҗәп, ни өчен шулай?

— Усманны беләм мин, ярар өчен тырышкандыр. Яхшыатлы булырга кирәк бит.

— Татар барда хәтәр бар дип әйтәләр шул. Мирхас, моны үзенә ала күрмә.

— Юк, Мифодий, мин үзем дә уйлап йөрим, ни өчен безнең авыл кешеләре бер-берсен күрә алмый икән дим.

— Югыйсә, бер үк инеш суын эчәбез, безнең белән басулары ызандаш.

— Уйлыйм да аптырауга калам, — диде Мирхас.

Мифодий трофей сигаретлар чыгарды, алар төтәтеп җибәрделәр һәм уйланып калдылар.

Тукташев телефонда ачык текстка күчеп, әйткәләшергә тотынды.

— Бюрократлар сугышта беткәндер дигән идем.

— Ну, бюрократсыз тереклек булмый, — диде телефондагы.

— Булыр иде әле.

— Гоман итеп әйтәм, булмый дим.

— Ярар, бюрократ, яшә, алайса, әмма хәзер үк картаны җибәрт.— Ул трубканы элемтәчегә бирде, башын селкеп, гаҗәпсенеп торды.

— Миналанган кыр картасын һаман кулга алган юк, ну, бюрократлар...

— Нәрсә дип тоталар?

— Кем беләндер килешенмәгән, имеш.

— Әйе, бюрократия — сәясәт калканы. Тозлырак сөйләш, — диде Алексей һәм тизрәк эшкә күчәргә ниятләп, өстәде:— Биредә кайчаннан?

— Ун көн була инде.

— Ничегрәк тота үзен? — Алексей башы белән немец ягына таба ымлады.

— Кикрикләре әле шиңмәгән.

— Әйе, көчле әле. Төгәллек белән дә көчлеләр. — Моны үзенең техникага бәйләнешле кеше булуыннан чыгып әйтте. Километрлы картасын өстәлгә куйды. Тукташев утны якынрак китерде, картасы өстендә карандашын йөрткәләп алды.

— Бу Пушкин тауларының көнчыгышка сузылган итәге, — диде Тукташев һәм оборона сызыгының үзенчәлекләре турында сөйләде.

— Немец бу урлардәмени?

— Бу урләр берсе өстенә берсен куйган әрҗәләр шикеллерәк торалар. Анда берничә кат траншея, алдына чәнечкеле тимер чыбык сузганнар иде. Каен казыклары төнлә дә аермачык булып күренеп тора.

— Ә күршеләр, фланглар?

— Сулдагылар бүгенме, иртәгәме алышынырга тиеш бугай. Арттарак тирән чокырлар башлана.

Алар блиндаждан чыгып, күзәтү пункты урынын карап йөрделәр. Таң беленеп килә, бик шомлы, чык та төшмәгән, күктә сәләмә кара болытлар шуыша, әллә нинди шыксыз җил өзек-өзек исеп куя. Кайдадыр пулемет аткан тавыш иртәнге тынлыкны урманга кадаклый шикелле иде.

Мирхаска бер куак артындарак казырга кушып, комбат кайтырга борылды.

— Фазлиев та калсын, — дип үтенде разведчик.

— Юк, аппаратлар алып килер. — Комбат Тукташевка «Хәзергә!» дип кул бирде дә китеп барды. Рота командиры моңсу гына карап калды, аның карашы Алексейның кай төшендер тырмап узгандай булды. «Бикиевны алыштыра алырмы соң бу?—дигән уй килде Алексейның башына. Ә гомумән, бер кеше икенче кешене алыштыра аламы: тәвәккәллектә, уңганлыкта? Кайберәү баш була да, бөтен нәрсә үзеннән генә тора дип, кешеләр өстенә үзенең ихтыярын авыр итеп тага башлый... Эх, Бикиев кискен хәлне ничектер үзенең шунда булуы белән үк җиңеләйтә торган иде. Һәр вакыт тыныч, тигез холыклы булганга шулай идеме? Әмма үзен артык нык җәлләүчеләр бик куркыныч... Немец һөҗүме вакытында Бикиевның бер солдаты да паникага бирелмәде. Командир курыкмагач, солдатка курку бик зур оят тоела... Аның шул сыйфатын сизделәр микән? Аның белән бергә булган кайбер сугышчылар сизмичә калмагандыр. Ә хатыны аны белде микән? Әйе, шундый хакыйкать тә бар: кеше белән гомер буе янәшә яшисең, ләкин аны яхшылап белә алмыйсың».

Кинәт Фира исенә төшеп, йөрәген чеметеп алды. Нишләп аңардан хат юк икән? Әй, тиле, синең аннан хат көтәргә хакың бармыни? Җибәргән аттестатларын өчен ничектер әҗер көткән кебек килеп чыга. Шулай да нигәдер Фираны күрәсе килә. Ниндирәк икән ул хәзер? Иреннән хәбәр бармы икән?

Алексей, позициягә кайтып җитәрәк, Мулла машинасын танып, шомланып куйды. Мулла, Яким Зиновьевичны кайтарып куйгач, старшина янында тылда калырга тиеш иде бит! Нәрсә булды тагы? Машина янында канатлары имгәтелгән бөркет кыяфәтендә Мулла басып тора иде.

— Нишләп болай? Ә Яким Зиновьевич?

— Кире борылдык, анда һәр яктан аталар, үтеп булмады. Әнә! — дип, Мулла тишкәләнгән һәм рикошет белән пуля сыдыргалаган капотны күрсәтте. Алексейның башында кинәт төрле уйлар һәм шикләр калкынды. Ул, берни әйтеп тормастан, тиз-тиз Сөенчалин блиндажына китте. Анда тавыш, шау-шу иде. Айкилдиев нәрсәгәдер гайрәт чәчә, аның хуҗасы киткән мәлдәге юашлыгы бөтенләй калмаган, күзләрендә ут яна, очкыннар сибелә иде.

— Майорның иминлеге өчен җавап бирәчәксез! — дип кычкырына ул. Ваһапов, башын картага иеп, тынып калган, Яким Зиновьевич читкәрәк караган килеш утыра. Сөенчалин җир өстәлгә карта җәйгән һәм шуңа төртә-төртә, Айкилдиевка таба иелеп, нәрсәдер исбатлый иде.

— Менә, нечкә муен кебек сузылып кергән.

— Син һәр вакыттагыча буталасың, лейтенант. — Сергей бик эре генә аңа кул селтәде. Сөенчалин кыза башлап тагы дәлилләргә керешмәкче иде, ишектә комбатны күреп, туктап калды. Бүтәннәр дә керүчегә өмет белән төбәлделәр.

— Нинди газават? Яким Зиновьевич, ничек болай?

— Анда немецлар.— Майор нәрсә уйларга да белмәгәнлеген тавышы белән аңлатты.

— Әллә ялгыш килдекме? — дип, комбат картага иелде, аңа җавап кайтаручы булмады.

— Алда без беркетелгән пехотамы? — дип сорады Сөенчалин.

— Әйе.

— Шулай булгач, ялгыш түгел. — Ваһапов тагы да аптырабрак калды.

— Әллә фриц тозагымы?

— Ниндидер матавык, мать якасын! — Комбат, Сөенчалинга җавап бирүдән бигрәк майорга суктырып әйтте.

— Приказ тикшерелми, комбат,— диде майор. Күренми торган энәләре белән җанны чәнчүче тынлык урнашты. Ярый әле, Сөенчалин блиндажны тиз өлгерткән, молодец, дип сөенде комбат.

— Бу нәрсә, чолганышмы инде? — дип, Ваһапов нәтиҗә ясамакчы булды.

— Бирегез, Яким Зиновьевичны үзем алып чыгам, — дип, Айкилдиев комбатка бик тәкәллефсез мөрәҗәгать итте. Аның шушындый оятсызлыгы яндагыларның ачуын китерде.

— Ну! — диде Сөенчалин, тәртмәле итеп.

Барысы да майорга карадылар. Кайберәүләр бәлки аның китмәвен дә өмет иткәндер.

Яким Зиновьевич батареяны позициягә урнаштыргач биредә калырга тиеш түгел, аңа кире кайтырга боерылган. Әмма бу чолганыш ихтималы аны бераз таркатыбрак җибәргән иде. Аларга төрле яктан атканнар. Яким Зиновьевичның муенын пуля да сыдырып киткән.

«Ничек болай булуы мөмкин соң?» — дип, мие кайнады аның... Айкилдиев майорны коткарырга ашкына иде. Ә Сөенчалин машинаны аларга биреп, орудиене җилкә белән генә тартып булмас дип кайгыра.

— Тагы бер машинаны бетерергәме? — диде ул, тынлыкны бозып.

— Сез куркак, сездән сорамыйлар!

Айкилдиев Яким Зиновьевичка текәлде, аның карашыннан үз сүзләренә таяныч тапмакчы булды. Тик бу сүзләр майорга тәэсир итмәде, ул аны ишетмәде дә бугай.

— Син майорны коткару сылтавы белән тозактан шылмакчы буласың,— дип, Сөенчалин көлеп куйды.

— Ай-яй, акыллы, — диде кемдер.

Комбат та нинди карарга килә алмыйча газапланды. Беренчедән, өлкән командирның иминлеге аның да намусында, икенчедән, Айкилдиевнең гаярьлеге бирегә файда китермәс төсле, киресенчә, майорны мөшкел хәлгә генә калдырыр дип уйлады Алексей.

— Ә сез үтеп чыга алуыгызга ышанасызмы? — дип, Ваһапов урыныннан торып Сергей янына килде.

— Ышанам, иптәш капитан, — дип батыраеп җавап бирде Сергей.

Алексей команда бирде:

— Урман ягына разведка җибәрергә, боеприпасларны барларга! Чолганыш турында солдатларга әйтергә!

— Отставить! — дип, Яким Зиновьевич кинәт командирларга борылды. — Чолганыш турында солдатларга әйтмәскә приказ бирәм, юкса, паника кубачак! — Аның йөзе гаять борчулы һәм икеләнүле иде.

— Дөреслекне әйтү сугышчыны оештыра, кыюлыгын, көчен арттыра!

— Мин дә әйтмәү ягында,— диде Ваһапов, һаман шул картадан башын күтәрмичә, гүя ул шуннан котылу юлын эзли иде.

Орудие командирлары туктап калдылар, кемне тыңларга соң монда?

— Чолганыш турында солдатлар инде беләләр, Яким Зиновьевич, тик моны командирлардан да ишетергә тиешләр. Дөреслекне яшерү аяныч хәлләргә китергәнен җитәрлек күрдек, — диде Алексей, каты һәм ышанычлы итеп. Аннары командирларга:

— Барыгыз! — дип боерды.

Айкилдиев, Яким Зиновьевичның сүзе үтмәвен күреп, һаман аңа карап торды. Үзсүзле, мин-минлекле кешенең дә шулай үзенең приказы үтәлмәвенә тыныч каравын аның башы сыйдырмый иде. Димәк, хәлләр көтелмәгәнчә кискен, ә моның белән исәпләшмичә ярамый.

— Урман эченнән коридор булырга тиеш! — диде Ваһапов картадан башын күтәреп һәм Яким Зиновьевичка карады.

— Мин ул юлны беләм, бирегез машина, замполитны сез дә коткарырга тиеш, иптәш комбат! — дип, Айкилдиев кинәт бу мөмкинчелеккә ябышырга теләде. Әмма аның командирны коткарырга тырышуыннан бигрәк үзен кайгыртуы сизелгән кебек булды. Бәлки бу аңа ышанып карамаганнан гына шулай тоелгандыр. Тик Айкилдиевнең өмет тулы күзләрендә очкын кабынды, аның Яким Зиновьевичны ихластан коткарасы килә иде. Шул вакыт тыштан снарядлар шартлаганы ишетелде. Әллә фриц һөҗүм башладымы? Ашыгып кече лейтенант Мушков килеп керде.

— Мина белән ата, — диде ул. — Тыл ягыннан, теге уйсулыктан тондыра!

— Дивизионга рация белән хәбәр итәргә кирәк, — дип торып басты Яким Зиновьевич, озак уйланып утырганнан соң. Бу юлы аның карашында керпе энәләре беткән кебегрәк күренде.

— Рациянең питаниесе юк, иптәш майор! — Комбат бу хәлнең әллә кайчан Яким Зиновьевичка мәгълүм икәнлеген сиздерде.

Яктырганчы орудиеләрне җиргә казып урнаштырдылар. Ашыгыч рәвештә окоплар, блиндажлар төзеделәр. Киеренкелек солдатларның берберсенә ярсынып кычкырынуларыннан беленә иде.

Комбат Мушковка стереотрубаны жайларга һәм дошманны күзәтергә кушты. Позициягә сирәк-мирәк миномет снарядлары төшкәли иде.

Мирхас кайтып килде. Тукташев аның артыннан язу җибәргән. Рота командиры фрицларның җанлануларын искәртеп, берничә пулемет ноктасының целен әйткән. Әмма шул чак кече командирлар батарея боеприпасының аяныч хәлдә булуын расладылар. Снарядлар бераз бар, ләкин патрон, гранаталар аз. Барлыгы өч-дүрт автомат, бер пэтээр[1], бер кул пулеметы, тагы карабиннар.

— Төнен моннан чыгарга, — диде Мушков блиндаж алдындагыларга.

Сөенчалин белән Черняев, комбат ни дияр икән дип, аңа карадылар. Комбат тиз генә җавап бирмәде, әле көн озын, ничек булып бетәр, әйтүе кыен иде.

— Чигенергә приказ юк. — Комбат Мушковның бөтен хәлне дә исәпкә алмаганлыгына ишарәләде.

— Яким Зиновьевич приказны алыштырырга хаклыдыр бит? — Монысын Черняев әйтте, ул да Мушков ягын каера иде.

— Ник безне тәбегә тыктылар? — Сөенчалин бу бәлане комбатның югарыдагылар каршында абруе юклыктан күрә иде һәм шуны төрттермәкче булды.

— Тәбе дип, немец кайда да бер инде. — Мушков, юк нәрсә әйтәсең дигән кебек, Сөенчалинга кул селтәде.

— Әллә бераз тегеләйме? — Комбат, көлгән булып, Сөенчалинга карады, ягъни аска юеш үтә башладымы әллә дигән мәгънәне күзләре белән әйтте.

Кече лейтенант кайтарып сүз кушмады, комбатның да хәле бик үк әйбәттән түгел шул дип уйлап, аны жәлләп куйды.

— Круговая оборона, шулаймы? — диде комбат, эшнең андый фаҗигагә хәтле барып җитмәвенә ышанып. Көн нәрсә күрсәтер тагы, нишләргә кирәклеген хәлләр үзләре әйтә.

— Минометлары калку артында, точно! — дип, Мушков окулярдан күзен алмыйча, комбатка сораулы карашын юнәлтте.

Шул чак траншеяга шап-шоп сикереп төштеләр. Разведчиклар тирәюньне капшап кайтты. Блиндаж эченә уздылар, кайсыларының йөзләре киеренке, икеләнүле иде. Шилов карта өстендә урта бармагын шудырып озынча элмәк сызды.

Бар яктан да аталар, без капчыкта, ахрысы, — диде ул бер ачыш белдергән кебегрәк. Ләкин аның кыяфәтендә курку да, югалып калу да юк, үзенә нык ышанганлык, хәтта гаярьлек сизелә иде.

Командирлар тынып калдылар. Нинди чара сайларга? Яким Зиновьевичтан карар көтәләр, ул шуңа тынычсызлана, үртәлә булса кирәк, һаман читкәрәк карап утыра. Бәлки аңа җитәкчелекне үз кулына алырга кирәктер? Әгәр мөмкин булса, бу хәлгә гаепле кешенең бугазына ябышыр иде кебек ул. Әмма аннан ни файда? Ваһапов та аска төбәлгән. Ул исә гаепләне эзләп газапланмый, бу киеренкелектән ничек котылу турында баш вата. Шул вакытта Яким Зиновьевич үзенә өмет баглауларын бөтен тәне белән тойды.

— Ничек тә штабка бу хәлне җиткерергә! — диде ул, ниһаять.

— Соң, анда беләләр. Рас хозчастьлар бире үтә алмагач!

— Нишләргә кушасыз, комбат?! — Яким Зиновьевичның элеккеге хөкемдар тавышы беткән иде инде, ул бик дусларча чырай белән карый.

— Фриц тимәсә, аңа тимәскә! Көтәргә.

— Ул безне көл итәчәк!

— Үзе дә кыл өстендә торганны сизә ул, борынын тыкмаска тиеш! — Комбатның тавышы ышанычлы, хәтта шатлыклы иде. Ул тагы

[1] Пэтээр — танкка каршы ата торган мылтык.

боерык алырга килгән командирларга борылды, орудиеләрне җиргә тирәнрәк казып, җайлырак итеп урнаштырырга кирәклеген әйтте.

Аннары Әнвәрне, Шиловны ияртеп, Мурзыевны эзләп китте. Эш шунда: хәзер кичекмәстән сугышчыларга аш юнәтергә кирәк, ә азык юк. Кухня янында Рая елап утыра. Күршедәге кырык бишле батареяларда яраланган атлар булмасмы дип өметләнә иде комбат.

Мурзыев окобында черем итеп утыра иде, комбатны күрү белән сикереп торды. Өс-башы пөхтә, бер дә балчыкка буялмаган, тик күз кабаклары гына салынып төшеп, күзен тәмам каплаган.

— Мурзыев, әллә кәеф юкмы? — дип дәште комбат, гади һәм кешелекле итеп. — Бар, анда «сорокопятка» атлары яраланган булырга охшый. Туп-туры Райкага, яме!

Мурзыевның шунда ук чыраена кояш чыкты. Комбат аның үзенә генә ишетелерлек итеп тагы нәрсәдер әйтте.

— Ужинга ат бульоны, ә? — дип шаяртты Шилов.

— Тәкәнәевне үзеңә ярдәмгә ал! — дип, комбат траншеяга төшеп, пулеметны барлап карады. Аннары Шилов белән Әнвәргә Мурзыев урынына калып торырга кушты.

— Әй, ат печүче, дискылар кая? — дип кычкырды Шилов, пулемет артына басып. Мурзыев әрекмән, үги ана яфраклары астыннан ике дискы тартып чыгарды, күн итек кунычындагы чүпрәккә төргән пычагын барлады да китеп барды. Комбат, Шиловта парабеллум күреп, аның янына килде.

— Ничәне ала аласың?

— Егерме биш мөмкинлектән егермене генә,— диде теге кимсенгән тавыш белән.— Әнә Фазлыев егерме өчне ала!

— Шулаймыни? Күнегү кирәк шул, кулны өйрәтергә кирәк. Өйрәтмәсәң, кул агач ул! — дип, комбат траншеяга сөялгән килеш тәмәке төрде, Шиловка да төрдерде.

Черняев килде, ул бик борчулы, зиһене таралган кыяфәттәрәк иде.

— Штабтан приказ юкмы, Алексей Егорыч? — диде.

Билгесезлек аның эчен кыра иде булса кирәк, эче авырткан кеше сыманрак, кашларын сындырды.

— Ярар, Коля,— диде комбат, аның иңенә кулын салып.— Әллә бераз мәлҗерәп калдыңмы? Менә кич белән бәреп чыгабыз.

— Бүре авызыннан ычкынырсың!..

— Шикләнмә, Коля! Анда фриц юка! Ләкин бу кәефеңне солдатка күрсәтмәскә боерам! — диде Алексей, кинәт көр тавышка күчеп.

— Есть, иптәш комбат!

— Әллә хорафатка ышанасыңмы? — диде комбат, Черняевның үзен генә бер кырыйга алып китеп.

— Күп бәлаләр кичергән кешенең хорафатка да ышана башлавы мөмкин.

— Танклардан курыкмаган егетме? Син нәрсә?

— Танк килгәндә куркыныч күренеп тора, цель билгеле.

— Әһә, билгесезлек куркыта!..

— Юк, юк, иптәш комбат.

— Безгә башка көчкә исәп тотарга ярамый, үзебезгә генә ышанырга туры килә.— Комбатның шелтәсендә ярату һәм ихтирам яңгырады.

Ул икенче орудие янына китте. Өченче көн анда ике яңа кеше килде, аларны Алексейның күргәне юк иде әле. Орудие әйбәт урнашканлыгын Алексей чамалап алды. Нусов уңган сержант булырга охшый дип канәгатьләнеп куйды.

— Ну, пополнение ничек? — диде комбат.

— Әлегә фәрештәләр кебек, мөгезләре күренми,— диде Нусов, күңел төшермәгәнлеген, расчетның да шулай икәнен белгертергә теләп. Комбат шаяруны аңлады, тик җитди итеп әйтте.

— Тыл ягына да траншея казыгыз!

«Орудие араларын траншея белән тоташтырсаң шәп буласы да бит»,— дип хыялланды Алексей, Нусов яныннан киткәндә...

Ике сугышчы белән Ваһапов пехотадан алып торган патроннарын өләшеп йөриләр.

— Немецны якын җибәр, аннары гына ат! — дип, сугышчыларга приказ бирә Ваһапов.

Ул патрон, граната өләшүне сугышчыларга калдырып, бер атна элек кенә килгән расчет янына барды. Сугышчылар траншея әзерлиләр иде. Ваһапов орудие командирын дәште, ул базык гәүдәле, зур гына башлы өлкән сержант иде.

— Тылдан да аталармыни, иптәш замполит? — Сержант чолганышны шулай йомшак төстә әйтеп, тагын нәрсәдер белергә теләде.

— Шулайрак,— диде Ваһапов һәм тегенең анкета мәгълүматларын сораштыра башлады.

— Үзең нинди милләттән?

— Белмим, иптәш замполит.— Сержантның кыска муенлы башы бик елгыр борылгалый иде.

— Ничек инде белмисең, фамилияң Енакиев?

— Әтием татар, әнием рус иде, мин кем булам инде? — Сержантның йөзе җитдиләнде, үзе яшь кенә күренсә дә, кабарынкы чигәсендә чәчләре көмешләнгән иде аның.

Ваһапов нәрсә әйтергә белмичә аптырап калды.

— Ә үзеңнең кем буласың килә?

— Миңа барыбер...

Егетнең тавышы бик моңсу иде. Ваһапов аны җәлләп куйды һәм татарчалатып:

— Кай якныкы буласың? — диде.

— Троицкидан.— Сержант саф татарча әйтте.

Ваһапов кесәсеннән хуш исле зур бер пачкалык тәмәке чыгарып сержантка сузды. Теге тәмәкене өтәләнә-өтәләнә алды.

— Расчетка да авыз иттерермен, рәхмәт,— диде ул. Аның аралашучан һәм сөйләшергә яратучан егет икәнлеге күренеп тора иде.

— Ә әти-әниләрең нихәл? — дип сорады Ваһапов, аның турында күбрәк беләсе килеп.

— Әти мин ике яшьтә чакта ук үлгән,— дип сөйләп китте сержант.— Мин белгәндә әни бер байда су ташучы булып эшли иде. Атны да үзе җигә иде. Дилбегә тотарга кайчак мине дә ала иде. Яз көне эче өзелеп, әни урынга ауды һәм шул ятудан тора алмады. Аннары бай мине өеннән куды. Минем барыр җирем юк иде, урамда калдым. Хуҗаның бик акыллы эте бар иде. Төнен шуның оясына кайтып куна башладым. Этне яхшы ашаталар иде, мин дә шунда ялмана идем. Көзен байны сөрделәр. Мине дә тотып алып детдомга озаттылар. Саратовта укыдым, аннан...— Сержант сүзеннән туктап калды, тәмәке төрде, җәһәт кенә куен кесәсеннән зажигалка алды, аңа ияреп кесәсеннән конверт һәм карточка җиргә төште.

— Дус кызларданмы? — дип сорады Ваһапов.

Сержант рәсемне аңа сузды. Рәсемнән ягымлы гына елмаеп бер кыз карап тора иде. Үреп салган калын толымнары аны ниндидер сер белән тутыра кебек иде.

— Хәтерен калдырдым мин аның, иптәш замполит.

— Ничек алай?

— Җүләрлек инде. Эх, исән калсам дим. Гафу сорап хат салдым, кичерерме, юкмы?

— Пушкаң белән бер-ике танк яндырсаң, кичерер,— диде Ваһапов, шаярулы итеп. Әмма сержантның йөзе бик уйчан иде.

— Белмим шул,— диде ул төшенке тавыш белән.
— Ә расчет ничегрәк?
— Ярыйсы кебек.— Сержант җилкәләрен кыймылдатып куйды. Ваһапов китәргә кузгалды, сержант мөһим нәрсә әйтергә теләгәндәй аңа текәлде.
— Иптәш замполит, безгә пистолет йөртергә рөхсәт бирегез әле?
— Ярый, рөхсәт итәм.
Әмма сержантның тагы нидер әйтәсе килә иде. Ваһапов шунда ук аңлап алды.
— Кичкә ачыкланыр,— диде Ваһапов, борчылырга урын калдырмаган кебек.
Сержантның кулын кысты да икенче расчетка юнәлде. Бу егеткә ышанырга була дип уйлады ул барганда. Шул уңайдан Кәбиров исенә төште. Мин бит аңа ышанмыйча йөргән идем, ә ул әнә нинди егет булып чыкты. Тыштан кайбер кеше шырпылы, аполитичный булып күренә. Без шуның буенча гына фикер йөртәбез. Солдат үлем арасында йөреп бик нык дорфалана, анысы хак. Шунда аңа кемдер дәште. Траншея борылышында бер сугышчы җир казып маташа иде.
— Иптәш замполит, партбилетны сезгә биреп торырга буламы? — Бу өченче көн генә учетка баскан өлкән чырайлы сугышчы иде.
— Нигә, әллә бераз өркеп куйдыңмы?
— Мин партиягә Сталинградта кердем, иптәш замполит,— диде сугышчы. Шул сүзе барысын да аңлатты.
— Кай тирәнеке?
— Пермяклар без.— Солдат бик салмак кешегә охшый иде.
— Ә-ә, якташ икән,— диде Ваһапов шатланып.— Мин Бардада комсомол райкомында эшләдем. Чапчы, Киндерово авылларында булырга туры килде.
— Ул хохол-татар авыллары, ә мин Тихоновкадан.
— Әй, бай, шәп җирләр инде! — Ваһапов, якын танышын очраткан кебек, үзенең анда булган чакларын сөйләп алды. Нинди беркатлы, гөнаһсыз булынган. Фатир хуҗасының Гөлфәндә исемле чибәр генә кызы бар иде. Кулын да тотып караганы булмады. Бервакыт Гөлфәндәнең әнисе аларның икесен генә калдырып, күрше авылга кунакка китте. Кыз, берүзем куркам дип, урынын Ваһапов йоклый торган бүлмәгә, түр якка җәйде. Шул төнне газапланганын аның мәңге онытасы юк. Бер уй аны, Гөлфәндә янына барып ят, дип иги, чөнки бу якта кыз белән егет куну гадәте бар иде. Икенче уй, син үзең үрнәк кеше булырга тиеш, акылсызланма, дип чәнчә.
— ...Тәки йөрәк җитмәде бит. Хәзер шуңа үземне тиргим.
— Стратегия, тактика булмаган,— дип, солдат җанланып көлеп куйды.
— Партбилет һәр вакыт үзең белән булырга тиеш,— диде Ваһапов, китәргә җыенуын белгертеп.
— Ә пленга эләксәң?
— Совет солдаты плен төшми.
Ваһапов траншеядан сикереп чыгып куаклар артына таба китте. «Юк, сугышчы хәзер 41—42 еллардагы кебек түгел инде,— дип уйлады ул.— Тәҗрибә әйбәт нәрсә шул, сугышчының үзенә ышанычы да нык артты. Кан кою бушка гына китмәгән. Әнә, Сергей, Мирхас, Шилов — алар һич куркуны белмиләр. Сугышның ниндидер серенә төшенеп алганнар. Әлбәттә, солдатта батырлык тәрбияләү партиянең оештыруы көченнән башка мөмкин булмас иде...» Ваһапов шуңамы, әчтән сөенеп куйды, Сталин турында уйлап алды. Аннары шунда ук хәзерге хәлгә кайтты һәм эче салкынаеп китте. Немецларның безнең тыл ягында кинәт кенә пәйда булуларын зиһене кабул итеп бетерә алмый иде.

Кечкенә тау артына яшеренеп урнашкан кухня янына житәрәк. Вәһапов быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлар ишетеп туктап калды.

— Сугышта йөри-йөри җан сөялләнеп бетте инде, хәзер алай ук курыкмыйм.

— Мин плен төшмим, әнә кесәдә зарядлы «лимонка», ничек тә божраны тартырга өлгерермен әле.

— Бу урман артында да фрицлар бит!

— Алда да, артта да. Фриц безнең монда кергәнне әллә көтеп торган тагы?

— Елкы ите шәп,— диде ниндидер мөселман.— Ә сезгә мырык-мырык ите тәмле.— Ул берәр рус кешесен ирештерде, ахры.

— Булмаганда барысы да әйбәт,— диде теге.

Болар безнең батарея солдатлары түгел, дип нәтиҗә ясады Вәһапов һәм тегеләр янына капылт кына килеп чыкты.

— Кайсы частьтан? — дип сорады коры гына. Пехотачылар мылтыкларын кочаклап, чирәмдә тәмәке тартып утыралар иде.

— Без кухняга килдек, махан пешкәнне көтәбез,— диде берсе.

Вәһапов кухнядан пехотачыларга да өлеш чыгарырга дигән сөйләшүне исенә төшерде. Кинәт немецның алты көпшәле минометы чиелдаганы ишетелде. Якында гына миналар шартлый башлады. Пехотачылар траншеяларга сикерешеп төштеләр һәм башларын иңнәренә җыерып йөгерделәр. Вәһапов алар алдында җиргә аварга кыенсынды, бераз басып торды. Икенче залпны ишеткәч кенә ятты. Налет тынгач, ул теге пехотачыларны күрергә теләп траншея буенча китте, ләкин таба алмады.

Вәһапов үзләренең блиндажына кайтты. Анда Мулла белән Тәкәнаев плащ-палаткага төрелгән кемнедер эчкә алып кереп маташалар иде. Ул Айкилдиев икән. Йөзе пәрәвез япкан кебек сорыланган. Блиндаждагылар аңа ябырылдылар.

— Приказ кая? — дип кабаланып сорады Яким Зиновьевич.

Айкилдиев җавап урынына авыр итеп ыңгырашып куйды. Күзен йомган килеш:

— Үтә алмадым, иптәш майор,— диде.

Яким Зиновьевич, шунда ук йомшап, аның маңгаена учын куйды.

— Чыгып була дигән идең бит!

— Фрицлар...— Айкилдиев һаман күзен ачмады.

Тәкәнаев аны чишендерә, ярасын эзли, бинтны иреннәренә кыскан килеш, кайда соң, дип үрсәләнә иде.

Сергейның күзләрен ачарлык та хәле юк иде, шулай да чырае белән Яким Зиновьевичтан уңайсызланганын белгертте.

— Борчылма, Сергей! — диде майор, аны тынычландырмакчы булып.

Ниһаять, Тәкәнаев аның ярасын табып бәйләргә кереште.

— Бот төбендә икән, сөяккә тимәсә, бер айдан йөгереп йөрергә була,— дип сөйләнде ул.

Командирларның чыраена билгесезлектән өзгәләнү шәүләсе чыкты.

— Әллә болай немец авызына килеп керүебезнең фронт өчен берәр хикмәте бармы икән? — Комбат бу чолганышны аңларга һәм ничектер нигезләргә тели иде.

— Немец дикъкатен юнәлтү өчен тактик маневр булуы бик ихтимал,— диде Яким Зиновьевич.

— Нәрсә? Просто уйламаганлык.— Вәһапов гадәти булмаганча нык ышанып әйтте.

Комбат үзенең әлеге сүзе өчен үкенеп куйды, чөнки Яким Зиновьевичның шул ихтималга ябышачак икәнен аңлады.

— Ягъни, чигенергә дисеңме, замполит? — Алексей ялгышын төзәтү өчен Ваһапов фикеренә таянмакчы булды.
— Юк, алай дип әйтмим.
— Немецка калҗа булганчы фланглар белән тигезләнергә кирәк, минемчә.
— Флангсыз сугышу үзеңне сую ул,— дип, сүзгә Тукташев та кушылды.
«Бу нишләп бирәдә әле», дип уйлады Ваһапов, аны яңа гына күреп.
— Без фронт сызыгыннан ничә чакрымлап эчтәрәк соң? — Комбат карта өстендә чамаларга итеп, бармагы белән үлчәштереп алды.
— Минимум сигез-ун,— диде Тукташев, күз белән чамалап.— Үзәннән турыга үткәндә тагы да якын.
Комбат урыныннан торды. Блиндажга Рая килеп керде.
— Кухняга аталар, төтен күренә,— диде ул. Гаепле кеше шикелле, бүтән сүз катмады.
— Хәзер үк туктат! — диде Яким Зиновьевич ачу белән, бүтәннәр эндәшмәделәр.
Рая тизрәк боерыкны үтәргә чапты.
Тукташев китәргә җыенып Яким Зиновьевичка таба борылды.
— Комбат, пехота белән элемтәгә кеше куярга кирәк булыр,— дип, Яким Зиновьевич рота командирына ымлады. Тукташев ярдәм сораган кеше сыман үзен җайсызрак сизде.
— Эшләрбез, Яким Зиновьевич,— диде Алексей, китәргә кузгалды һәм Тукташевны да:— Әйдә, киттек,— дип, үз артыннан ияртте.
Алар сүзсез генә траншея буенча атладылар. Алексейның башында кемне билгеләргә дигән уй иде. Сөенчалин янына килгәч, эшне аңлатып бирде.
— Һәр яктан атып торганда ни мәгънә, Алексей Егорыч?
— Алгы сызыктан куркыныч зуррак, төнлә безгә бәлки яңа көчләр килер. Элемтә булмаса, бик начар бит...
— Кемнәрне алырга соң?
— Мирхас белән Тәкәнәевне.
Сөенчалин шунда ук әзерләнде, һәм, күп тә үтми, Тукташев аларны алгы сызыкка алып китте. Пехотаның батальон штабы белән урнаштырылган элемтә чыбыгы бар иде һәм ул батарея позициясе аша уза иде. Тылдан аны немецлар өзгәч, хәзер шул линияне «эшкә җигү» бик ансат булды. Әнвәр белән Шилов чыбыкны тиз таптылар. Яким Зиновьевич блиндажына аппарат куеп, элемтәне эшләтә дә башладылар.
Караңгы төшеп килгәндә Тукташев разведчиклары, ничек тә үзебезнекеләргә чыгарга ниятләп, тыл ягына таба киттеләр.
Немец әледән-әле миналар яудырып тора. Бер дә тынгы бирми. Траншеяларга яшеренгән булсалар да, сугышчылар яраланалар иде.
Алексей, бик нык пошаманга төшеп, блиндажга кайтты.
— Төнлә тәвәккәллик микән әллә, Яким Зиновьевич? — диде. Майор пистолетын чистартып маташа иде, тиз генә җавап бирмәде.
— Нинди каргалган җир булды бу, ә? — Ваһапов Алексейның ниятен хуплаганлыгын кыяфәте белән белгертте.
— Приказны гамәлдән чыгара торган властем юк,— дияргә мәҗбүр булды Яким Зиновьевич.
— Мостафинга бирәр нәрсә булды микән әллә? — диде Ваһапов аптыраганнан.
— Киңәшмәдәдер, кайчак икешәр тәүлеккә сузыла ул,— дип, Яким Зиновьевич фуражкасын салып куйды. Ак маңгаенда кызыл тасма кебек эз каймаган шикелле булып күренә иде.
Алексей блиндаждан чыкты. Сугышчылар һаман траншея казыйлар, җиргә тирәнрәк керергә тырышалар. Һәркем яшәргә өмет итә. Алда хәлиткеч һөҗүмнәр торганда бирәдә баш салу бик зур аяныч булачак

сыман тоела Алексейга... Аны Ваһапов куып житте. Алар траншея төбенә утырдылар. Яңа казылган җир салкынлыгы тәннәренә рәхәтлек бирә иде.

— Батареяны синең белән миннән сораячаклар,— диде Алексей.

— Нишләргә кушасың?

— Бүген төнлә чыгарга.

— Ә приказ?

— Без гаепле түгел ич, күрәсең.

— Приказны үтәмәгәч, без гаепле.

— Төнен чыксак, югалту әзрәк булачак дим мин.

— Тукташев разведкасы кайтсын әле, шунда күренер.

— Яким Зиновьевич нәрсә әйтер тагы,— диде Алексей.

Ваһапов җавап бирмәде, әкрен генә торды да:

— Мин машиналар янына барам,— дип, шул уңайга атлады.

— Ярый, хуп.— Алексей да кузгалды. Үзебезнекеләр янына бүген үк бәреп чыгу уңышлырак булыр кебек тоела иде аңа. Немецлар безнең артта көч туплап өлгермәгәннәрдер әле. Чигенгән өчен, әлбәттә, бик каты шелтәләячәкләр. Анысына да әзер торырга кирәк. Кулдан килгәнне эшләрбез инде, солдат җилкәсе күтәрә, ягъни вөҗдан тыныч булачак, ә башкасы өчен кайгырган юк.

Ул орудие расчетлары ягына юнәлде. Гаҗәп, нигә безне коткарырга тырышып карамыйлар? Атышлар ишетелми, бернинди хәрәкәт сизелми...

Төн уртасында, җиде кешедән дүртесен югалтып, разведка кире кайтты, «стенаны» тишеп чыга алмаган. Алексей, разведкадан могҗиза көтмәсә дә, болай ук өмете өзелер дип башына да китермәгән иде. Ул Ваһапов янына килде.

— Нишлибез? — диде гаҗизләнгән тавыш белән.

Ваһапов траншеяләр әзерләшеп, машиналар яныннан кайткан иде.

— Тегеләй итсәң дә бер баш, болай итсәң дә? — диде ул. Аның бик нык арыганлыгы сөйләшүеннән сизелеп тора иде.

— Юк, башны бетермик әле.

Хәлне үзгәртерлек көчең булмагач, гамәл агымына йомычка кебек буйсынырга туры килсә дә, Алексей реаль уй йөртте. Ул ниятләгәнчә, төнлә чолганыштан сугышып чыгуга берәү дә тәвәккәлләп алынмый, димәк, калырга туры килә.

Алексей төне буе орудиедән орудиегә чапты, үзе дә траншеялар казышты, һаман сугышчылар белән мәш килде. Таң алдыннан хәлдән таеп окоп төбенә егылды. Яким Зиновьевич та расчетларга йөреп, барын тикшерде, таңның мәкерле йоклата торган чагын да аяк өстендә уздырды.

Алексей немец аткан тавышка уянып китте. Торып караса, бөтен позицияне снарядлар һәм миналар тетә. Барча җирне куе төтен, майлы корым белән аралашкан туфрак каплаган. Сугышчылар блиндажларга тулганнар. Берничә минут эчендә көн караңгыланып калды, күтәрелеп килгән кояш төтен аша бакыр тәлинкә төсле генә булып күренә. Сугышчыларның карашлары киеренке, борчулы. Бераздан фриц атакага киләчәк.

Ут тыну белән солдатлар цепькә чыктылар һәм коралларын җайларга керештеләр. Алгы сызыктагы пехота белән элемтә өзелде. Командирлар дошманны тыл ягыннан көткәннәр иде, чыннан да шулай булып чыкты. Уйсулык куаклары арасында немецлар күренде, алар якын иде, шуңа күрә орудиедән ут ачуның мәгънәсе булмады.

Ә арткы якта, пехота ягында, әлегә тыныч шикелле. Аркадан һөҗүм юклыгы бик зур терәк булды. Шилов белән Әнвәр кул пулеметы алып куркыныч төшкә урнашканнар. Немецларны күрүгә Әнвәр түземсезләнә башлады, тизрәк атарга кушып, күршесен төрткәләде, ә Шилов фриц-

ларның тагы да якынрак килүләрен көчкә түзеп көтте. Моның өчен нервы корычтан булырга тиеш. Шиловның тыныч йөзенә менә тиздән булачак канәгатьләнү сөенече чыккан кебек. Ганимәт көткән сунарчы сыман бар дикъкатен шуңа юнәлткән иде.

— Ат-ат! — дип тыпырчынды Әнвәр, үзе дер-дер калтырый иде. Аның тизрәк беренче каушавын җиңәсе, үзен тизрәк кулга аласы килә. Ләкин ул тәҗрибәсезлектән Шиловны аңлап җиткерми, үзенең гаярьлегенә артык нык ышанып, үз көчен күбрәк санап, фрицларны бигрәк якын җибәрә дип курка иде. Менә немецларның берничәсе торып, куаклар ышыгыннан чыктылар һәм, автоматтан ата-ата, болайга килә башладылар. Аларның чырайлары аермачык күренә иде. Нәкъ шул чакта Шилов тәтегә басты. Эре, квадрат каскалар, кинәт аяк асларында җир шуышкан кебек, һавага тотындылар һәм тигезлекләрен җуеп авып төштеләр. Дәррәү һәм кинәт булган залптан фрицлар кире тәгәрәделәр, кычкырган, янаган тавышлар ишетелде. Икенче залптан соң инде фрицларның җирдә эре гәүдәләре генә күренгәләде. Исән калганнары уйсулык артына сыпырдылар. Нәкъ шул вакыт оруднеләр чигенүчеләр артыннан шрапнель белән аттылар һәм немецның телгә килгән алты көпшәле миномётын бастырдылар.

Машиналар янында Яким Зиновьевич, пистолетын тоткан килеш, сугышчыларны әйдәп, өйрәтеп, траншея буенча йөренде.

— Гранаталар әзерләргә! — Аның тавышы өзек-өзек чыкты.

Никишин, Мурзыев һәм Раяга гранаталар җитмәде, шуның өчен бер дә юк эше булмас дип, яндыргыч сыекчалы шешәләр хәстәрләп куйдылар.

Ә немецлар алда да, артта да ракеталар чөя, нәрсәдер сөйләшәләр иде.

— Немецны якын җибәрергә дә дәррәү атарга, гранаталар ыргытырга һәм «ура» кычкырырга! — Яким Зиновьевич һаман траншеялар буенча чаба. Ул бөтенләй икенче кешегә әйләнгән, ярсынган кыяфәтле иде.

Сугышчылар дошманны якын җибәрергә дигән приказны истә тотып, атмыйча тәкатьләре корыды, ә шулай да түзделәр. Әмма кайберләре түземлелекне арттырып та җибәргән, ахры, немецлар бруствега ук якынаерга өлгергән булып чыкты. Мулла кинәт каушап кала язды, карабиннан атып җибәрде. Рая, ни эшләргә белмичә, алда яткан шешәләрне ыргытты. Ул немецларның үзләрен күрмичә, шул якка алагаемга кизәнде. Мурзыев бруствер өстенәрәк менеп яткан иде, ул фрицларга төзәбрәк атты, аннары кул астындагы шешәне немецларга томырды. Кинәт ике җирдә ике ялкын пәйда булды. Немецлар киемнәренә ут капкан икәнен белеп тә өлгермәделәр. «Ике ялкын» кирегә элдерергә тотынгач кына шәйләделәр. «Ура-а» тавышы һаваны ярды. Фрицлар янучыларга иярә башладылар һәм чигенергә мәҗбүр булдылар. Траншеяларына төшеп күздән югалдылар. Әмма яндыргыч пулялар белән бик каты атарга тотындылар.

Ниһаять, бераз тынлык урнашты. Немецлар кырда калган яралы солдатларына окоптан озын бау ыргыталар, яралы шул бауга ябыша, ә окоптагылар аны тартып алалар иде.

Өйләдән соң немецлар пехотачылар ягыннан һөҗүм иттеләр. «Безнең сул франгтан бәреп керделәр, ут, ут!» — дип кычкырды Тукташев һәм шунда ук элемтә тагы өзелде, егерме минут эчендә миналар шартлаудан бөтенләй тетелеп бетте. Әнвәр линиянең өзекләрен генә табып, кире кайтты, пехотачыларга таба һич үтәрлек түгел иде. Алай да оруднеләр баштагы цельләргә өч залп бирделәр, ләкин сукыр атудан тыелдылар.

Гранаталарны саграк тотарга, дигән боерык белән комбат Әнвәрне Черняев орудиесенә йөгертте. Алар түбәнең икенче кабыргасынарак урнашканга, биредән күренмиләр иде.

Әнвәр, бер чокырдан икенчесенә үрмәләп, немец пуляларын, мина ярчыкларын «хәйләләргә» тырышкан булды. Тирәнрәк бер чокырга төшкәч, тын алып торды. Фрицлар бик каты ут өеләләр. Әнвәр, кош баласы оядан башын сузып караган кебек, чокырдан аз гына калкынган итә дә тагы башын аска ядерә. Биредә озаграк юанган шикелле тоела аңа. «Бар, бар!» — дип, эчтән ниндидер көч әйди аны һәм ул, китмәкче булып, чокыр якасына үрмәләп менә, ләкин пуляларның җан өзгеч выжылдавы тагы аска таба тартып төшерә. Эх, командир булса хәзер, дип уйлый Әнвәр, ул бер кычкырыр иде дә, мин моннан атылып чыгып китәр идем. Бу «упкынга» төшәсе калмаган, курку тойгысы аны үзенең «тырнакларына» каптырырга өлгерде бугай...

Әнвәр гаҗиз булып, чокыр эчендә мүкәләп йөрде, пулялар арасына чыгарга куркып газапланды. Үз-үзенә чиксез ачуы килде, нишләргә белмәде. Шуннан соң, актык чиктә ни булса ул дип, чокырдан атылып чыкты һәм алга таба ыргылды. Бераз йөгергәч, снаряд актарган җирне күреп, шунда сикерде. Бу зур гына чокыр иде. Бераз йөзтүбән ятканнан соң, башын күтәреп тирә-якны күзәтте. Ни күрсен, чокырның икенче ягында урта эргәдәрәк зәңгәр киемле бер гәүдә ята иде. Әнвәр, үлгән, дип уйларга өлгермәде, теге капылт кына калкынды да аның өстенә килә башлады. Әнвәр кинәт тез буыннары көчсезләнгәнен сизгәндәй булды, тәпи баса алмады, артына утырган көе, өскә таба шуышты. Ул торып басканда, кай арададыр немец аның иңбашыннан эләктереп алган, аны егарга теләп, бик нык өстери иде. Немецның уң кулын ремень белән муенына асып куйган булуы Әнвәрнең күзенә чалынып китте. Яралы икән, дип уйлады ул һәм тәненә көч кергәнен тоя башлады. Немец аны екмакчы булып, җан көче белән аска тарта, ә үзе бик каты гыжлый иде. Әнвәр кинәт бер яккарак ыргылды, касыгыннан парабеллумын тартып чыгарды да немецның күкрәгенә төртеп җибәрде. Немец парабеллумның көпшәсенә ябышты, чак тартып алмады, балчык ишелеп, аягы таеп китте дә аска шуышты, Әнвәрне дә үзе белән сөйрәде. Немецның йөзен каска каплаган, тик алга таба тырпайган калын ияге бик аяусыз, зәһәр иде. Шул бер-ике минутлык тартышта Әнвәр чирканчык алырга өлгерде, буыннарына көч керде, уйлары да тәртипкә килә башлады. Бер җайда кинәт парабеллумның тәтесен тартты, әмма ату булмады, нәрсә, әллә патроны юкмы? Әһә, парабеллум предохранительгә куелган икән. Ничек ычкындырырга соң? Немец һаман Әнвәрне җиргә егарга азаплана, ахырда типмәкче булып аягын күтәргән иде, Әнвәр бер кулы белән тиз генә аны эләктереп алды, теге сыңар аякта тора алмыйча, сул якка янтаеп төште, тик шунда ук сикереп тә торды. Шул мәлдә Әнвәр дә парабеллумын предохранительдән ычкындырды һәм аның урта бармагы үзеннән-үзе чакмага басты. Немец кулдан шуган авыр капчык кебек җиргә ишелде. Әнвәрнең күзенә аның чырае чагылып китте, какча гына йөзле яшь кеше иде ул. Муен тамырының балаларныкыча зәңгәрләнеп торуы, үлем газабы белән җыерылган йөзе әллә нинди кызгану хисе уятты...

Ул бер кырыйгарак утырды, ни сәбәптәндер кузгалып китә алмады. Менә бит ул үз кулы белән кеше үтерде. Әгәр болай кеше үтерүен әнисе белсә, ул Әнвәргә бик нык рәнҗиячәк инде. Немец кеше түгел, ерткыч ул, дип тә аны ышандыра алмассың. Мин сине кеше үтерер өчен үстермәдем, дияр. Эх, әни, сугыш без уйлаганча түгел икән шул. Әгәр мин аның башына җитмәгән булсам, ул мине мәче урынына буып ташлый иде. Син, әни, немецларны үтерүемне яратып бетермисең икән, ул чагында минем үлгәнлек язуымны алырга телисең... Бу турыда әнә нинди

акыллы егет Шилов та тукыды миңа, әни, үзем дә күреп торам, сугышта закон шул: мине немец үтерә, мин аны теге дөньяга озатам... Эх, әни...

Әнвәр, эчене үт савылган кебек, тамак төбендә чиксез ачы тойды. Буыннары хәлсезләнеп калганлыгын сизсә дә, китәргә кирәклеген исенә төшерде. Шунда гына үзенең умырылган гимнастеркасы, канга буялып беткән чалбары күзенә чалынды. Әллә яралануыммы? Юк, тәндә ул-бу беленми...

Әллә нинди җанны кимерә торган тойгыдан тизрәк арыну өчен, куркуны да, саклануны да онытып, бөтен буйга сурайган килеш, сыртның теге ягына таба чабып китте...

Ә алгы сызыкта хәлләр тагы да кискен булды. Немец котырган ут белән позициянең астын-өскә китерде. Траншеяда яраланучылар һәм үлүчеләр күренгәли башлады. Бу исә солдатларга бик начар тәэсир итә иде. Тукташев шартларга җитеп кычкыра, сугышчыларны каушамаска өндәп, цепь буенча җан-фәрманга чаба. Кинәт сул флангтан, үзәнрәк җирдән, һич көтмәгәндә фрицлар атакага ташландылар. Анда урнашкан кырык бишле орудие расчетлары чигенделәр. Менә-менә паника кубар төсле иде. Әмма Тукташев һәм тагы берничә сержант сугышчыларны фрицларга каршы тупладылар, менә немецлар җиргә ятарга мәҗбүр булды. Сөенчалин траншеяга чыкты һәм Мирхасны, ут таләп итеп, батареяга йөгертте. Кайбер пехотачыларның кача-поса артка шуышырга маташуларын күреп, аларга пистолет белән янады, цепькә ятарга мәҗбүр итте. Ләкин немецлар күзгә күренеп болай таба үрмәлиләр иде. Сөенчалин ачудан нишләргә белмәде, тәне тоташ калтырарга тотынды. Үлгән солдатның автоматын алып ата башлагач кына тынычланды ул. Кинәт кенә күз алдына кара багана күтәрелүен күрде, муенына бик каты нәрсәдер китереп бәргәнен тойды, каядыр убыла баруы хәтерендә чагылып узды, аннары аны куе караңгылык чолгап алды.

Күпме вакыт үткәндер, ул күзен ачканда, аны иңбаш һәм аякларыннан күтәреп каядыр алып баралар иде.

— Мин кайда? — диде ул тыпырчынырга итеп. Тәне чуен кебек авыр иде.

— Бусы тере икән ич, — дип мыгырданды ниндидер ят аваз.

— Мин кайда дим? — Сөенчалин катырак дәште. Шул мәл аны тирән траншея читенә китереп куйдылар. Аның тавышын ишетеп, ике фриц йөгереп килеп, ике ягына бастылар. Немец аяк очы белән Сөенчалинның җилкәсенә төртте, ертылган сырмасы ачылып, аннан погоны күренде.

— Офицер, гут, гут, — диде фриц. Сөенчалин әллә саташаммы дип өнсез булып торды, юк, бу төш түгел иде. Тукташевлар чигенгән, ул немецларда калган. Әйе, менә безнең траншеялар. Немецлар безнең үлгән солдатларны шунда тутырып, күмәргә әзерләнәләр икән. Ә бу эшне хәзер генә әсир калган безнең солдатларга кушканнар. Сөенчалинны монда өстерәп килүчеләр дә шулар иде. Менә бит ничек! Уйламастан Сөенчалинның кулы артка каерылды, ләкин кабурасы буш иде. Ул авызына тулган туфракны төкереп ташлады. Эченә салкын йөгерде, торырга дип кинәт талпынган иде, — аягына баса алмыйча җиргә лапылдап төште. Фриц, офицерны күтәрегез дип, әсирләргә кычкырды. Тегеләр исә, аңламаганга салышып, кыймылдамадылар, вакытны суздылар. Кинәт бик каты гөрелдәү колакны ярды. Түбәннән генә очып безнең өч истребитель килеп чыкты һәм пулеметтан сиптереп узды. Фрицларның берсе Сөенчалин аша чокырга сикерде, лейтенант исә аның өстенә барып төште. Сөенчалин фрицка ничек ябышканын, аның бугазына бармакларын җан ачуы белән батырганын үзе дә юньләп аңламады, ниндидер ак чырайны гына күрде.

— Монысын да Берлинга озаттым, иптәш лейтенант! — дигән тавыш-

ка сискәнеп карады Сөенчалин һәм немец автоматы тоткан Тәкәнәевне күреп алды.

Истребительләр тагы түбәннән генә ут сиптереп уздылар. Тегендәрәк маташкан фрицлар артка таба элдерә башладылар. Кайберләре әле болай, әле тегеләй барып төртелә иде. Сөенчалин капылт кына тезләнде, тәненә чиксез көч туплануын тойды һәм траншеяга посынган «әсирләр»гә бик каты кычкырып җибәрде:

— Корал алыгыз, анагызны!.. — Үзе чигенүче фрицларга немец автоматыннан ата башлады. Траншеядагыларга кинәт җан керде, мылтык хәстәрләп, тагы әүвәлге сугышчылар кыяфәтенә кайттылар. Шунда ук безнең танклар күренде, алар яныннан пехотачылар йөгерә иде. Бер сугышчы кинәт калкынып торды һәм әллә нинди кыргый бер тавыш белән кычкырып елап җибәрде.

Немецлар, сул флангтагы үзәннән чигенеп, күздән югалдылар. Танклар траншеяны узыбрак туктадылар, немец үзенең алты көпшәле миномётыннан ата башлады. Сугышчылар траншеяларга тулдылар. Налет тынганда, тагы бер танк килеп җитте. Аннан Алексей белән Мостафин сикереп төштеләр. Сөенчалин брустверда тагы хәлен җуеп ята иде, командирларны күргәч, аның да күзләренә яшь килде. Үзе бер сүз дә әйтә алмады, тик йөзе могҗиза кичергәндәге кебек гаҗәпсенү белән тулы иде.

Аны күтәреп танкка салдылар һәм батареяга алып киттеләр. Карангы төшеп килә иде инде.

Батареяда ыгы-зыгы иде. Ваһапов контужен булган икән. Римма, аның янына тезләнеп, укол кадап маташа. Сөенчалинны блиндажга керү белән, ул аңа ташланды. Сөенчалин күзләрен ачты, ләкин хәлсезләктән күз кабаклары кире йомылды. Кемдер, кабалана-кабалана, тыны-өне бетеп, Алексейга кычкырды:

— Сержант Енакиевның башы белән аягы гына калган, нишләтергә? Снаряд туры килгән.

— Нигә кычкырасың? Кум, мәгънәсез! — диде кемдер.

Сугышчы чыгып китте. Енакиевны күз алдына китерергә тырышып, Алексей аның артыннан иярде. Санын күтәреп тора алмаслык дәрәҗәдә арыганлыгын тойды, әмма ял турында уйларга да мөмкин түгел иде. Блиндаж алдында кинәт Мостафин пәйда булды.

— Алгы сызыкка 304 нче урнаша, — диде ул. Батареяны барлап килеше икән. — Ә сиңа берничә көн монда торырга туры килер, ахры. Хәзер тылдан куркыныч юк инде. Ләкин югалтуларың шактый күп икән.

— Шулай булмыйни! — Алексей сүзен әйтеп бетермәде, Мостафин аның нәрсә хакында белергә теләвен аңлап алды.

— Иртәгә ачыкланыр, — диде. — Каушап калмагансыз, молодцы!

— Яким Зиновьевичның шунда булуы ярады, юкса... — Алексей сүзләрен көчкә-көчкә генә әйтте. Мостафин бу юлы да аның нәрсәгә ишарәләвен сизде, ләкин я болай, я тегеләй җүпләп сүз катмады.

Мостафин китте. Старшина үзенең хуҗалыгы белән килеп җитеп, сугышчыларга берьюлы өч көнлек ипи һәм тәмәке өләште.

— Ну, Мулла, моны ашап бетерә алмыйсың инде,— дип сугышчылар шаяртып сөйләнделәр.

— Юк, бетерәм, үлсәм калыр да, гөнаһысы миңа булыр. — Мулла кай арададыр ипиенең яртысын ашап та бетергән, әмма аның шаярырга бер дә исәбе юк иде.

Берничә вакыттан соң кайбер нәрсәләр билгеле булды. Ул каһәр суккан төнне безнең флангтагы пехота частьлары алышынган. Немец моны ничектер алдан сизгән булса кирәк. Бер кырыйдагы ике-өч чакрымлы тирән чокырдан, коры созадан килеп, безнекеләрнең киткәнен сагалап торган һәм шунда ук тылга төшкән. Ә ул коры үзән ни сәбәптәндер

безнең командирларның чакрымлы карталарында бөтенләй билгеләнмәгән үк булган.

Мостафин батареяның чолганышта калуын сонгарып белгән, ул Великие Луки станциясендә кирәк-яраклар кабул итеп йөргән икән. Кайту белән бу хәлне төзәтү хәстәренә керешкән, летчиклар, танкистлар белән сөйләшә-сөйләшә, аларны кузгатып җибәрү өчен тагы бер тәүлектән артык вакыт узып киткән.

Штабларда да каршылыклар чыкмый калмагандыр, тик Яким Зиновьевич флангларның ачык торуын исбат иткән, ниндидер дәрәҗәдә гаепне үз өстенә алган һәм Мостафинны да, батареяны да бәла-казадан йолган, дип сөйләделәр. Чолганышны кулпертергә һәм батарея командирларына кулэгә төшерергә маташучыларның да авызын тиз япкан, ди. Һәр нәрсәгә яхшы һәм начар теләк белән карарга була бит. Әгәр югарыда танышларың бар икән, синә ышанып карыйлар. Шул нәрсә барысын уңай якка хәл итә дә инде. Ә Яким Зиновьевичның полкта абруе зур иде.

Ваһапов өч-дүрт көннән аякка басты. Алексей да ял итәргә өлгерде. Шулай да немец эскәнҗәсендә кичергәннәреннән тиз генә арына алмадылар.

— Чигенмәскә ничек акыл җитте инде, шуңа сөенәм әле, — диде Ваһапов. Алексейның чигенүне таләп итеп йөрүенә һәм бу очракта юка тиреле булуына төрттерде, ахрысы.

Сөенчалинның бер аягы тубыктан тайган булып, аны бик тиз урынына утырттылар. Шуннан соң ул өч тәүлек буе тоташ йоклады. Контузиядән башы шаулавы да әзәеп калган сыман булды. Яшь организм барысын да тиз җиңде бугай. Хәзер ул үзен ниндидер бик куркыныч һәм авыр караңгылыктан кояш нурлары елтырап торган мәрхәмәтле дөньяга кире кайткан кебек хис итте. Үлемнән дә эшәкерәк нәрсәдән котыла алуын исенә төшерде һәм чиксез шатлыктан җаны кинәнде. Аның шунда ук Тәкәнәевне күрәсе, аңардан ничек әсир төшә язуларын сораштырасы килде. Бүген үк әнигә хат салырга кирәк, дип уйлады ул. Бәлки мин аның теләге белән исән-имин калганмын. Нәрсә бу, язмышмы? Монда әллә ниләргә ышана башларсың. Немец автоматы астында кичергән беренче минутлары хәзер исенә төшсә, бөтен тәне эченә боз салган шикелле калтырый башлый. Шул хәл күзлегеннән караганда, аның Сергей белән килеп чыккан бәрелешләре бала-чагадай уйсыз беркатлылык кына икән бит. Риммага да кайчак нигәдер шикләнебрәк карадым бит мин, дип, Сөенчалин үзен-үзе битәрли, элеккеге ялгышларына эчтән генә сызып ята. Хәзер аның кешеләргә, үз кул астындагы солдатларга бик күп яхшылыклар эшлисе килә иде.

Ул Римманы китәсе көнне дә очратты. Кәефе бик шәп иде, шуңадырмы, сүзләре бәйләнешсезрәк чыкты.

— Безнең Камышлыда бер кечкенә, әмма бик гүзәл инеш бар, Римма. Эх, син аны күрсәң, тугайлары шундый матур аның, суы көмеш кебек саф. Тик инеш һәр яз саен диярлек үзенең юлын алмаштыра, искеярларын ташлый да яңа эздән агып китә. Характеры бик тотрыксыз.

Римма моңсу гына елмаеп, уйланып торды. Аның менә шундый үзенә каршы әйтәсе сүзне көчсез итеп калдыра торган елмаюы бар. Кызның кашлары тибрәнеп куйды:

— Шуңа күрә дә гүзәл инде ул,— диде һәм көлеп җибәрде.

— Гүзәлләрнең холкы шулай була торгандыр шул, — дип, Сөенчалин да көлеп куйды.

Аерылганда Римма ниндидер әйтелмәгән ым, уйга чорнала торган мәгънәле күз карашы, кызыксынуны тагы да кузгата торган ишарә калдыра иде. Бу юлы да шулай булды. Сөенчалин аның йомшартучан елмаюын күңелендә саклап алып китте.

*Ахыры бар*

## Фәнис Яруллин

### Яңгыр

Шундый аяз иде күк йөзе,
Юллар пешерә иде табанны.
Бүрек кадәр болыт чыкты да
Кинәндерде кырны, яланны.
Кырда эшли иде кешеләр,
Турайтырга онытып билләрен.
Хәтта бераз ялга туктарга
Кызганалар иде көннәрен.
Уйламастан яуган бу яңгыр
Кешеләргә рәхәт ял бирде;
Эш дәрләде яңа дәрт белән,
Басуларга кабат җан керде.
...Кайчак арып эшләп ятканда,
Кунак килеп төшсә өеңә,
Ял итәргә сәбәп булды дип,
Күңел дә бит шулай сөенә.
Күтәрелеп китә кәефең,
Аңа карап калмый эшең дә.
Көтмәгәндә яуган яңгыр күк
Ял бирергә кирәк кешегә.

●

Калганда караңгы төннәрдә
Әйттем мин бушлыкка күз терәп:
— Юк, алдый алмассың, кара төн,
Дөньяда яктылык күберәк,
Дөньяда яктылык күберәк.

Кешеләр яманлык кылса да,
Шуңардан әрнесә дә йөрәк.
Әйттем мин күз яше аралаш:
— Дөньяда яхшылык күберәк,
Дөньяда яхшылык күберәк.

Хаксызлык тантана итә дип,
Каршымда торса да мең өрәк,
Әйттем мин чын-чынлап ышанып:
— Дөньяда гаделлек күберәк,
Дөньяда гаделлек күберәк.

Арына алмыйча сагыштан,
Барсам да гел авыр йөк сөйрәп,
Әйттем мин гөлләргә үрелеп:
— Дөньяда гүзәллек күберәк,
Дөньяда матурлык күберәк.

## Ник коела алмалар

Җәйләр дә бик җылы килде,
Матур тора һавалар —
Ник коела алмалар?
Күз яшедәй әче-әче,
Тәмсез-тәмсез алмалар
Җилләр исмәгән чакта да
Җиргә тып-тып тамалар,
Күз яшедәй алмалар.
Тыңлап ятам. Төн җиттеме,
Коелалар алмалар.
Әйтерсең кайгысын әйтми
Яшерен елый аналар.
Тып-тып тама алмалар.

## Үкендереп булмый

Элек шулай, рәнҗетсәләр әгәр
Бер дә юкка, бер дә нахакка,
Әй, үләсе килә иде минем,
Я китәсе ерак-еракка.

И еларлар кебек тоела иде,
Үлсәм яки китеп югалсам.
Ничә тапкыр үләр идем инде
Һәр теләгән саен үлә алсам.

Тормыш әле дә баштан сыйпап тормый,
Хаксызлыклар талый гел җанны.
Тик мин беләм хәзер: үлеп кенә
Үкендереп булмый дошманны.

Кимсетүче булса, яуга чакыр,
Мәйданнарга чыгып, көр дәшеп.
Без хаклыкны исбатларга тиеш
Үлеп түгел,
яшәп,
көрәшеп!

●

Меңнәргә кирәк булып та,
Кирәк булмасаң әгәр дә
Якыныңа — берәүгә:
Дәрәҗәң булса да олы,
Бәхетең булмас тулы.

Меңнәргә кирәксез булып та,
Кирәкле булсаң әгәр дә
Дөньяда тик берәүгә —
Дәрәҗәң олы булмас,
Бәхетең тулы булмас.

●

Алтыннан кече түгел мин,
Ипидән олы түгел.
Үлемнән көчле түгел мин,
Тик язмыш колы түгел.

●

Куркакның җаны кала,
Батырның даны кала.
Җан гомере — санаулы,
Дан гомере — дәвамлы.

●

Икеләтә йөрәк әрни
Дустан күргән җәбергә.
Дошман угы тәнгә тия,
Дусларныкы — бәгырьгә.

●

Өндә дә шигырь язам,
Төштә дә шигырь язам.
Өндәгесен ертамын,
Төштәгесен онтамын.
Ертылганы — буш шигырь,
Онытылганы — шедевр.

●

Бастырды шагыйрь
Начар шигырен
Һәм күпмегәдер
Кыскартты гомерен.

Көчсез белән көрәшеп
Егуың зурлык түгел.
Көчле белән көрәшеп
Егылу хурлык түгел.

●

Яман кеше кылса яманлык,
Сүгенәбез дә китеп барабыз.
Яхшы кеше кылса яманлык,
Әрни-әрни искә алабыз.

Яхшы кеше итсә яхшылык,
Рәхмәт әйтәбез дә онтабыз.
Яман кеше итсә яхшылык,
Гомер буе истә тотабыз.

●

Беребез кызып китүчән,
Беребез сабыр, тыныч:
Беребез корыч калкан да,
Беребез булат кылыч.

Тормыш безнең алдыбызга
Куйган катлаулы бурыч:
Калканы да ватылмасын,
Һәм дә сынмасын кылыч.

●

Әллә күктә яшен гөлт итте,
Әллә кызлар кашын сикертте —
Өлгермәдем аны аңларга,
Ялкын капты зәңгәр таңнарга.
Әллә казлар очып үттеләр,
Әллә кызлар яулык болгады —
Җиле генә биткә бәрелде,
Үзен аның күреп булмады.
Әллә көзләр артык тиз җитте,
Әллә яшьлек артык тиз үтте,—
Утын күрдем — җылысын сизмәдем,
Болынын күрдем — гөлен өзмәдем.

●

Кайчагында көтмәгәндә
Эшлим дә бер юләрлек,
Газапланып йөрим аннан
Инде кеше көләр дип.

Кабат алай булмамын дим,
Үкенәм, тәүбә итәм.
Бары яхшы уйлар гына
Күңелемә беркетәм.

Тик яңадан хата ясыйм,
Ялгышлар килми сорап:
Һич кенә дә була алмыйм
Үземнән акыллырак.

Мәгъсүм Насыйбуллин

# ТЕЛСЕЗ ШАҺИТЛӘР

ПОВЕСТЬ

Мин аны көткән чагымда
«Бер кеше туар»,— дидем.
Тиран буласын белсәмче...
Мин аны буар идем.

Илдар Юзеев.

## 1

Мәрфуга иртәнге чәйне өстәлгә китереп утырткан гына иде, кемдер ишек шакыды. Мин шундук барып ачтым. Ишек төбендә телеграмма тоткан яшь кенә бер кыз басып тора иде. Кул куеп алдым да телеграммага күз төшердем: «Ашыгыч. Акбүләк. Прокуратура. Тикшерүче Ибраһимов Гайнанга. Кичекмәстән Чулпан районы Байтимер авылына барыгыз», диелгән иде анда.

Мәсьәләнең бу ягы ачык: республика прокуратурасы миңа тагын җаваплы бер эш йөкли. Мәрфуга шыпырт кына минем янга килеп басты. Күзләрендә борчылу: тагын телеграмма! Нинди эш белән? Кайда, озаккамы?.. Соңгы вакытта мондый телеграммалар ешаеп китте. «Сынауны яхшы үттең, абынган-сөртенгән чакларың да булмады түгел, әмма егылмадың, күңелеңне төшермәдең, Гайнан. Тик моннан соң гына тынычлык көтмә инде. Синең кебек тикшерүчегә эшнең иң катлаулылары тапшырылыр»,— дигән иде узган ел миңа республика прокуроры, бер четерекле җинаять тикшереп бетергәннән соң.

Әйе, мактау иде бу. Ләкин бу сүзне ишеткәнче баштан күп кенә күңелсезлекләр узды. Төннәр буена йоклый алмыйча уйланып чыккан чаклар булды. Партиянең шәһәр комитетында да, республика прокуратурасында да шактый сүз ишетергә туры килде.

Республика прокурорының кисәтүе юкка булмаган икән. Бер-бер чуалчык эш килеп чыктымы — телеграмма: «Бар, Ибраһимов, чиш төенне», диләр. Шулай итеп, мин Акбүләк прокуратурасы тикшерүчесеннән районара тикшерүчегә әверелдем, иң буталчык эшләрне хәл итүче булып киттем.

Юлга чыгар алдыннан, гадәттәгечә, үзебезнең прокурор янына сугылдым. Әсхәт абый Мөхәммәтшинның кәефе яхшы иде. Мин аңа, телеграмманы сузгач, ничек тәэсир итәр икән бу? дип күз салдым. Мөхәммәтшинны алмаштырып куйдылармыни: йөзе кара болытка әйләнде. Мондый телеграммалар прокурорның йөрәгенә пычак булып кадала. Кәефсез, ачулы була ул мондый чакларда. Барлык хезмәткәрләре дә үз урыннарында булса, һәрбер прокурор үзен ышанычлы сизә. Тормыш тормыш инде ул, бер-бер хәл килеп чыгып, кул астында тикшерүче булмаса? Күңелен шундый шик кимергән җитәкче тыныч эшли алмый, әлбәттә.

— Боерык боерык инде ул! Барып кайт, Гайнан! Штат кыскартуга караганда яхшырактыр да әле ул. Күршеләргә дә ярдәм итәргә кирәк. Күрсәт үзләренә Акбүләкләрнең ничек эшләгәнен.

Эш бүлмәмә кереп, урманга балтасыз бармагандай, тикшерү чемоданын алдым да, машинага утырып, врач Шакирҗановлар йортына ашыктым. Аны үгетләп тору кирәк түгел. Күп еллар буе хөкем медицинасы белгече булып эшләгән, илле ике яшьтәге эксперт мондый мәшәкатьләргә күнеккән, мәсьәләне бер сүздән аңлый торган кеше иде. Минем белән күрешүе булды, шундук киенә дә башлады.

— Сәлимҗан абый, Чулпан районына барабыз бит.

— Җәһәннәм тишегенә икән! — дип, ул киез итеген киде.— Ярар, энем, юл чыкканчы гына авыр булып тоела, бер кузгалгач барасың да барасың, сизми дә каласың.

Бу чал чәчле ягымлы врачның сүзләре күңелемне күтәреп җибәрде.

Акбүләктән чыгып киткәндә сәгатькә күз салдым: тугыз тулып килә иде. Юлны бульдозер чистарткан, алда кап-кара асфальт сузылып ята.

Портфельдән кич белән укый башлаган китапны алдым да битләрен актарырга керештем.

— Гайнан, нинди китап ул? — диде Сәлимҗан абый, күзлеген киеп.— Немецча да укыйсың икән, молодец!

— Бельгия криминалисты Луваж язмалары.

— Ниләр язган соң?

— Алар яза инде! — дим.— Ул язганнарга ышансаң, бүген үк тикшерү хезмәтен ташларга кирәк.

Шакирҗанов — әйбәт юлдаш. Аның белән һәр нәрсәне ачыктан-ачык сөйләшеп, күзгә-күз карап аңлашып була.

— Луваж мәсьәләгә сәер карый,— дим мин, сүзне дәвам иттереп.— Аныңча, тикшерү эше — сәнгать. Тикшерүче булып туарга кирәк.

— Берәү дә артист булып та, философ һәм тикшерүче булып та тумый. Бу эш өчен кирәкле сәләтне тормыш үзе тудыра, тәрбия, уку бирә.

— Шулай да, Сәлимҗан абый,— дим мин аңа,— башка төр профессияләрдән аермалы буларак, тикшерүче кеше кирәк информацияне үзенең шәхси тәҗрибәсеннән ала алмый. Әйтик, укытучы кайчандыр үзе укучы булган, аның хәленә керә, халәтен аңлый ала. Сезне, врачларны, алыйк. Әлеге көндә сезнең карамактагы пациентларныкы шикелле авыруларны, ихтимал, кичермәгән булсагыз да, барыбер кайчандыр үзегезнең дә авырып караган булуыгыз мөмкин. Димәк, үз кичерешләрегезгә нигезләнеп, пациентларны да аңлый аласыз. Ә тикшерүче? Аның җинаять эшләгән кеше хәлендә булганы, кулга алынганы, гаепләнгәне юк бит. Тикшерүче дә, башкалар шикелле үк, тоя, кичерә белә торган кеше. Шулай да ул бүтәннәрнең кайгыларына салкын канлылыгын җуймыйча карарга, коточкыч явызлыкларны күреп тә, ачуын тыярга тиешле. Тойгы, хисләргә бирелеп, хакыйкатькә, үз бурычыңа зыян китерсәң...

Әлеге китап уңае белән, юлда барганда без Шакирҗанов белән байтак кына фикер алыштык.

## 2

Байтимер авылы тәбәнәк тауның итәгенә урнашкан. Тау битләрендә зелпе, гөлҗимеш куаклары, анда-санда яшь каеннар җилгә чайкалып утыра. Уртача гына бер авыл ул Байтимер. Боргалы елгасы буена урнашкан Балыклы, Сазтамак, Туенбаш кебек авыллардан берни белән дә аерылмый. Мәгърур тупыллар, тал куаклары белән аралашып утырган агач йортлар тау бите буйлап елгага таба төшеп бара шикелле. Шифер яки калай түбәле өйләрнең чакрымнан артыкка сузылган бер генә урам булып төзелүе бу күренешне тагын да көчәйтә төшә. Башка авыллардагы шикелле, монда да таңны әтәчләр уята, кичләрен тәрәзәләрдән урамга көлтә-көлтә нурлар сибелә, яшьләр культура йортына йөри. Шушындый тыныч тормыш белән яшәгән авылда фаҗигале вакыйга булыр дип беркем дә башына китермәгәндер.

Авыл Советында безне Чулпан район прокуроры белән милиция хезмәткәрләре каршылады.

— Саттаров, Рәүф Галиевич,— дип таныштырды үзен прокурор. Аның кулы миңа җинел һәм кечкенә шикелле тоелды.

Республика прокуратурасы язмаларында минем бу фамилияне очраткалаганым бар иде. Ә Чулпан прокуратурасы исә берни белән дә аерылып тормый — алдынгылар исемлегенә дә кертелми, артта калучылар җөмләсендә дә исәпләнми иде.

Безнең прокурор Мөхәммәтшин һөнәрдәшләрен игътибардан читтә калдыра торган кеше түгел иде. Әмма бу юлы мине озатканда Саттаров турында ни өчендер бер-ике генә сүз әйтте. Аның бу сүзләре әле дә хәтердән китми: Саттаров Ватан сугышына кадәр тегермән комбинатының директоры булган; юристлар фронтка китеп беткәч, аны тугыз айлык курска җибәреп укытканнар да район прокуроры итеп куйганнар. Ике-өч ел институтта да читтән торып укып йөргән. Шулай калган да калган, үзен сугышка алмаганнар. Ул хәзер дә Чулпанда район прокуроры. Белеме аз булса да, житезлеге, бигрәк тә куштанлыгы белән алдыра. «Сак бул, шамбы балыгы кебек шома кеше»,— дип, Мөхәммәтшин мине азактан кисәтеп куйды.

Саттаровка сынаулы караш ташлап, исем-фамилиямне әйттем. Аның да күзе миңа төбәлгән иде. Ул миннән егерме яшьләргә олырак. Зур гәүдәле, күркәм кыяфәтле, чиста итеп кырылган алсу йөзле, зур пеләш башлы бер кеше иде. Карасу-зәңгәр костюмының ялтырап торган җиз төймәләре ике рәт булып тезелеп төшкән. Үзе иңбашы аша эленгән коңгырт-сары планшетны туктаусыз сыйпый; кулындагы кан тамырлары ап-ачык беленеп тора иде.

Менә берничә ел инде мин үземнең һөнәрдәшләремне өйрәнәм. Тик, әйтергә кирәк, күп нәрсә белдем дип мактанып булмый. Әлбәттә, үземә ярдәмчене тышкы кыяфәтенә карап кына сайламас идем, әмма шулай да күп очракта без кеше турында аның тышкы кыяфәтенә карап хөкем йөртәбез, йөз-кыяфәтенә, күзләренә игътибар итәбез. Һәм еш кына ялгышып та куябыз. Кеше характерының бер генә ягын күрә алганга, безнең сиземләвебез әнә шулай чынбарлыкка туры килеп бетмидер. Бер күрүдә үк аның нинди кеше икәнлеген белдем, диючеләрнең сүзенә ышанмыйм. Минемчә, андыйларны үтә сизгер кеше дип булмый, аның каравы, үзләре турында бик зур фикердә булалар алар. Ә миңа киресенчә тоела: кешене никадәр тирәнрәк белсәң, шул кадәр серлерәк була бара кебек ул. Саттаров белән очрашкач, бу уйларым тагын да ачыклана төште. Мондый сөйкемле кешене дә шамбы балыгы белән чагыштырсыннар инде. Аңламассың бу кешеләрне.

Ул әледән-әле майорга сүз ката, тәэсирләрен уртаклаша иде. Майор Чулпан милициясе начальнигы икән.

Саттаров мине дә игътибарыннан читтә калдырмады. Сизәм: кемне җибәрделәр икән дип кызыксына ул.

— Миңа сезнең кулдагы җинаять эшен тикшерергә куштылар,— дидем мин һәм кесәмнән документымны чыгарып күрсәттем.

— Беләм, беләм,— диде Саттаров, игътибар белән таныклыгымны карап чыкты.— Безнең тикшерүчебез бәхетсезлеккә очрады. Хәзер Казан больницасында ята. Ярдәмгә сезне чакырырга туры килде шул...

Күп нәрсәләрне чагыштырып карап беләсең. Мин дә прокурор Саттаровны үзебезнең Акбүләк прокуроры Мөхәммәтшин белән чагыштырам. Әсхәт абый һичбер очракта да ярдәм сорап авыз ачмас, бу турыда башына да китермәс иде. Ә Рәүф Галиевичка ярдәм кирәк, минем килүем шуның өчен. Бәлки бу начар да түгелдер әле: һәркем үзенең сәләт чамасын белергә, шуннан чыгып эш итәргә тиеш. Саттаров ярдәмче турында сүз каткач, минем күңелгә шик төште. Ул эшне үз кулына алып, тикшерүгә үзе җитәкчелек итәрме? Ә ярдәмче роле мине канәгатьләндерми иде. Мөхәммәтшин кул астында булса, башка эш әле. Саттаров миңа таныш кеше түгел. Тикшерүче булып эшләгәне бармы аның? Тәҗрибәсе, сәләте нинди? Мин бу турыда уйланмый булдыра алмадым. Сүз җитди җинаять хакында бара бит. Вак-төяк өчен генә башка районга чаклы җибәрмәсләр иде. Әйтик, прокурор Саттаров яхшы тикшерүче дә, ди. Элек тикшерүче булып эшләгән прокурорлар аз түгел. Алай булса, ни өчен аңа ярдәмче кирәк. Бер җинаятьне икәүләп тикшерү эшне катлауландыра гына, өстәмә кыенлыклар китереп чыгара. Тикшерү эше уңышсыз бетсә, кем җавап бирер? Керүеңнән алда чыгарыңны уйламыйча ярамый. Үзен хәвефхәтәрдән саклый, җаваплылыктан курка торган кеше түгелме ул? Эшләргә икән, җиң сызганып, бөтен җаваплылык тоеп эшләргә. Туры килсә, җавабын да бирергә. Юк, әүвәл бу эштә үземнең бурычны ачыкларга кирәк: алдыңа бер карасаң, артыңа биш кара.

— Эшне башлагансыздыр инде, мөгаен?

— Юк, кая ул! — Саттаров планшетын тезләре өстенә салып сыйпавында дәвам итте.— Төрле карарлар, беркетмәләр язарга яратмыйм мин. Бусы — сезнең эш.

Бу сүзләрне Мөхәммәтшин ишетсен иде! Мин моны һавалану, чиркану, тикшерүче хезмәтенә бармак аша карау дип бәяләдем. Барын да документ итеп теркәмичә ничек була инде ул?

Университетта укыган чакта да, эш дәверендә дә мин документның нәрсә икәнлеген яхшы төшендем. Рәсми кәгазьнең өскә аварга торган бәлаләрдән коткарып калган чаклары күп булды. Өлкән яшьтәге прокурор тарафыннан әйтелгән бу сүзләрнең миңа ничек тәэсир итүе аңлашылса кирәк. Документларны туплау минем өчен информацияне саклау, башкаларга җиткерү чарасы гына түгел, закончалыкны ныгыту, совет кешеләренең хокукларын саклау чарасы да. Тикшерүченең һәр адымы беркетмәгә теркәлгән, һәр карары кәгазьгә төшерелгән булырга тиешлеге миңа яхшы аңлашыла. Бу — закон таләбе дә.

Бу таләптән бервакытта да читләшкәнем булмады. Ә монда — шундый сүз. Аны кем әйтә бит әле! Мин — әйткәнне язып баручы секретарь булып кына йөрүдән канәгать түгел идем, әлбәттә. Илчегә үлем юк дигәндәй, мин үз уйларымны ачыктан-ачык әйтергә булдым.

— Телеграмма алгач, миңа секретарьлык роле түгел, ә тикшерү бурычы йөкләнгән дип уйлаган идем.

— Дөрес аңлагансыз, иптәш Ибраһимов.— Саттаровның җавабында рәсмилек сизелеп китте һәм ул бер-ике мәртәбә планшетына шапылдатып сугып куйды.— Тотыныгыз, эш кузгатыгыз. Никадәр тизрәк булса, шул кадәр яхшырак.

Шуннан соң ул миңа Казанга җибәрелгән кыска гына телефонограмманың күчермәсен сузды.

Эшләнгән җинаять биш-алты җөмләгә сыйган һәм ашыгыч рәвештә Казанга телефон аша тапшырылган булса да, ачык булып минем күз алдыма килмәде. Менә ул ничек булган.

...Сызылып таң атып килә. Әкренләп авыл уяна башлый. Әле анда, әле монда ишек, капкалар шыгырдап ачыла. Яшь кенә бер хатын, көянтә-чиләкләрен асып, авыл читендәге чишмәгә суга китә. Чиләкләреннән бозлы тамчылар тамыза-тамыза, кире борылганда күзе чишмәнең теге як ярына төшә. Ә анда — карга, саескан җыелган: ак кар өстендә караеп күренеп торган ниндидер нәрсә тирәсендә кайнашалар. Хатын сагаеп кала. Ни булыр бу? Нәрсә чукый алар? Ул, үзе дә сизмәстән, каргалар җыелган җиргә китә. Чиләкләрен сукмакка утырта да көянтәсе, аяклары белән карны актарырга тотына. Кинәт сискәнеп, ихтыярсыз артка чигенә: кар эченнән сыңар аяк — кеше аягы килеп чыга...

— Яхшы, Рәүф Галиевич,— күңелсез сөйләшүне тәмамларга теләп, урынымнан күтәрелдем.

Әмма ялгышканмын икән.

— Тик исегездә тотыгыз, Гайнан Ибраһимович,— дип басым ясап әйтте Саттаров.— Аерым хуҗалыкны яратмыйм мин. Районда эшләнгән һәр җинаять өчен мин җавап бирәм, шуңа күрә тикшерүнең барышына ваемсыз карый алмыйм.

— Рәүф Галиевич,— дип сүз башладым мин, тикшерүченең мөстәкыйльлеген чикләргә чамалаган Саттаровка.— Бер хатны бөтен авыл җыелып язмаган шикелле, тикшерүне дә авыл белән алып бармыйлар. Җинаять эшен тикшерү миңа тапшырылган. Ә прокурор күзәтүенең нәрсә икәнен яхшы беләм мин.

— Ярый, ярый,— диде Саттаров, артыграк ычкындырып ташлавын сизенде бугай.— Монда без дә кул кушырып утырмадык.— Һәм ул планшетының кнопкасын берничә тапкыр баскалап шыртлатып алды.— Гаҗәп хәл бит, ә? Бик гаҗәп! Киселгән аяк! Кеше аягы. Уң аяк,— дип ачыклый төште ул.— Ә югалган кеше юк. Бер Байтимердән генә түгел, күрше Сазтамак, Балыклы, Туенбаш авылларыннан да беркем дә югалмаган. Бөтен районда. Димәк, мәетне кайдандыр башка җирдән китереп ташлаганнар,— дип сөйләп китте ул.— Ә беләсезме, Гайнан Ибраһимович, сер итеп кенә әйткәндә, бу җинаять безнең өчен — сукыр эчәк ул. Процентка суга бит ул! Каяндыр китереп ташланган сыңар аяк аркасында януың бар. Күрсәткечләреңне түбәнәйттеңме — җавабын да бир. Квартал саен — отчет. Еллык отчеттан соң аңлатма яз. Бәлки, Гайнан Ибраһимович, бусын җилкәдән төшереп булыр, ә?

Ул миңа ялварып диярлек карады. Прокурорның элекке һавалануыннан берни дә калмаган иде. Бу минутта аңа каравы да кызганыч иде. Йөзе-бите үзгәргән, хәтта башы да ат башына охшап озынчаланып калган сыман иде. Аның «авыруына» диагноз кую өчен әллә ни уйланып торасы юк. «Безнең Мөхәмматшиннан ерак тора бу, ай, ерак тора»,— дигән уй үзеннән-үзе башыма килде.

— Нинди уйларга чумдыгыз? — дип бүлдерде Саттаров мине.

Мин, башымны күтәреп, аңа игътибар беләнрәк карадым. Шаяртмыймы икән? Мыскыллавы түгелме? Кызганычка каршы, аның йөзендә шаянлык билгесе дә, уңайсызлану галәмәте дә юк иде.

Мин кискенрәк булса да җавап бирми кала алмадым:

— Сөйләүдән элек уйлау кирәк. Бер аягың белән җиргә ныклап басмый торып, икенче аягың белән атлап китеп булмый...

Саттаров көрсенеп куйды:

— Ярый, эшкә башлыйк, алайса,— диде ул, ләкин һаман аның нәрсәгәдер өметләнүе сизелә иде.— Вакыйга булган урынга сак куелды.

— Монысы яхшы булган,— дип, мин ишеккә таба атладым.

Барысы да минем арттан кузгалдылар.

Альфа тартылып алга ыргылды. Эз табучы этләргә хөрмәтем әллә ни зур булмаса да, бу юлы безнең белән шундый җанвар да бар иде. Чулпаннан килгән милиция лейтенанты этне табылган уң аяк янында туктатты да, тирә-якны иснәтеп чыкты. Чокыр тирәсендә бераз йөргәннән соң Альфа эз табып, иснәнеп бара башлады. Кинәт тукталып калды, борынын җиргә төртте дә алгы аяклары белән карны актарырга кереште. Озак та үтмәде, кар астыннан икенче аяк килеп чыкты. Бу аяк та чабып өзелгән иде. Эт борчулы шыңшып лейтенантка сыенды, аннары чокырга, елга ягына таба юл алды.

Чокырда кар шактый тыгызланган. Альфа тегендә сугылды, монда сугылды һәм, ниһаять, нәкъ елга читендә туктап калды. Ачулы ырылдап боз катыш карны тырнаклары белән казырга тотынды. Кар астында ниндидер кара нәрсә күренде, эт алгы аякларын ныклап терәде дә, әлеге нәрсәне тешләре белән эләктереп, бөтен көче белән тарта башлады. Без Әскәров белән көрәк алып ярдәмгә килдек. Кар астыннан зур киндер капчык килеп чыкты. Саклык белән генә капчык авызын чиштек һәм беравык барыбыз да тынсыз калдык. Капчыкта хатын-кыз гәүдәсе иде. Аяксыз. Өстендә үтә күренмәле материалдан тегелгән эчке күлмәк кенә.

Эксперт Шакирҗанов мәетне карый башлады.

— Яшь хатын-кыз гәүдәсе бу,— диде ул башын күтәрмичә генә.— Өч ясалма теше бар, тутыкмый торган металлдан.

— Сәлимҗан абый, кайчанрак үтерелгән? — дип сорадым мин.

— Гәүдәне эреткәч белербез.

— Билгеләре нинди: чәченең төсе, йөзе, күзләре, борыны?

— Боларын әйтә алмыйм, Гайнан энем,— диде эксперт иңбашларын җыерып.— Йөзен танырлык түгел, күзе чокып чыгарылган, чәче яндырылган...

Безнең алдыбызда коточкыч бер хәл иде...

— Да-а-а!..— дип сузып әйтеп куйды Саттаров.— Хәзер монын кем булуын белеп кара инде!

Ул тагын да картайган, кечерәеп калган шикелле күренде. Бу авыл Советындагы прокурор түгел иде инде. Аның бу халәте аңлашыла иде: Саттаровка күптән инде мондый җинаять күрергә туры килмәгән. Мондый чакта миңа да үз-үземне кулга алуы кыен. Хәтергә уелып калган сүзләрне эчтән генә кабатлыйм: «Үзеңнең хәрәкәтең, сүзләрең белән мавыгып китеп, тәэсиргә бирелеп, бурычыңа, хакыйкатькә зыян китермәс өчен, син кешенең хәсрәтенә тетрәнмичә, коточкыч явызлыкларга тынычлыгың җуймыйча карарга тиешсең». Кайвакыт моңа җиңел генә дә ирешеп була, кайвакыт көч-хәл белән.

— Белербез, һичшиксез белербез,— дидем мин. Үземнең дә кәеф шәптән булмаса да, Саттаровның күңелен күтәрәсе килде.

— Күпме көч, күпме хезмәт салырга туры киләчәк!

— Шундый вәхши җинаятьне ачарга кирәк булганда, көч белән исәпләшеп торып булмый инде.

## 3

Кышкы көннәр кыска. Әйләнеп карарга да өлгермисен, караңгы да төшә башлый. Авыл ягыннан кичке авазлар ишетелә. Салкынайтты. Мин сикергәлим, кулны-кулга суккалыйм. Башкалар да тик тора алмый. Саттаров белән милициядән килгән ике офицер гына бирешми шикелле. Аларның өсләрендә тун, аякларында киез итек. Ниһаять, прокурорның да эченә салкын йөгерде бугай. Ул тәмәке кабызды. Аның белән янәшә, бер-берсенә сыенып ук диярлек, эксперт, авыл Советы председателе һәм Чулпан милиционерлары тора. Бары да сүзсез. Беркетмә язуны төгәлләп, мәетнең гәүдәсен, баш, аякларын рәсемгә төшердем дә Шакирҗанов янына килдем.

Ул башын чайкап куйды:

— Гайнан энем, мәетне Казанга алып барырга туры килер.

Безне дулкынландырган сорауларга җавап бирә алмагангадыр инде, Шакирҗанов абыйның кыяфәте дә, тавышы да гаепле кешенеке шикелле иде. Олы яшьтәге, чал чәчле бу кешенең авыр уйлар кичергәне сизелеп тора иде. Билгеле, ул врач буларак үлем белән аз очрашмаган. Әмма кешеләр авырудан, картлыктан үлә. Фронтта да үлем адым саен. Ләкин бу кадәр үк ерткычларча үтерелгән яшь хатын-кызны аның да беренче күрүедер, мөгаен. Бу яшь кешенең гомерен өзгән нәрсә чор да, дошман пулясы да түгел бит.

— Сәлимҗан абый, сез мәетне Чулпан больницасына илтеп, Казанга җибәрү өчен әзерли торсагыз...— Шакирҗанов янәшәдә генә булса да, мин бу сүзләрне кычкырып әйттем: Саттаровны да күңелсез уйларыннан арындырырга кирәк иде.

Теләгәнеңчә эшлә дигәнне аңлатып, прокурор баш какты.

Чулпан милиционерлары брезентка салынган мәетне машинага таба алып киттеләр.

Саттаров һаман бер урында басып тора бирде. Бер кулы белән авызындагы сигаретын, икенче кулы белән планшетын тоткан. Ул нидер уйлый, ниндидер карарга килергә җыена иде бугай. Мин аңа якынрак килдем, Саттаров җанланып китте.

— Башка сыймаслык нәрсә,— диде ул әрнүле тавыш белән.— Минем районда шундый җинаять бит! Мондый хәлне күргәнең булдымы?

Саттаровның адым саен «минем район» дип кабатлавы ошамаса да, артык игътибар итмәскә булдым. Минем сүз белән генә, берничә көн эчендә генә аның характерын барыбер үзгәртеп булмас иде.

— Моңа охшашларны күрергә туры килде. Бер генә тапкыр да түгел,— дидем мин.

— Я, ничек бетте соң? — дип, Саттаров җанлана төште.

— Җинаятьне ачмый калган чак булмады.

Ул уй-тойгыларын яшерә белми иде, күрәсең. Җавабымны ишеткәч, балалар кебек шатланды.

— Бик әйбәт, Гайнан! Тырыш инде, монысын да ачарга кирәк,— Саттаров ялварып диярлек минем күзләремә карады.— Ачылмаган җинаять — баш өстендә асылынып торган балта кебек бит ул!

— Тырышырбыз, Саттаров абый.

— Барын да эшләрмен, эш кенә уңсын! — Ул нәкъ шушы җөмләгә басым ясарга теләгәндәй тын калып, тагын планшет кнопкасын шыртлатырга тотынды.

Вакытны әрәм итәргә теләмичә, сүзне икенчегә бордым:

— Менә хәзер бер ун дружиначы белән көрәкләр булсын иде.

— Ялт эшлибез аны, күз ачып йомганчы!..— Саттаров тагын житез, тәвәккәл кешегә әверелде.

Пунэтәйләр кул куйган беркетмә, төшерелгән кадрлар әзер, мәет моргка озатылды. Мин уйга чумдым: нәрсә булса да табылырга тиеш

бит бирелә! Кечкенә генә булса да. Ни генә эшләнмәсен, ничек кенә яшерелмәсен, кеше һәр вакыт эзен калдыра. Нинди генә булса да... Мәет күктән төшмәгән ләбаса. Эзләре булырга тиеш.

Саттаров чыннан да кинәт үзгәреп китте. Аның «аш дигәндә ашыгыр, эш дигәндә башын кашыр» кеше түгеллеге күренеп тора иде. Ул буран уйнатып кар актара, җилкәсенә аскан планшеты кая сугылырга белми. Кыска тунын кар өстенә салып аткан. Кешеләрнең аркаларыннан пар күтәрелә. Кардан арчылып, тикшерелә торган мәйдан киңәйгәннән-киңәя бара. Чокыр һәм елга буе оборонага әзерләнгән фронт участогы кебек булып китте.

Агач көрәк тоткан килеш әле бер, әле икенче урынга ашыгам. Итек табаннары астында зарланган сыман тавыш чыгарып кар шыгырдый: шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт. Башымда һаман бер уй: ни дә булса табылырга тиеш бит. Ат аунаган җирдә дә төк калмый булмас. Табылырга тиеш...

Милиционерлар, депутатлар, дружиначылар. Берсе янынннан икенчесенә атлыйм. Юк, һаман юк.

Ун... йөз метр. Эшләсәң — эш карышмый шул. Күпме кар көрәлгән, урыннан-урынга күчерелгән, иләк аша үткәргән кебек тикшерелгән. Кешеләр сулыш алыр, билләрен язар өчен ешрак туктала башладылар. Минә тагын көрәкләренә таянып тынып калдылар. Барысы да миңа карый, нидер көтә. Аларның арыган кыяфәтләрендә өметсезлек тә бар. Даладагы җилне эзләп күпме җәфаланырга була? Юкны бушка аударып ни файда? Тәҗрибәле булган, күрәсең, явыз: берни дә калдырмаган.

Кар көрәүчеләрнең хәлен аңлыйм мин. Чөнки үземнеке дә шундыйрак. Саттаров моны теле белән үк әйтеп бирде.

— Бәлки бүгенгә җитеп торыр, ә? — диде. Һәм көрәге белән кояш баешы ягына төртеп күрсәтте.

Кичке караңгы төшеп килгәнен мин шунда гына абайладым.

— Ярый, алайса...— дип, теләр-теләмәс кенә килешергә мәҗбүр булдым һәм Саттаров басып торган төшкә атладым.

Аның белән янәшә эшләүче озын буйлы кеше һаман казына иде әле. Соскы сыман көрәген тутырып кар ала да салмак селтәнеп читкә ыргыта. Менә ул көрәгенә тагын кар сосып алды да читкә ыргытмакчы булды. Әмма көрәге нәрсәгәдер эләгеп туктап калды. Нидер сизеп, мин аның янына ашыктым.

— Әй, бау кисәге генә икән! — дип, ул аягы белән бауны эләктереп чөеп җибәрде.

Саттаров өлгеррәк булып чыкты. Мин килеп җиткәндә бау аның кулында иде инде.

— Нindидер бау кисәге шунда,— диде кемдер ваемсыз тавыш белән.— Бауның да мунчаладан ишелгәне...

Прокурор кулында чыннан да мунчаладан ишелгән бармак юанлыгы бау иде. Ул аны пыяла ваза сыман итеп саклык белән генә тоткан иде.

Бау таныш сыман тоелды. Мәет салынган капчыкның бер почмагында да шундый ук мунчала бау бар иде. Юанлыгы да шундый ук, ишелүе дә бер — уңнан сулга ишелгән. Аерма — озынлыкларында гына. Икесе дә нindидер үткен нәрсә белән киселгән. Икенче очы сүтелмәсен өчен төйнәп куелган. Мин бау бәйләнгән капчыкны алдым да ике бауның очларын бер-берсенә куеп карадым. Туры килә.

Прокурор бауны кулыннан да ычкындырмый. Аны үлчәп, фоторәсемгә төшерү генә минем өлешкә туры килде. Аппаратны бер-ике тапкыр чыртлатып алырга да өлгермәдем. Саттаров планшетын ачып, бауны шунда салып та куйды.

Аның бу кыланышы миңа аңлашылып җитмәде. Табылган дәлилне җил-яңгыр тидермичә саклау нияте белән эшләдеме, әллә бу уңышны үзенеке итеп күрсәтергә тырыштымы?

— «Телсез шаһит бу!» — Прокурор планшетына сугып алды да, йөзенә ихласлык чыгарып, имән бармагын тантаналы төстә югары күтәрде.

Мәетнең кем булуы да, ни өчен үтерелүе дә әлегә ачык түгел, шикле кешеләрнең исемнәре, вакыйганың сәбәбе дә билгесез, әмма кул очына эләктерерлек деталь бар. Зыян күргән кеше дә, шикле кеше дә билгесез, шаһитләр дә юк, ләкин капчык белән бау кисәкләре бар. Болар гына аз, бик аз, әлбәттә. Шулай да берни булмаган ише түгел инде. Кул тамчыдан җыелган шикелле, җинаятьне дә шундый юк-бар кебек тоелган, вак булып күренгән дәлилләр ача бит.

## 4

Авыл Советына кайткач, табышларыбызны тагын бер кат җентекләп карап чыктык.

Үтерелгән кеше кем?

Җавап юк. Моны беркем дә белми. Мәет янында документлары да, киемнәре дә, үзенә генә хас билгеләре дә юк.

— Нәрсәдән башлыйбыз соң?

Саттаров сорауга каршы сорау бирде:

— Үзең ничек уйлыйсың?

Бусы инде җаваплылыктан котылырга тырышу сыман иде.

Шулай итеп, үз соравыма үзем җавап бирдем.

— Иң элек җинаятьчене таррак мәйданда эзли башлыйк диюем: бу кешене үтерү кемгә кирәк булган? Ул кешене үләр алдыннан кем белән күргәннәр? Элек кем шуңа охшашлы җинаять эшләгән? Шушы сорауларга җавап таба-таба, шикле кешеләрнең санын киметергә мөмкин,— дидем.

Милиция начальнигы игътибар белән тыңлап, куен дәфтәренә нәрсәдер язып бара. Прокурор да тыңлый сыман.

— Килешәм,— диде Саттаров, бармакларын биетеп.— Авылларны бүлешеп алыйк та кем югалганын белергә тырышыйк, бер уңайдан шикле кешеләрне дә ачыклыйк.

— Бу юл катлаулы булыр, вакыт күп кирәк аңа,— дип каршы төштем мин.

— Нәрсә тәкъдим итәсең соң? — дип, прокурор гаҗәпләнеп миңа карады.

— Эксперт мәетне Казанга алып барырга кирәк диде. Мин дә шулай уйлыйм.

— Нигә?

— Баш сөягенә карап йөзен-битен ясау өчен. Гәүдәсен җентекләбрәк тикшерү дә кайбер сорауларга җавап табарга мөмкинлек бирер.

— Ә мин үтерүчене эзли башларсың дип уйлаган идем. Районда ачылмаган бер генә җинаять булуына да түзеп тора алмыйм,— диде Саттаров.

— Әгәр үтерелгән кеше кунакка килгән булса? Бәлки командировкага килгәндер? — Шундый сораулар белән прокурорны уеннан кире кайтарырга тырышып карадым.

— Моны исәпкә алырмын.

— Бәлки кем дә булса берәрсенең килүен көткәндер?

— Бусын да ачыклармын.

— Иптәш прокурор, бу сорауларны милиция хезмәткәрләренә рәсми йөкләмә итеп тапшырам. Кем үтерелгәнлеген белми торып,

үтерүченең дә кем икәнлеген белеп булмый. Мин моңа берничә тапкыр үз тәҗрибәмдә ышандым инде. Ничек кенә булмасын, үтерелгән кешенең кемлеген ачыклау — тикшерүнең төп шарты.

Ышандырырлык итеп өзеп әйтү Саттаровка да тәэсир итте булса кирәк.

— Ярый, үз алымың белән эш ит, Гайнан, ә без милиция белән монда эш алып барырбыз,— диде ул.

* * *

Татарстанның танылган медицина профессоры, бармаклары белән сак кына кагылгалап, мәетне тикшерә. Минем белән бергә килгән Шакирҗанов аңа ярдәм итә.

Минут артлы минутлар үтә. Профессор кыска, әмма катгый сүзләр белән тикшерүнең нәтиҗәләрен әйтә бара.

— Буе — 158—159 сантиметр.

— Яше?

— Унтугыз.

— Нинди дә булса авыру кичергәнме?

— Кичергән. Тешләренә, сөякләренә карагыз. Өч теше юк. Уң якта өске тешләре. Алар урынына тутыкмый торган металлдан ясалма теш куелган.

— Һөнәреме? — дип кайтарып сорый профессор.— Тегүче булырга тиеш.

Мәетнең һәр өлешен җентекләп күздән үткәреп, галим билгесез хатын-кыз турында яңадан-яңа мәгълүматлар хәбәр итә. Мин аның һәр сүзен куен дәфтәренә төрки барам.

— Тән төзелеше дөрес, тыгыз тәнле. Туры басып йөри торган булган. Утыз алтынчы размерлы аяк киеме кигән. Йөзе түгәрәк, киң иякле. Милләте татар, яисә чуваш, мари. Чәче коңгырт төстә, озын булган. Тәне дә шулай ук коңгырт.

— Йөкле түгелме?

— Йөкле түгел.

— Бала тапканмы?

— Юк.

— Күзләре? — дип, профессор бераз уйланып торды. Шакирҗанов миңа карап алды.— Монысын әйтеп булмый, күзен чокып алганнар.

— Үзенә генә хас билгеләре бармы?

— Бар. Биш тиен акча зурлыгы миңе бар. Уң ботында тездән югарырак, эчке якта.

Шулай итеп, билгесез хатын-кыз турында мәгълүмат арта барып, аның кыяфәтен күз алдына китереп була башлады. Ләкин болар гына аз иде әле, минем өчен аз иде. Шулай да канәгать идем. Туракланган мәетнең һәр өлеше «телсез шаһит» булса да, күп нәрсә сөйли иде. Әмма бу галимнәр белән башлаган эшнең беренче адымы гына иде әле.

— Үлүенең сәбәбе нәрсә?

— Үтерелгән. Баш сөяге арткы яктан һәм чигәсеннән яньчелгән. Баш капкачы да ватылган. Бу яралар барысы да үлгәнче ясалган.

— Җинаятьче нинди корал белән эш иткән?

— Тупас, каты әйбер. Таш, кастет, балта түтәсе булгандыр.

— Кайчан үлгән?

— Моннан җиде көн элек.

— Мәет кайчан туралган?

— Үлгәннән соң, мәет ката башлагач.

— Күпме вакыт үткәч?

— Бер-ике сәгатьтән соң.
— Нинди корал белән чапкаланган?
— Балта кебек әйбер булырга тиеш. Ләкин үткен балта түгел.
Никадәр мәгълүмат! Без Шакирҗанов белән медицинаның мөмкинлекләрен белгән хәлдә дә гаҗәпләнеп тордык. Ләкин тикшерү эшенә болар гына җитми иде әле. Шакирҗанов мине анатомия галимнәре янына алып китте. Без аларга белгәннәребезне сөйләп, ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек.
Баш сөягенә карап йөзен элекке кыяфәткә китерәсе иде.
Берничә көннән соң белгечләр тарафыннан тегелгән гәүдә, төзәтелгән баш һәм аның фоторәсемнәре әзер иде инде. Мин аларны алып кире Чулпанга очтым.

* * *

Кичен Байтимер авылы кешеләре радиодан гадәти булмаган тапшыру тыңладылар: үтерелгән кешенең кем икәнен танып белү өчен аларны авыл Советына чакырттым. Авылга килгәч, беренче эшем шул булды.
Кабинетка бер-бер артлы кешеләр керде. Берәүләре тыгыла-кысыла кире чыкты, икенчеләре этешә-төртешә бүлмәгә узды. Әлбәттә, монда төрле халык бар иде, берәүләр — кызык өчен, икенчеләре — ләчтит сатарга азык булсын өчен, өченчеләре — чын күңелдән ярдәм итү теләге белән килә иде. Җинаять эшләрен тикшергәндә гел шулай инде ул.
Күз алдымнан байтак кеше үтте. Билгеле, күбесе беркемне дә кунакка көтмәгән, таныш-белешләре дә юкка чыкмаган. Фоторәсемгә карыйлар да баш чайкыйлар: юк, танымыйбыз, диләр.
Шулай да мин өметемне өзмәдем. Менә олы гына яшьләрдәге бер хатын, бераз икеләнеп торганнан соң, рәсемне сеңелесе Зөлфиянең бер дус кызына охшатуын әйтте. Ул кыз Якты Тауда яши икән. Милиция капитаны Сәмигуллин, һәммәбез шикелле үк эшнең тиз чишелүенә өмет баглап, шунда юл тотты.
Бер сәгатьтән соң мине телефонга чакырдылар. Якты Таудан шалтыраталар икән.
— Осечка,— диде Сәмигуллин.— Барып чыкмады. Зөлфиянең ахирәте үтерелгән кызга чыннан да охшаган, тик ул исән-сау, мин килгәндә рәхәтләнеп йоклап ята иде.

Байтимер авылында мәетне белүче кеше табылмады. Авылдан хәбәрсез югалган хатын-кыз да юк иде.
— Безнең авылда начар кеше юк,— диделәр Байтимер кешеләре, горурлык белән.— Яманатың чыкканнан кара күзең чыккан артык. Бездә беркайчан да кеше үтергәннәре юк. Җинаятьчене башка урыннан эзләгез. Яхшы исем малдан артык.
— Димәк, мәетне каяндыр китереп ташлаганнар,— дип, элекке нәтиҗәсен ясады Саттаров.
— Булуы бик мөмкин,— дидем мин килешеп.— Тик кайдан китереп ташладылар икән?
— Их, белсәм мин аны! Шулай да кайгырма, Гайнан,— дип прокурор серле кыяфәт белән планшетына чиертеп куйды.— Син Казанда чакта милиция байтак кызыклы нәрсә ачыклады бит. Ничә кеше Чулпан районына командировкага килгәнен белергә телисеңме? — Ул үзе сорау бирә һәм, минем җавапны көтеп тә тормастан, үзе үк җавабын да чыгарып сала.— Унбер. Шуннанмы? Шуннан барысы да сау-сәла-

мәт. Ә районнан ничә хатын-кыз киткән? Егерме җиде. Сине унтугызегерме яшьтәгеләр кызыксындырамы? Рәхим ит, андыйлары сигез. Кая киткәннәрме? Бусы да төгәл беленде. Өчесе — санаторий белән ял йортына, өчесе — Мәскәүгә күргәзмәгә, икесе — кунакка. Барысы да исәнме? Рәхим ит, җавап әзер. Җидесе турында телеграммасы бар. Берәү генә билгесез. Чулпанныкы үзе.

Мин, бу сүзне ишеткәч, урынымнан сикереп үк тордым.

* * *

Төш вакытларында минем янга бер хатын килеп керде. Ул Котлы Яр дигән авылдан иде, мин аны Чулпан район прокуратурасына телеграмма белән чакырттым. Ул миңа ничектер куркынган төс белән карый, моны яшерергә дә тырышмый. Вакыт-вакыт дерт итеп тирәягына карап ала. Тикшерүче кабинетында аны кемдер яшертен сагалап тора диярсең.

Хатынның дулкынлануы миңа да күчә барды. Бу кадәр нәрсә тәэсир иткәндер, үзем дә аңламыйм. Гадәттәгечә, эчтән үземне тыярга тырышып карасам да — ярдәм итмәде. Бу хатын кабинетка килеп керү белән аны кайдадыр күргәнем бар шикелле тоелды. Бөтен хәтеремне эшкә җигеп карадым, тик исемә төшерә алмадым. Кайда күргән идем соң әле бу хатынны? Киң генә иякле, каратут йөзле, бер генә толым итеп үрелгән калын коңгырт чәч. Горур кыяфәт, төз гәүдә. Мин үземне ниндидер зур бер хәл алдында торган шикелле тойдым, серне ачуга күп калмаган кебек хис иттем.

Турыдан-туры сорашуга керешкәнче, сүзне ераграктан башларга уйладым. Монысы минем өчен дә, аның өчен дә яхшырак иде. Безнең икебезгә дә котылгысыз күңелсезлек алдыннан бераз тынычлана төшәргә кирәк иде.

— Исем-фамилиягез? Кайда яшисез?

Болар гадәти сорау, кешене борчуга төшерерлек берни дә юк.

— Мин — Бибинур Аллаярова, Котлы Ярдан...— Хатын, дулкынлануын басарга теләгәндәй, бераз тынып торды. Аннан соң тукталатуктала сөйләп китте:— Кызым Зарима кайтырга тиеш иде. Монда, Чулпанда тора ул. Кайтмады... Хаты килгәненә ун көн. Юк та юк... Ни уйларга да белмим...

— Сезнең кызыгыз кем?

— Зарима инде, Аллаярова. Чулпанда тегү фабрикасында эшли. Тегүче.

— Аның кайда икәнен фабрикада беләләрме?

— Ничек белмәсен инде. Ялда. Ялга чыкканына сигез көн. Приказларын күрсәттеләр.

— Тагын нәрсә диләр соң?

— Башкасын белмиләр. Дус кызы Ташкентка киткәндер, ди. Алдый...

— Алдаганын каян беләсез?

— Белми ни! Ташкенттагы улымнан телеграмма алдым. Зарима килсен, дигән. Кунакка чакыра. Димәк, Зарима анда түгел...

— Кызыгызга ничә яшь?

— Унтугыз.

— Аягына 36 нчы размер кияме?

— Әйе. Кайдан беләсез?

— Ясалма тешләре дә бармы?

— Бар.

— Өчәүме?

— Ө-өч-ә-ү...— Аның күзләре зураеп китте, ә үзе ничектер кечерәеп калды, иңбашлары бизгәк тоткан кешенеке шикелле дерелди башлады, калтыранган куллары белән йөзен каплап, өстәлгә сыгылып төште.

Су салып бирим дип урындыктан күтәрелдем. Өзгәләнеп, ачыргаланып йөрәк түреннән чыккан тавышы мине тетрәндереп җибәрде:

— Ай алла! Заримам, балакаем!..

Ана кеше бераз тынычлана төшкәннән соң, мин аңа реконструкцияләнгән башның фоторәсемен суздым:

— Менә шушы рәсемне карагыз әле, Бибинур апа.

Ул башын көч-хәл белән өстәлдән күтәрде, күзләрендә хәсрәт катыш гаҗәпләнү иде. Ул, маңгаен җыерып, үзенең кайда икәнен, минем кем булуымны хәтерләргә тырыша иде булса кирәк. Күз яшьләрен кулы белән сөртеп алды да кыюсыз гына рәсемгә үрелде.

— Юк, улым, юк! Зарима түгел бу. Менә нинди ул минем кызым! — дип, газетага төргән кәгазьләрен калтыранган куллары белән сүтеп, миңа Зариманың фотосын сузды.— Синең фотоң да охшаган, ләкин ул түгел. Менә кара. Зариманың күзләре көлеп тора аның, ә монда — җансыз. Минем кызымның кашлары сызылып тора, бит очлары чокырлы, толымнары озын. Юк, Зарима түгел бу.

— Аның миңе бармы?..

— Кемнең генә юк ул!

— Уң аягында, тезеннән югарырак, биш тиен акча зурлыгы?

— Каян беләсең аны?! — Бибинур апаның күзләрендә гаҗәпләнү булса да, иреннәре дерелди, тартышып-тартышып куя, ә иңбашлары баягыдан да ныграк калтырана иде.

Никадәр авыр булса да, Бибинур Аллаяровага мәетне күрсәтергә туры килде. Башлый белсәң, бетерә дә бел, дигәннәр.

Үтерелгән кызның Зарима Аллаярова икәнлеге ачыкланды: анасы кызын ясалма тешләре һәм аягындагы миңенә карап таныды.

«Әгәр башка кеше булса?» — Күңелдәге эчке тавыш шулай дип пышылдады.

Һәм тагын эзләнүләр башланды. Чыннан да Заримамы ул? Хата юкмы?

Өстәлемдә — Чулпан больницасыннан соратып алган Зарима Аллаярованың авыру тарихы, аны Вәлитова дигән фельдшер язган. Зарима бер яшьлек чагында кызамык белән авырган. Әнисе белән кырык ике көн больницада ятып чыккан. Узган ел өске өч тешен алдырып, ясалма теш куйдырган.

Тулай торакта бергә яшәгән ике ахирәте Зариманың эчке күлмәген таныдылар. Алар мондый күлмәкне өчесенә бергә кибеттән сатып алган булганнар. «Ышанмасагыз, менә,— дип, күлмәкләрен китереп күрсәттеләр.— Чагыштырып карагыз. Нәкъ үзе».

Суд-медицина экспертизасы да ярдәмгә килде. Зарима Аллаярованың әнисе биргән фоторәсеме белән мәетнең баш сөяген чагыштырып карап, катгый нәтиҗә чыгарды: үтерелгән кеше — Зарима Аллаярова.

Шулай итеп, иң әһәмиятле сорауларның берсенә ачык җавап табылды. Бусы эшнең башы гына әле. Сораулар адым саен катлаулана бара иде. Зарима Аллаярованың үлүе кемгә кирәк булган?

## 5

Мин шуны аңладым: һәр җинаять эшендә ике табышмак бар. Берсе, тикшерү барышында тулысынча ачыла торганы — җинаятьнең яки вакыйганың үзе. Икенчесе — тикшерүче эшенең барышы. Аны беркайчан да аңлап бетереп булмый шикелле.

Кайчак мин битараф бер кеше кебек үз эшемә үзем читтән карарга яратам. Безнең эшнең бик күп яклары башкалар өчен очраклы булып күренә, аңлаешсыз булып тоела. Хәер, моңа гаҗәпләнерлек тә түгел.

Үтерелгән кешенең кем булуы хәзер һәркемгә билгеле: Зарима Аллаярова. Аның кем тарафыннандыр үтерелгәнен дә сорап торасы юк. Бусы — беренче табышмакның җаваплары. Икенчесенеке исә катлаулырак.

Бәлки Саттаров хаклыдыр да. Ул тәҗрибәле кеше, районны биш бармагы кебек белә. Елга буенда, мәет табылган җирдә кан таплары да, эзләр дә, җинаять кораллары да юк. Үтерелгән кыз нигә шулай эчке күлмәктән генә? Бәлки җинаятьче аңа өйдә йоклап яткан чагында һөҗүм иткәндер? Ул чакта аны авыл кешеләреннән кемдер белергә, ишетергә тиеш иде. Ләкин ләм-мим дәшкән кеше юк. Җинаятьчене башка урыннан эзләгез, диләр. Алай дип әйтүе җиңел ул. Мәсәлән, башка бер җирдә үтереп, Байтимер авылына китереп ташлаган булсалар? Ә ни өчен Байтимер авылына? Җинаятьче өчен моның нәрсәсе уңайлы булган?

Үтерелгән кызның дуслары Әкълимә һәм Гатифә белән дә очраштым. Бу тыныч авылның исеме һаман күңелдән китми.

Очраклымы бу хәл? «Кем үтергән?» дигән сорауга җавапның башы шушы авылда түгелме? Кызның үлүе кемгә кирәк булган? Кирәкле белешмәләр портфельдә. Соңгы илле ел эчендә районда мондый вәхшиләрчә кеше үтерү булмаган. Зариманың дошманнары булмаганмы? Юк, булмаган. «Үләр алдыннан Зариманы кем белән күргәннәр?» Аның яшәгән мохиты — фабрика, тулай торак; дуслары, танышлары күп түгел: Әкълимә, Гатифә, Гатаулла, Әхмәт. Төп сорауларга җавап менә шулар.

Зариманың үлеме кемгә кирәк булган? Үләр алдыннан Зариманы кем белән күргәннәр? Шул ук дүрт исем: Әкълимә, Гатифә, Гатаулла, Әхмәт. Икесе билгеле исем, икесе яңа. Гатаулла белән Әхмәт. Кем соң алар Заримага? Җепнең очы шушы түгелме? Бу сорауга вакыт үзе җавап бирде. Шул көннәргә кайтып, ком арасыннан алтын бөртекләре эзләгән кебек казына, эзләнә торгач, Зарима белән дуслары арасындагы мөнәсәбәтләрнең эченә керә алдым.

* * *

Зариманы тормыш артык иркәләми. Әнисе колхозчы, әтисе балыкчы. Көнне төнгә ялгап эшлиләр. Зарима да кечкенәдән үк эшкә өйрәнеп үсә. «Кызың бигрәк уңган, Бибинур, кем бәхетенә генә үсә икән?» — дип соклана күрше-тирә.

Котлы Ярда унынчы классны тәмамлагач, Зарима эш, һөнәр турында уйлана башлый. Уйланып киңәшкәч, Казанга китә.

Әти-әнисе аның үзеннән дә, техник училище дирекциясеннән дә күңелле хатлар алып торган.

Чулпандагы тегү фабрикасына Зарима тегү машиналары механигы булып эшкә кергән. Берничә айдан соң ук аның исеме «Яхшы эше һәм үрнәкле тәртибе өчен...» дип башланган приказларда күренә башлаган. Осталыгы үсү белән бергә, хөрмәте дә, акчасы да арта барган. Тулай торактан урын биргәннәр. Иптәш кызлары белән уңайлы да, күңелле дә яшәгән Зарима. Шулар өстенә кызның йөрәген беренче мәхәббәт канатландырган.

Көннәрдән бер көнне:

— Хәерле кич! — дип эндәшә аңа бер егет.

Зарима аңа ялт кына күз сирпеп ала да исе китмәгән кыяфәт белән иптәш кызлары артыннан иярә. Көлешә-көлешә юлларында булалар. Ләкин егет оялып тормый, аларның артларыннан килә, кызлар тулай торак ишегеннән кереп югалганчы карап кала.

Зарима кызлар белән кереп киткәч, димәк, егете юк дип уйлый ул. Егетләр дәшә дип тә ачылып китмәде, шулай булгач, тыйнак, тәртипле кыз. Буй-сыны зифа. Киеме дә зәвык белән тегелгән.

Егетнең йөрәге кысылып куя. Бу татлы да, гаҗәп тә хисне кичергәне юк иче әле аның. Тик моның нилектән икәнен аңлап җиткерми әле ул.

Көнеле аны тулай торакка әйди. Таныш вахтер апа башка егетләргә якты чырай күрсәтмәсә дә, Әхмәт белән мөлаем сөйләшә. Тегү фабрикасында эшләүче бу кызлар егет-җилкенчәк белән артык чуалмыйлар, тәртипле яшиләр, киногa йөрергә яраталар икән. «Исәбең булса, йоклап йөрмә»,— ди вахтер апа Әхмәткә.

Үзе дә кызлар күзе төшмәслек егет түгел ул Әхмәт. Буе-сыны килгән, ачык йөзе, нурлы күзләре кеше күңеленә шунда ук сеңеп кала. Ап-ак тешләрен күрсәтеп бер елмайса, йөзе яктырып китә. Эшләгән урыны да әйбәт — Чулпан промкомбинатында столяр. Кыскасы, Әхмәт Дәүләтшин яше җиткән бер буйдак егет була. Сигезенче класстан соң кечке мәктәпкә күчеп, әтисе шикелле үк кулына балта ала. Армиядән әллә никадәр мактау кәгазьләре алып кайта. Колхозда кулына ни тотса шуны эшли ала торган балта остасына хөрмәт бар инде ул. Әнисе Әхмәт өчен шатланып туя алмый. Тату, җитеш яшиләр. Әхмәт өй салырга ниятләп, бүрәнәсен, тактасын хәстәрли башлый. Әмма бәла дигәненнән күзгә күренми генә килеп керә торганы да була икән. Оста куллы егеткә авылда эш җитәрлек. Һәр өйдә кагар-сугар нәрсә табыла. Эшен эшләдеме — хуҗа кеше инде сиңа бурычлы булып калмый — өстәлгә «акбашны» китереп куя: бераз тамак чылатып ал, ди, арыган тәннәрең язылып китәр, янәсе.

Әнисе кисәтмәгән түгел. «Ташла, улым, эчү белән мәртәбәң артмас»,— дип күпме әйткән. «Куанычтан сыйлыйлар бит, шулай гадәткә кергән инде»,— дип кенә җавап бирә аңа Әхмәт. Ана кеше ничек кенә тырышып караса да, улы һаман аракыга хиресләшә бара. Кулың алтын икән, башың аек булсын. Әмма Әхмәтнең аек чаклары торган саен сирәгәеп, әлеге баткаклык аны тирәнрәк суыра барган.

Бервакыт табындашлар арасында гауга чыгып, Әхмәт берәүнең яңак сөяген сугып сындырган. Шулай итеп, аны ике елга иркеннән мәхрүм иткәннәр.

Срогын тутырып кайткач, Чулпанга килеп эшкә урнаша. Байтимергә кайтып йөри, һәр ялны диярлек әнисе, туган-тумачалары белән үткәрә. Тормыш күңелсез түгел. Тик менә көзгегә күз салса гына бераз боегып куя Әхмәт: чәчләре сирәкләнеп килә, йөзендә җыерчыклар да күренгәли башлаган. Ләкин артык борчылмый. Шаянрак табигатьле кеше ул, берникадәр купшыланырга да ярата. Бераз авызлыксыз, әмма зарарсыз егет дип саныйлар аны. Хатын-кызларга үзенең ошаганын белә ул. Әхмәт бу юлы да шикләнеп тормый. Кыюлык өчен бераз салып ала да тулай торакка килә, ишек шакый. Кызлар, кичә үзләрен озата килгән егет икәнен танычач, бүлмәгә керергә дә рөхсәт итәләр. Әмма Әхмәткә монда озак утырырга туры килми, салганын сизеп алгач ук чыгып китәргә кушалар.

Үзен бер сынаткач, икенче килүендә дә шул ук хәл кабатлана. Тагын барып күренүе оят булса да, әлеге Зарима дигән кыз аның күңеленнән бер генә минутка да китми. Бер җаен табарга кирәк. Шунда ул үзенең дусын искә төшерә: авылдашы Гатаулла югала торганнардан түгел, әмәлен тапмый калмас ул.

Гатаулла Вәлитов Әхмәттән бик нык аерылып тора. Чырае белән дә ул әле шактый яшь күренә. Үз-үзен тотышы да йөз кызартырлык түгел. Башкалар карта уйнаганны күрсә, читләп үтә, шешә-фәлән ачкан төштә стаканга чат ябышмый. Юкка-барга исе китми. Туң йөрәкле эгоист дип уйларлык урын булса да, бик итагатьле, тәртипле егет санала. Байтимер авылында менә дигән йорты-курасы, өр-яңа мотоциклы бар, пенсиядәге әнисе барына да өлгереп тора. Вәлитовның дәрәҗәсе дә юк түгел: механикалаштырылган төзү колоннасында мастер, үзенә беркетелгән аерым автомобиле бар. Кичләрен еш кына китапханәдә утырып уздыра, контроль эшләрен әзерли, имтиханнарга әзерләнә. Төзелеш институтында читтән торып укый ул. Ял көннәрен гадәттә Байтимердә үткәрә. Өс-башы да әйбәт, энәдән-җептән генә чыккан булыр. Килгән-киткән артистларның концертларын калдырмый. Иптәшләре аны хөрмәт итә. Шәп әңгәмәдәш ул, күп белә, үзен күңелле тота. Гатаулла бәхет өчен генә дөньяга килгән шикелле. Егет — житеш кенә гаиләдә туган, ачлык-ялангачлык күрмәгән, хәзер дә рәхәттә яши. Әнисе аның өчен үлә язып тора...

Әхмәт аңа үтенечен әйтеп биргәч, Гатаулла аны шундук аңлап ала, сызгырына-сызгырына киенергә дә тотына.

Әхмәт — житди кеше. Зарима исеме теленә килү белән йөрәге ешеш тибә башлый. Әмма Гатаулладагы ышаныч аңа да тәэсир итә, янәшә барган иптәшенә карап, бераз тынычлана төшә.

Вахтер апа аларга ишек төбендә калырга кушып, үзе якындагы бүлмәгә таба китә. Бүлмәдә инде ут алганнар. Ишектән тонык пыяла аша хатын-кыз гәүдәсе чагылып кала. Шуннан соң вахтер апа егетләрне бүлмәгә уздырып җибәрә. Аларны ишектә чибәр генә кыз каршы ала.

— Зарима,— дип исемен әйтә ул.

Вәлитов та үз исемен әйтә һәм:

— Әхмәтне сез беләсез инде,— дип, сәер генә елмаеп куя.

Вәлитов кызга сокланып карый, аның буй-сыныннан, күпереп торган куе чәчләреннән, мөлаем йөзеннән күзләрен ала алмый карап тора.

Гатаулла да кызга ошый. Егет игътибар итмәслек түгел шул. Кыю, ачык карашы, дугаланыбрак торган кашлары, кояшта янган шома йөзе, килешле гәүдәсе үзеннән-үзе карашыңны тартып тора.

Кыз оялып башын ия, битләре алсуланып китә, күзләре озын керфекләре астына яшеренә. Гатаулла нидер әйтмәкче булса да, авызыннан сүзе чыкмый. Шул вакыт Зариманың бүлмәдәш кызлары кайтып керә. Егетләр алдында оялып кына басып торган Зариманы күргәч, Әкълимә белән Гатифә аның күңелендә нииндидер үзгәреш булуны шундук сизеп алалар.

Шул көннән бирле җиде ай вакыт уза.

Әхмәт кызлар янына йөрүдән туктамый. Кызмача килгән чаклары булса да, хәзер инде аны кумыйлар. Күнектеләр шикелле, шаярталар, көләләр. Әхмәт исә ара-тирә Заримага караштыргалап хәрәкәтсез утырудан узмый. Егет берәр сүз кушса, Зариманың чырае караңгыланып, күңелсезләнеп китә.

Вакыт уза тора. Әхмәт Зариманың Гатаулла белән дуслашып китүен сизеп ала. Аларны бергә очраткан чаклары да була.

Аларга «бигрәк пар килгәннәр» дип сокланып карыйлар. Гатифә генә Гатаулланы беренче күрүдә үк ошатмый. «Нәрсә таптың шул тәкәббер мактанчыктан! Ул бит үзеннән башка бер кешене күрми дә, белми дә»,— дип, ачыктан-ачык Заримага әйтә. Әкълимә кызларның сөйләшкәнен тыңлап-тыңлап тора да: «Миңа да ошап бетми ул,— дип, сүзгә кушыла. Зарима аларны көлемсерәп кенә тыңлый, ә ахырдан: «Кызлар, сез көнләшәсез бит. Карагыз аны, берегезгә дә бирмим мин аны!» — ди.

Әлбәттә, Әхмәт бу хәлне бик авыр кичерә. Дуслары аны башка кызлар белән таныштырырга тырышып карыйлар, ләкин егет теләми. Әкълимә дә шаярткан-көлгән булып искәргәли: имештер, Гатифә көне-төне аны гына уйлый. Гатифә үзе дә хисләрен яшерми. Үзе әйтмешли, «алтын куллы, ләкин бозылган тормозлы» бу егет аңа бик ошый икән. «Кулыма эләксә, ефәк кебек итәр идем мин аны», дип тә ычкындыргалый.

Әхмәт кызларның тел төбен яхшы аңласа да, бу турыда сөйләшүдән гел баш тарта. Сораша башласалар, «өйләнми торам әле хәзергә» дип кенә җавап кайтара. Аның күңелендә ни асраганлыгын беркем дә ачык белми.

Вакыт-вакыт Әхмәтнең йөрәгендә усал ачу кайный башлый. Эчеп килгән чакларында ул тешләрен шыгырдата, яңакларында төерләр уйный. Баштарак кызлар аңа куркыбрак карый, соңыннан игътибар итми башлыйлар. Аның Заримага янауларын исерек кешенең буш сүзе дип калдыралар.

* * *

Мин карлы Байтимер урамы буйлап атлыйм. Битләрне салкын чеметкәләп ала. Башымда буталчык уйлар өерелә. Мин — нәкъ юл югалткан аучы. Тик шулай да ниндидер бер сиземләү дөрес юлда син дип колагыма пышылдый, өметкә канат куя сыман. Мәрхүмә Зариманы, аның әнисен, якыннарын кызгану тойгысы күңелемне биләп алган. Үтерүчегә булган нәфрәт йөрәкне көйдерә.

«Кем икән ул җинаятьче? Кайда ул? Нигә Байтимерне сайлап алган?» Авыл Советы бусагасын атлап кергәндә күңелемдә шул сораулар кайный иде.

Беренче күргән кешем прокурор Саттаров булды. «Тегү фабрикасында аз гына тоткарланган идем, ул монда килеп тә җиткән,— дип, аның җитезлегеннән көнләшеп куйдым.— Күптән түгел генә аның кабинетында тикшерү юлларын уйлашып утырган идек бит, кай арада өлгергән диген!»

Ул өс-башын салып утырган. Янында ике милиция офицеры — безнең даими ярдәмчеләр һәм авыл Советы председателе. Саттаров мине күрү белән урыныннан сикереп торды.

— Киттек! Пунәтәйләр күптән көтә,— диде ул.

Күмәкләшеп авыл Советыннан чыктык.

* * *

Илле яшьләрдәге, оялчан кыяфәтле хатын,— Дәүләтшин Әхмәтнең әнисе иде ул,— башындагы шәлен төзәтеп алды, безгә сораулы карашын төбәде. Ял көнендә нишләп минем тынычлыгымны бозасыз әле, дигән сыман иде аның кыяфәте.

Саттаров тыйнак кына итеп исәнләште дә:

— Улыгыз кайда? — дип сорады.

— Өйдә,— дип, хуҗа хатын кулы белән күрше бүлмәгә күрсәтте.

Алдан килешенгәнчә, тентү эшенә прокурор җитәкчелек итә. Безгә билгеле: табуга караганда яшерү җиңелрәк. Чөнки яшерүче бер генә билгесезле мәсьәләне хәл итә: ул ничек эзләячәкләрен генә белми. Калганнары: тикшереләчәк, яшерелә торган әйберләр дә, әйбер яшереләсе урын да һәм башкалар да аңа билгеле. Бу хәл, һичшиксез, исәпкә алына. Саттаров сүз белән дә «разведка» ясаячак, тентүгә дә җитәкчелек итәчәк. Ә мин бары тик күзәтү белән генә шөгыльләнәчәк-

мен. Димәк, тентүчеләр дә, тентелүчеләр дә минем игътибар үзәгендә булачак. Читтән караганда күбрәк күренә.

Мин — күзәтүче. Шулай уйлаштык. Кем ялгышса да — прокурормы, шикле кешеме — сизми калмам.

Егет, безне күргәч:

— Вәлитов Гатаулла,— дип урыныннан торып басты. Ул купшы гына киенгән, үзен тыйнак тота. Аны чибәр дип әйтерлек: бөдрәләнеп торган коңгырт чәч, йөзе якты, сөйкемле. Сөзәк маңгае гына чибәрлеген бераз боза төшә кебек, усаллыгы да булырга тиеш.

Өйдә тагын икенче бер ир заты да бар иде. Прокурор үзенең кем булуын әйтсә дә, әлеге кеше аңа игътибар итмәде.

Мин аны баштанаяк карап чыктым. Агарган чырайлы, ниндидер газап кичергән кешегә охшый иде ул. Күз төпләре зәңгәрләнеп тора, тоныкс күзләре битараф карый. Үз яшенә караганда олырак күренә иде ул.

— Ә бу кем? — дип сорады прокурор Вәлитовтан.

— Дәүләтшин Әхмәт, шушы йортның хуҗасы,— дип җавап бирде Гатаулла.

— Ә сез нигә монда?

— Күршеләр без. Мунчага әйтергә кергән идем,— Вәлитов дусына үпкәле караш ташлап алды.— Ә ул бармаска итә. Шулай дигәч, Вәлитов акрын-акрын ишеккә табан чигенде.

— Чыгарга ярамый! Без тентүгә килдек,— диде прокурор, аны туктатып.

Вәлитов безгә гаҗәпле караш ташлады да Дәүләтшинга табан атлап куйды.

— Торып басарга кирәк! — диде Саттаров Дәүләтшинга кәефсез генә тавыш белән, планшеты өстендә бармакларын биетеп алды.— Киен!

Дәүләтшин Әхмәт иңбашларын җыерып куйды да торып басты. Әле беребезгә, әле икенчебезгә гаҗәпләнеп карый-карый, ашыкмый гына киенергә тотынды. Аның акрын, сүлпән хәрәкәтләре, битараф карашы, бөкрәя төшкән гәүдәсе — һәммәсе дә: «Телисез икән, киенәм, ләкин аннан ни файда?» дип әйтә сыман иде. Әнисе хәвефләнеп улына карады. Ләкин улының күзләре гүя бу аңлашылмаучылык кына дип әйтә иде.

Без дә Саттаров белән күзгә-күз карашып алдык: Дәүләтшинның битарафлыгы, акрын гына җыенуы ясалма түгел иде.

Саттаровның күңелендә ниндидер икеләнү булуын абайлап алдым. Аның тәвәккәллеге кимегән төсле иде. Ул бармакларын планшеты өстендә биетүдән туктап, аны учы белән сыйпый башлады.

Әйе, прокурор Саттаров безнең шикләрнең нигезле булуына икеләнә иде.

Аның алдында гаепсез кеше тора. Юк, ул моңа кадәр очраткан җинаятьчеләрнең берсенә дә охшамаган булса кирәк.

— Без тентү белән килдек,— дип кабатлады ул рәсми генә.

— Аңлашыла, гражданин прокурор. Кунакка түгелдер инде,— диде Дәүләтшин.

— Балта, капчык, бауларыгызны күрсәтегез,— дип, прокурор безне кызыксындырган әйберләрне санап китте.

Ана белән ул, гаҗәпләнеп, бер-беренә карашып алдылар.

— Нәрсәдән башлыйсыз? — дип сорады Әхмәт.

— Балтадан булсын әйдә.

— Әйдәгез! — Әхмәт алдан чыгып, өйгә кушып салынган лапас астындагы слесарьлык өстәле янына алып килде безне.— Өч балта да менә шушында.

— Аларны кайда саклыйсыз?

— Ничек кайда? Шушында.
— Шулай ачык көеме?
— Авылда кем нәрсәне бикләп тота?
— Күрсәтегез.

Әхмәт безнең алдыбызга өч балта китереп салды. Берсе кечкенә — столяр балтасы, икенчесе, үткене — зуррак, өченчесе — утын яра торган авыр, тупас балта. Прокурор, өстәл, әрҗәләрдә яткан, шүрлекләргә тезелгән коралларны җентекләп күздән кичерә-кичерә, йөренеп алды. Милиция хезмәткәрләре дә шуны ук эшләде.

— Капчыкларыгыз бармы?

— Ничек инде булмасын! — Дәүләтшин уң як почмакка өелгән әйберләр янына барып, аягы белән типкәли-типкәли, капчыкларны безгә таба этте.— Менә карагыз, бишәү.

— Тагын икесе базда, өчесе келәттә,— дип сүз кыстырды аның әнисе.

Капчыклар өстенә иелгән Саттаров кинәт турайды да башы белән ымлап мине чакырды. Аның йөзе кискен үзгәргән иде. Бармаклары тагын планшет өстендә биергә тотынды.

Әйе, капчыкларның бишесе дә Зариманың гәүдәсе салынган капчыкның ишләре иде. Шундый ук зур, житен капчыклар. Кесәдән метрлы тасма чыгарып, үлчәп карадым: иңе-буе да шул ук.

— Барын да китерегез! — Прокурорның дулкынланган тавышы таләпчән яңгырады.— Барлык капчыкларыгызны да!

Әнисе җәһәт кенә өйгә кереп китте, Әхмәт канәгатьсез төс белән келәткә таба атлады, култык астына кыстырып капчыклар алып килде. Әнисе дә Саттаров алдына тишек капчыклар китереп ташлады.

— Менә барын да алып чыктым.

Саттаров сүз белән «разведка» ясавында дәвам итте:

— Ничә капчыгыгыз бар?

— Унбер,— хатын борчулы күзләрен Саттаровтан алмый иде.— Тугызы яңа, икәүсе иске. Барысы унбер.

— Кайдан алдыгыз?

— Кайдан булсын? — дип кайтарып сорады Әхмәт.— Алабуга пристаненнан.

— Кайчан?

— Былтыр.

— Берәүсе кайда? Яңасы! Монда унау гына. Икесе иске, сигезе яңа.

— Кайда булсын?! Шушындадыр...— Дәүләтшин иелеп капчыкларны санарга кереште.— Шушында булмый кайда булсын...— һәм аның сүзе бүленеп калды. Тураеп, иңбашларын җыерып куйды, әле күптән түгел генә капчыклар яткан почмакка килде, әйберләрне ачу белән актара-туздыра башлады. Шунда түбәдән ниндидер авыр бер нәрсә килеп төште. Житез Саттаров аны шундук эләктереп тә алды. Бу тутыгып кызгылт төскә кергән иске балта иде. Прокурор аны күзенә якын ук китереп әйләндергәләргә тотынды. Аның битләренә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Мин дә, үз-үземне белешмәстән, аның янына барып бастым. Балтаның ак җепселләр һәм туң май катламы белән капланган булуын шунда гына күреп алдым.

Саттаров үзенең тойгыларын тыя белми иде. Күңелендә ни булса, телендә шул. Бу юлы да ул салкын канлы булып кала алмады.

— Нигә монысын әйтмәдең? Нигә яшереп яткырдың, эттән туган?! — дип кычкырып җибәрде ул, бөтен гәүдәсе белән Әхмәткә таба борылып.

Прокурорның кыяфәте бу минутта шундый тәвәккәл, шундый усал иде, Дәүләтшин я куркып качарга, я тезләнеп гафу үтенергә тиеш кебек иде. Ләкин Дәүләтшин урыныннан да кузгалмады, дөрес, бераз каушады каушавын, әмма селкенмәде дә. Ул, яклаучы эзләгән шикел-

лерәк, бик җитди төс белән миңа карап алды да гадәтенчә иңбашларын җыерып куйды:

— Кайчандыр хөкем ителгән булганмын икән, нигә әле шулай кычкырырга? — Бу сүзләрне ул тамак төбеннән, көч-хәл белән чыгарды.

Мин, тынычланырга кирәклеген аңлатып, Саттаровның беләген кыстым, ә колагына: «Ачу — дошман, акыл — дус»,— дип пышылдадым.

— Авызың кыек булса да, сүзең туры булсын,— диде Саттаров сабыр гына.— Дүртенче балтаңны нигә күрсәтмәдең?

— Нигә дип, ни... Иске балта бит ул, ташландык. Йөри шунда, аяк астында.

— Унберенче капчык кайда?

— Юк, тапмадым.

— Бер капчыгыбыз югалган,— дип, әнисе дә сүз кыстырды.

— Күршеләрегез алмадымы?

— Юк шикелле.

— Эзләгез,— дип боерды прокурор милиция офицерларына.— Бауны эзләгез. Нинди бау икәнен беләсез.— Аннары Дәүләтшинга таба борылды:— Нәрсә катып калдың? Бар, бауларыңны китер. Барын да! Балта шикелле яшереп калдырасы булма!

Шушы минутта җил капка шыгырдап ачылды һәм ихатага бер хатын килеп керде. Безне күргәч, туктап калды. Ул озын буйлы, өстенә иске модалы кара драп пальто кигән, башына соры мамык шәл бөркәнгән, аягында кара киез итек. Сөйкемле генә түгәрәк йөзе кызарып тора иде.

— Исәнмесез! — дип дәште ул йомшак кына итеп һәм, Саттаровны күргәч, тыйнак кына елмаеп исәнләште:— Исәнмесез, Рәүф Галиевич!

— Ә, иптәш Вәлитова! — дип, прокурор кул биреп күреште, сорау яудырырга кереште.— Нинди җил ташлады? Депутат эше беләнме?

— Улымны эзләп кергән идем,— дип, хатын стенага сөялеп торган Гатауллага табан ымлап күрсәтте.— Күрше генә без. Чәй эчәргә керегез.

— Рәхмәт, иптәш Вәлитова, бик рәхмәт,— диде прокурор һәм өстәп куйды:— Белеп булмый...

Хатын ары үтте, уйга калган Гатаулла янына килеп туктады:

— Нәрсә, дөньяңны оныттың? Мунча суына бит,— диде.

Тегесе гаепле төс белән баш какты, күзләре белән Саттаровка таба ымлады.

— Өлгерер әле, өлгерер, иптәш Вәлитова,— диде прокурор, узышлый гына, һәм тукталып тормастан, өйгә кереп китте.

Мин күзәтүемне дәвам иттерәм. Келәттән чыгып килүче Әхмәтнең йөзе тагын да агара төшкән. Үзе бер кочак баудыр, каештыр күтәргән. Гатаулла белән тыныч кына сөйләшеп торган Вәлитованы күргәч, Әхмәт туктады, җәһәт кенә як-ягына каранып алды. Беркемне дә күрмәгәч, кочагындагы бауны ташлап, ялт кына Вәлитова янына килде һәм аңа: «Бау эзлиләр!» — дип пышылдады. Үзе шунда ук читкә тайпылды.

Өйдән чыккан прокурорның калын тавышы яңгырады:

— Ну, нәрсә? Алып килдеңме?

Мин, сүнгән сигаретымны аяк астына ташлап, күзәтүемдә дәвам иттем. Вәлитованың йөзендә ниндидер әчке хисләр көрәше чагыла иде. Кыска бер мизгелдә аны биләп алган гаҗәпләнү, каушау, курку галәмәтләре прокурор тавышы ишетелү белән юкка чыкты. Ул баягыча итагатьле күрше хатын булып калды. Ләкин хәзер инде ул сүз таба алмый җәфалана иде.

— Сау булыгыз, Рәүф Галиевич...— диде хатын һәм бераз тотлыга төшеп:— Эштән соң рәхим итегез,— дип өстәде.

Прокурор, закон кушканча, тентү беткәнгә кадәр Вәлитованы җибәрмәскә уйлаган иде, мин башкаларга сиздермичә генә аны кисәтеп өлгердем: җибәрегез, китсен, дидем.

— Рәхмәт, сау булыгыз,— дип хушлашты Саттаров һәм миңа таба усал гына итеп күз ташлап алды.

Җинаять бик сирәк очракта гына тулысы белән күз алдында ярылып ята. Безнең һөнәр кешеләренә башлыча яшерелгән эзләр, күзгә чалынмастай хәлләр, әйберләр белән анализ һәм синтез юлы белән эш итәргә туры килә. Безнең эштәге берничә билгесезле мәсьәләләрне чишүгә шулар китерә, җинаятьнең очы шулар ярдәмендә табыла. Инде әлеге тентүгә килгәндә, гаҗәеп бер хәлгә тап булырмын дип кем уйлаган? Гаҗәеп хәл дигәнем — Әхмәт Дәүләтшин белән Тәзкирә Вәлитованың очрашуы. Ул бик аз вакыт эчендә генә булып алса да, моңа кадәр караңгыда торган нәрсәләрне яшен яктыртып җибәргән төсле булды. Бу хәлне очраклы табыш дип тә, кинәт ялтыраган бер психологик ачыш дип тә атап була.

Саттаровка ачуын тыеп калырга туры килде: урыны түгел. Ләкин аның усал күзләре мине ашардай булып ялтырый иде. Тәҗрибәмнән чыгып беләм, ун-унбиш минуттан соң Саттаров тынычланачак, ярсуы басылачак. Вакытын туры китереп, аны эш белән мавыктырырга кирәк. Мин аны баулар өеме янына чакырдым.

Ләкин Дәүләтшиннар йортында бауның дружиначы тапканга охшаганы юк иде. Мин беркетмә язарга утырдым, ә бераз сүрелә төшкәч, Саттаров телсез шаһитләр белән булашты. Тентү вакытында табылган балта, капчыкларны үзебез белән алырга кирәк иде.

Тентү бетеп килә. Ләкин Саттаровка болар гына аз булып күренде бугай. Күңелен тынычландыру өчен дипме, ул ирексездән шаһит булган Вәлитов Гатаулла белән дә сөйләшеп алды. Сөйләшкәннәреннән минем колагыма Гатаулла әйткән соңгы сүзләре генә кереп калды:

— Үзегез беләсез, Рәүф Галиевич, мин монда очраклы кеше. Мине катнаштырмагыз. Өйләнгән кеше мин...— диде ул.

## 6

«Мин монда очраклы кеше. Өйләнгән кеше». Гатаулла Вәлитовның бу сүзләре күңелдән һич китми. Ни генә эшләсәм, ни генә уйласам да, шул сүзләр кылт итеп искә килә дә төшә, килә дә төшә. Күз алдымда һаман шул бер күренеш: Дәүләтшинның Вәлитова янына килүе, колагына пышылдавы, Тәзкирә Вәлитованың күзләрендәге каушау, курку. Үземә ни булганын үзем дә аңламыйм.

Шик — Дәүләтшинда. Тентү нәтиҗәсе дә гел аны гаепле күрсәтә: балта, капчыклар табылды. Ә минем фикер икенче якка борыла. Колагымда һаман шул ук тавыш: «Мин өйләнгән кеше...»

— Әйе, Вәлитов өйләнгән, менә карагыз,— дип, авыл Советы секретаре минем алга загс кенәгәсен китереп салды.— Хатыны — фельдшер Рәйсә Нуркаева.

— Аны чакырырга буламы?
— Өйдә юк ул.
— Кайда?
— Ульяновскида. Укырга җибәрделәр аны.
— Күптәнме?
— Байтак була инде. Өйләнешеп бер атна торгач ук китте.

Мәсьәлә ачык кебек, ә мин, кемдер колагыма тәкърарлап торган шикелле, һаман эзләнәм, казынам. Ни өчен Дәүләтшин Вәлитовага бау турында пышылдады икән?

Кешене эш-хәрәкәткә өндәгән һәрнәрсә аның аңы аша үтә, ихтыярына тәэсир итә. Минем күрүемчә, Дәүләтшин моны уйлап эшләде. Ни өчен ул Вәлитовага әйтеп куярга булды икән? Димәк, болай эшләү кирәк дип уйлаган. Ә бу хәл нәрсә белгертә соң? Беренче версия: үтерүче ул үзе. Икенче версия: катнашы юк, җинаятьне белә. Өченче версия: үтермәгән, белми, ләкин сизенә. Ничек кенә булмасын, ачык җавап табарга кирәк. Ни өчен Вәлитовага әйтте ул? Аның да катнашы бар микән әллә? Булуы мөмкин. Тормышта мондый очраклар да булгалый. Логикага сыймас кебек күренгән хәлләр булмыймыни бу дөньяда? Бер-бер артлы туып торган сорауларга җавап табарга кирәк. Шик һаман Дәүләтшинга төшә.

Тыелып кала алмадым, Дәүләтшинга чакыру кәгазе җибәрдем. Ләкин үз-үземне кисәтеп куйдым: кара аны, бел, Гайнан, алдан ук билгеле бер фикердә торып эш итү — тикшерүче өчен иң куркыныч нәрсә. Нәтиҗәләрне ялгыш аңлауга китерүе мөмкин. Иң элек объектив булырга, һәр нәрсәне тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяли белергә кирәк!

Әхмәт Дәүләтшин белән сөйләшеп китүе әллә ни кыен булмады.

— Әйе, Гатаулла өйләнде,— диде ул минем соравыма каршы. Туенда үзем дә булдым.

— Вәлитов Гатаулланы яхшы беләсезме?

— Белмичә! Ике ыштансыз малай дигәндәй, бергә уйнап үстек...

— Ыштансыз ук булмагансыздыр инде...

— Нишләп булмасын!.. Әй, юк икән, гражданин следователь, Гатаулланың ыштансыз йөргәне булмады. Әтисе — командир, әнисе — доктор. Тәзкирә апа аны ыштансыз йөртәме соң! Энәдән-җептән чыкканны гына киеп йөрде. Шуның өчен бик үк өнәп тә бетермиләр иде үзен. Урамга купшыланып чыга иде. Ә малайларга шул гына кирәк тә: коры көнне тузанга аунаталар, яңгырлы көнне баштанаяк пычрак белән коендыралар иде.

— Яхшы киенгән өчен түгелдер инде?

— Түгелдер...

— Ни өчен яратмыйлар иде соң?

— Малай чакта, беркатлы чакта төрлесе була инде ул, гражданин следователь. Аткан ташың кеше чебиләренә, бәбкәләренә тия, таягың да песи, көчек башларына төшә. Юк кына нәрсә өчен дә ачуланышып та китәсең.

— Сез дәме?

— Мин — юк, гражданин следователь, мине юаш диләр иде.

— Әтәчләнгәне өчен Гатауллага эләгә идеме соң?

— Кайчакта ару гына эләгә иде, я авыз-борынын канаталар, я кычытканга утырталар, мин булмасам...

— Ничек инде ул «мин булмасам?»

— Яклый идем мин аны. Аның аркасында үземә дә эләккәли иде, әлбәттә.

— Әтәчләнгән өчен генәме?

— Аңа гына түгел инде.

— Ни өчен тагын?

— Ну, ничектер шулай килеп чыга иде: Гатаулла белсә-күрсә, малайларның бөтен шуклыгы, серләре ачыла да куя иде.

— Шуның өчен дә кыйныйлар идеме?

— Кыйнау түгел! Малайларның яратмаганнары — хыянәт.

— Сез шулай да яклый идегезме?

— Яклый идем.

— Гатаулланың үзен шулай тотуы ошый идемени?
— Юк та соң. Ничек булса да, Гатаулла күрше бит. Өстәвенә, мин аннан олырак та. Аның әнисен авылда яраталар иде. Әле дә шулай. Безнең ашау яклары такыр булды. Тәзкирә апа икмәген, сөтен биреп торды. Гатауллага күз-колак була күр, ди иде. Шуннан әтисенең үле хәбәре килде. Ятим малайны ничек кыерсытасың?..
— Димәк, сез дуслар?
— Дуслар, гражданин следователь...
— Туйга дуслары күп килдеме?
— Туган-тумачалары гына. Дусларыннан мин дә тагын Казаннан берәү.
— Ә Чулпан кызлары?
— Сез кемне күздә тотасыз, гражданин следователь? — Әхмәтнең тавышында сагаю, борчылу сизелеп калды. Кешенең эчке кичерешләре тышка чыкмый калмый, әлбәттә.
— Әйтик, Әкълимә, Зарима, Гатифә?
— Юк, алар булмады.
— Туй буласын беләләр идеме соң?
— Юктыр, белмәгәннәрдер...— диде Әхмәт, уйлана төшеп.
— Туйдан соң алар белән очраштыгызмы?
— Очраштык.
— Вәлитов тамы?
— Әйе.
Әхмәт Дәүләтшин дөресен сөйлиме, юкмы, мин моны белми идем. Минем урында Америка тикшерүчесе булса, лайдетекторын, ягъни ялганны ачыклау приборын, тоташтырыр иде дә һәртөрле юллар белән үзе теләгән күрсәтмәләрне сыгып чыгарырга тырышыр иде. Ә бездә закон андый нәрсәне рөхсәт итми. Минем коралым — гаделлек.
— Очрашканда туй турында сүз чыктымы? — дип, сорау алуны дәвам иттердем.
— Юк, сүз чыкмады.
— Вәлитов өйләнгәнлеген үзе әйтмәгәнме?
— Белмим, гражданин следователь.
— Зарима Вәлитовны ничек каршылый иде?
— Элеккечә. Үзгәреш-фәлән сизгәнем булмады.
— Кайчанга кадәр?
— Зарима югалганчы.
— Туйдан соң да Зарима белән очраша идеме ул?
— Зарима ачуланмасын, андый-мондый юләрлек эшләмәсен өчен, аны әкренләп әзерләргә кирәк, дип әйткән иде Гатаулла.
— Гатаулла үзенең мәхәббәт серләрен сезгә сөйли идеме?
— Кем көндәшенә йөрәген ачсын инде...
— Аңламыйм мин, Дәүләтшин: әле дуслар, әле көндәш...
— Вәлитов минем мәхәббәтемне урлагач, элекке дуслыклар бетте инде ул.
— Дошманлаштыгызмы?
— Дошманлашуын дошманлашмадык, тик дуслык та суынды.
— Вәлитов Рәйсә Нуркаевага өйләнгән бит.
— Өйләнсә соң. Барыбер бернәрсә дә үзгәрмәде. Хатыны Рәйсә укырга китеп барды. Ә Вәлитов Зарима белән очрашуын дәвам иттерде.
— Зариманы кем үтергән дип уйлыйсыз?
— Кем дип тә уйларга белмим.
Ничектер бөрешеп калган Дәүләтшин, озын керфекләрен сирәк-мирәк кенә каккалап, аска карап утыра. Күзләреннән менә-менә яшь сыгылып чыгар сыман.
— Вәлитов моңа ничек карый?

— Ул да кайгыра,— дип җавап бирде Әхмәт, авыр сулап.— Үзен кая куярга белми. Бик дуслар иде. Аптырый да безгә керә. Бүген дә кергән иде. Мунчага дәшәргә.
— Зарима белән ачуланыша идеме?
— Юк, гражданин следователь, ачуланышмый иде.
— Заримага янаганы булмадымы?
— Анысын белмим, гражданин следователь.
— Ә сезнең Заримага янаганыгыз булмадымы?
— Булды, гражданин следователь. Яшерә алмыйм.
— Ешмы?
— Бер генә тапкыр түгел...— Әхмәт гаепле күзләре белән миңа карады.
— Үтерәм дип тәме?
— Анысы да булды, гражданин следователь.
— Һәм тормышка да ашырдыгызмы?
Әхмәт урыныннан сикереп торды, күзләре зур булып ачылды, йөзе куркыныч кыяфәткә керде.
— Сез нәрсә, гражданин следователь! — Аның тавышы гына түгел, бөтен гәүдәсе калтырый иде.
— Утырыгыз,— дидем мин аңа тыныч кына.
Мин, әлбәттә, уйлаганымның барысын да әйтеп бетермәдем. Әхмәтнең теге вакытны Вәлитова янына килүе, аның колагына пышылдавы күз алдына килде. «Сайра инде, сайра»,— дип кычкырасы һәм барысын да берьюлы чыгарып саласы килә иде.
— Эчкечелек белән бит ул, гражданин следователь. Аңламыйсызмыни? Көнләшүдән...
— Ә үтерү кем эше?
— Белсәм иде мин аны?!.
«Артист! Гаепсез булып кылана»,— дип уйладым мин.
— Тентү вакытында Вәлитовага ни өчен бау әзләгәнне әйттегез?
Дәүләтшин сискәнеп китте. Бу сорауны көтмәгән иде ул. Гаҗәпләнеп миңа карады, әйтерсең җавап бирер алдыннан минем моны каян белүемне ачыклыйсы килә иде. Җавапның котылгысыз булуын аңлап, теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды:
— Аптыраганнан гына. Күрше бит, гражданин следователь. Бау эзләгәндә килеп керде бит.
Бу җавап мине ышандырмады да, канәгатьләндермәде дә, Дәүләтшинның Вәлитова колагына пышылдавыннан соң туган буталчык уйларга ачыклык кертми иде ул. Дәүләтшин тынычсыз күзләрен миннән алмый, тагы нинди сораулар бирелер икән дип көтә иде, күрәсең.
— Капчыкны ник әйтмәдегез?
— Андый капчыклар бездә генәмени, гражданин следователь...
— Ә бер капчык кайда булган?
Җавап урынына Дәүләтшин иңбашларын гына җыерды.
— Ә балта турында ни әйтерсез?
— Әйттем бит инде: аяк астында йөргән балта...
— Балтада нәрсә барлыгын беләсезме?
— Каян белим мин аны.
Экспертиза озак көттермәде. Тентү вакытында табылган әйберләр белән Казанга киткән милиция капитаны Сәмигуллин телефон аша болай диде:
— Биолог-экспертлар тутыккан иске балтаның йөзендә кеше тәне җепселләре, май күзәнәкләре булуын ачыкладылар. Хатын-кызныкы... Ләкин үлгән кешенеке, Гайнан Ибраһимович. Димәк, балта белән үтергәннән соң эш иткәннәр. Аллаярованың гәүдәсен тикшергән экспертлар мәетнең шушы балта шикелле тупас әйбер белән тураклануын әйтәләр.

— Аңлашылды. Капчыкларга экспертиза ясалдымы?
— Ясалды. Сәүдә институты галимнәре ярдәм итте. Капчыклар житмешенче елны, Казан житен комбинатында эшләнгән. Аллаярованың гәүдәсе салынган капчык һәм Дәүләтшиннарда табылган сигез капчык бер үк материалдан, бер үк төрле ысул белән, бер үк цехта, бер үк вакытта эшләнгән. Экспертизаның катгый нәтиҗәсе шундый, Гайнан Ибраһимович.
Менә «телсез шаһитләр» телгә килде. «Мәет балта белән чапкаланган». Дәүләтшиннарда ясалган тентү нәтиҗәсендә дүрт балта табылды. «Мәет тупас корал белән киселгән»,— ди телсез шаһит. Балталарның берсе чыннан да тупас, тутык. «Мәет үлгәннән соң кискәләнгән». Эксперт-биологлар иске балтаның йөзендә үлгән кешенең тән җепселләре, май күзәнәкләре булуын ачыкладылар.
Мәет белән бергә икенче телсез шаһит — житен капчык та табылды. Ул да телгә килде. Дәүләтшиннарда үткәрелгән тентү, сөйләшү-сорашу тагын бер ачыклык кертте: нәкъ шундый капчык юкка чыккан. Калган сигезе исә: «Без Аллаярова гәүдәсе салынган капчык белән бертуганнар»,— ди иде.
Шулай итеп, телсез шаһитләр Әхмәт Дәүләтшинга төртеп күрсәтә иде.

* * *

— Дәүләтшинны кулга алдыңмы? — каударланып килеп кергән Саттаровның беренче сүзе шул булды.
— Җибәрдем әлегә,— дидем кыюсыз гына.
— Нәрсә сөйлисең?! — дип кычкырып ук җибәрде ул аптыравыннан.— Ә мин, карт юләр, аны шатландырам дип киләм тагы. Приказ чыгарып мактауларын гына көтәсе калды бит. Республика прокуроры үзе мактады,— дип, бармагын югары күтәрде Саттаров.
— Ничек республика прокуроры?..— дип сорадым мин, гаҗәпләнеп. Җинаять ачылган, Дәүләтшин фаш ителгән икән, мин моны яшереп тора алмыйм бит инде.
— Ничек инде ул, Рәүф Галиевич?
— Мин Казан белән сөйләштем, әйттем.
— Җинаять бит ачылмаган әле.
— Син, дустым, акыл сатма, мине шаяртма. Казанда хупладылар.
— Рәүф Галиевич, мин бит чынлап әйтәм.
— Менә мин дә синең белән чынлап сөйләшәм бит,— дип башлады ул үз дәрәҗәсен белә торган олы кеше тоны белән һәм бармакларын планшеты өстендә биетеп алды.— Күп акыл сату кирәкми...
— Акыл сату дип нәрсәне әйтәсез, Рәүф Галиевич?
— Тентү вакытында Тәзкирә Вәлитованы җибәреп, башбаштаклык эшләдеңме? Эшләдең. Бу — бер.— Саттаров үз сүзләрен раслап планшетына сугып куйды.— Шул ук тентү вакытында дүртенче балтаны яшергән Дәүләтшинны якладыңмы? Бу — ике. Дәүләтшинны башта ук кулга алып, тиешенчә сорамадың. Бу — өч. Бер тәүлек үтеп бара инде, ә җинаятьче әле һаман иректә. Бусы — дүрт. Акбүләктә теләсә ничек эш итәргә өйрәнгәнсең, күрәсең. Үземнең районда мин моңа юл куймам. Мин сиңа Мөхәммәтшин түгел, кадерлем. Җинаятьченең урыны төрмәдә.
— Нинди җинаятьче турында сөйлисез сез?
— Белмәмешкә салышма, Гайнан,— дип дәвам итте ачулы прокурор.— Кем Аллаяровага үтерәм дип янаган? Дәүләтшин. Үзеңнең яраткан соравыңны бирик: аның үлүе кемгә кирәк булган? Дәүләтшинга. Мәет нәрсәгә салынган иде? Җитен капчыкка. Мондый капчыклар

кемдә бар? Дәүләтшиннарда. Мәет нәрсә белән кискәләнгән? Үтмәс балта белән. Андый балта кемдә табылды? Дәүләтшиннарда. Өстәвенә, балта йөзендәге нәрсәләр? Болар җитмиме әллә сиңа?

— Гаепсезлек презумпциясе дигән нәрсәне сез яхшы белергә тиеш. Закон көченә кергән хөкем карары булмый торып, кешегә «син — җинаятьче!» дип төртеп күрсәтергә минем дә, прокурорның да хакы юк.

— Ташла шул теорияләреңне! Монда университет түгел! Уйлап кара: Дәүләтшин — эчкече, элек хөкем ителгән. Дустының яңагын җимергән кешедән хатын-кыз нәрсә көтә ала?

— Иптәш прокурор, теорияне бутамагыз. Мин кабатлап әйтәм — аны җинаятьче дип санарга әлегә тулы ышанычым юк.

— Тагы нинди шик булырга мөмкин монда?

— Дәүләтшин тентүне тыныч кына кичерде. Капчыклар да кул астында гына, балта да чүп арасында. Җинаятьче булса, мондый дәлилләрне шул кадәр озак саклар иде микән ул? Болар мине шикләндерә. Дәүләтшиннарда бау да табылмады.

— Ташла әле, Гайнан, психологик тәҗрибәләреңне. Бер җинаять икенчесенең күчермәсе булмаган шикелле, җинаятьчеләр дә бер-берсенә охшамый. Соңыннан хатаңны үзең дә аңларсың. Вакыт көтми. Җинаятьченең иректә йөрүенә түзеп тора алмыйм. Аннан соң, кулга алган өчен син түгел, мин җавап бирәм. Хәзер үк карар әзерлә!..

— Юк, кешенең гаепле икәнен исбатламый торып, мин моны эшли алмыйм...

— Курыксаң, документны минем исемнән әзерлә.

Әгәр Саттаров мин студент чагында нинди трагедия кичергәнне, урлашуда гаепләнеп, ниләр күргәнемне күз алдына китерә алса, бәлки мондый сүзләрне әйтмәс тә иде. Саттаровка хәзер бу турыда сөйләп торып булмый бит инде. Мөхәммәтшин булса, башка эш. Ул шундук аңлар иде. Шуның өчен мин Саттаровка үзе минем белән сөйләшкән тондарак җавап бирдем:

— Сез мине аңларга теләмисез, сабырсызлыкка өндисез бит. Сабырсызның эше — тамырсыз, диләр.

— Язма резолюция салам, үтәми кара,— дип янарга ук кереште ул.

— Мин, ул резолюцияне законсыз дип, югары инстанциягә мөрәҗәгать итәчәкмен. Кирәк булса, Генеральный прокурорга кадәр...

— Шул гына җитмәгән тагын! Мин монда эш өчен, район өчен янам бит! Безгә тапшырылган эш турында сүз бара бит.

— Мин алай агым уңаена гына агарга күнекмәгәнмен.

— Ни телисең соң син?

— Хакыйкатьне табарга кирәк.

— Хакыйкать синең алдыңда,— дип ачу белән планшетына шапылдатып сукты ул.— Пешкән алма кебек авызыңа төшәргә тора. Дәүләтшинның ни өчен тентү вакытында үзен тыныч тотуы, капчыкларның, балталарның ни өчен аяк астында ятуы турында уйлап карадыңмы? Артист ул Дәүләтшин. Елан аягын кискән кеше ул. Тентүне дә көтеп торган, буласын белеп, әзерләнеп торган. Үзен ничек тоту турында алдан уйлап куйган. Балтасын, капчыгын да юри аяк астына ташлаган. Ни өченме? Синең кебек беркатлыларны эздән яздыру өчен. Имештер, гаепле кеше дәлилләрне өендә сакламас.

— Рәүф Галиевич, мин барыбер үз фикеремдә калам.

— Ә кем гаепле соң, синеңчә?

— Бәлки улдыр, ләкин дәлилләр җитәрлек түгел әле...

— Нишләп җитмәсен! Сиңа тик бер генә нәрсә җитми. Ул да булса — кыюлык.

— Сез әйткән дәлилләр белән генә мәсьәлә ачыкланып бетми. Бау да табылмады әле.

— Университет кафедрасы түгел бу, иптәш Ибраһимов, тормыш бу! Лес рубят, щепки летят,— дип, рус мәкален кыстырып куйды һәм: — Анларга кирәк! — дип үгетләргә кереште.— Исеңдә тот, кадерлем, минем белән шаярырга ярамый. Яхшыга карата — яхшы, яманга — яман мин. Дәүләтшин кебек әчкече аркасында чәкәләшүнең кирәге юк.

— Сез әйткәнчә эшли алмыйм мин. Беләсегез килсә, теория дә, намус та, интуиция дә, хәзерге замандагы җинаять эшен тикшерү практикасы да андый ашыгыч карар кабул итүгә каршы...

Безнең бу сөйләшү күңелсез килеп чыкты. Саттаровның хуплавы, җылы сүзе канатландырып җибәрер иде. Күңелсез уйларга бирелеп, тәрәзә янына килдем. Каршымда — мәктәп ихатасы. Бер төркем малай кар бабай ясыйлар. Тик уен күпкә бармады. Кыңгырау шалтырау белән ихата бушап, тынып калды. Миңа да үз уйларыма кире кайтырга туры килде. Ә алар — йөзләгән. Саттаров белән иркенләп уйланып-сөйләшеп тә булмады, ичмаса.

Прокурорның соравын яңадан ишеткәндәй булам: Дәүләтшин түгел икән, кем үтергән? Уйларым яңадан тентү вакытына әйләнеп кайта. Дәүләтшиннарның тынычлыгы гаҗәпләнмәслек түгел. Борчылуның эсәре дә юк иде. Вәлитова кергәнгә кадәр шулай булды. Эзләгән нәрсәләрнең һәммәсе аяк астында ята диярлек. Һәм кинәт үзгәреш: Әхмәтнең Вәлитова янына килүе, тегесенең күзләрендәге курку, каушау. Моның сәбәбе нәрсә соң? Табышмак дисәң дә табышмак. Тентү катыйдәләрен бозып, ни өчен аны ихатадан чыгарып җибәрдем әле. Белгән кеше дә түгел. Әмма фамилиясе таныш. «Вәлитова». Кайда очраткан идем әле бу фамилияне? Ә-ә... Чулпанда, больницада. Зарима Аллаярованың архивтан алынган авыру тарихын актарганда! Хәтер төпкеленнән тикшерүнең алдагы көннәрендә күргәннәр калкып чыкты. Чигәләрне кечкенә чүкечләр белән төйгән шикелле. «Вәлитова», менә ул серле Вәлитова... Бу табышмакны нигә дип әле шул вакытта ук чишеп карамадым? Артыннан ук тентү белән бармадым? Аннан бирле инде әлләниләр булуы мөмкин. Их, бу вакыт дигәнең!

— Телефонга! — Уйларымны Саттаровның тавышы бүлде.

Бу — Саттаровның үзсүзлелеге иде.

— Иртәгә үк кайтып җит! — диде телефоннан республика прокуратурасының тикшерү бүлеге начальнигы. Тавышы борчулы иде.

— Юк, Ислам Садриевич, булмый. Берничә көн түзегез инде.

— Сәбәбе?

— Кешеләр чакырылган.

— Аларны яңадан чакырырлар.

— Эш бик мөһим! Саттаровның капризлары артыннан йөрергә вакытым юк,— дип кырт кистем.— Тикшерүгә аяк чала ул, мин республика прокурорына мөрәҗәгать итәчәкмен. Ә хәзергә миңа вакыт кирәк, аннары эш узган булуы мөмкин. Шуны аңлагыз.

Трубка беразга тынып торды.

— Ярый, кызма! — дигән тавыш ишетелде аннары. Бу тавыш каткый һәм салкын иде, армиядә командалар гына шундый тавыш белән бирелә.— Төгәл ике көн сиңа! Эшеңне бетереп кайт! Кемгә, ничек мөрәҗәгать итү турында да сөйләшербез.

## 7

Танышларыбыздан берәрсе нәрсәгә булса да кирәгеннән артык нык ышанса, без, үзебез дә сизмәстән, аның ялгышуын телибез. Тик тормыш күп очракта синең теләкләрең белән исәпләшми. Прокурор Саттаров та үзен хаклы дип саный, ә мин аның уйлары хата булуын тели идем. Чөнки мин хакыйкатьнең үзем уйлаганча ачыласына шикләнми идем. Әмма ул уйлаганча да, мин теләгәнчә дә булып чыкмады.

Прокурор Саттаровның басым ясавы «дәлилләрдән чыгып гаепне танырга» дигән схемага корылган иде. Бу схеманы яклаучылар җинаять тикшерүчеләр һәм башка юристлар арасында гына түгел, танылган галимнәр арасында да шактый очрый. Имештер, «телсез шаһитләр» серне ача икән, эшне сузма. Ягъни, менә сиңа капчык, балта, экспертиза нәтиҗәсе, ә син Әхмәт Дәүләтшиннан үз гаебен таныт. Мин шушы юлга баскан да шикелле идем инде. Әхмәтне чакырып сорау да алдым. Тик «дәлилләр сине гаепле итеп күрсәтә, гаебеңне таны» дигән сүзләрне генә ычкындырмадым. Сорау алу, Саттаров көткәнчә, чишелешкә китерә торган соңгы юл булмады, сүз белән разведка ясау гына иде.

Шулай да мин Дәүләтшинны кулга алу өчен санкция сорап прокурорга бармадым. Саттаров хаклы да кебек, аны яклаучылар да бар. Хисләр интуициясе дә, логик интуиция дә җинаятьченең Дәүләтшин булуын әйтә. Тик икенче бер интуиция — акыл интуициясе каршы төшә. «Барысы да бик гади килеп чыга бит,— ди ул.— Җинаятьтән соң байтак вакыт үткән булса да, «телсез шаһитләр» кул астында гына яткан». Дәүләтшин үтергән булса, аларны ераграк җыештырган булыр иде. Ә бит башка дәлилләр үтерүченең тәҗрибәле булуын сөйли. Мәетне, аның киемнәрен, җинаятькә шаһит булырдай башка дәлилләрне шулай оста яшергән кеше үз өендә яткан дәлилләргә игътибарсыз карар микән? Фаш ителүдән котылу өчен ни генә эшләми ул җинаятьче! Ә Дәүләтшинда бу нәрсә сизелми. Нигә алай? Бу сораулар миңа җиде кат үлчә, бер кат кис дигән мәкальне искә төшереп тора иде. Бәлки җинаятьче башка кешедер.

«Бәлки» дип икенче версия кору тикшерүченең эшен катлауландыра гына төшсә дә, аны да исәпкә алмыйча булмый. Чөнки сүз кеше язмышы турында бара.

Куркү — тикшерүче өчен начар юлдаш. Моны яхшы беләм. Шиген бар икән, курыкма, тикшер. Тентү вакытында Дәүләтшин белән Тәзкирә Вәлитованы күзәтү бу фикерне тагын куәтли төште. Күңелдә шик туды. Шуның аркасында тикшерүдә, эзләнүдә икенче юнәлеш барлыкка килде.

Шикләнү әле чынында да шулай булган дигән сүз түгел. Ул алдынартыңны уйламыйча көч, энергия түгәргә, шул юнәлештә эш итәргә нигез булып бетә алмый. Әмма ул уйларга азык бирә, яңадан-яңа версияләр эзләргә этәргеч була.

Һәм шулай булып чыкты да.

## 8

Кыюсыз гына ишек кагучының ул икәнлеген мин шундук аңлап алдым. Тәзкирә Вәлитова бусага төбендә туктап, калтыранган тавыш белән әкрен генә сорап куйды:

— Сез чакырдыгызмы?

Мин игътибар белән аңа карадым. Хатын бик борчулы иде. Тентү вакытында күргәннән соң бер төн эчендә шактый үзгәргән иде ул: өстенә дә аннан-моннан гына киенгән. Битендәге җыерчыклар да арта төшкән кебек.

Ул, күзен дә күтәрмичә, ни үле, ни тере дигәндәй басып тора. Мондый хәлдәге кеше белән ачыктан-ачык сөйләшеп булмый.

— Әйе, чакырдым,— дидем мин тыныч кына.

Ул шикле күзләрен күтәреп миңа сынап карады, әмма чыраемда үзен борчырлык нәрсә тапмады булса кирәк — акрынлап тынычлана төште.

Сүзне аның өчен күңеллерәк темадан башладым:

— Прокурор Саттаров чакыруыгыз өчен рәхмәт әйтте, сәлам җиткерергә кушты,— дидем, ләкин уемда башка сүзләр иде. Аларны әлегә әйтергә ярамый.

— Ул сезне бик мактап сөйләде. Авыл Советы депутаты булгансыз икән. Яхшы кеше, актив җәмәгатьче диде.

— Алай ук түгел лә инде түгелен,— дип каршы төште Вәлитова.— Рәүф Галиевич сөйләр инде ул...

Хатын куркуыннан беркадәр арынды кебек. Йөзенә җиңелчә кызыллык йөгерде, сизүемчә, күңеленә өмет очкыны кабынды булса кирәк. Димәк, Вәлитова белән «эшлекле мөнәсәбәт» урнаштыру өчен басма сала башларга вакыт. Турыдан ярырга яраткан Саттаров биредә булса, ак перчатка киеп эшлисең, дип мине битәрләми калмас иде.

— Чыннан да, сезнең турыда яхшы сүз генә сөйлиләр,— дип әйткән сүземне куәтләдем мин.

— Ярый инде, алай булса,— дип килешкәндәй итте Вәлитова һәм миңа житди карашын төбәп, үзе сорау бирде:— Ә нәрсә бар соң, иптәш Ибраһимов?

— Без, иптәш Вәлитова, сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Җинаять бик житди.

— Ишеттем. Ишетмимме соң! Авыл халкы китереп ташлаганнар, имеш, дип сөйли.

— Мин башкачарак уйлыйм.

— Каян чыга шундый явызлык, ә! — диде Вәлитова, тагын миңа карап алды.

— Билгеле, тормыштан,— дидем мин аның сүзләрен игътибарсыз калдырмас өчен.— Кеше акрынлап бозыла, иң элек вак-төяктән башлана. Башта ярамаган кечкенә эшләрне эшли, аннары бу нәрсә гадәткә әйләнеп китә. Иң ахырдан инде җинаятькә барып житә...

— Әгәр белгән булсаммы! — дип кинәт ычкындырды Вәлитова.

— Нишләр идегез?

Мине үзеннән нидер яшерә дип шикләнеп булса кирәк, Вәлитованың кыяфәте шундук үзгәреп китте. Йөзендә бик кызганыч булып тирән хәсрәт, ачы газап галәмәтләре чагылды.

— Менә шушы кулларым белән!..— дип йодрыкларын төйнәп тезенә сукты.

— Аңламыйм сезне, гомер буе кешеләрне авырудан, үлемнән коткаргансыз...

— Яхшы белән яманны без дә аера беләбез, иптәш Ибраһимов.

— Монда бит сүз кешенең яшәве яки үлүе турында бара. Менә яшь кенә бер кызның гомерен кискәннәр, ә җинаятьче сезнең арада йөри.

— Безнең арада?

— Әйе, сезнең арада.

— Иптәш Ибраһимов, гафу итегез...— дип, өзек-өзек сөйли башлады Вәлитова.— Үзегез ярдәм дисез, үзегез миннән нидер яшерәсез...

Бу минутны мин көткән идем. Күп тапкыр ышанганым бар инде: кеше күренеп, аңлашып торган куркынычка караганда, билгесезлекне авыррак кичерә. Ул нәрсәдән сакланырга, нәрсәдән сакланмаска кирәген белмәсә, гадәттә иң начарын күздә тота. Әгәр хәл билгеле булса, кеше шуңа каршы тору яки яраклашу юлларын эзли.

— Ярый, хәзер белерсез,— дидем мин, алдан ук килешеп куелганча, чакыра торган сигнал төймәсенә бастым.

Бүлмәгә чал чәчле, бөкрәя төшкән хатын килеп керде, өстәл янында туктап, башта дикъкать белән миңа, аннары хәрәкәтсез утырган Вәлитовага текәлде.

— Тәзкирә җаным! Син түгелме соң бу?! — дип елап ук җибәрде ул.

— Бибинур! — дип, Вәлитова да аны кочаклап алды.— Син каян килеп чыктың? — дип кинәт сорап куйды ул. Ниндидер озак ачылмаган зур сернең очына төшә башлаган кеше кебек була башлады.

— Котлы Ярдан,— диде Аллаярова, күз яшьләрен сөртә-сөртә.— Тәзкирә җаным, бәла йөртә.— Аның күзләреннән тагы яшь тәгәри башлады.— Кызымны һәлак иттеләр бит, Тәзкирә җаным!..

— Кайсы кызыңны? — Вәлитованың гаҗәпләнүдән күзләре зур булып ачылды.

— Кечесен... Зариманы...

— За-ри-ма-ан-ы?..

— Әйе. Харап иттеләр балакаемны... Чулпан больнисында яткан идек бит, исеңдәдер, яныбыздан китмәдең, үзең терелттең... Исеңдәме, Тәзкирә җаным?

— Бүгенгедәй хәтеремдә, Бибинур, ә унсигез ел үткән дә киткән...

— Менә, кара,— дип, Аллаярова ашыга-ашыга җитез генә төенчеген чиште һәм аннан бер төргәк кәгазь чыгарды. Алар арасында мактау кәгазьләре, фоторәсемнәр, төрле-төрле документлар бар иде.

— Менә ул, балакаем,— дип, Аллаярова, алдан сөйләшкәнчә, Вәлитовага кызының фоторәсемнәрен сузды.— Харап кына иттеләр бит каһәр суккырлары!.. Ләгънәт кенә төшсен!

Минем бөтен игътибарым Вәлитовада. Кызның рәсемнәрен күрү белән ул кинәт үзгәреп китте, шомлы гына тирә-ягына каранып алды, бер фоторәсемне ике кулы белән тотты да, шуңа текәлеп, таш сыман катып калды. Урындыктан калкына төшеп, аның кулындагы рәсемгә күз салдым. Бу парлашып төшкән фоторәсем иде: берсе — Әхмәт Дәүләтшин, икенчесе — Гатаулла Вәлитов.

— Зариманың дуслары, Тәзкирә җаным,— диде Аллаярова һәм Гатауллага бармагы белән төртә-төртә өстәп куйды:— Монысы йөргән егете булган, диләр.

Бибинур апа бу минутта үзенең кызыннан башка берни дә уйламый иде. Тудырган, күкрәк сөтен имезеп, бәла-казалардан саклап үстергән йөрәк парәсенең вәхшиләрчә үтереп ташлануы дөнья гамьнәрен күңеленнән кысрыклап чыгарган иде. Мондый йөрәк газабын, күз алдымда басып торган мондый кара кайгыны минем әле беркайчан да күргәнем юк иде.

Тәзкирә Вәлитова, хәсрәт тулы күзләрен бер ноктага төбәгән килеш, сүзсез-өнсез утыра бирде. Бу минутта аның өчен тикшерүче дә, үтерелгән кызның әнисе дә юк иде.

Хатирәләр аны Дәүләтшиннарда тенту үткәрелгән көнгә кайтарды.

* * *

...Дәүләтшиннардан чыгу белән Тәзкирә Вәлитова өенә йөгереп кайта. Аның күңелен курку баса. «Гатаулла түгелме? Юк, булмас, булмас!» ди. Ләкин куркудан тыны бетә, чырайлары агарып китә. «Гатаулла! Балакаем! — Ниләр генә күрергә язган, нәрсәләр булыр икән? Ай, улкаем!..» — дип, йөрәге өзгәләнә.

Ананың үз баласын, бердәнбер улын саклау инстинкты шул ук вакытта бәладән арыну юлын да эзли. Куркудан, каушаудан томаланган акыл инстинктка урын бирә. Ана үз-үзенә урын таба алмыйча ары сугыла, бире сугыла. «Бау эзлиләр, бау эзлиләр...» дип кабатлый ул Дәүләтшиннан ишеткән сүзләрне. «Бау эзлиләр!» Хатын мич артындагы әрҗәгә тутырылган әйберләрне актарып ташлый, шундагы бер кочак бауны тиз генә күтәреп ала да ишеккә ташлана. Ишекнең ачык

булуын күреп, калтыранып китә. Кемдер күзәтә шикелле тоела аңа. Ә колагында һаман Әхмәтнең борчылулы сүзләре: «Бау эзлиләр!»

Хатын мунчага йөгереп килә. Мунча эче кызу, тын алырлык түгел. Тәзкирә кочагындагы бауларны көйрәп яткан утлы күмер өстенә ыргыта. Шундук аларны ялкын ялмап ала...

Кире өенә кайткач, тәрәзә пәрдәләрен төшереп куя. Өй эче караңгыланып кала. Караңгылык белән бергә тынычлык та килгән шикелле була. Тирән сулап, ул шәлен, пальтосын салып ташлый, хәле бетеп, урындыкка утыра. Караса, башындагы яулыгы, өстендәге күлмәге сыгып алырлык манма су булган.

Шәлен карават аркасына ташлыйм дип борылгач, иренең стенадагы рәсеменә күзе төшә. Офицер киеме кигән иренең кара күзләре һәр вакыттагыча тыныч, ләкин ничектер үтә җитди, сынап карый кебек тоела. Ана дерт итеп китә, Әхмәт әйткән сүзне тагын ишеткәндәй була. Нәрсә булыр бу? Саттаров нигә шулай шикле итеп карады аңа? Күптән белә бит ул аны, югыйсә. Нинди бау кирәк аларга? Гатауллаһың ни катнашы бар анда? Әхмәт нигә дип бу турыда аңа әйтә? Җитмәсә, ишеттереп. Нинди сер бу? Бәлки... Әхмәт эчкечелеге белән берәр юньсезлек эшләгәндер, күршесеннән ярдәм көтәдер? Бәлки... Гатаулла белән?.. Нинди баулар ул? Янды инде баулар, барысы да янып бетте.

Баулар янды януын, ләкин...

* * *

Ләкин янмаган нәрсәләр күрде бит әле ул. Фоторәсемнәр. Гатауллаларның рәсеме Бибинур Аллаяровада! «Зариманың йөргәне».

Тәзкирә Вәлитованың күңелен икенче хатирәләр, башыннан үткән истәлекләр биләп алды.

...Август аеның кояшлы бер көне. Ана улы Гатаулла белән бакчада, чия куаклары күләгәсендә утыралар. Тирә-якта бал кортлары безелдәшә. Урамда, койма артында, бала-чага чыр-чу килә.

— Үзең белеп торасың, Гатаулла, гомеремнең күп өлеше синең күз алдыңда үтте,— дип башлады ул җитди сөйләшүне.— Син туганга хәтле ни булганын да сөйләгәнем бар. Башта укыдым, аннары Чулпанда район больницасында фельдшер булып эшләдем. Әтиең белән тора гына башладык — сугыш чыкты. Син ул фронтка киткәч тудың. Әтиеңнең үле хәбәре килгәч, ачлыктан куркып, яшәргә җиңелрәк булыр дип, Байтимергә күчтем. Хәзер менә пенсиягә чыктым инде. Машина шикелле, кешеләр дә туза. Табигать кеше өчен запас әгъзалар әзерләп куймаган шул. Кеше үзе китә, эше кала. Ярый әле, эшемне яраттым. Сиңа әйтергә була инде: шул фельдшер, депутат булудан башка берни дә эшли белми бит әниең. Хәтта ял итә дә белмәде. Бар шатлыгым — эш тә син булдың...

— Беләм, әни,— диде Гатаулла ягымлы гына,— барын да беләм.

— Бит синең өчен борчылам, улым, уйлап кара.

— Минем иртә өйләнәсем килми.

— Сиңа егерме биш яшь инде, аз түгел.

— Эш яшьтә генә түгел бит әле.

— Шулаен шулай да, улым. Булыр адәм ун яшеннән баш булыр, булмас адәм кырыкка җитсә дә яшь булыр, димәсләр иде. Мин әтиеңне соңыннан ярата башладым. Башка кешегә чыккан булсам, аерылышыр идек, мөгаен.

— Әтине яратуың очраклы гына булдымыни?

— Юк, нишләп алай булсын. Ләкин чыгуым очраклы булды. Матурлыкка матур иде, көчле иде. Тик ул чакта әле бәхетнең дә, яратуның

да ни икәнен аңламаган булганмын. Соңыннан бер-беребезгә күнеккәч, син туар алдыннан гына яратуымны аңладым. Син тугач инде бигрәк тә... Үзем дә яңадан туган кебек булдым... Нишләп өйләнмисең соң?

— Әллә, бу турыда уйлаганым юк.

— Гомер уза бит, улым, аны кире кайтарып булмый. Дөньяда бер генә тапкыр яшибез. Кешегә шатлык та кирәк. Тормыш кеше белән матур.

— Институтны бетерим инде.

— Өйләнгән кешене кем укудан тыя?

— Тыймыйлар да соң.

— Мин үлеп китсәм...

— Юкны сөйләмә, әни!..

— Тормыш бу. Барын да күтәргә була. Бәла агач башыннан йөрми, һәммәбезнең дә башыннан йөри. Бәла килгәндә ялгыз булудан да кыены юк. Сау чагымда оныкларымны да күрәсе килә... Йөрәгем сау түгел бит...

— Бераз сабыр итик инде, әни.

— Күздә тоткан кызың бармы әллә?

— Юк, әни. Булса әйтер идем.— Гатаулла, кызарып, башын түбән иде.

Ана кеше улының тормышка, кешеләргә җиңел карарга гадәтләнеп китүен белми иде, әлбәттә. Зарима белән танышканнарына байтак. Шулай булгач, ике арада булган соңгы хәлләрне очраклылыкка гына кайтарып калдыру мөмкин иде микән? Гатаулла уртага бөгелеп әнисе каршында утыра, аның өйлән дигән сүзен кире кагып баш чайкый. Ярты еллап дәвам иткән мәхәббәтен шулай ук күңеленнән чыгарып ташларга уйлый микәнни?

— Кара аны, кызлардан яшь түктерәсе булма! Алар да синең кебек үк кеше. Алар да бәхет көтә, гаилә корып, кешечә яшәргә телиләр,— дип кисәтте аны әнисе.

— Юк, әни, миңа ышанмыйсыңмы әллә син?

— Бернинди күз яше, бернинди алдау булмасын! Ишетсен колагың!

— Әни, нигә шулай каты бәреләсең әле?

— Минем урынга килгән кызны димләргә исәп сиңа.

— Мин аны белмим дә бит.

— Белерсең, таныштырырмын. Кыз менә дигән. Төсе-бите дисеңме, буе-сыны дисеңме — бер генә дә килмәгән җире юк. Белеп тор: яхшы белән юлдаш булсаң — юлың уңар дигәннәр... Тик үзең карга булма.

Гатаулла Рәйсә Нуркаевага әнә шулай өйләнде.

* * *

Ана сагышлы күзләре белән иренең рәсеменә күтәрелеп карады. Ичмаса, янында ирең булсын иде! Сугыш, сугыш! Кеше башына нинди генә бәла-каза, кайгы-хәсрәтләр китермәде бу сугыш! Нишләп Вәлитовны үтердең син, сугыш? Ни өчен Тәзкирә ялгыз? Нишләп аның Гатаулласы әтисез үсте? Ананың уйлары буталчык, чуалчык иде. Кинәт ул бөтен тәнендә хәлсезлек-арыганлык сизә, башында кайнашкан бер генә сорауга да җентекле туктала алмый. Авыраеп калган аякларын көчкә өстерәп, шкаф янына килә, валерианка белән йокы даруы ала да, стаканга су салып, бер-бер артлы эчеп җибәрә...

Вакыт тукталып калгандай була.

Салкын тиргә баткан ана төн буе ыңгырашып-саташып чыга.

Ниһаять, ул авыр күз кабакларын ача. Өй эченә ниндидер сагышлы моң тулган. Бу иртә аңа кичәге кичнең дәвамы гына булып тоела.

«Гатаулла кайтты микән?» — дип, хатын күрше бүлмәгә чыга.

Улы үз караватында йоклый. Юрганын иягенә кадәр үк тартып куйган. Ана улы өстенә иелә, карашларын аның йөзенә төби. Күзләрендә сөю, соклану. Гатаулла тын гына йоклый кебек, ләкин йөзендә әниләр генә сизәрлек яшерен борчылу эзләре бар. Ана кеше улыннан күзен дә алмый. Әле яңа гына сабый иде бит ул. Күкрәк сөтен имезеп үстерде, җил-яңгыр тидермәде, үз авызыннан өзеп, аңа бирде, барысы да улына гына булды. Хәзер инде Гатаулла буй җиткән, ир кеше булган. И бала, бала! Тәзкирә, авыр сулап, яңагын стенага тери, сиздермичә генә саркылган күз яшьләре тирәнәеп калган җыерчыклар буйлап агып төшә. Кызганыч иде ул бу вакытта. Аның бөтен гомере, күңелендә булган бөтен тойгылары бары бер нәрсәгә — ана хисенә әверелгән, шуңа буйсынган иде. Үзенең кайнар мәхәббәте белән, көндәлек хезмәте белән ул бердәнбер баласын үз канат астында тотарга теләде. Армиягә алмасыннар дип, бүсеренә дә вакытында операция ясатмады. Авырлык белән булса да, әлегә кадәр Гатаулланы ул үз янында тотып килде. Ә хәзер ни көтә аның газиз баласын?.. Күңелендәге ярату, кызгану, ачы сагыш тойгылары кайнар яшькә әверелеп, яңаклары буйлап тәгәри дә тәгәри.

Шунда капка шыгырдаган тавыш ишетелә, ишек шакыйлар. Кичәге вакыйгаларны бер мизгел эчендә хәтереннән кичереп, Тәзкирә ишек ачарга юнәлә...

— Тәзкирә апа, сезне тикшерүче чакыра.

Ана кеше, авырайган аякларын көчкә сөйрәп, кире өйгә керә. Гатаулла да уянган. Ләкин Тәзкирә улына берни дә әйтә алмый. Яшенә тыгылып, киенә дә чыгып китә. Әледән-әле артка, улы калган якка борылып карый, әмма бер ни дә күрә алмый...

* * *

Әхмәт белән Гатаулланың парлашып төшкән рәсеме һаман Вәлитова кулында иде әле. Мин алмакчы булып үрелгәч тә, Вәлитова миңа бирмәде аны. Аның каядыр еракка төбәлгән күзләре битараф карый кебек иде...

Тикшерү барышында һәр көн, һәр сәгать саен уйланып, фикер йөртер өчен яңа сәбәпләр туып кына тора. Минем уйлар да — искеләре дә, яңалары да — һаман Вәлитова тирәсендә әйләнә. Тентү барган җирдән чыгарып җибәрүнең ут белән уйнау икәне миңа башта ук ачык иде инде. Бу тәвәккәллекне эшләгәндә мин начар нәтиҗә килеп чыгуы мөмкинлеген дә күздә тоткан идем. Бу турыда ачыктан-ачык сөйләсәң, берәү дә ышанмас иде бәлки. Хәтта Саттаров та планшетына шап иттереп сугар да мыскыллап: «Үз акылыңдамы син?» дияр иде. Чыннан да, үзен хөрмәт иткән нинди тикшерүче «телсез шаһитләр»не юкка чыгаруга юл куяр икән?

Ләкин бу ялгышлык — ачышның башы иде.

Мин җыйган документлар һәм фотоларны үземә таба шудырдым. Аларны күздән үткәреп, аңымда берләштерергә, Зарима Аллаярованың эчке дөньясын төшенергә һәм шуның аркылы үтерүченең эзенә басарга кирәк иде.

Әмма Вәлитова моңа игътибар да итмәде, күрәсең. Кулындагы фоторәсем белән аерылышырга да теләге юк иде аның. Күзләре һаман да каядыр текәлгән. Үзе таш сын шикелле катып калган иде.

Бераздан иелә төшкән башында ак чәч бөртекләре ялтырап күренгәч, мин аптырап киттем. Игътибар белән карасам, ни күрәм: алар торган саен арта, куера бара сыман иде. Вәлитованың моннан бер сәгать элек кенә чал кермәгән чәче күз алдында дигәндәй агара башлаган иде.

Шундый тышкы үзгәрешләр кичергән кеше эчтән үзгәрмичә кала микән? Аның күңелендә нинди тойгы үсә, көчәя иде булса кирәк. Нинди тойгы ул? Нәфрәтме? Бәлки.

## 9

Туракланган кеше мәете табылганлыгын ишеткәч, Вәлитованың күңеле нәфрәт белән тула. Соңыннан авылда мәетнең каяндыр читтән китерелеп ташлануы турында хәбәр тарала. Бу имеш-мимешләрдән соң вакыйганың тәэсире кими төшкәндәй була. Димәк, җинаятьчеләр бу тирә кешеләре түгел, аларны барыбер тотачаклар дип фараз кылып, Тәзкирә Вәлитова тынычлана төшә.

Һәм аңа көтмәгәндә шушы вакыйга аркасында прокурор Саттаров белән йөзгә-йөз очрашырга туры килә. Тентү! Күршеләрдә тентү! Моны ничек аңларга? Ул, үзе дә белешмәстән, бауларны яндыра. Ләкин бу да тынычлык китерми. Уйлары бөтенләй таркала Тәзкирәнең. Төн буе саташып чыга... Тикшерүчегә чакырыла... Бибинур Аллаярова белән очраша...

Елга буенда табылган мәет хәзер Тәзкирә Вәлитова өчен нииндидер билгесез хатын-күз гәүдәсе түгел, ә якын кеше — Зарима Аллаярованың мәете.

Әйе, бу коточкыч җинаять турында Тәзкирә хәзер күп нәрсә белә. Белмәү җиңелрәк булган икән аның өчен...

Бибинур Аллаярова да, мин дә авыл Советында әле генә күз алдыбызда булган кискен үзгәрештән өнсез калган идек. Аллаярова каушау катыш гаҗәпләнеп: «Нәрсә бу? Ни булды аңа?..» дигәндәй күзләрен миңа төбәде.

Кинәт Вәлитова йокыдан куркып уянгандай сискәнеп китте, кисәк кенә урыныннан купты да, мин стакан белән сузган суга игътибар да итмичә, ишеккә атылды:

— Мин... Мин хәзер... Хәзер киләм...— дип чыгып китте.

Бибинур Аллаярованы озатып, коридорга чыктым. Шунда ашыгып кергән Дәүләтшинны күрдем. Кызарынган, бүртенгән, тиргә баткан. Элекке ваемсызлыгы, исереклек эзләре җилгә очкан иде. Ул миңа ияреп кабинетка керде.

Әхмәт үз-үзенә урын таба алмаган кешегә охшый иде. Һәм бу хәл гаҗәп тә түгел иде. Ул нәрсәдер яшерә, кичерешләрен эчендә саклап, берьюлы ике тормыш белән яши иде.

Гадәттә, ялганны очраклы нәрсә, бернинди законнарга да буйсынмый торган нәрсә дип уйлыйлар. Әмма тормыш моның хата икәнен раслый. Ялганның үз принциплары, үз кагыйдәсе, алымнары, формалары бар. Ялганлаган кеше үзенә күрә бер фикерләү законына, логик формага таянып эш итә. Ялганлаучының аңында бер-беренә параллель булган ике вакыйга яши. Аларның берсе — чын вакыйга. Икенчесе — уйлап чыгарылган вакыйга. Моны ул, әлбәттә, сөйләр өчен уйлап чыгара. Ялганчыга булган вакыйганы «онытып», уйлап чыгарылган вакыйганы «хәтеренә сеңдерергә» туры килә...

Дәүләтшинның минем каршыдагы урындыкка килеп утыруы булды, күзләре өстәлдә яткан фоторәсемнәргә текәлде. Мин Әхмәтне чакырыр

алдыннан аларның Вәлитов белән икәү төшкәнен дә, Зариманың төрле-төрле фоторәсемнәрен дә өстәл өстенә махсус таратып салган идем.

— Юк, гражданин следователь, мин башкача түзә алмыйм,— дип, кире сикереп торды ул.

— Нәрсә булды тагын?

— Нәрсә булса да булган инде, ләкин шуны белегез: Зариманы үтерүче кеше — Вәлитов.

— Гатаулламы? Сезне аңлавы кыен: кичә генә белмим дидегез бит, дустыгыз Вәлитовны якладыгыз.

— Миңа җинелме әллә? Барысы да кичә, сездән кайткач ачыкланды.

— Нәрсә ачыкланды?

— Барысы да, гражданин следователь, сез озатканда мине дөрес кисәткәнсез икән,— дип, Әхмәт тирән сулап куйды.— Минем сезнең яннан кайтканны Вәлитов безнең капкага сөялеп көтеп торган. «Үтерүне үз өстеңә ал!» — ди. Бәлки Вәлитовтыр дип мин үзем дә шикләнә идем. Шуңа күрә тентү вакытында әнисенә дә бау эзләвегезне әйттем. Шик шик инде. Ул ком кебек, таянып булмый. Гатаулланың бу сүзләрен ишеткәч, шиккә урын калмады. «Син нәрсә?!» — дип кычкырдым мин. Ул һаман үзенекен тукыды: «Мин нәрсә түгел, Әхмәт. Менә син — нәрсә! Болай да, тегеләй дә син — эләккән кеше. Үзең уйлап кара: көнләшүче — син, үтерәм дип янаучы — син. Балта да, капчык та сезнеке. Утырып кайткан кеше — син. Әнигә бау турында әйтүче дә син. Моны Ибраһимов үзе дә ишетте. Каюк, парень,— ди,— үзеңнең гаебеңне үзең тану — иң дөрес юл», ди.

— Шуннан?

— Шуннан ни, бугазына ябышыр идем, Вәлитов үгез кебек көчле. Уң кулын да шикле итеп кесәсендә тотып тора. Имеш, җинаятьне үз өстемә алсам, гаебемне «танысам» — унбиш ел гына алып, исән калуым да бар...

Дәүләтшин беразга туктап калды, күзләрен күтәреп, миңа карады. Белергә тели: ышанаммы, юкмы?

— Балта белән капчыкны ничек аңларга соң?

— Хәзер билгеле инде: барысы да Вәлитов эше, гражданин следователь. Бездә нәрсәнең кайда ятканын биш бармагы кебек белә ул.

— Ә бау?

— Анысы аларныкы. Андый мунчала бауны аларда гына күргәнем бар.

Дәүләтшин сөйләгән сүзләрне магнитофонга язып барсам да, булачак суд өчен ул гына аз иде. Һәрбер дәлил закон нигезендә тикшерелгән һәм җинаять эшенә рәсми протокол белән беркетелгән булырга тиеш.

— Сөйләгәннәреңне үз кулың белән яз,— дип, Әхмәткә кәгазь, ручка бирдем.

Күп уйланып торырга вакыт юк иде. Пальтомны элеп алдым да авыл Советы председателе янына кердем.

— Киен тизрәк!

— Ни булды? — дип сикереп торды председатель.

— Киттек Вәлитоваларга! Ике пунәтәй дә кирәк булачак.

Председатель озак сорашып тормады, җәһәт кенә киенеп алды да минем арттан ашыкты:

— Әйдә, ындыр ягыннан!

Йөгерә-йөгерә Вәлитовалар ихатасына килеп кердек. Әллә дөрес булды, әллә юк, миңа хатын-кыз елавы ишетелгән шикелле булды. Без тагы да ашыга төштек.

Йөгереп керсәк, идән уртасында, җәелгән паласта Тәскирә Вәлитова хәрәкәтсез ята иде. Без суынып та өлгермәгән гәүдәгә абына

яздык. Сул кулын тотып карадым, әмма пульсы сизелми иде инде. Хатынның уң кулында мунчала бау кисәге, нәкъ җинаять урынында табылган бау шикелле. Без күпме көч түктек ул «шаһитне» табу өчен! Әмма ул безнең кулга бик урап, зур кыенлыклар аша гына килеп эләкте. Тәзкирә Вәлитова бауны безнең кулга тапшырырга теләгән, күрәсең.

Мин Вәлитованың мәетен берничә мәртәбә фотога төшереп алдым да, пүнәтәйләрне сакта калдырып, Акбүләккә шалтыратырга һәм Вәлитованың үлү сәбәбен ачыклау өчен эксперт Шакирҗановны чакырырга булдым. Председательне дә үзем белән иярттем. Ишектән чыгуга, безгә Гатаулла очрады. Без аны туктатып, кулга алынуын әйттек.

Вәлитов, рөхсәт сорап-нитеп тормыйча, өйләренең тәрәзәсенә капланды һәм, аяк очларына басып, эчкә карады.

Өйдә, идәндә үлеп яткан әнисен күрмәде. Вәлитов тагын да калкына төште, йөзе белән тәрәзәгә бөтенләй капланды. Гатаулланың кипкән иреннәре тартышып кыймылдады, күкрәгеннән әрнүле тавыш чыкты:

— Әнкәй!

Ләкин өйдән җавап бирүче булмады...

Тәрәзәдән аерылуы булды, Вәлитов күз ачып йомганчы сөзгәк үгез шикелле миңа ташланды, кулымны күтәрергә өлгермәдем, башыма нindидер каты әйбер белән сугып, карга бәреп екты. Күземне ачканда, минем белән рәттән, председательнең кара бүреге дә кар өстендә тәгәрәп ята иде. Сукранып яткан председательне тартып торгыздым да урамга атылдым.

Әмма Вәлитов белән безнең ара ерагайган иде инде. Йөгерәм. Башымда бер генә уй: куып җитеп, җинаятьчене тотарга кирәк. Йөгергән килеш, төймәләрне ычкындырып, иңбашыннан шудырып кына пальтомны ташлап калдырдым. Җиңеләйдем кебек, әмма ара ераклаша гына бара. Артта председательнең дә еш-еш сулыш алганы ишетелде. «Гаражга чаба ул, гаражга!» дип искәртте миңа председатель, үзе артка кала башлады. Мин бирешмәскә тырышам, пинжәкнең дә төймәләрен ычкындырып җибәрдем. Пинжәк чабуының ике якка җилкән кебек ачылып китүе булды, эчке кесәдәге пистолет, «мин кирәк түгелме?» дип сорагандай итеп, күкрәккә бәрелә башлады. Авыл уртасы — нинди атыш булырга мөмкин. Менә Вәлитов авыл Советына якынлашып килә, ә аннан соң өч йорт аша гына колхоз гаражы. Машинаның нindиен телисең, утыр да сыз.

Кинәт үзем-үзем ышанмый калдым: авыл Советының өйалды баскычыннан Әхмәт Дәүләтшин төшеп килә иде. «Нишләр икән?» дип уйларга өлгермәдем, урам буйлап йөгерүчеләрне күргәч, бераз тукталып торды да Вәлитовның каршысына ыргылды. Вәлитов, моны күреп, уң кулы белән Дәүләтшинга кизәнде, Әхмәт бераз читкә тайпылды да селтәнеп Вәлитовның аяк астына сукты. Вәлитов гөрселдәп юлга барып төшкәч, Дәүләтшин аның өстенә үк менеп атланды. Бераз тыпырчынып, аяклары белән тибенеп караса да, Вәлитов аны өстеннән алып ыргыта алмады. Ләкин шул чак Дәүләтшин, каты кычкырып, үзе авып төште. Вәлитов тиз генә сикереп торды да каяндыр пычак тартып чыгарды. Тик без килеп җиткән идек инде, ул бер генә селтәнергә өлгерде...

Без күтәреп алганда, Дәүләтшинның сул яңагыннан иягенә таба канлы эз сузылган иде. Әмма ул шат иде.

— Сатлык җан! — дип, усаллыгы йөзенә бәреп чыккан Вәлитов тагы да Дәүләтшинга ташланмакчы булды. — Үзең кеше үтерүче була торып...

— Син ул кеше үтерүче! — дип араларына килеп басты председатель.— Син ул, хәсис! Әниеңнең дә башына җиттең!

Яшен суктымыни! Вәлитов тетрәнеп китте һәм баскан урынында катып калды.

— Әйтәм аны, эндәшмәде...— дип мыгырданды ул ишетер-ишетмәс кенә.

* * *

Җинаятьче һәр вакыт җинаятьче инде ул. Нинди генә сынау, тетрәүләргә очрамасын, ул үзе корган ялганыннан тиз генә, җиңел генә аерыла алмый.

— Юк, мин белмим! — дип кырт кисмәкче булды Вәлитов.— Әхмәтән сорагыз. Ул үтерде.

Киңәге күршеләр, бергә үскән дуслар — Дәүләтшин һәм Вәлитов минем алда. Алардан кара-каршы китереп сорау алам.

— Ышанмагыз, Әхмәт ялганлый. Гаебен миңа аударырга тырыша.

— Нишләп Әхмәт?

— Ул булмый кем булсын! — дип, Вәлитов бармаклары белән дәлилләрне санарга кереште:— Көнләшеп, янап йөрүче — ул! Зарима югалгач, эчкечелеккә бирелүче — ул. Балта да, капчык та...

— Юк, бау сезнеке,— дип, кинәт өстәлдәге кәгазьне ачып җибәрдем.— Уңнан сулга ишелгән, мунчала бау...— Өстәл өстендә кулдан ишелгән юкә бау ята иде.

— Дөньяда баулар күп...

— Ләкин мондыйлары мәет салынган капчыкта да, сездә генә шул.

— Нишләп бездә генә?

— Үлгән әниегезнең кулында иде.

— Булмас! — дип Вәлитов урыныннан сикереп торды.— Ышанмыйм.

— Фоторәсемнәрне күрсәткәч ышанырсыз!

— Нинди рәсем тагын?!

— Берсе әниегез мәете, икенчесе аның шушы бауны кыскан уң кулы,— дип, Вәлитованың соңгы фоторәсемнәрен кулга алдым.

— Мә, карагыз,— дип, әле генә эшләнгән, дымлы фоторәсемнәрне Вәлитовка суздым.— Әниегезне тану кыен түгел, уң кулында, баудан тыш, әтиегезнең бүләк балдагына кадәр күренә.

— Эх, әни, әни! — дип сукты ул кинәт кенә маңгаена.— Нәрсә кирәк, язгыгыз... Эх, әни!..— дип өстәде ул ачыргаланып.

Һәм тотлыга-тотлыга сөйләргә тотынды. Мин Вәлитовны бүлмәскә булдым. Ул сөйләгәннәрне язып алдым. Менә ул юллар...

— Әни, ни булды сиңа? — дип, Гатаулла әнисен сорау белән каршылаган.

— Сорап тора тагын!..

Вәлитованың йөзенә җирәнү билгеләре чыккан.

— Рәйсә килен белән таныштырганда, күз атып йөргән кызың юкмы, дип сорадыммы?

— Әйе, сорадың, әни.

— Син бит ул чакта Зариманың да башын әйләндергәнсең.

— Булган — беткән. Нигә бәйләнәсең? Аш ашка, урыны башка. Яшь чакта үзең дә...

— Телеңне тый! — дип бүлдергән аны Вәлитова, калтыранып.— Гомер буе әтиеңне көтеп яшәдем мин. Бер генә кыздан да яшь түктерәсе булма дип әйттемме сиңа?

— Әйтсә.— ни булган?

— Син бу юлы да алдадың, аманәткә хыянәт иттең.

Ана улыннан җавап көтепмедер, бераз тынып торган. Тегесе бер сүз дә дәшмәгәч, дәвам иттергән:

— Бер көнне канга батып кайттыңмы? Эштә яраланган, имеш. Төн буе ишегалдында кар шыгырдатып йөрдеңме? Йөрдең. Өс-башыңны юганда су кып-кызыл булды. Бер атнадан соң — авылда мәет. Зарима мәете. Үзем дә җинаятьче мин хәзер! — Ана үкси-үкси сүзен дәвам иттергән:— Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрсең хурлыгыңнан... Нигә дәшмисең? — дигән Вәлитова, ярсуы бераз басыла төшкәч.— Тик торуым алтын, дисеңме? Хәзер үк тикшерүчегә бар!

— Мин гаепле түгел, әнкәй!

— Син булмыйча, Мөхәммәтдәминме әллә?

— Зарима үзе.

— Зарима?! Вәт оятсыз! — Ананың күзе шардай булган.

— Әйе, әнкәй, үзе. Без эштән соң очраштык. Зарима ялга чыккан. Байтимергә алып бар, ди. Мин алып бармыйм, дим. Аның һаман үз туксаны туксан. Ачу чыкты. Өйләндем, бүтән очрашмаска кирәк, дип кырт кистем. Балавыз сыгарга ук тотынды. Тынычландырмакчы булган идем — кая ул. Тузыныпмы тузына бара. Ялганчы да алдакчы. Кул селтәдем дә ташлап киттем. Буфетка кереп бер стакан аракы эчтем. Кайтырга дип автобуска килеп керсәм — Зарима утыра. Кеше күрсә?.. Рәйсә ишетсә?.. Шушы уйлар күңелгә шом салды. Авылга җиткәнче автобустан төшеп калдым. Ул да төште. Кая барасың, димен. Сезгә, ди. Сизеп торам: уенда усаллык. Ачуланышып киттек. Сумкасы белән селтәнгән иде, мин этеп җибәрдем. Башы белән ташка егылды...

Вәлитовның комга корылган хәйләсе барып чыкмаган. Гадәттәгечә, үзен кызгандырып, әнисеннән яклау тапмаган.

— Бар, тикшерүчегә сөйлә! — дигән.

— Әхмәт барсын,— дигән улы.

— Ә-әх-мә-әт! Нишләп ул?

— Минем алиби бар,— дип, җитез генә юридик термин китереп кыстырган Гатаулла.— Зарима үтерелгән көнне башка урында идем. Шаһитләрем дә бар. Егетләр ышанычлы! Алар булмаса, күптән башымны алып өйдән олагыр идем инде. Алиби — моны аңларга кирәк, әни!

— Әхмәтнең ни катнашы бар? Ул бит...— дигән әнисе, кулы белән йөрәген тотып.

— Әхмәт белән сөйләштем. Килешеп бетмәде әле бетүен. Килешми, кая барсын! Әхмәт тегеләй дә беткән, болай да беткән.

— Кешене яшәүдән туйган дисеңме әллә?

— Туймаса ни! Барыбер аның урыны тимер читлектә.

— Ничек? — Гаҗәпләнүнең чигенә җиткән Тәзкирә улын беренче мәртәбә күргәндәй текәлеп карый.

— Килешер, үз өстенә алыр.

— Ни сөйлисең син, явыз?

— Күрерсең, әни, дуслар сүз бирде, Әхмәтне кысалар, борылыр урыны да калмас. Әнисен үзем тәрбияләрмен.

— Ай, ходаем,— дип кинәт кычкырып җибәргән түземен җуйган ана, йөрәген кысып.— Нинди кабахәтлек! Нинди елан! Еланның башы үлсә дә үзе үлмәс. Хәзер үк тикшерүчегә бар! Бармасаң, үзем барам,— дип, Вәлитова сикереп торган да ишек кырындагы чөйдә онытылып калган мунчала бауны алган һәм:— Мә, тикшерүчегә тапшыр! — дип Гатауллага сузган.

— Әни, нишләвең бу? Әни, дим! — дип ялварган Гатаулла, әнисенең алдына тезләнеп.

— Нишләгәнемне беләм. Бар тикшерүчегә!

— Әни дим. Хәзер Әхмәтне алып керәм,— дип Гатаулла ишеккә киткән.— Әхмәт үзе әйтер... Хәзер, әни, хәзер...— Шуннан күршеләренә йөгергән.

Вәлитова дәшмәгән. Ул әйтәсе сүзен әйтеп бетергән инде.

Тагы нәрсә әйтсен инде ул! Яшьтән үк баласын үзе бозды бит. Улы теләгәнен ашады, сораганын эчте, энәдән-җептән генә киенде. Нәрсә теләсә, шуны эшләде. Һичбер «ярамый!» дигән сүз чыкмады ана авызыннан. Нәтиҗә — Гатаулла үз-үзен генә яратучы, үзе турында гына кайгыртучы эгоист булып үсте. Бала чактан ук улының һәрбер гаебен, ярамаган эшләрен үзе каплап килде, яклады. Тәзкирә, улына яхшылык телим дип, вак җанлы, юлдан язган бер кеше үстерде. Хәзер әнә ике аяклы ерткычка әйләнде.

Вәлитованың мәетен җентекләп тикшереп чыкканнан соң:

— Йөрәк,— диде врач-эксперт Шакирҗанов, чал чәчле башын аска игән килеш.— Йөрәгенә кинәт кан сауган. Башына төшкән кайгыны күтәрә алмаган, бичара...

* * *

Вәлитов кинәт тынып калды. Сорап су эчте. Әмма авызыннан бүтән бер сүз дә чыкмады. Аның чырае караңгы, юка иреннәре кысылган иде. Вәлитовның сөзәк маңгае бөтен йөзенә ямьсез кыяфәт биреп тора, усал итеп күрсәтә иде. Четерекле мәсьәләләрдән читләшергә теләптерме, Вәлитов тынып калды. Ул акылына кимчелек килгән кешегә охшый иде. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Вәлитовның әнисенә дә, безгә дә ихлас сөйләмәгәне ачык иде. Ул җинаять серен каплап торган пәрдәнең бер читен генә ачып күрсәтте дә, «нишлим икән?» дигән сыман ярты юлда шып туктады. Нәрсәне яшереп калдырырга чамалый ул?

— Шуннан? — дип тынлыкны боздым мин.

Вәлитов сискәнеп китте.

— Шуннан ни булды? — Вәлитов, җавап биргәнче, бераз уйланып торды.— Дәүләтшиннарга керсәм, Әхмәтегез өйдә юк. Аны эзләргә әнисен йөгерттем. Юк та юк. Кайтсам, каршымда — сез...

— Нигә качтыгыз?

— Нигә булсын! Минем урында булсагыз, үзегез нишләр идегез?

— Зариманы үтергәнгә кем җавап бирер?

— Нинди җавап?! Үзе үлде ул.

— Үзе? Үзен-үзе тураклап, үзен капчыкка тутырган булып чыгамы, сезнеңчә?

— Үзе шул! Үтерү — бер нәрсә, иптәш Ибраһимов, үлгән кешене тураклау — икенче нәрсә! Сез, юрист буларак, аны гына беләсездер, шәт. Иптәш Ибраһимов, табыгыз әле җинаять кодексында мәет тураганга статья.

— Гаепләнүчеләргә тикшерүче — иптәш түгел, бу — бер. Үзе үлгәч, Дәүләтшиннарның балтасы белән капчыгы нигә кирәк булды?

— Әхмәткә ул гына аз әле.

— Бауны әйтәсезме?

— Их, әни, әни.— дип, Вәлитов тезенә сукты,— бәйләдең бит кулларымны шул бау белән.

— Нишләп бау гына булсын?

— Нәрсә тагын? — дип, Вәлитов урыныннан сикереп торды.

— Ташны да онытмагыз, Вәлитов!

— Нинди таш?

— Яссы таш. Дүрт килода өч йөз граммлы.

— Мушкага аласыз, гражданин следователь.

— Дүрт чәч бөртеге ябышкан, ми һәм кан таплары да ярылып ята.

— Дөньяда таш күп ул.

— Монысы сез әйткән төштә, юл кырыенда табылганы. Менә беркетмәсе,— дип, Вәлитовка башта протоколны, аннары ташның фоторәсемен суздым.— Буран да ярдәм итмәде сезгә, кар астыннан казып алдык.

— Ышанмыйм! Бу — провокация!

— Бәлки хәзер ышанырсыз,— дип почмактагы кәгазьне ачып җибәрдем. Идәндәге таш ачылып китте.

— Таш белән коралланып, кешедән булмаган гаебен танытмакчы икәнсез, гражданин Ибраһимов.

— Таш — сезнең корал ул, Вәлитов!

— Сезне, гражданин следователь, Зарима үлгән җирдә шаһит булып торган диярсең.

— Менә ул шаһит,— дип, Вәлитовка ташны күрсәттем.— Телсез булса да, иң мөһиме. Медицина экспертизасының нәтиҗәсе катгый: Зариманың баш сөяге шушындый таш белән бәреп яньчелгән. Эләгеп калган чәч бөртекләре Зариманыкы кебек, таштагы кан таплары Зариманыкы белән бер төсле. Икенче группа.

— Кабатлану була, гражданин следователь, әмма Зарима, сумкасы белән селтәнеп, башы белән ташка үзе килеп төште.

— Башына нәрсә кигән иде?

— Бүрек, норкадан тегелгән, тартышканда ул атылып читкә төште.

— Вәлитов, сез алдашмагыз. Менә беркетмә! Анда акка кара белән: Зариманың норка бүреге торган бүлмәсендә калган. Ул югалган көнне мамык шәлен бөркәнгән дип язылган.

— Хәтер...— дип, Вәлитов тына төште һәм теләр-теләмәс өстәп куйды:— Кайсын гына истә тотасың инде аларның.

— Ул шәл кайда?

— Янды.

— Белгечләрнең карары, Вәлитов, шундый: чәчен артка үргән хатын сез әйткәнчә баш арты белән ташка ничек кенә килеп төшмәсен, үлү түгел, җиңелчә җәрәхәт булуы да икеле. Ни өчен дисәгез, беренчедән, чәч толымнары, икенчедән, кешенең үзен-үзе саклау инстинкты бар. Монда кирәкле расчетлар ясалган. Моңа мамык шәлне дә өстәсәк, нинди логик нәтиҗә соралганын сез беләсездер?

— Әмма мин үтерергә теләмәдем.

— Бу сүз бөтенләй аңлашылмый. Әйдә, Вәлитов, экспертларның нәтиҗәләренә күз салыйк,— дип, рәсми кәгазьне Вәлитовка суздым.— Монда: «Авыр таш өстән аска, бик зур көч белән ыргытылган, исән кешенең башын ясмык кебек яньчегән һәм үлемгә сәбәп булган», диелгән.

— Барыбер мин түгел.

— Кем соң?

— Зарима очраклы үзе килеп төште.

— Киемнәре, чәчләре кая?

— Яндырдым.

— Нишләп?

— Нахакка гаепләүдән курыктым.

— Мәетен кем туралы?

— Мин.

— Нишләп?

— Сәбәп бер, гражданин следователь.

— Әмма эчке күлмәгенә, гәүдәсенә тимәгәнсез.

— Йөкле хатын бит.

— Йөкле? — дип кычкырып җибәрә яздым.— Кемгә ышанырга: профессоргамы, сезгәме? Профессор әйткәнчә Зарима бер дә буйга узмаган, бала тапмаган, аборт ясатмаган.

Әйтеп өлгермәдем, Вәлитов коелды да төште.

— Су эчәргә мөмкинме? — дип, Вәлитов миңа карамыйча уң кулын сузды.

— Рәхмәт,— дип, ягымлы гына эндәшеп, Вәлитов тентү вакытындагы әдәпле, тәртипле Гатауллага әйләнде дә куйды.— Ул турыда экспертизаның нәтиҗәсе бармы соң?

— Булмыйча. Мә, рәхим итегез, укыгыз,— дип нәтиҗәне Вәлитовның кулына тоттырдым. Ашыкмады, энәсеннән җебенә кадәр дигәндәй җентекләп укыды.

Байтак вакыт узды. Әмма тынычлыкны бозмаска булдым. Ул түземлегемә хәзер үзем аптырыйм. Вәлитов тагы су эчте.

— Җүләр мин, гражданин следователь,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.— Эшләрнең болай тирәнгә китәсен башыма да китермәдем. Танышкач, дуслашкач, Зарима ачыктан-ачык кушылу турында хыяллана башлады. Түз, сабыр ит, дидем. Кая ул, өйлән дә өйлән, янәсе. Мин дә сүземнән кайтмыйм, түз, сабыр ит, дим. Кая ул, сабырлык. Өйлән, имеш, ул буйга узган, миннән йөкле. Аборт сүзен ычкындыруым булды, Зарима ду күтәрде. Аны кешегә санамыйча, хурлыкка калдырырга телим, имеш. Ташкентка, абыең янына барып кайт, дим. Син барсаң гына дип, кырт кисте. Бер яктан Рәйсә кайтыр көн җитә, икенчедән, Зарима белән аптыраш. Ул йөкле, имеш, безнең өйгә килә дә утыра. Туйны ашыктырмакчы булган, күрәсең. Фаҗиганең сәбәбе шул. Ә мин, җүләр...— дип, Вәлитов көрсенде дә, куллары белән ике яңагын тотып, башын иде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Мин урынымнан кузгалмыйча озак кына Вәлитовка карап утырдым. Алдымда — гаепләнүче Вәлитов, башымда — борчулы уйлар. Сәгатьләп вакыт узды, әмма Вәлитов селкенмәде дә. Тораташмыни. Бу очракта ул үзе дә «телсез шаһитләргә» охшаган иде.

* * *

Берничә ел вакыт узды. Җәй көне миңа телеграмма килеп төште. Университетта бергә укыган иптәштән. Ул эшеннән азат ителгән Саттаров урынына Чулпан район прокуроры булып эшли башлаган. Курсташым, алдан сөйләшеп куйганыбызча, ял итәргә, балык каптырырга чакырган. Озакка сузып тормастан, юлга чыктым. Чулпан районының бай табигате, урман-болыннары мине күптән үзенә тарта иде инде.

Юлым Байтимер авылы аша үтә иде. Авылга кергәч, мин шофердан акрынрак баруын үтендем.

Күңелем бик кузгалган иде. Иске яралар ачылгандай булды. Зурзур тирәкләр тагын да юаная төшкән. Тик менә алар янында Вәлитовларның шифер түбәле өе генә юк иде. Берни дә калмаган. Нигез өстендә җилләр уйный. Ә рәттән, Дәүләтшиннарның кыйшая төшкән өе урынында, шифер түбәле, алты почмаклы яңа йорт утыра, капкасына тикле бизәкләп эшләнгән.

Өй алдында ике бала уйнап йөри. Берсе — кыз, икенчесе — малай. Узып барган газикны күргәч, авызларын ерып, кулларын болгап калдылар. Шоферга туктатырга ымлап, кабина ишеге тоткасына да тотынган идем инде, ләкин мине нәрсәдер тыеп калды. Хәер, Әхмәт Дәүләтшин, мөгаен, Чулпандадыр, ә башкаларны минем килү шатландыра алмас. Аларның иске хәсрәтләрен яңарту кирәкмәс. Вакыт узган, судның Вәлитовны үлем җәзасына хөкем итү турындагы карары күптән үтәлгән.

Лəкин табигате буенча кызыксынучан бит ул адəм баласы. Авыл Советына туктамыйча үтə алмадым. Председатель һаман шул элекке икəн. Без шатланышып кул кысыштык, исəн-саулык сораштык һəм, бер-беребезгə карашып, икебез берьюлы тынып калдык. Үткəннəрне искə төшереп алдык.

— Күпме вакыт узды, һаман онытылмый,— диде ул бераздан соң салмак, сабыр тавыш белəн.

— Ə Дəүлəтшин ничек?

— Сау-сəламəт, балалар үстерə. Узышлый игътибар итмəдегезме? Мин «күрдем» дигəнне аңлатып, баш кактым.

— Туп шикелле тəгəрəп йөрилəр үзлəре,— дип өстəде председатель сокланып.— Игезəклəр.

— Өйлəндемени шулай да?

— Өйлəнде. Хатыны колхозда яшелчə үстерə. Хəзер егетне танырлык та түгел. Нинди зур кичереш бит! Акыл керде үзенə. Тамчы да авызына алмый хəзер. Промкомбинатта эшли. Столяр. Мастерскойга җитəкчелек итə. Менə дигəн йорт салды. Газы, суы — барысы да үзендə.

Мин канəгать идем. Үзенең моңа кадəр тайгак юлдан барганын аңлаган кеше турында җылы сүз ишетү һəр вакыт күңелле.

Əйе, мин бирегə яңалык ишетергə исəп тотып тукталган идем. Лəкин бу кадəр шатлыклы хəбəр ишетермен дип уйламадым. Җитмəсə, шундый язмыштан соң. Язмыш кешегə сынау ул. Кешенең кемлеге авыр сынауларда беленə. Буыны сыекларны бөгə, көчлелəрне чыныктыра ул.

Авыл Советыннан киткəндə Əхмəт Дəүлəтшин йорты каршында шул ук балалар уйнап йөри иде. Якынлашып килгəн машинаны күреп, алар капкага таба елыштылар, шатланып сикерешə-сикерешə, хəерле юл телəгəндəй, кул болгап калдылар. Бу минутларда аларның шатлыклы чыркылдавы үземə күчкəндəй тоелды.

Дəүлəтшинның исəн калуына, чын кеше булуына шатлана идем мин. Бəхетнең барлыгына, аның яхшы кешелəрне читлəтеп үтмəвенə шатлана идем. Балалар елмайганда шатланмый каламыни кеше!

## Госман Бакиров

# БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫ

●

Бер көн Айдар әбисеннән алма сорап алды.

— Алманы бик яратам мин, әби.

— Шулаймыни, бәбкәм, ә алма сине ярата-мы соң?

— Нишләп яратсын, аның авызы юк бит! — диде Айдар.

●

Айдар яшь кызларның сикерә-сикерә биегәннәрен телевизорда карап торган да, әбисеннән:

— Әби, син бии беләсеңме? — дип сораган.

Әбисе аңа каршы:

— И-и, бәбкәм, мин биегәндә идәннән утлар чыга торган иде,— дигән.

— Ә хәзер нигә биемисең? — дигән бала, кызыксынып.

— Һай, бәбкәм, бик биер идем дә, аякларым тыңламый шул хәзер,— дигән әби.

Айдар уйлап торган-торган да:

— Алай булгач, син аларны почмакка бастырып куй, тыңларлар,— дигән.

●

Бер көнне Айдар бабасының орденын тагып урамга чыкты да Ирек мәйданына таба китеп барды. Малай бу юлны белә иде. Балалар бакчасыннан шушы мәйдан аша кайталар. Менә чатны гына борыласы да... Нәкъ шунда Айдарны бер абый туктатты.

— Орденлы егет, кая болай ашыгасың? — диде ул.

Кинәт бирелгән сораудан малай каушап калды, тиз генә җавап бирә алмады. Абый кеше яңадан сорады:

— Син кайсы урамда торасың?

— Мин урамда тормыйм, безнең өебез бар,— диде Айдар бу юлы.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

Иң авыр эш — мүкләк сыерның мөгезеннән тоту.

Дөньяның татлысын гына татыган — әчесеннән һәлак булган.

Арттагылар алдыннан барганчы, алдынгылар артыннан барыйк.

Танылмавы белән танылган язучы.

Язучы өчен иң куркынычы — мактану белән макталу.

Акыллы акыл сатканчы, юләр юләрлеген бушлай өләшеп өлгерә.

# Хәйдәр Гайнетдинов



*Гомер юлым — Зәй төбәге, Дүрт Мунча авылыннан башлана. Мәктәп еллары, Казан дәүләт университетының татар теле бүлеге. Егерме бер яз, егерме бер көз аша узылган.*

*Безнең заман — әкияти чынлык. Кеше акылының борынгы мирасларны барлап, Киләчәкне иҗат итү чоры. Чиксез Вакытның шигъри мизгелләрен җыр итеп калдырасы иде!*

## Май яңгыры

Аста — яшеллек дөньясы.
Кояш нуры буйлап җиргә
яңгыр төшә
яланнарга...
Җылы яңгыр килгән Илгә.

Дөнья — бала чактагыдай:
инешләр дә калган тулып.
Яңгыр түгелә диварларга
үткәннәрнең төсен юып.

Агачлар — яңгыр эчендә
яшел сүсемнәр сыман.
Әкрен генә кызлар бара,
күкрәкләре манма булган...

...Тук башаклар зеңгелдәве
ишетелгәндәй була кырдан!

●

Салкын болытлар аклыгы
Кыяларның башында.
Исем китеп кычкырам мин
Шул биеклек каршында.

«А, биеклек!..» дигән сүзләр
Яңгырый таулар аша.
Чак күтәреп биеклекне
Кыялар ыңгыраша...

•

Ашкынып керәсең утларга,
Керәсең упкынлы диңгезгә.
Керәсең.
Ни булып бетәсен
Беләсең, беләсең үзең дә.
Дәртләнеп көләсең — яралар,
Хәсрәтләр булса да йөзеңдә,
Көләсең...
Ни белән бетәсен
Беләсең, беләсең үзең дә.

Бу җиргә мәңгегә килгән күк
Яшисең тормышның үзендә.
Яшисең,
Ни булып бетәсен
Беләсең, беләсең үзең дә...

•

Аккош ята кан эчендә...
Чәчәктән тик көл кала...
Газапларны күтәрә бит
Үз өстенә Җир-ана.

...Җиргә капланып үксерлек
Җанга күпме сүз сыйган.
Авыр булса да күтәрәм,
Җир улы мин,
Җир сыман.

•

Кире кайта җылы җилләр,
Һавада киек казлар.
Ә мин менә — мәңге монда...
Уйландырырдай язлар бу,
Уйландырырдай язлар...

Яшел төскә кушыла бара
Кош сайрау, шат авазлар.
Ә мин менә — бары тыңлыйм...
Уйландырырдай язлар бу,
Уйландырырдай язлар...

Кемнәргәдер яңа булып
Кабатланалар назлар.
Хисләр якты дөнья сорый!..
Уйландырырдай язлар бу,
Уйландырырдай язлар...

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

АПРЕЛЬ, 1973

«Без барлык комсомол-яшьләр бригадаларына КамАЗның сафка басачак беренче заводы — ремонт-инструменталь заводын шефлыкка алырга тәкъдим итәбез» — март ахырында бөтен Союз удар төзелешендәге Е. Вдовина һәм В. Напалов җитәкчелек иткән алдынгы бригадалар шундый чакыру белән чыктылар. «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең барлык идарәләре бу башлангычка кушылды. Унарча иң яхшы бригадалар — меңнән артык кеше — ремонт-инструменталь заводында эшләүче «Автозаводстрой» коллективына ярдәмгә килде. Барлык производство мәйданнарының өчтән бер өлешендә хәзер инде идән җәю, стеналарны буяу эшләре тәмамланды. Монтажчыларның да эше уңышлы бара».

«Правда». Мәскәү.

«Кама автомобиль комплексының ремонт-инструменталь заводы токаре Николай Иванович Ягуткинга мактаулы эш тапшырылды. Свердловск өлкәсеннән килгән бу оста булачак КамАЗ машинасының беренче детален — арткы рессорның кронштейнын ясарга тиеш. Шулай итеп, иң беренче сафка баскан заводта өр-яңа станокта иң беренче деталь ясалды».

«Известия». Мәскәү.

«Татар драматургы Д. Вәлиевнең «Дәвам» пьесасында КамАЗ төзүчеләр тормышы сурәтләнә. Аны иң беренче сәхнәгә В. И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры куйды. Спектакльнең режиссеры — Н. Орлов, художнигы — Э. Гельмс, композиторы — Л. Блинов».

«Театральная жизнь». Мәскәү.

«Чаллыда, КамАЗ төзелешендә «Художниклар — КамАЗга» дигән махсус күргәзмә ачылды».

«Комсомольская правда». Мәскәү.

«Новый мир» журналының дүртенче санында «Металлургстрой» идарәсенең комплекслы бригада җитәкчесе Нигъмәтулла Абдуллин үзе һәм иптәшләре турында болай дип яза:

«Минем бала чагым һәм яшьлегем Удмуртстандагы Воткинск шәһәрендә узды. Сораулары мөмкин: нигә соң мин туган җиремнән йөзләрчә километр читкә кит-

тем? Минем җавабым әзер. Ә минем якташларым Днепрогэс, Магнитка, Кузбасс төзелешләренә нигә дип киткәннәр иде соң? Бетончыларның атаклы бригадиры Хәбибулла Галиуллинның якташларын Магнитстройга чакырып язган хатын бездә әле дә хәтерлиләр. (Хәзер Магнитогорскида Галиуллин исемендәге урам да бар, диләр.)

Энтузиастлар поселогы — автозавод төзелешендә беренче поселок иде. Безнең бригада членнарының күбесе шунда яшәде. «Мин Дилнур Хаматуллин белән дә шунда таныштым. Ул — Башкортстаннан. Уфада юл төзелеше техникумын тәмамлаган, 1968 елда Кыргызстандагы Ош шәһәренә киткән. КамАЗ турында ишеткәч, хатынын һәм ике баласын алып, Чаллыга килгән. Хатыны Венера, белеме белән укытучы булса да, штукатур-маляр булып эшли, ә үзе — безнең бригаданың техник-механигы. (Шунысын да әйтергә кирәк, килгәч тә ул булачак заводта эшкә калырга гариза бирде.)

Мин Дилнурны үз бригадама чакыруыма куанып бетә алмыйм. Чөнки аның кебек балта остасы башка бөтен күрше бригадаларда юк. Аның звеносы безне әллә ничә тапкыр кыенлыктан коткарды».

Абдуллинның башка иптәшләре дә Дилнурдан ким түгел. Шуңа күрә дә аның бригадасы бөтен төзелештә атаклы. Алар бөтен көчләрен төзелешкә бирәләр, булачак завод аларның күз алларыннан китми...

«Төзелеш темпы зур,— дип дәвам итә Абдуллин.— Яңадан-яңа һөнәрләр таләп ителә. Озакламый бетончыларга эш азаячак. Шул ук вакытта монтажчылар, стеналарны бизәү, шомарту белгечләре күбрәк кирәк булачак. Аннан инде заводта эшләүчеләр. Дилнур Хәбибуллин автомобиль заводының баш механигы кул астында эшләячәк. Валерий Неверов та, институтны тәмамлагач, бригададан китәчәк. Хәер, мин үзем дә — машина төзүче...»

«Новый мир». Мәскәү.

«— Кайсы Игнатьев ул. Географмы? Казан педагогия институты доцентымы? Әллә художник Игнатьевмы?

Мондый сорау бирүчегә җавап бер:

— Географ та, доцент та, художник та шул ук үзе инде.

Чыннан да В. П. Игнатьев фәннәр кандидаты, вузда укыта. Шул ук вакытта ул күп кенә күргәзмәләргә катнаша. Мәсәлән, аның әсәрләре «Зур Идел», халыкара «Тынычлык өчен көрәштә сатира» күргәзмәләрендә күрсәтелде. Алар өлкә газеталарында, «Чаян» журналында еш басылып килә.

Күптән түгел Казандагы китап кибетләренә «КамАЗ башлана» дигән альбом чыкты. Аның авторы — В. П. Игнатьев. Бу альбомдагы рәсемнәрендә художник Чаллының бүгенгесе, андагы батыр кешеләр, социалистик ярыш алдынгыларын сурәтли.

«Советская культура». Мәскәү.

Асия Хәсәнова

# ЯПОНИЯ... НИНДИ УЛ?

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ



Сәяхәтебез Владивосток шәһәрендә башланачагын ишеткәч, бик сөендем. Ул миңа бала чактан ук бик серле шәһәр булып тоела иде. Ерак Көнчыгыш... Иң кызыгы шунда: 31 декабрьда син Владивостокта дус-ишләрең белән Яңа елны каршы алдың, ди. 1 январьда алар белән саубуллашып самолетка утырасың һәм ярты тәүлек очкач... 31 декабрьда Мәскәүгә килеп төшәсең. Биредә Яңа елны тагын бер кат каршы алырга мөмкин. Шуның өстенә әле ул планетабызда иң зур һәм иң тирән океан — Тын океан буенда урнашкан. Аның исемен ишетүгә, минем күз алдыма тау чаклы дулкыннар килеп баса иде. Менә шул шәһәрдән без Япониягә китәргә тиешбез.

Без Казаннан чыгып киткәндә — 16 мартта — бездә әле кыш иде. Өч-дүрт көн рәттән өзлексез кар яуганга, урамнарны кар баскан. Ә Владивостокта исә яз. Кояш кыздыра, битне җылы яклардан искән йомшак җилләр иркәли.

Бу шәһәр чыннан да бик үзенчәлекле икән. Ул калкулыкта, дөресрәге, кечерәк таучыкларда урнашкан. Тугыз-унике катлы йортлар биек калкулыкларда һәйкәлләр сыман утыралар. Күрше йортка керү өчен бер таудан төшеп, икенчесенә менәсең. Машинада йөргәндә дә үзеңне таганда атынгандай хис итәсең: машина әле калкулыкка күтәрелә, әле тау астына төшеп китә.

Океанның якынлыгын һәркайда тоясың: портта һәрберсе тау чаклы булып күренгән дистәләрчә океан кораблары тора, тәүлек буенча өзлексез «диңгез заводлары» — рефрижераторлар эшли, урамда очраган өч-дүрт кешенең берсе диңгезче. Хәтта урам, кибет исемнәре дә шуңа бәйле: «Океан проспекты», «Океан балыгы», «Диңгез вокзалы», «Диңгезчеләр клубы»...

Японнар безгә үз илләрен иң отышлы вакытта япон чиясе — сакура чәчәк атканда бөтен матурлыгы белән күрсәтергә теләгәннәр, күрәсең. Маршрут шуннан чыгып төзелгән. Безнең теплоход иң элек Японияләнең бездән иң ерак, иң җылы ноктасы — Нагасакига юл тотты. Сәяхәтне без Японияләнең СССРга иң якын ноктасы — Хоккайдо утравында тәмамладык.

Мин палубада басып торам һәм үзем өчен көтелмәгән ачыш ясыйм. Казанда чакта әллә кайда, бик еракта булып тоелган Япония безнең илдән әллә ни ерак түгел икән бит: Сахалиннан Хоккай-

дога нибары 43 кенә километр, Курильдәге Кунашир утравыннан шул ук Хоккайдоны үткен күзле кеше аяз көнне болай да күрә ала: аларның арасы нибары 15 километр.

Ике тәүлек диңгездә баргач, алда япон утраулары күренде. Бу утраулар ерактан бик тар, текә, очлы башлы, әле генә судан калкып чыккан кебек күренәләр. Без тауларны, бер-бер артлы тезелеп торган килеш, һәрхәлдә, җирдә күрергә күнеккәнбез. Биредә исә һәр тау су эчендә. Теплоход әнә шул су эченнән калкып торган таулар арасыннан бара. Менә ул шул таш кыяларның берсенә — Кюсю утравына юнәлде, һәм тиздән без терраса-терраса булып өскә күтәрелгән Нагасаки шәһәре портына кердек. Портта безне бик җылы, бик тантаналы каршы алдылар. Икесе дә чибәр, икесе дә японча киенгән һәм бик мул итеп иннек-кершән ягыннан япон кызлары безнең вәкилләргә чәчәк бәйләмнәре, ә безнең һәрберебезгә исә японча «Нагасаки» дип язылган кәгазь эшләпәләр бүләк иттеләр.

Безгә монда барысы да яңа, барысы да кызык һәм үзгә: язның беренче генә ае булуга карамастан, һава бик җылы, бик дымлы. Безнең өйләрдә генә үсә торган камелия, магнолия, драцена кебек чәчәкләр биредә өч-дүрт метр биеклегендәге агачлар булып бакчаларда үсәләр. Японнарның иң яраткан агачы — япон чиясе сакура бик кызык икән: бер генә яфрагы да юк, ә үзе шау чәчәктә утыра. Аның ал чәчәкләре корымыйча гына, нәфис килеш кенә җиргә коела икән.


Игътибарны җәлеп иткән тагын бер нәрсә: ул да булса иероглифлар. Ярты миллион чамасы кеше яши торган бу шәһәрдә магазиннар, конторалар бихисап күп. Димәк, вывескалар да санап бетергесез. Алар да японча иероглифлар белән язылган. Төрлечә, төрле стильдә матурлап язылган бу иероглифлар бигрәк тә кичен, мең төрле утлар белән бизәлгәч, бик матур орнаментлар булып күренәләр һәм шәһәргә милли төс бирәләр.

Нагасакиның урамнарында йөрү бик читен, чөнки алар машина һәм халык белән шыгрым тулган, алма төшәрлек тә урын юк. Бу Япониянең барлык шәһәрләренә хас бер кыенлык икән. Токиода исә кайбер үзәк урамнарда бензин исеннән тончыкмас өчен постта торучы полицейскийлар вакыт-вакыт махсус аппараттан кислород суларга яки противогаз кияргә мәҗбүр булалар. Японнар үзләре: «Безнең урамнарда халык шул кадәр күп, этләр койрыкларын бары астан өскә таба гына селки алалар», дип шаярталар.

Белгечләрнең исәпләп чыгаруларына караганда, Япония халкының яртысы яшәгән урын Япония җиренең бары 1,5 процентын тәшкил итә. Ни өчен халык шул кадәр бер урынга килеп тыгылган? Бу мисалда капитализм законнарының бер характерлы ягы күренә: капиталистик илдә завод-фабрикалар бары бер генә максат белән төзелә: кыска вакыт эчендә, азрак расход тотып, мөмкин кадәр күбрәк табыш алу. Зур шәһәрләр янында бар да әзер: уты да, суы да, юллары да, магазин-рестораннары да — һәммәсе дә. Шуңа күрә химия, металлургия заводларын да, башкаларын да зур шәһәрләр янына салганнар. Япониянең бер тирәдәрәк урнашкан җиде шәһәрендә халык саны һәрберсендә миллионнан артык, ә Токиода исә 12 миллионнан узып киткән. Эшкә барып кайту өчен биредә яшәүчеләрнең күбесенә өч-дүрт сәгать вакыт кирәк була икән. Шуның өстенә, бу шәһәрләр газ исеннән, төтеннән газап чигеп яшиләр.

Күзгә ташланган икенче нәрсә — биналар арасындагы зур аерма. Японнар җир тетрәүдән курыкмый торган 20—30 катлы һәйбәт йортлар сала башлаганнар. Бу йортларда кеше якынлашуга ачылып китә торган ишекләр, хәрәкәт итүе түгел, хәтта кузгалып китүе дә сизелми торган уңайлы лифтлар, өй эчендә үзеңә кирәкле климат

тудыру өчен кондиционерлар куелган, иң бай йортларда исә бассейннар, бакчалар ясалган. Мондый йортларның бизәлеше, уңайлылыгы иң таләпчән кешеләрне дә канәгатьләндерерлек. Ләкин мондый йортлар бик аз. Япон халкының сиксән проценты җил очырып китәрдәй йөзләрчә, миллионнарча бәләкәй агач йортларда яши. Дөньяда иң зур кораблар һәм иң кечкенә, 25 грамм авырлыгындагы телевизорлар, соклангыч транзисторлар һәм фотоаппаратлар эшли ала торган сәләтле һәм тырыш халыкның шундый начар йортларда яшәве безне гаҗәпкә калдырды. Бу агач йортларның бер тәрәзә-ишекләре дә юк. Җиңел түшәм һәм ширманы хәтерләткән стеналар. Ширма дим, чөнки стена дигәнебез агач рәшәткәдән һәм шул рәшәткәләргә тарттырылган дөге кәгазеннән генә гыйбарәт. Хуҗа шушы рамны шудырып ача да тәрәзә була, икенче бер рамны шудырып җибәрүенә ишек була. Мондый өй хуҗаның бакчасында, я су буенда, урманда торса һәм ул өйдә кешеләр җәй көннәрендә генә яшәсәләр, бәлки исең дә китмәс иде. Ләкин курчак өен хәтерләткән мондый өйләрнең японнарның бердәнбер торагы булып, бу торакның шау-шулы шәһәр урамында булуы безне тәмам аптырашта калдырды. Шуның өстенә,



Киото шәһәрендә Милли парк.

тагын бу өй буп-буш: анда бернинди җиһаз да юк. Бүлмә уртасында бары тик бер тәбәнәк өстәл генә тора. Шул өстәл тирәсенә тезләнеп утыралар да, ашап туйгач, өстәлне стенага терәтеп куялар. Кич җиткәч, стена эченә кертеп ясалган шкафлардан урын-җирне алып, идәнгә җәеп бөтен гаиләләре белән яталар. Стеналар да буш. Бары бер почмакта рәсем, яки шигырь язылган озынча кәгазь, аның астында тере чәчәкләр куелган ваза була.

Баштарак без японнарның бик ярлы өлеше генә шулай яшидер дип уйлаган идек. Ләкин Япония буйлап сәяхәт иткәндә мондый өйләрне без бихисап күп күрдек. Еш кына 10 метрлы бер бүлмәдә бер гаилә яши. Матбугатта басылган мәгълүматларга караганда, Япониядә йортларның 80% ында канализация юк. Җылыту системасы, кайнар су краннары кебек нәрсәләр япон йортларында сирәк күренеш, дип яза япон матбугаты. Йортларның шундый җиңел һәм шәрә булуын японнарның бер өлеше җир тетрәү куркынычы зур булу белән аңлата. Башкалары милли традицияләрнең көчле булуыннан, диләр. Японнар үзләре моны уңай күренеш дип саныйлар. «Япон халкы әйбер колы булырга теләми. Аңа тиргә батып әйбер эзләп

йөрисе, акча каян алыйм икән дип баш ватасы юк, чөнки ул идәндә утыра, идәндә йоклый. Аңа карават та, сервант, диван, урындыклар да кирәкми», диләр.

Биредә дә без музейларда, храмнарда, паркта, мәктәптә булдык. Кайсы музейга гына барсак та, аның янында бездәге бәйрәм демонстрацияләрендәге кебек дөнья кадәр кеше була. Боларның күпчелеге японнар үзләре. Балалардан алып ерак авыллардан килгән әби, бабайларга кадәр рәт-рәт тезелеп, тавышсыз-тынсыз гына музейга керткәнне көтеп торалар. Бу хәл безне башта гаҗәпләндерде. Ял көне дә түгел, берәр бәйрәм-фәлән микән әллә, дип уйладык. Әмма бу хәл Япониянең һәр шәһәрендә, һәр музеенда кабатланды. Сәяхәт итү, музей, паркларга йөрү япон халкының традициясенә әйләнгән икән. Бала беренче класска кергәч, аның ата-аналары булачак сәяхәт өчен аз-азлап акча кертә башлыйлар. Мәктәпне тәмамлагач, балаларның барысын да ил буйлап сәяхәткә алып чыгалар. Бу сәяхәттә бала туган иле белән таныша. Яңа өйләнешкән яшьләр дә, кагыйдә буларак, сәяхәткә чыгалар. Махсус туристик бюро акчаны алып куя да аларның кулына махсус китапчык бирә. Шул китапчык белән гостиницага да, музейга да, кафе-рестораннарга да түләүсез керәләр.

Безнең игътибарны аеруча җәлеп иткән тагын бер нәрсә — ул японнарның табигатькә булган мәхәббәтләре. Ул мәхәббәт искиткеч тирән, бер дә сүрелми, суынмый, киресенчә, кеше олыгая барган саен үсә, тирәнәя бара икән. Без булган унбиш шәһәрдә парклар күп түгел иде, ләкин аларны халык күз карасы кебек саклый. «Үз гомеремдә берәр кешенең агач ботагы сындырганын яки чәчәк өзгәнен, яки үләнне таптаганын һич хәтерләмим»,— диде бакчачы карт. Паркта халык гадәттә акрын гына йөри, берәр агач, чәчәк яки таш янында туктап, аңа сокланып карый. Менә бер япон хатыны әле бер таш, әле икенче таш янына килеп (ул ташлар безнең ике-өч кирпеч зурлыгында) озак кына карап торды. Мин тәрҗемәчегә: «Сорагыз әле зинһар, бу ташлар аңарда нинди хисләр уята икән?» — дидем. Әлеге ханым барлык япон хатын-кызларына хас булганча мөлаем итеп елмайды, кулларын күкрәгенә куеп, башын иде һәм тәрҗемәчегә озак кына сөйләде. Бер-ике сүз белән әйткәндә, ул аңа болай диган: «Бу ташлар бик борынгы булырга тиеш. Күрәсезме, аның менә бу кояш төшми торган ягы мүк белән капланган. Менә монтанрак караганда ул борынгы бронзаны хәтерләтә. «Нинди матур төс!» ди. Мин дә иеләм һәм соңгы 30 ел эчендә беренче тапкыр гади бер ташны зур игътибар белән карыйм. Ихтыярсыз бала чакларым искә төшә. Мин дә һәр чәчәк, һәр бөҗәк белән кызыксына идем бит, кош сайраганны хәйран калып тыңлый идем. Су буйларында үләндә ятып сәгатьләр буе елганы, узып киткән пароходларны, елга уртасында көймәдә сәгатьләр буе кымшанмыйча балык тотучы агайларны кызыксынып күзәтә идем. Никадәр җан рәхәте бирә иде ул минутлар! Нигә, олыгая башлагач, ул кызыксыну сүнде икән? Нигә мин язын сыерчыклар килгәнне, Иделдә боз кузгалганны үз күзем белән күреп түгел, бәлки газеталар аша гына беләм? Нигә мин балалыкка хас шул соклана белү тойгысын югалттым икән? Моның сәбәбе нидә?

Мин генә түгел, бик күп таныш-белешләрем дә шулай яши. Ярамый бит болай табигатькә ваемсыз карарга дим эчемнән генә.

— Сез рәссаммы әллә? — дим әлеге ханымга. Ул бик гади генә:

— Юк, мин балык кибетендә сатучы булып эшлим,— ди.

Менә кечкенә генә ясалма күл янында суга иелебрәк ике япон утыра. Мин башта алар балык тоталардыр дип уйлаган идем. Карыйм, кулларында бер нәрсә дә юк. Алар суда кояш нурларының чагылуын шулай игътибар белән карап утыралар икән. Японнар елның һәр фасылын — язын, көзен, җәен, кышын, һәр күренешне:

кояш чыкканны һәм батканны, ай калыкканны, яңгырны, карны, гомумән, табигатьнең барлык күренешләрен сокланып күзәтәләр икән. Бу ярату табигать күренешләрен тәрәзәдән карап утыру белән генә чикләнсә, бу турыда бәлки сөйләп торуның да кирәге булмас иде. Язын азалия, чия, кара җимеш агачлары чәчәк атканны, көзен тау өрәңгесенең янып торган кызыл һәм алтын кебек сары яфракларын, яки тулган айны күмәкләшеп, хозурланып күзәтү өчен завод-фабрикаларда, фирмаларда махсус автоколонналар оештырыла, хәтта махсус өстәмә поездлар, автобуслар җибәрелә икән.

Япониянең иң җылы дип исәпләнгән көньягындагы өйләрдә мичләр бөтенләй юк. Кышкы айларда, бигрәк тә давыллы-җилле көннәрдә мондый өйләрдә халык шактый туңа икән. Ләкин, шуңа карамастан, кар ява башласа, япон кешесе өенең бер стенасын шудырып ача да, кайнар чәй эчеп кар яуганны озак кына хозурланып карап утыра. Чөнки кар явуны ул бәйрәм итеп исәпли, аннан матурлык һәм җан рәхәте таба. Өе янында ике-өч метр чамасы гына буш урын булса, япон аны күреп туймаслык бакчага, сәнгать әсәренә әйләндерә. Шушы уч төбе кадәр җиргә ул, әлбәттә, бер-ике агач та утырта. Ләкин ул теләсә нинди агач булмый, юк. Иң матур, иң күркәм һәм биеклеге 1—1,5 метрдан артмаган агач була. Хуҗа аның артык ботакларын кисеп, аңа үзе теләгән форманы бирә. Андый кечкенә урында, билгеле, чәчәк, үлән күп булмый, әмма алар уйланып сайланган, кайдарак, ничек утыртылырга тиешлеге бик нык чамалап эшләнгән була. Җирне йомшарткач чәч тарагы белән тарыйлар микән әллә дип уйлыйсың, туфрак шул кадәр җентекләп, пөхтәләп эшкәртелгән була. Әгәр бакчаның мәйданы зуррак булса, мәсәлән, 7—8 квадрат метрга җитсә, анда инде мүкләнгән ике-өч ташка да урын табыла. Бу атаклы «Япон бакчалары» японнарның табигатькә булган олы мәхәббәтләрнең күркәм бер чагылышы дияр идем мин. Японияне өйрәнгән бик күп белгечләр «матурлык культы — японнарның милли дине» диләр. Бу сүзләрдә хаклык бар. Юл тирәләрендә бүрек кадәр генә чокыр хасил булса да, кемдер аның төбенә төрле-төрле вак ташлар тезә. Бу чокырга су тулып торса, аңа бер-ике кечкенә балык җибәрә. Чокыр янына бер-ике зур таш куя да бу урын табигатьнең матур бер почмагына әйләнә. Бу чокырны инде кешеләр генә түгел, хәтта зур-зур машиналар да әйләнеп уза башлыйлар. Һәр буш урын әнә шулай файдаланыла.

Японнарның табигатькә булган мәхәббәтләренә тагын бер мисал. Күптән түгел «Известия» газетасында бер хәбәр басылган иде. Япония балыкчылары Осака култыгында Филиппин утравыннан очып килгән, туңып тәмам хәлдән тайган диңгез акчарлагын тотып алалар да аны Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшыралар. Министрлык эшчеләре акчарлакны Япониянең Филиппинга очарга тиешле самолетының экипажына биреп, аны Филиппинга алып китүләрен үтенәләр. Әмма Филиппинга барып җиткәч, чик сакчылары кошны кертергә рөхсәт итмиләр, чөнки кошның сәламәт булуы турында белешмә кирәк икән. Аның әллә нинди авыру йоктыруы мөмкин бит. Шуннан соң экипаж ул акчарлакны... яңадан Япониягә алып кайта.

## «Мадам Баттерфлай» өендә

Атаклы итальян композиторы Джакомо Пуччини 1904 елда «Мадам Баттерфлай яки Чио-Чио-Сан» исемле мәшһүр опера яза. Бөтен дөньядагы опера театрларының репертуарларына кергән бу операда композиторның иҗатына хас булган драматик коллизия япон экзотикасы белән бизәлгән. Һәм менә без язучы Лонг новелласы һәм

Беласко драмасы нигезендә композитор тудырган образның... «өенә» барабыз! Бәләкәй генә япон өе, кечкенә генә бакча. Бакчада сакура агачлары чәчәк атып утыра, гөлләр эчендә — кечкенә генә эскәмия. Бакча кичен япон фонарьлары белән яктыртыла икән. Бу чын гашыйклар почмагы. Менә агачлар арасыннан чибәр Чио-Чио-Сан килеп чыгар да, кулларын күкрәгенә куеп, үзенең зур өметләр белән тулы атаклы ариясен җырлап җибәрер кебек:

Өзелеп көткән көн дә житте,
Безнең кайгы үтеп китәр...

Әмма өметләр акланмый. Чио-Чио-Сан үзен-үзе юк итә. Менә бирелә аның кабере дә бар: кабер ташына аның исеме дә язылган, тик туган һәм үлгән еллары гына күрсәтелмәгән.

— Сорауларыгыз бармы? — ди гид. Без, ни дияргә дә белмичә, бер-беребезгә карыйбыз. Язучы белән композитор иҗатында гына яшәгән образның кабере янында басып торганда үзеңне сәер хис итәсең икән. Кайгырыргамы, әллә елмаергамы?..

Эчтәрәк бер йорт бар. Аны XIX гасырда инглиз Томас Гловер салдырган булган. Һәм гаиләсе белән ул анда күп еллар яшәгән. Үзенең атаклы операсын Пуччини шушы Гловер йортында язган. Соңгы елларда Гловерның йортын музейга әйләндергәннәр. Аның янына Чио-Чио-Санның «өен» дә салып куйганнар. Туристларның күбесе Гловер йорты белән түгел, шушы кечкенә йорт белән кызыксына икән.

Америкалылар атом бомбасы белән Япониянең ике шәһәрен яндырдылар. Шул ике шәһәрнең берсе — Нагасаки. Биредә тынычлык паркында зур һәйкәл бар. Ул һәйкәл шушы явызлыкка халыкның нәфрәте, сугышка каршы протесты булып тора. Бирегә меңнәрчә японнар киләләр, һәйкәлгә гөлләр куеп, бер мизгел аның янында башларын иеп басып торалар.

Нагасакида туристларның игътибарын тарта торган музей, храмнар шактый күп. Шуларның берсе Конфуций храмы. Ул сугыштан соң салынган. Алтын бизәкләрдән ялт-йолт итеп торган храмда без барганда халык күп иде. Күп тә узмады, сәхнә кебек биек урында дракон биюен башкардылар. Нинди урын бу: гыйбадәтханәме, әллә театрмы? Бу сорау безнең башка еш кына килә иде. Дин мәсьәләсе дә Япониядә гаять үзенчәлекле. Биредә күп кенә урында ике дин храмнары: буддистлар һәм синтоистлар храмнарын янәшә салганнар. Бу ике диннең фәлсәфәсе ике төрле. Будда тәгълиматы буенча тормыш газаплардан гыйбарәт. Моның сәбәбе тормышка ашмаган теләкләр. Газапланмас өчен гомер буе үзеңнең теләкләреңне басарга, аларга ирек бирмәскә кирәк. Синтоизм исә дөньяда барлык нәрсәнең: тауның да, чәчәк атып утырган гөлнең дә, чылтырап аккан чишмәнең дә җаны бар, димәк, алар бар да изге, ди. Һәрбер изге нәрсә алдында баш ияргә, табигатьнең һәр күренеше белән хозурланырга кирәк. Японнар бер-берсенә һичбер нинди охшашлыгы булмаган шушы ике диннең икесен дә кабул иткәннәр. Бер үк кеше ике динне дә тота. Әгәр аның тормышында шатлыклы вакыйга булса, мәсәлән, ул өйләнсә, яки аның баласы туса, ул аны күтәреп синто храмына бара. Әгәр инде аңа берәр төрле кайгы килсә, аның якын кешесе үлсә, ул Будда храмына бара. Динчеләр дә бу бүленешкә өйрәнгәннәр. Һәр икесе шул чыганаклардан килгән акчага яши.


Буддистларның храмнары зур, биек, әмма ни өчендер караңгы. Бөтенләй тәрәзәсез зур бинада кеше кыяфәтендә һәм шул зурлыкта эшләнгән йөзләрчә, кайберләрендә меңнәрчә Будда сыны сыңа карап тора. Син үзеңне мәетләр арасында йөргән кебек хис итәсең...

Бу исем күңелгә шом сала. Американлылар 1945 елның 6 августында иң беренче атом бомбасын шушы шәһәргә ташлыйлар. Шәһәр домна миче кебек дөрләп яна башлый, чирек миллион кеше һәлак була. Чирек миллион! Әйтүе генә җиңел. Әллә ничә йөз мең кеше гарип булып кала.

Бу фаҗигадән соң инде күп еллар узган. Бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең игътибарын үзенә тартып торган бу шәһәрне торгызуга, төзекләндерүгә күп көч куйганнар. Ул яңача, заманча салынган, Япониянең башка шәһәрләреннән нык аерылып тора. Урамнар, проспектлар бик киң, парклар, бульварлар, стадионнар бик зур. Таштан салынган биек йортлар бик күп. Кичен меңнәрчә кафе, ресторан, мюзик-холларның аллы-гөлле утлары кабына...

Атом бомбасы шартлаган урында йөрибез. Хәзер бирәдә бик матур парк.

Һәлак булганнарга бирәдә берничә һәйкәл куелган. Беренчесе — атом бомбасы шартлаган урында, аның эпицентрында. Һәлак булган 240 мең кешенең мәетләрен яндырып, көлләрен шушы һәйкәл астына салганнар.



Хиросима шәһәрендә атом бомбасыннан һәлак булган балаларга куелган һәйкәл.

Һәйкәлләрнең берсе снаряд рәвешендә эшләнгән. Аның өстендә кулына торналар тоткан бала фигурасы басып тора. Бу һәйкәл япон халкында яшәп килгән легенда белән бәйле. Авыру кеше үз кулы белән кәгазьдән 10 мең торна ясаса, терелә, имеш. Садака исемле япон кызчыгының атом бомбасыннан тәне бик каты пешә. Ул тәне әрнүдән йоклый алмый, каты ыңгыраша. Шулай да госпитальдә ул хәлсез куллары белән ашыга-ашыга кәгазьдән торналар ясый.

Кайберәүләрнең моны юк-барга ышану дип аңлаулары мөмкин. Әмма бу легенда аша халык сабыр булырга, нинди генә кыенлыкларга юлыкканда да коелып төшмәскә, өметне өзмәскә өнди. Бу кызчык та, хәле авыр булуга карамастан, өмет белән яши.

Менә ул ясаган торналарның саны 5 меңгә җитә. Бераздан 5 мең

700 була, әмма кызчыкның хәле һаман авырая. Ул инде тора да, башын да күтәрә алмый. Шулай да хәлсез куллары белән эшен һаман дәвам иттерә. Япон газеталары бу турыда язып чыккач, бөтен ил балалары, кызчыкны терелтү өчен, ул яткан госпитальгә меңнәрчә кәгазь торналар җибәрәләр. Әмма Садакага инде беркем дә ярдәм итә алмый.

Һәйкәлдәге бала фигурасы: «Без һәлак булдык. Әмма башкаларны саклагыз!» дип кисәтә төсле.

Биредә 200 врачка һәм медсестрага куелган һәйкәл бар. Бу врачлар һәм сестралар, Хиросимадагы фаҗигане ишетеп, Япониянең төрле почмакларыннан ярдәмгә ашыккан кешеләр. Әмма Хиросима хәрабәләре һәм яраланган кешеләр бик күп көннәр, айлар, ә кайбер белгечләрнең сүзләренә караганда, еллар буена тирә-якка үлем таратып торганнар. Ул вакытта әле радиоактив нурланыш авыруларыннан саклану чаралары да, аннан дәвалану ысуллары да билгеле булмаган. Шул сәбәпле, ярдәмгә килгән врачлар үзләре дә һәлак булганнар. Ерак та түгел мемориаль музей. Биредә тиресе кубып төшкән кешеләрнең чәчләре, тешләре коелган нәниләрнең фотолары тетрәтә. Безгә иң каты тәэсир иткәне — кеше шәүләләренең фотолары булды.

Хиросиманы «Япон Венециясе» дип атыйлар, чөнки шәһәрне аркылыга-буйга каналлар һәм Ота елгасы кисеп уза. Бу елга һәм каналлар буенда бөдрә таллар шәһәргә гаҗәеп ямь биреп торганнар. Америка офицеры бомбаны әнә шул таллар арасыннан күренеп торган Ота елгасы аша салынган Айой күперенә төбәп төшергән. Бу вакытта күпер аша велосипедчылар узып бара икән. Бомба нәкъ алар турысында җирдән 570 метр биеклектә шартлый. Әлеге велосипедчылар велосипедлары белән бергә күз ачып йомганчы янып, парга әйләнәләр, тик аларның күпер култыксасының исән калган ташына төшкән шәүләләре генә мәңгегә сакланып кала. Кеше шәүләләре... Музейдагы бу ташлар янында, экскурсантлар, гадәттә, ни әйтергә белмичә, тетрәнеп калалар. Һәлак булган кешеләрнең шәүләләре иң шомлы һәйкәлләрнең берсе дияр идем мин. Узган фаҗиганең шаһите булып, елганың икенче ягында сәүдә палатасының хәрабәләре калган. Халык аны «Атом йорты» дип атый икән. Кайчандыр бу бинада күргәзмәләр оештырыла торган булган. Хәзер ул үзе экспонатка әйләнгән.

Беренче карашка Хиросимада яралар төзәлгән кебек. Шәһәр матур, урамнары халык белән тулы, ресторан-кафелар гөрләп тора. Әмма халык моннан чирек гасыр элек булган бу фаҗигане һич онытмый, дөресрәге, оныта алмый икән, чөнки бу фаҗиганең тәмамланганы юк, ул әле һаман дәвам итә. Хиросима муниципалитетының тикшерүләренә караганда, ире яки хатыны атом фаҗигасен кичергән семьяларның яртысында бала булмый. Хәтта бомба шартлагач беренче өч көндә Хиросимага килгән кешеләрнең дә 62 процентында бервакытта да бала булмаячак икән. Атасы яки анасы бу фаҗигане кичергән семьяларда туган ун баланың берсе я акыл ягыннан, я физик яктан нормаль түгел. Эпицентрдан еракта булган кешеләр дә авыр газаплар кичерәләр. Киккави исемле кеше, мәсәлән, бомба шартлаганда эпицентрдан километр ярым ераклыкта булган. Әмма аңа больницада 6 ел ятарга, 14 операция ясатырга туры килгән. «Калган гомеремне Хиросиманы кабатламау өчен көрәшкә багышладым»,— ди ул. 46 яшьлек шагыйрь Мунэтоси Фукагава — җиде китапның авторы. Бу китапларның барысы да Хиросимага багышланган. Тәнкыйтьчеләрдән берәү: «Шартлаудан соң 20 елдан артык вакыт узды бит. Бәлки сезгә яңа темаларга күчәргә кирәктер. Япон лирикасы элек-электән язга, чәчәкләргә, Фудзи тавының гүзәлле-

генә багышланган аһәңле шигырьләре белән дан тота ич!» дигәч, шагыйрь: «Мин инде беркайчан да башка нәрсә турында яза алмаячакмын. Мин үлгәнче Хиросима турында язачакмын!» — дип җавап биргән.

Тынычлык паркындагы һәйкәл янышнан кеше өзелми. Монда делегацияләр дә, Хиросима халкы да күп килә. Япон хатыннары, ирләр, балалар, һәйкәлгә чәчәк салгач, башларын иеп басып торалар. Менә һәйкәл янына сигез-тугыз яшьлек кызын ияртеп, егерме тугыз-утыз яшьләрдәге япон хатыны килеп басты, һәйкәлгә бер сабак сакура чәчәген куйды. Бер мизгел башын иеп басып торганнан соң, акрын гына безнең янга килеп утырды. Тәрҗемәчебез кызчыктан: «Анда синең кемең ята?» — дип сорады. «Әбием»,— диде кызчык. «Әбиең ничә яшьтә иде соң?» — дип сорагач, кызның әнисе: «26 яшьтә иде», ди. «Мин ул вакытта 6 яшемдә булганмын. Мине әтиемнең әнисе авылга кунакка алып киткән булган. Шуңа күрә генә исән калганмын. Шул сәбәпле кызым да исән-сау туды. Әтием белән ике абыем әле дә авырыйлар, бернинди эшкә ярамыйлар»,— ди ул күңелсез генә.

Без атом бомбасы корбаннары өчен ачылган госпитальдә булдык. Мине кечкенә генә бер деталь тетрәтте. Япон халкы бик чиста. Өйгә, мәктәпкә, милли ресторанга һәм хәтта кайбер магазиннарга да аяктан салмыйча керергә ярамый. Ә бу госпитальгә кергәндә исә аяк киемен генә түгел, өс киемен дә салдырмадылар. «Карарга кешесе булмаган каты авырулар гына ята,— ди врач.— Моннан бер генә юл бар, ул да булса зиратка».

Үлем көтсәләр дә, боларның, ичмаса, ятарга урыннары, ашарга ризыклары бар. Ә бит бомба шартлаудан тагын 100 меңләп кеше бөтен гомеренә авыру булып калган. Ләкин бомба шартлаганда алар эпицентрдан ерак булганга, хөкүмәт аларны дәүләт хисабына дәваламый да, карамый да. Аларның яшәргә өйләре, ашарга ризыклары, дәваланырга акчалары юк. Эшкә кергәндә дә алар үзләренең авыру булуларын яшерәләр. Бу авыруларны «хибаси» дип атыйлар. Хибасиларга эш табу бик авыр. Алар тимер-томырлардан корыштырып ясалган алачыкларда, коточкыч шартларда яшиләр.

Хиросимада атом бомбасыннан һәлак булганнарның һәйкәленә: «Тыныч йоклагыз. Бу — кабатланмас»,— дип язылган.

## Автомобиль заводында

Еш кына капиталистик илләрнең матбугаты Японияннең үсешен «экономик могҗиза» дип атый. Икенче бөтен дөнья сугышы Японияннең экономикасына зур зыян китергән иде. Сәүдә флотының 80% ы дип әйтерлек батырылды, бомбага тотудан шәһәр районнарының 40% ы зарарланды, производство күләменең 30% ы җимерелде. Ә атом бомбасыннан Хиросима шәһәре бөтенләй җимерелде. Нагасаки шәһәре нык зарарланды. Сугыштан соң илне АКШның кораллы көчләре оккупацияләде. 1950 елда промышленностьның эшләп чыгару дәрәҗәсе 1934—39 елларныкыннан түбән иде. Ләкин соңгы елларда Япония экономикасы аякка басты. 1950 елларда империалистик конкурентларыннан артта сөйрәлгән Япония 1960 елларга аларны куып җитте, ә соңгы елларда аларның күбесен узып та китте.

Бүгенге көндә ул суднолар төзү, кино-фотоаппаратура, химик сүс эшләп чыгару буенча капиталистик илләр арасында беренче урынга, корыч кою, электрон аппаратура, сульфат кислотасы, ясалма ефәк эшләп чыгару буенча АКШтан кала икенче урынга, электр

энергиясе эшләп чыгару һәм китаплар басу буенча өченче урынга чыкты.

Ә менә кеше башына туры килә торган милли доход буенча Япония 12 нче урыннан күтәрелә алганы юк әле.

Японияне̦ң тиз үсеп китүене̦ң берничә сәбәбе бар. Болар арасында чит илләрдән әзер патентлар сатып алып, промышленностьны фән-техника яңалыклары нигезендә үзгәртеп кору ысулы өстенлек итә.

Мин биредә барлык сәбәпләр турында сөйләмичә, бары берсенә генә тукталасым килә. Ул да булса, Япония капиталистларының эшчеләр сыйныфын башка капиталистик илләрдәгегә караганда ныграк эксплуатацияләве. Бу мәсьәләне аңлап җиткерү өчен, әлбәттә, ике-өч заводка кереп чыгу гына җитми. Шулай да зур капиталистик предприятиеләрдә күп нәрсә күзгә ташлана, күп нәрсә гаҗәпкә калдыра. Японияне̦ң автомобиль промышленносте җиде фирма кулында. Менә шул фирмаларның берсенә — «Тое когё» фирмасының Хиросимадагы автомобиль заводына барабыз. Ул һәр көнне 1800 машина чыгара икән. Завод бик зур, ул 650 акр[1] мәйданны алып тора, заводта 27 мең кеше эшли. Металл эретүдән башлап уенчык кебек ялтырап торган әзер машиналар чыгаруга чаклы барлык процесслар шушы заводка тупланган. Без заводның барлык цехларында да булдык. Цехларда һәм ишегалдында, беркайда да өелеп яткан агач, металл һәм башка нәрсәләр юк. Тиешле нәрсәләр бар да складта булса кирәк. Чисталык. Ишегалдында, коридорларда бер генә кеше дә очрамады. Барысы да эш урынында. Берәр әйбер күтәреп, я эзләп йөргән кеше дә юк. Вак әйберләрне автокарлар белән илтәләр.

Менә без җыю цехында. Биредә машинаны җыялар, буйыйлар һәм ул инде цехтан «үз аягы» белән чыгып китә.

Бик озын цехның бер башыннан икенче башына кадәр конвейер сузыла. Ләкин конвейер идәнгә түгел, эстакадага куелган. Эшчеләр сәхнәдәге кебек: аларның һәр хәрәкәте күренеп тора. Барлык эшчеләрне̦ң башында, өстендә, аягында күк төстәге эш киеме. Күрше цехтагы эшчеләрне̦ң өстендә кызыл, аннан алдагысында яшел төстә иде. Димәк, эшче икенче цехка керсә, ул мастерга әллә кайдан күренеп торачак.

Конвейердан читтә бер кеше юк. Менә эшчеләрне̦ң берсенә каядыр китәргә кирәк булган икән. Ул телефоннан мастер әфәндене чакырган. Күп тә үтмәде, цехның икенче башыннан яхшы костюм кигән мастер әфәнде килде, эшчене̦ң урынына басты һәм кул сәгатенә карады. Эшче йөгерә-йөгерә китте. 8—10 минут узмагандыр, ул йөгереп килеп тә җитте, берничә тапкыр иелеп, рәхмәт әйтте һәм урынына басты. Стеналардагы плакатларда: «Цехта эшкә кагылышы булмаган мәсьәләләр турында сөйләшергә рөхсәт ителми», «Мастер рөхсәтеннән башка эш урыныннан кузгалырга ярамый», дип язылган. Бер генә цехта да (конвейер булмаганнарында да) сөйләшеп яки тәмәке тартып торган эшче күрмәдек. Сигез сәгать эш вакытының бер генә минуты да югалмый икән. Цехларда буйдан-буйга платформа сузыла. Мастер эшне шуннан күзәтә икән. Эшчеләр арасында 40 яшьтән олыларны күрмәдек. Соңыннан дирекция залында очрашу вакытында шул турыда сорау биргәч, Тусико Тамафура әфәнде: «Кырыктан олыларга бездә эшләү кыен, шуңа күрә алар үзләре китәләр»,— диде. Үзләре китәме, әллә җибәрәләрме, ул хәтлесен без белә алмадык. «Пенсия» түләү системасы түбәндәгечә оештырылган: һәр айны эшчене̦ң хезмәт хакыннан 10% ын тотып калалар. Заводтан киткәндә аңа шул җыелган акчаны кире бирәләр. Шул

[1] Акр — 4046,86 м².

пенсия дип атала. Эшче аны берьюлы аламы, әллә аз-азлапмы, ул хәтлесе аның үз эше. Кыскасы, эштән киткәндә, эшченең, җыелган акчаны кулына тоттыру белән, завод хуҗалары да, дәүләт тә аның белән араны өзәләр. Исәнме ул, юкмы, ашарына бармы, юкмы? — ул ягы белән кызыксынган кеше булмый икән.



## Легендар Зорге эзләреннән

Рихард Зорге яшәгән урыннарны күрү, ул йөргән юллардан узу мөмкинлеге Токиога барып җитәр алдыннан ук дулкынландыра башлаган иде. Билгеле, Япониядә унбер ел[1] яшәвенә карамастан, сәяхәтләр бюросы төзегән маршрутта Советлар Союзы Герое Рихард Зоргеның исеме телгә дә алынмаган иде. Шулай да без өметне өзмәдек. Зоргеның кабере бирeдә, аны күреп китү үзе ни тора. Ләкин һич көтмәгәндә зур бәхеткә юлыктык: безнең теплоходка кунак булып Рихард Зоргеның якын дусты Исии ханым Хонаки килде. Легенда белән очрашкан кебек булдык.




Токио шәһәре янында Рихард Зорге кабере.

Бөек Ватан сугышы миллионнарча яшьләрне яңадан-яңа җиңүләргә рухландыра алырлык бик күп батырлар бирде. Шулар арасыннан берничә кеше: рус кешесе Кузнецов, татар Муса Җәлил һәм немец Рихард Зорге мине аеруча сокландыра. Без аларның исемнәрен һәр вакыт горурланып искә алабыз. Дошманның үз оясында эшләделәр бит алар. Ай түгел, ел түгел, берничә еллар! Кем икәнлекләрен дошманга түгел, дусларга да әйтергә ярамады.

Рихард Зоргеның кем икәнен без үзе үлгәч, берничә елдан соң гына белдек. Ул Карл Маркс белән Фридрих Энгельсның көрәштәше Фридрих Зоргеның оныгы булган икән.

Рихард Зорге 1895 елда Бакуда туган. Егерменче елларда аларның гаиләсе Германиягә күчеп киткән. 1924 елда Рихард Зорге Советлар Союзына кайта. Утызынчы еллардан башлап ул, Ватанның кушуы буенча, Германиядә һәм Япониядә эшли башлый. Берничә телне ана теле кебек белгән, тирән белемле, талантлы журналист, коммунист Рихард Зорге бөтен тормышын хезмәт ияләренең социалистик Ватаны булган СССРны саклап калу өчен гаять әһәмиятле, авыр һәм куркыныч эшкә — разведка эшенә багышлый. 1933 елда ул фашистик Германиядә чыга торган «Франкфуртер цейтунг» газетасында эшли һәм аның махсус хәбәрчесе булып Япониягә китә. Бирeдә ул фашистик Германия илчелегенең иң ышанычлы кешесенә әйләнә. Илче аңа Берлиннан килгән барлык яшерен кәгазьләрне укыта, илчелекнең эше турындагы барлык җавапларны Рихард Зоргедан яздыра. Менә шул чорда Рихард Зорге үз Ватанына — Советлар Союзына гаять әһәмиятле хәбәрләр җибәреп тора. Ул фашистлар Германиясенең СССРга каршы сугышка әзерләнүен, сугышның

[1] Шуның өч елы төрмәдә узган.

кайчан башланырга тиешлеген [1], сугыш алдыннан, 1941 елның җәендә, СССР чикләрендә аның ничә дивизиясе тупланганлыгын хәбәр итә. Сугыш башлангач, илебезнең җитәкчеләрен бер мәсьәлә борчый: Япония СССРга каршы сугыш ачармы, әллә юкмы? Моны белү гаять әһәмиятле иде, чөнки Япония ул елларда аеруча агрессив иде, 1938 һәм 1939 елларда ул СССРга зур көчләр белән бәреп керде һәм җимергеч отпор алу аркасында гына тынып калган иде. Шуңа күрә илебез көнчыгышта шактый күп кораллы көчләр тотарга мәҗбүр иде. Зорге бик күп көч куеп, япон империалистларының планнарын белә. Алар СССРга каршы түгел, үзләренең көчле конкурентлары булган АКШка каршы сугыш ачарга җыеналар икән. Бу турыда Мәскәүгә хәбәр китә. Шуның нәтиҗәсендә 1941 елның декабрендә Мәскәү янындагы атаклы сугышларда Ерак Көнчыгыш, Себердән килгән бик күп частьлар катнаша. Себер магистрале буйлап Мәскәүгә солдатлар, танклар, артиллерия, самолетлар төягән эшелоннар өзлексез агыла башлый.

Шундый әһәмиятле мәгълүматларны Япониядән СССРга хәбәр итүләрнең никадәр авыр икәнлеген күз алдына китерү дә кыен. Мәгълүм булганча, ул елларда Япония хөкүмәте фашистик Германиянең «ахирәт дусы» иде. Фашистик Германия җиңсә, хәтта Мәскәүне алуга ук, Япония империалистлары Ерак Көнчыгыштан үзләренә кирәкле җирләрне умырып алырга әзер торалар иде. Шушы шартларда бу планнарны фаш иткән кешенениләр көтүе көн кебек ачык иде.

Үлем Рихард Зоргеның эзеннән йөргән, ул моны белгән һәм коммунист Рихард Зорге сугышны булдырмау, җир шарында беренче социалистик дәүләтне саклап калу өчен тормышын корбан итәргә һәр вакыт әзер булган.

Япония полициясе аны 1941 елның октябрендә кулга алган. Тагын 35 кешене кулга алып, шуның 17 сен җавапка тартканнар. Хәтеребездә, ике ел авыр допрос барды. Зоргены «Коминтерн агенты», «Япония дәүләт строен җимерергә теләүче» итеп күрсәтергә, Зоргедан шул сүзләрне әйттерергә теләделәр. Ул бер фикерне кабатлады: «Мин бары сугыш булмавын, СССРга каршы Япониянең сугыш ачмавын гына теләдем»,— диде. 1943 елны аларның икесен: Рихард Зорге һәм күренекле япон журналисты Хоцуми Одзакины үлем җәзасына хөкем иттеләр. Алар тугыз ай үлем көтеп яттылар. Төрмә шартларының никадәр авыр булганын күрсәтү өчен бер генә мисал китерү дә җитәдер: 17 кешенең бишесе төрмәдә үк үлә. Рихард Зоргены һәм Хоцуми Одзакины 1944 елның 7 ноябрендә асып үтерәләр. Фашист инквизиторлары бу көнне махсус сайлыйлар.

(1974 елда Рихард Зоргеның һәлак булуына 30 ел тула.) Приговорны укыгач, Рихард Зорге баса да немец телендә: «Соңгы сүземне әйтергә телим»,— ди. Аннан соң япон теленә күчеп: «Коммунистлар партиясе, Советлар Союзы һәм Кызыл Армия яшәсен!» — ди.

Ул заманнардан соң инде Токио үзгәргән, кайбер йортлар сүтелеп, алар урынына яңа биналар салынган. Ләкин кайберләре исән. Мәсәлән, Токионың үзәк урамы Гинзада җиде катлы йорт бар. Заманында биредә Дамэй Цусин агентлыгы урнашкан булган. Рихард Зорге көн дә шунда килә торган булган. Менә «Ginza Tokyu Hotel». Элекке исеме «Тэйкоку». 1933 елда, фашистик Германия газетасының махсус хәбәрчесе булып Токиога килгәч, Рихард Зорге башта шушы отельдә яшәгән. Бинаны иркенләп карап булмый, урам-

[1] 1941 елның 15 маенда ул түбәндәге телеграмманы җибәрә: «Германия СССРга 20—22 июньдә һөҗүм итәчәк. Рамзай»; 15 июньдә җибәргән хәбәрендә ул: «Һөҗүм киң фронт буйлап 22 июньнең таңында башланачак»,— ди.

нан машиналар, тротуардан бик күп халык агыла. Ишекнең бронзадан ясалган тоткасыннан ачып вестибюльгә керәм. Керүем була, өч-дүрт япон (берсе швейцар, калганнары кемдер) урталай бөгелеп мине каршы алалар. Минем тәҗрибә бар инде: керүгә мин ашыкмыйча, вәкарь белән генә татарча сөйли башлыйм.

Японнар чит ил кунагын урталай бөгелеп озак кына сәламләгәндә, мин сөйләвемне дәвам итеп, вестибюльне карыйм. Монда бөтенләе белән химия хакимлек итә: идән аяк тавышын йота торган синтетик келәм белән капланган. Тәбәнәк кызыл креслолар, каракөрән төстә тәбәнәк диваннар һәм шундый ук тәбәнәк ялт-йолт итеп торган өстәлләр. Бернинди люстра-лампалар юк, түшәмнән һәр якка күзне чагылдырмый торган тигез яктылык сирпелә. Бар да яңа, бар да химиянең соңгы казанышларының җимешләре.

Бу келәмдә Зоргеның эзләре юк. Әмма ул каршыдагы мәрмәр баскычтан ничәмә-ничә тапкырлар төшкәндер. Бу биек тәрәзәләр янында ул уйланып урамга карап торгандыр. Кем белә, бәлки ул шушы ишек яңагына да таянгандыр. Мин әкрен генә ишек яңагына таянам һәм моннан күп еллар элек булган вакыйгаларны күзалларга тырышам.

Менә японнарның гәүдәләре турая һәм мин аларның дымлы карлыган кебек чем-кара күзләрендә сорау галәмәте күрәм.

«Сез мине аңламыйсыз инде, нишләп тә булмый, китәргә мәҗбүрмен»,— дим татарча һәм башымны иеп, саубуллашып чыгып китәм. Алар янә урталай бөгелеп мине озатып калалар.

Безнең Токиога килүебезгә бишенче көн. «Бүген безгә кунак булып Рихард Зоргеның дусты — Исии Хонаки ханым киләчәк»,— диделәр. Токио да, аның экзотик урыннары да, музейларны хәтерләткән кибетләре дә онытылды. Сәгать өчләр иде. Палубага бер төркем японнар күтәрелде. Алдан урта буйлы, 55 яшьләрдәге, зифа гәүдәле чибәр япон хатыны атлый. Европача киенгән. Өстендә көрән костюм, дулкынланып торган чәчләре җилкәсенә төшкән. Күзләре яшьләрнеке кебек һәркемгә кызыксынып карыйлар. Япон хатыннарына хас булганча гел елмая. Менә без дәррәү кул чабабыз. Ул, кулларын күкрәгенә куеп, бөгелә-бөгелә өзлексез баш ия.

Исии ханымны алып килгән гид безгә: «Сезне Рихард Зоргеның хатыны Исии Хонаки белән таныштырырга рөхсәт итегез»,— диде. Япон хатыннары бик тыйнак, күп сөйләмиләр. Исии ханым да безнең сорауларга баш кагып кына яки «ие», «ие» дип кенә җавап бирә, өстәп бернәрсә дә сөйләми. «Искиткеч талантлы, тирән белемле кеше иде ул. Бездә аны бик күп кеше хөрмәт итә»,— диде. Чыннан да Япониянең прогрессив интеллигенциясе арасында Рихард Зорге хәзер дә бик популяр кеше икән. Мәсәлән, француз режиссеры Ив Чампи куйган «Кем сез, доктор Зорге?» фильмында баронесса Сакураи ролен башкарган Кейка Киси (аны бирелә «Япония киносының иң зур йолдызы» дип атыйлар) «Литературная Россия» корреспонденты белән сөйләшкәндә Рихард Зорге турында болай дигән иде: «Мин Рихард Зоргега гашыйкмын. Ул философ. Зур масштаблы политик. Талантлы журналист. Социолог һәм экономист. Дипломат. Революционер. Лингвист. 1941 елның 18 октябренда аны кулга алырга килгән полицейскийлар аның өстәлендә XVI гасырда яшәгән япон шагыйренең шигырьләр җыентыгы күрәләр. Минем Зоргены яхшы белгән бик күп кешеләр белән сөйләшкәнем бар. Алар аның турында сөйләгәндә күз яшьләрен тыя алмыйлар. Япониядә Зоргены үз геройлары итеп саныйлар. Зорге да, аның Япониядәге дуслары да Японияне һәм дөньяны сугыштан коткарып калырга тырыштылар. Алар үз ватаннарын яраталар һәм сугышның Япония халкына һәлакәт һәм газаплар алып киләчәген беләләр иде, шуңа күрә алар

фашизмны җиңү өчен үз-үзләрен аямадылар. Менә шуңа күрә «Кем сез, доктор Зорге?» фильмында япон һәм француз драматурглары Убуката һәм Виллербю, немец һәм япон актерлары Томас Хольцман һәм Якира Ямануци кулга-кул тотынышып эшләделәр».

Исигк ханымга без илебездән алып килгән сувенирлар бүләк иттек, аның белән рәсемгә төштек. Вакыт күбрәк булса һәм аның белән болай җыелышта түгел, кайдадыр тынычрак урында очрашсаң, ул, әлбәттә, Зорге турында күп нәрсә сөйләр иде. Ләкин без — туристлар, безнең озын-озак сөйләшеп торырга вакытыбыз юк. Ике сәгать тә үтмәгәндер, без аның белән саубуллашырга мәҗбүр булдык.

Менә Токионың читендә (бистәсендә дип әйтергә була) Тама-боти каберлеге. Японнарның каберлекләрендә гадәттә зур-зур һәйкәлләр дә, челтәрле-челтәрле рәшәткәләр дә, хәтта ихата да булмый икән. Кабер янында күмелгән кешенең исеме язылган кечерәк таш багана гына тора. Биредә Япониянең йөзләрчә антифашистлары җирләнгән.

Менә эшкәртелмәгән соры таш. Аңа немецча һәм японча «Рихард Зорге» дип язылган. Таш өстендә кара мәрмәр плитә. Аңа русча: «Герой Советского Союза Рихард Зорге» дигән сүзләр уелган. Кабер янында гөлләр, куаклар, ерак та түгел, мәһабәт наратлар үсеп утыра. Вазаларда чәчәкләр. Зорге кабере янында, уңда аның группасының һәлак булган членнарының исемнәре язылган стена. Сулда кара мәрмәр обелиск. Аның икенче ягында иероглифлар белән түбәндәге сүзләр язылган: «Мияги мәетенең көле, күп еллар чит илләрдә яткач, туган иленә кайтты».

Мияги — талантлы япон художнигы, Зорге группасы геройларының берсе. Подпольеда эшли башлаганда аңа утыз, кулга алынганда 38 яшь була. Кырык яшендә аны төрмәдә газаплап үтерәләр. «Сугыш еллары булганга мин асачакларын белә идем. Шулай да группада калдым, чөнки мин Япония белән Россия арасында сугыш булуын теләмәдем, бу сугышны булдырмас өчен бөтен көчемне куеп көрәшергә булдым»,— дип язган ул.

Газиз гомерләрен фашизмга каршы, сугышка каршы көрәшкә багышлаган батырларның һәлак булуына 1974 елның 7 ноябренда 30 ел тула. Күп еллар узса да, халык аларны онытмый, һәр көнне каберләренә куела торган тере чәчәкләр моның шаһите.

## Япон хатын-кызлары

Япон хатын-кызларының үзләрен бик итагатьле, тыйнак тотулары турында күп китаплар укырга туры килгән иде. Бу язмаларда еш кына япон хатын-кызларын «курчак кебек» дип атыйлар.

Чыннан да, әлеге чагыштыруда дөреслек бар. Кечкенә буйлы, нәфис гәүдәле, чәчен һәр вакытта бик матур итеп тараган, чиста, килешле, ыспай киенгән, үзен бик тыйнак тотучы япон хатыны киштәгә куела торган статуэткаларны хәтерләтә. Әмма карап торуга чамадан тыш нәзберек, нәфис күренсәләр дә, япон хатын-кызлары бик уңган, тырыш, күп эшлиләр икән. Япон йорты бик чиста, анда аяк киемен салмыйча керергә ярамый. Оек кигән булсаң, оекчан, туфли генә кигән булсаң, ялан аяк кереп китәргә мәҗбүр буласың. Хәер, ишек төбендә башмаклар тора. Өйдә берничә бүлмә, кухня, туалет булса, аларның һәрберсенә махсус аяк киеме киеп керергә кирәк.

Башка илләрдәге кебек монда да халыкның күпчелеге европача киенгән, әмма күп кенә хатын-кызлар милли киемнән — кимонодан йөриләр. Бу бик тар һәм озын итеп тегелгән кием вак-вак атлап

йөрергә мәҗбүр итә. Һәм, әйтергә кирәк, кечкенә буйлы, нәфис гәүдәле япон хатын-кызларына болай йөрү бик килешә. Алар тагын да нәфисрәк булып күренәләр.

Өендә кунак көтәме яки ирен каршылыймы, алучыга кибеттә товар күрсәтәме, яки урамда синең кая барырга белмичә аптырап торганыңны күреп ярдәмгә ашыгамы, ул һәр вакытта башын бик түбән иеп, елмаеп, әкрен генә сөйләшә.

Бөтен Японияне әйләнеп чыксак та, без кашын-күзен җимереп, кычкырышып, ызгышып торган япон хатынын бер генә тапкыр да күрмәдек.

Хатын-кызның күркәм холкы баласына булган мөнәсәбәтендә аеруча ачык чагыла. Ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә ул балаларын паркка, бакчага, су буена алып чыга, агачлар, кошлар, бөҗәкләр, чәчәкләр турында сөйли, баласында кече яшьтән табигатькә мәхәббәт тәрбияли. Инде баласы тыңламый икән, анасы чакырган якка бармыйча көйсезләнә икән, әнисе бервакытта да аңа акырмый, кулыннан каерып алып кычкыртып алып китми, сукмый, хәтта катырак та сөйләшми.

Нинди авыр эш эшләсәләр дә, япон хатыннарының гәүдәләре, куллары олы яшьтә дә кызларныкы кебек нечкә, сыгылмалы булып кала икән. Без моның сәбәбен аңларга тырышабыз. Урамда танышлары очраса, алар әллә ничә тапкыр урталай бөгелеп исәнләшәләр, өйләренә бик кадерле кунак килсә, тезләнеп куллары белән идәнгә таянып, маңгайларын идәнгә тигезеп сәламлиләр. Өйләре бик тәбәнәк булып, ишекне шудырып ачарга кирәк булгангамы, алар ишекне тезләнеп ачалар, тезләнеп ябалар. Өстәл янында тезләнеп утыралар. Бәлки әнә шундый «өзлексез гимнастика» белән шөгыльләнгәнгә алар шундый зифа булып калалардыр?

Япон кызын семья тормышына алты яшьтән үк әзерли башлыйлар икән. Мәктәптә кул эше дәресләрендә ул тегәргә, аш-су пешерергә, курчакларны юындырып, киендереп, йоклатып, бала карарга өйрәнә башлый. Япон мәктәбендә йөргәндә без моны үз күзебез белән күрдек.

Япон хатын-кызы үзенең кечкенә генә өен яки бүлмәсен бик чиста, бик матур итеп тотарга тырыша. Нинди ярлы өй булмасын, стена уентысына куелган гади генә вазада булса да чәчәк бәйләме тора. Өч-дүрт чәчәктән торган әлеге бәйләм гаҗәеп матур итеп, зур зәвык белән җыела. Бәйләмдәге һәр чәчәкнең матурлыгы, нәфислеге күренеп тора. Чәчәк бәйләме оештыру сәнгате икэбана дип атала һәм аны кызлар өч-дүрт ел буе өйрәнәләр.

Япониядә җир бик кыйммәт. Күпчелек крестьянның җире чирек яки ярты гектардан артмый. Ул җир дә әле бер генә урында булмый. Япония таулы як бит. Крестьян җиренең бер өлеше еш кына тау итәгендә, икенчесе үзәндә, өченчесе башка бер урында була. Мондый кечкенә мәйданнарда техника куллану кыен. Аны алырга крестьянның акчасы да юк. Күп эшне кулдан башкаралар. Авылдагы барлык авыр эш хатын-кыз җилкәсендә. Башларына салам эшләпә кигән хатын-кызлар иртә таңнан караңгыга кадәр тубыктан су эчендә дөге утырталар. Машинамы уза, кешеме, күтәрелеп тә карамыйлар.

Әнә шундый уңган, тырыш, эшчән, мөлаем япон хатыны җәмгыятьтә бик кадерле кеше булырга тиеш дип уйлыйсың. Хәлбуки, ул бик авыр шартларда, җәмгыятьнең иң хокуксыз кешесе булып яши. Дөрес, сугыштан соң, 1946 елда, яңа конституция нигезендә алар ирләр белән тигез хокук алдылар, әмма тормышта бу хокуклардан файдалана алмыйлар.

Хиросима шәһәрендәге автомобиль заводында 27 мең кеше эшли. Шуларның утызы гына хатын-кыз. Җитәкчеләр, инженер-техниклар,

квалификацияле эшчеләр арасыннан хатын-кызны эзләү файдасыз. Алар ишегалларын, цехларны җыештыралар, ә яшьрәк, чибәррәк кызлар килгән-киткән кешеләргә ишек ачып, аларны баш иеп каршы алалар һәм озатып калалар, хезмәткәр ирләр ял иткәндә аларны чәй яки кофе белән сыйлыйлар. Бернинди квалификация таләп итми торган мондый эштә хезмәт хакы да бик түбән.

Дәүләт учреждениеләрендә ирләр белән хатын-кызларның эш хакы тигез. Ләкин, беренчедән, андый урыннарга хатын-кызны бик аптыраганда гына алалар. Икенчедән, Япониядә дәүләт учреждениеләре бик аз. Монда завод-фабрикалар, ресторан, кафе, театрлар, универмаглар, хәтта Япониянең Фудзияма тавыннан башка барлык таулары, җирләре — һәммәсе дә хосуси милек санала, ягъни байлар кулында.

Япониядә хезмәт хакы Европа илләре белән чагыштырганда бик түбән. Ә хатын-кызларга тагын да азрак түләнә.

Закон гел ирләр ягында, Япон хатыны иреннән аерылса, бала һәм барлык мөлкәт ирендә кала.

Хәзерге вакытта Япон хатын-кызлары мондый гаделсез законнарны үзгәртү, хатын-кызларны ирләр белән чыннан да тигез хокуклы итү өчен көрәш алып баралар.

Хәзер Япониядә хатын-кыз хәрәкәте киң колач алып бара. Анда бик күп оешмалар бар. Япониянең аналар конгрессы, Хезмәт иясе хатын-кызларның үзәк берләшмәсе, Махсус поселокларда яшәүче хатыннарның милли берләшмәсе, Демократик хатыннар клубы, Япония хатын-кызлары җәмгыяте һәм башка оешмалар актив эшлиләр.

## Гейшалар

Япониядә башка бер илдә дә булмаган бер профессия кешеләре бар. Ул да булса гейшалар. Чит илләрдән килгән кунакларны кабул иткәндә, төрле приемнарда, гадәттә, берничә гейша була. Кимоно кигән, традицион формада биек прическа ясаган, битенә мул итеп иннек-кершән яккан курчак кебек чибәр гейша, әлбәттә, бу приемнарга экзотик ямь бирә, ә үзенең әдәбият, сәнгать мәсьәләләреннән хәбәрдар булуы, тапкыр сүзле, әңгәмәне алып бара, җанландыра белүе белән бер-берсе белән таныш булмаган кешеләр арасында киеренкелек тудырмыйча, аларның тиз арада барысын да әңгәмәгә тарта. Ул инде кунак сыйлауның, чәй әзерләүнең барлык нечкәлекләрен яхшы белә. Шуның өстенә бик яхшы бии, музыка коралларында уйный, җырлый да белә.

Япониядә төрле фирма вәкилләре арасындагы сөйләшүләр, килешүләр шушы гейшалар катнашы белән бара икән. Чөнки алар әңгәмәне бик тиз башлап, җанландырып җибәрәләр, шул ук вакытта ирләрне сакэ (16 градуслы дөге аракысы), чәй, кофе белән сыйлыйлар, тәмәкеләрен кабызалар, әңгәмә бик арытса, берәр музыка коралында уйнап, җырлап күңел ачып җибәрәләр икән.

Япониягә килеп төшүгә без әле алар турында уйларга да өлгермәдек, безнең гидыбыз Мацуи Хисао әфәнде әйтә куйды:

— Гейшалар турында начар уйлый күрмәгез. Алар сәнгать кешеләре.

— Нигә алай дисез?

— Соң, Япониягә килгән берсе «Ниндирәк хатыннар соң алар?» дип сорап үзәккә үтәләр. Аларга Европа халкы шикләнеп карый.

Гейша — сәнгать кешесе дигән сүз. Махсус вербовщиклар ил буйлап йөреп, 12—16 яшьлек чибәр һәм талантлы кызларны эзләп таба-

лар да аларның ата-аналары белән контракт төзиләр. Кыз махсус мәктәпкә керә һәм мәктәп хуҗасының өендә яши башлый. Берничә ел буена кызны музыка коралларында уйнарга, җырларга, биергә, кеше арасында үзен тота, киенә белергә өйрәтәләр, әдәбият, сәнгать белән таныштыралар.

— Чибәр, яшь, талантлы гейшаның гонорары зур була,— ди гидыбыз. Гид хаклы. Чибәр, яшь кызның шулайдыр.

Әмма кыз гел яшь, чибәр булып калмый бит. Ләкин 12—16 яшьлек кызларның кайсысы картлык турында, киләчәге турында уйлый?

Гидыбыз аларны бик якласа да, без кайбер гейшаларның язмышы фаҗигале булуын, зур байларның яшь һәм чибәр гейшаларны сатып алып, соңыннан бу кызларның тормышы арзанлы кабареларда узуын да белдек.

## Япон мәктәбендә

Безнең күбебез өчен Нагасакида истәлекле вакыйгаларның берсе япон мәктәбе белән танышу булды.

Японияда балалар алты яшьтән укый башлыйлар икән. Башлангыч белемне алыр өчен бала алты ел, түбән белемне алу өчен өч ел, урта белемне алу өчен өч ел, югары уку йортында дүрт ел укый (6—3—3—4). Тугыз ел уку, ягъни беренче ике баскычны тәмамлау һәр бала өчен мәҗбүри һәм бушлай. Башлангыч мәктәптә балалар япон телен, арифметика, Япония географиясен өйрәнәләр, Япония тарихы һәм әхлак турында кайбер төшенчәләр алалар. Урта мәктәптә башка предметлар белән беррәттән чит телне, күбесенчә, инглиз телен өйрәнәләр, һәм бу телне япон интеллигенциясенең шактый өлеше яхшы белә икән.

Мартның 23 е. Без шәһәрнең Нихакоруку («Шәһәрнең 200 еллыгы») исемендәге урамында урнашкан алты еллык башлангыч мәктәпкә юнәләбез.

«П» хәрефе рәвешендә салынган өч катлы зур бина. Ишегалдында спорт мәйданы. Бина иске, әмма идәннәр, бүлмәләр бик чиста. Монда без аяк киемнәребезне салып керәбез.

Бу мәктәптә режим түбәндәгечә. Балалар мәктәпкә иртә килеп, 4 сәгать укыйлар, аннан соң ашханәдә кайнар аш ашыйлар да 20 минут ял иткәч, йокларга яталар. Йоклап торгач, чәй эчәләр һәм махсус бүлмәдә ике сәгать чамасы дәрес әзерлиләр. Дәресләрен әзерләп бетергәч, өйләренә кайталар.

Без музыка, рәсем, кул эше, спорт дәресләрендә булдык, балаларның дәрес әзерләгәннәрен карап утырдык. Һәр класста җиһаз баланың яшенә, буена карап куелган. Һәр балага кечкенә генә аерым өстәл.

Дәрес хәзерли торган бүлмә шактый зур. Дүрт стенаның буеннан-буена балалар сузылмыйча алырлык биеклектә китап киштәләре эшләнгән. Минә кечкенә генә өстәлдә 8 яшьләрдәге бер кыз бик җитди кыяфәттә дәрес әзерләп утыра. Аңа ниндидер китап кирәк булган. Ул урындыгын акрын гына шудырды да китап киштәсе янына барып, үзенә кирәкле китапны сайлап алды һәм, үз урынына утырып, китаптан нәрсәдер күчереп яза башлады. Бүлмәдә 6 дан 11 яшькә чаклы кырыкка якын бала, ләкин һичбер тавыш юк. Зурлар китапханәсендә утырасыңмыни. Аның каравы, шул ук балалар тәнәфес вакытында тирә-якны шаулаттылар.

Балаларны физик тәрбияләүгә (спортка) япон мәктәпләрендә зур игътибар бирелә икән. Безнең алда парад үткәрелде. Бу парад белән

10 яшьлек кыз җитәкчелек итте. Ул бу эшне шул чаклы яхшы белә, үзен шул чаклы тыныч тота, әйтерсең лә күп еллар шундый парадлар белән генә эш иткән.

Ишегалдында зур спорт мәйданчыгы, бинада зур спорт залы бар. Икесе дә спорт уеннары өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгәннәр.

Соңыннан безне мәктәп директоры Баба һәм аның урынбасары Мацумури әфәнделәр кабул иттеләр.

Мәктәптә 1250 укучы, 36 укытучы, шуның 14 е ир, 22 се хатынкыз икән. Укытучының атналык нагрузкасы 44 сәгать. Сүз арасында мәктәптә беренче классларның берничә булуын белдек.

— Аларны нинди принциптан чыгып комплектовать итәсез? — дип сорадык.

Директор:

— Эй, би, си системасы кулланабыз, ди, ягъни «эй» классына иң көчле, иң сәләтле балаларны алабыз. «Би» классына сәләтләре, хәзерлекләре кимрәк булганнарын, ә «си» классына иң сәләтсезләре керә,— ди.

Беренче карауга болай бүлү дөрестер кебек. Хәлбуки, менә бу очракта сыйнфый бүленеш күзгә аеруча нык бәрелә. Капиталистик илләрнең күбесендә шулай эшлиләр бит. Иң хәзерлекле бала кем баласы? Бай кеше баласы. Ул музыканы да, телләрне дә өйрәнгән була, бии дә, җырлый да белә, ул диңгезне дә, тауларны да күргән, самолетта күккә дә күтәрелгән. Ә иң хәзерлексез бала иң ярлы кеше баласы була. Алар «өченче» категориядәге класска эләгәләр. Бу класста укыган балаларга киләчәктә югары белем алу турында хыялланырга да урын калмый.

## Милли ресторанда

Киотоны шәһәр-музей дип атарга мөмкин. Кайсы якка гына борылсаң да, япон архитектурасына хас стильдә салынган храмнар, сарайлар күрәсең. Биредә тимер-бетоннан салынган биналар юк. Бу — борынгы Япония, ди безнең гид. Шул тәэсирне көчәйтү өчендер инде, безне ашарга да милли ресторанга алып бардылар. Без барган Мисимати рестораны зур түгел. Тәбәнәк бүлмә. Тәрәзәләр урынына шудырып ачыла торган стеналар. Идәндә дөге саламыннан эшләнгән матылар.

Милли кием киенгән һәм иннек-кершән ягынган ханымнар (гадәттә япон хатын-кызлары милли кием кисәләр генә шулай нык бизәнәләр) бусагадан ук безне тезләнеп, идәнгәчә бөгелеп каршы алдылар. Без аягыбыздан салып эчкә үттек һәм кечкенә, тәбәнәк өстәл янына ефәк мендәргә тезләнеп утырдык. Япон йортында да, милли ресторанда да тезләнеп үкчәңә утырырга кирәк. Аякларны бөкләп утыру килешми, ә инде аякларны сузып утыру бик зур әдәпсезлек булып исәпләнә икән. Ләкин безнең ише урындыкка күнеккән кешеләргә тезләнеп утыру бик кыен булды. Ун-унбиш минут узмагандыр, безнең аяклар, билләр талды, тәрләп утырасы, хәтта сузылып ятасы килә башлады. Һәр өстәлнең уртасында — электр плитәсе. Элекке заманнарда уртада кечкенә генә мич яна торган булган. Традиция буенча ашны кунакның күз алдында әзерлиләр икән. Безне бусагадан ук каршы алган ханым тезләнеп (алар, әлбәттә, үкчәләренә бик җиңел һәм матур утыралар), безнең алда японнарның милли ашы «сукияки»не әзерли башлады. Иң элек безнең алга бер пияла белән сытылган чи йомырка, икенче пияла белән пешкән дөге китереп куйды. Аннан соң кызган табага май салды һәм шул майда юка

телемнәр итеп киселгән сыер итен, суган һәм безгә таныш булмаган тагын нindидер яшелчәләрне кыздыра башлады. Ит пешкәч, без аны таякчыклар (хаси) белән алып чи йомыркага манып ашый башладык. Сукияки бик тәмле азык икән. Аның тәмле булуының сере дә бик хикмәтле булып чыкты. Бу ашны теләсә нинди иттән түгел, бәлки махсус азыклар ашатып (сыра эчереп, йомырка ашатып) симертелгән сыер итеннән генә әзерләргә мөмкин. Ә мондый итнең бер килограммы квалификацияле эшченең ун көнлек эш хакына тигез икән.

Итне хаси белән ничек кирәк алай ашадык. Әмма дөгене ашау бик тә авырга килде. Ике таяк арасындагы дөге авызга килеп җиткәнче коелып бетә иде. Әле җитмәсә, дөгене алуың була, чибәр япон хатыны күзенең чите белән генә елмаеп сиңа карап тора башлый. Капсаң кабасың, капмасаң, дөгегә кереп чыккан таякның төмен генә татып каласың.

Япон халкы гасырлар буе диңгез биргән азык — балык, суүсемнәр, диңгез кәбестәсе, төрле моллюскалар белән тукланып килгән. Алар икмәкне бөтенләй белмәгән диярлек. Итне дә бик сирәк ашаганнар. Хәзерге вакытта да әле аларның иң яраткан азыгы чи балык. Мәсәлән, соя соусы белән бирелә торган чи балык — «сасими» аларның иң яратып ашый торган милли ашы. Бик вак итеп тураган һәм дөгедән пешерелгән кабартма өстенә куеп бирелә торган чи балык «суси» дип атала. Балык, дөге, яшелчә урта хәлле японның бүгенге көндә дә төп азыгы булып кала. Ләкин яшьләр икмәк белән итне көннән-көн күбрәк кулланалар.

Японнарның матурлыкны ярату хисе аш-су әзерләгәндә дә өстенлек ала. Алар азыкның табигый тәмен, үз төсен саклауга аеруча нык игътибар итәләр. Мәсәлән, көзен аш пешергәндә алар кишерне шулпага өрәңге яфрагы формасында кисеп салалар икән. Ул алтын көз җиткәнне күрсәтеп, ашны бизәп тора.

Тагын бер кызыклы хәл. Японидә «культуралы кеше» булып исәпләнү өчен үзеңне тота белү, күп уку гына түгел, бәлки нәфесне тыя белү, чама белән генә ашау, юанаймау да таләп ителә икән.

Без японнарның ике йөз еллык тарихы булган һәм хатын-кыз рольләрен дә ирләр башкара торган Кабуки театрында булдык, көнбатыш мюзик-холларын хәтерләткән Такарацуки театрының спектакльләрен карадык, крестьян фермаларын, ерак таулардагы водопад, океан буендагы дельфиннар океанариумы һәм бихисап храмнар, музейлар белән таныштык.

Японияләнең дәүләт эшлеклеләре генә түгел, күп кенә фирма җитәкчеләре дә Советлар Союзы белән экономик элемтәләрне киңәйтергә телиләр, шуңа күрә дә СССРдан килгән кунакларга, туристларга Японидә игътибар зур икән.

Бу экономик элемтәләрне киңәйтү, ныгыту, һичшиксез, ике ил өчен дә файдалы булачак.

Габдрахман Әпсәләмов

# КОЯШ ТОТЫЛГАНДА ТАБЫЛГАН ХӘЗИНӘ

ИКЕНЧЕ ДӘФТӘРДӘН

*(30. 11. 1960 — 17. 1. 1961 ел)*[1]

30. 11. 1960. Яңадан шифаханә, яңадан врачлар, сестралар, нянялар, авырулар. Тик бу шифаханә инде башка, тегесе кебек, кысан да, кечкенә дә түгел, һава да монда башка. Өченче больница Алтынчы август урамында, завод-фабрикалар арасында иде, монысы — шәһәрнең югары ягында, Чехов урамында. Палаталар иркен, биек, чиста. Безнең алтынчы палата Чеховның мәгълүм алтынчы палатасына якын да килми. Ике кешелек, калган палаталар өчәр, дүртәр кешелек. Коридорда, ял итү бүлмәләрендә, ашханәдә — келәмнәр, гөлләр; стеналарда — рәсемнәр. Ашханәдә телевизор. Һәр карават янында радио, сигнал төймәсе. Төймәгә бассаң, тышкы яктан ишек башында, бер үк вакытта сестра бүлмәсендә, палаталарның номерлары язылган щитта ут кабына. Сестра үз бүлмәсендә булса да, коридорда булса да, кайсы палатага чакыруларын күрә ала. Элекке больницада боларның берсе дә юк иде.

Минем күршем Евгений Никандрович Павловский — уртача буйлы, юан гына бер кеше. Ветеринария институтының директоры. Илле бишь яшьләр булыр үзенә. Өстендә, барыбызныкы кебек, куе яшел пижама. Чәче шактый агарган, директор кешегә шулай килешә дә кебек. Муены юан, ияге белән тигезләнеп килә. Табигате тыныч булса кирәк, бик ягымлы һәм эреләнмичә сөйләшә. Һәрхәлдә, Николай Иванович кебек, палатаны сәхнә ясамый. Мин килеп кергәндә өстәл янында ниндидер кульъязма укып утыра иде. Соңыннан белдем, институт хезмәткәрләренең фәнни мәкаләләрен караштыра икән.

Минем фамилияне ишетеп белә икән. Миннән язучы Әпсәләмовны беләсезме дип сорады. Шуннан инде кемлекне әйтергә туры килде. Әдәбият турында сөйләшеп алдык. Рус һәм дөнья әдәбиятыннан

[1] Ахыры. Башы 2 санда.

хәбәрдар. Татар әдәбияты турында сүз булмады. Авыл хуҗалыгына күчтек. Татарстанда терлек азыгының җитешмәвен, аның да 75 проценты тупас азык булуын (салам икәнен) әйтте. Шуннан ит, май, сөт җитешми дип зарланабыз. Терлекләрнең баш санын арттыру һәм сыйфатларын яхшырту өчен, иң элек азык проблемасын хәл итәргә кирәк, диде.

Сизеп торам, Евгений Никандровичның сүзе әле бетмәде, миңа сагаеп карап-карап ала. Кешеләр арасында: язучылар өстә ятканны гына җыеп йөри дигән сүзләр йөри бит. Күрәсең, Павловский да шулай уйлыйдыр. Мин аны гаепләргә җыенмыйм, без, чыннан да, тормыш тирәнлегенә сирәк чумабыз, калын катламнарны актармыйбыз. Бу тормышны җитәрлек белмәүдән килә торгандыр инде.

Тормышны белү... Бу — язучылар алдына куела торган төп бурыч. Ул кичә дә булган, бүген дә бар, киләчәктә дә булачак. Чөнки тормыш — әдәби иҗатның үзәгендә; тормышсыз иҗат юк. Тормышны иҗат командировкаларында гына өйрәнергә димәгән. Кайчакта әллә кая барырга хаҗәт тә тумый, без көн саен шул казанда кайныйбыз, тик... кешеләргә тиешенчә күз салмыйбыз. Кеше исә — безнең төп материалыбыз. Төзүчеләр кирпечтән, тимер-бетоннан биналар салалар, без, язучылар, кешелек материалыннан. Төзүчеләргә материалларның каршылык сыйфатын белү бик кирәк, язучылар да аннан кача алмый. Тик кешелек материалы һәр вакыт катлаулырак, җитдирәк. Шуңа күрә сиңа таныш булмаган һәр кешегә күзләреңне киң итеп ачып кара, онытма: таныш булмаган һәр кеше — үзе бер дөнья! Танышларың белән генә яшәсәң, барысын бер аршинга үлчәсәң, бик чикләнгән кешегә әверелүең мөмкин. Язучы өчен чикләнгәнлек ифрат та куркыныч нәрсә.

Павловский белән сөйләшеп утырган арада палатага дәвалаучы врач Диләрә Кадыйровна килеп керде. Без инде аның белән танышлар. 1958 елда больницада ятканда ул безнең палатага кергәли, кайчагында дәвалый да торган иде. Ул чагында минем төп дәвалаучы врачым Мансура Хафизовна иде, хәзер — Диләрә ханым булачак.

Николай Иванович булса, түзмәс иде:

— Сез, Диләрә ханым, чыннан да күңел юаткыч булгансыз, матурлангансыз, чибәрләнгәнсез! — дияр иде.

Ул күзлек кия башлаган, ләкин бу аны олыгайтмый да, аңа эрелек яки салкынлык та өстәми. Бик ягымлы сөйләште, сәламәтлегемне сакламаган өчен (мин аңарда поликлиникада да булгалый идем) җиңелчә орышып та куйды. Хак сүзгә ни әйтәсең, хәлебез аз гына яхшыра төшсә, врач киңәшен онытабыз шул.

Мин сиздерми генә Диләрә ханымның йөзенә карыйм. Врач, теле белән, барысын да әйтеп бетерми бит. Әмма хәлең начар яки хәвефле булса, бу аның йөзендә чагылмый калмый. Тик бик тәҗрибәле врачлар гына авыруга бер нәрсә сиздерми. Ә авыру сагайган, ул борчыла да, шикләнә дә. Шундый чакта врачның йөзендә күләгә күрсә, аның кояшы берьюлы бата. Мин инде врач эшенең хикмәтләренә беркадәр төшенә башлаган идем. Врач палатадан чыгып киткәндә авыруның күңеле тынычланган булырга тиеш. Моны бик күп атаклы врачлар әйткән.

Диләрә ханым чыгып киткәч, минем дә күңелемдә тынычлану хисе туды. Югыйсә, йөрәк тагын шактый газаплый башлаган, ихтыярсыздан башка күңелсез уйлар килеп китә иде. Көлке, ләкин мин васыять турында да уйлый идем. Болай булгач, васыять түгел, көндәлек язам әле! «Мәңгелек кеше» өстәлдә калды бит. Ул болай оч-

ланган булса да, яңадан аңа кайтмый булмый, башта яңа фикерләр һаман туып тора...

Мансура апа — хәзер өлкән врач, бүлек мөдире. Бер күренде, хәлне сорашты да, елмаеп, юк булды — чакырып алдылар.

— Мансура Хафизовнаны көн-төн больницада күрәсең. Аның больницадан башка тормышы да юк, ахрысы,— диде Павловский. Сез аны электән белә идегезме?

— 1958 елда инфаркт белән ятканда мине ул дәвалады.

— Хәзер дә йөрәкме?

— Шул инде.

Мин тәрәзә янына барам, тышка карыйм. Аксыл-сары койма. Койма артында кызыл кирпечтән салынган ике катлы йорт. Бу йорт борынгы бакча эчендә. Урындыкларда кар...

1. 12. 1960. Йөри ала торган авырулар — мин дә шулар арасына керәм — кичләрен ял бүлмәсенә җыелалар. Дүрт кеше домино суга, биш-алтысы карап тора, чират көтә. Кызып, бәхәсләшеп уйныйлар. Оттыручыларга көн юк, шундый чәнечкеле сүзләр әйтәләр, чыдап кына тор. Ганиев — элекке Авыл хуҗалыгы министры — баш консультант булып алган. «Анда йөрмә, монда йөр, дошманны дөмбәслә, үзеңнекен түбәләмә»,— дип өйрәтеп тора.

Мин әле уйнамыйм, читтән генә күзәтәм. Дөресен әйткәндә, рәтләп уйный да белмим. Ганиев әйтә:

— Монда күбрәк ятсаң, аздырырлар. Әйдә, мин бар чакта уйнарга өйрәнеп кал. Әҗерен күп алмам. Минем өчен бер-ике порошок йотсаң яки укол кадатсаң, шул җиткән...

Авырулар үз хәлләре турында гына сөйли, диләр. Моны мин теге шифаханәдә дә ишеткән идем. Ә без менә көне буе космик кораб турында сөйләшәбез. Бүген космоска инде өченче корабны җибәргәннәр. Кеше акылының куәте таң калдыра, һәр төрле чирләрне оныттыра.

Авырулар арасында элек дөньяның тоткасы булган кешеләр: министрлар, секретарьлар, партия һәм совет работниклары байтак. Аларның күпчелеге — хәзер пенсионерлар. Бу кешеләр үз җилкәләрендә нинди кыен чорларны күтәреп чыктылар, халыкны вакытлы кыенлыкларга каршы торырга дәртләндерделәр, үзләре дә шул утта яндылар. Кешелек аларга бер генә сокланмас әле. Ә больницада алар, нәкъ ваемсыз балалар төсле, дөньяларын онытып домино уйныйлар, анекдотлар сөйлиләр, оттырсалар турсаялар, бәхәсләшәләр, гүя алар өчен шуннан да мөһимрәк нәрсә юк.

Бу «картлар» белән якынрак таныша башлагач, аларның үз тормышларыннан бер дә канәгать булмауларын күрдем.

— Эшләгәндә авырырга вакыт юк иде, ә хәзер башыбыз авырудан чыкмый,— диде аларның берсе.— Уптым иләйһи пенсиягә чыгарганчы, көчебез җитәрдәй эш бирсәләр, эшләмәс идекме?

— Пенсиягә чыкмаска кирәк иде,— дим.

Ял бүлмәсендә һаман домино сугалар. Ганиев тантана белән кычкыра:

— Кәҗә мал түгел, баҗа кардәш түгел, әйдә, энем, урыныңны башкага бир!

4 һәм 5 декабрьлар — кыш башы, ә тышта... яңгыр ява. Бакчадагы агачлар күмер төсле, кап-кара. Шәрә ботаклары әйтерсең ыңгырашалар. Шифаханәдә ике көн инде дежур врачлар гына. Ял көне һәм Конституция көне. Гадәттәге ыгы-зыгы юк, тын. Безнең бөтен «язмыш» сестралар кулында. Безнең бүлектә алар дүртәү: Люся,

Тамара, Геля, Мәрьям. Люся, авыл кызы кебек, таза, калфагын да, халатын да гади генә иттереп кия, җиңнәрен һәр вакыт сызгана, беләкләре симез, гәүдәсе дә шундый. Тамара уртача буйлы, чибәр, ирене өстендә кечкенә генә миңе бар. Бу — аны балага охшата. Мәрьям бәләкәй буйлы, йомшак холыклы, аз сүзле. Дүртенче сестрабыз — француз исемле татар кызы Геля (Глиоза) — матур һәм көяз. Аның калфагы да, халаты да башкаларныкына охшамаган. Калфагы башында гүя назланып кына утыра, халаты бик таман, тезенә генә җиткән. Җиңнәрен дә ничектер бик килешле сызганган. Күзләре зур, серле дә кебек.

Башкалар алмашып эшли, Геля — көндез генә. Ул — Әгерже кызы, әнисе — укытучы, кызына матур исемне ул сайлаган. Киләсе елга медицина институтына керергә хыяллана. Аңардан бик яхшы врач чыгар төсле тоела миңа.

6. 12. Бүген, ниһаять, аяза башлаган. Тәрәзәдән урамга карап торам. Күлдәвекләр булып яңгыр сулары җыелган. Мондый һава уҗымнарга бер дә килешми, уҗымнар боз белән каплана, боз һаваны җибәрми, шуннан үсемлекләр тончыга, ди Ганиев.

Берәү зарланып утырды әле:

— Бер ай инде саф һава иснәгән юк, дарулар да дарулар. Көненә егерме төрлене бирәләр. Эчләрем катып бетте. Әле уколы да бар. Бүген минә температурам күтәрелә башлады.

— Монысы инде терелүеңнең башы,— диде яныбызга килгән өченче бер авыру.

Ял бүлмәсеннән Ганиевнең:

— Терлек санын арттырабыз! — дигән тавышы ишетелә.— Ләкин бәла: «кәҗәләрне» мясозаготовкага алмыйлар.

— Терелүнең башы дисеңме? — ди иптәш доминочыларны тыңламыйча.— Кеше ул, туган, шундый: авыруы булсын өчен үзе көн-төн тырыша, ә чирен дәвалауны врачлардан гына таләп итә. Тиз генә дәвалый алмасалар, турсайган була. Янәсе, юньле врач түгел.

Бүген Диләрә ханым дежур. Кич безнең палатага кереп утыргач, сүздән сүз чыгып, врач булып эшли башлаган чакларын сөйләде. Ул еракта, урман кискән җирдә, врач булган. Кыш көне чанага утырып, толыпка төренеп, бер участоктан икенчесенә йөргән.

— Искә төшерсәң, күңелләр әллә нишләп китә,— ди.— Яшь-яшь башың белән... Тәҗрибә дә юк... Ләкин син врач, сине көтәләр... Дөрес, урман кисүчеләр газа халык. Авырсалар — ангина белән генә. Тик кайчакта бик кыен хәлләргә дә очрыйсың. Якын-тирәдә синнән башка бер врач юк. Бер үзең диагноз куй, бер үзең дәвала... Елаган чакларым да булгандыр, аның каравы, үз алдыма эшләргә өйрәндем, башкаларга салынмадым. Тагын шунысы хәтердә: кышкы юл, толып эчендә чанада барасың. Кышкы урман. Агачлар ап-ак — бәс сарган. Нәкъ әкияттәге кебек. Күктә ай йөзә, җирдә, көрт өстендә, күгелҗем күләгәләр. Барасың, барасың — юлның очы да, кырые да юк. Уйланасың, куркасың да, шатланасың да. Шулай да яшь чакта батырлык күбрәк була, ахрысы. Хәзер шундый шартларга эләксәм, эшли алмам кебек. Кара төндә кара урман аркылы барырга йөрәк җитмәс кебек...

Кинәт кеше бөтенләй көтмәгән-уйламаган яктан ачылып китә, һәм син аңа чиксез хөрмәт белән карый башлыйсың. Моңарчы Диләрә ханымны бөтенләй белмәгәнмен икән.

Бер авыру белән сөйләшеп утырабыз. Коридор буйлап бик эре кыяфәтле абзый йөренә. Якын килмә, түбәңә басып узар.

— Телисезме, мин аңа бик төгәл характеристика бирәм,— ди күршем.— Бу бәндә югары начальниклар алдында бил бөккән, урта начальниклар белән ягымлы булган, үзеннән түбәннәрне бар дип тә белмәгән.

— Әнә теге абзый,— ул коридорның икенче башына күрсәтә,— тормышта бүтән төрле тактика алып бара иде: яңа начальник билгеләр икән, бу кеше: ну, егетләр, бәхетебез бар икән, Ван Ванычны безгә начальник итеп куйганнар, бик тә кешелекле кеше! ди. Бер заман Ван Ванычны төшерәләр, бу кеше тагын кычкыра: бик дөрес иткәннәр, берәүгә дә көн күрсәтми иде! ди.

Гаҗәп күп төрле кешеләр бар дөньяда һәм барысы да аз гына фәлсәфә сата. Берсе минем белән сөйләшкәндә болай диде:

— Кеше барыннан да элек үзенең горурлыгын югалтмаска тиеш. Горур кеше, әгәр бер-бер эшне булдыра алмаса, юк, егетләр, көчем җитми, дип турысын әйтә. Горурлыгын җуйган кеше, булдыра алмаса да, борынын чөя һәм, билгеле, иртәме-соңмы мәтәлеп төшә. Шуннан чокыр төбеннән кычкыра:

— Дошманнарым аяк чалды, югыйсә, минме халык өчен тырышмаган!

7. 12. 1960. Кичә Идел аръягы аяза башлаган иде, бүген тагы болытлар белән капланган. Ишегалдында һаман кар сулары. Павловский белән сөйләшеп утырабыз:

— Бер-бер нәрсәгә ирешим дисәң, ул эшкә башың белән чумарга кирәк. Һәм шул турыда гына уйларга кирәк. Ә мин — директор, мең эшне берьюлы эшләргә күнеккәнмен. Ә чәчелү — яхшы нәрсә түгел.

Мин чыннан да аның берьюлы өч-дүрт китап укуын күрә идем. Берсен бетермәгән, икенчесен башлаган, анысының яртысына да җитмәгән, өченчесенә тотынган...

Павловский физиолог. Сүз ара сүз чыгып, мин аңа кайбер эпизодларны һәм геройларны төштә күреп язганымны әйттем.

— Бу бик табигый,— диде Павловский һәм бер зур галимнең төштә мөһим ачыш ясаганын сөйләде.— Бу хәл Павловның йокы теориясендә аңлатыла. Йоклаганда мигә тәэсир итә торган барлык тышкы нәрсәләр юкка чыга, ә акыл үзенең эшен дәвам иттерә бирә. Ул үзен борчыган нәрсә турында гына уйлый һәм аны бөтен тулылыгы белән күрә.

8. 12. Тәрәзәдән озак-озак карап торам. Бүген дә көн соры, дымсу, күңелсез. Уйсу җирләр карлы яңгыр суы белән капланган. Койма буйларында боз катламы ялтырап тора. Авыл кешеләре — больницада алар байтак — бу кара бозга аерата борчылып карыйлар.

Кичә Җәүдәт Фәйзине китереп салдылар. Йөрәк. Палаталары — дүрт кешелек. Җәүдәт ишектән кергәч тә уң кулдагы караватта. Башка караватлар аңа каршы. Берсендә цирк директоры ята. Җәүдәт белән сөйләштем. Хәле артык куркыныч түгел шикелле. Палаташлары Җәүдәт күп йоклый диләр. Йоклый алу — шәп нәрсә ул.

Беренче палатада профессор Әбүбәкер абзый Терегулов ята. Аңарда берничә тапкыр пневмония булган. Шул хәлендә операция дә кичергән. Аның янына шәкертләре килеп йөри. Профессор аларның гыйльми хезмәтләрен тикшерә икән. Бу турыда аның белән бер палатада ятучы Ганиев сөйләде.

Ганиев өенә кайтып киткәч, беренче палатага мине күчерделәр. Әбүбәкер абзый Ганиевтән аерылуын авыр кичерә. Алар якташлар икән, икесе дә Уфадан, уртак сүзләре, уртак белешләре булган. Шифаханә өчен бу аз түгел.

Теге больницада ятканда профессор мине берничә мәртәбә караган иде. Билгеле, ул моны хәтерләми торгандыр. Минем ише авырулар аның кулыннан йөзәрләп үткән бит.

Әбүбәкер абзый торып йөри алмый, күп булса, урындык артына тотынып, өстәл янына килеп утыра. Беренче көннәр ничектер салкын үтте, сөйләшеп тә булмады. Мин күбрәк домино уйнаучылар янында утырдым. Ә аннары, үзебез дә сизмәстән, бер-беребезгә якынаеп киттек, бер туктаусыз сөйләшә башладык.

Әбүбәкер абзый сөйләргә ярата икән, матур сөйли, аны тыңлап утыруы үзе бер рәхәт. Ул ятып сөйли, еш кына кыска ак мыегы астыннан елмая, имән бармагын сузып, кискен-кискен ишарәләр ясап куйгалый. Башы йомшак ак чәч белән капланган, йөзе, больницада озак вакытлар ятса да, матур, таушалмаган, җыерчыклар юк.

Бала вакытта Әбүбәкер абзый мәдрәсәдә бер-ике ел укый да, әтисе аны Уфада хосусый пансионга урнаштыра. Күрәсең, заманы өчен ул шактый алдынгы карашлы кеше була. Монда Әбүбәкер абзый гимназия тәмамлый, аннары Казан университетының медицина факультетына керә һәм аны 1911 елда тәмамлап чыга.

— Егерме-егерме бер яшьләрендә минем апам үлде,— ди.— Аңа берничек тә ярдәм итә алмадылар. Мин аны бик ярата идем. Мин аңа доктор булырга һәм авыруларга ярдәм итәргә вәгъдә бирдем. Мин сүземдә тордым...

Ул чакта медицина факультеты студентлары матур әдәбиятны укымый торган булганнар, янәсе, алар җитди кешеләр, медицина китаплары гына укырга тиешләр. Бәхеткә каршы, бу ялган масаюны Әбүбәкер абзый тиз аңлап, матур әдәбияттан байтак китаплар укып өлгерә, китап җыя. Букинистлар аның иң яхшы дуслары булып китә.

Бер тапкыр аны «Болгар» номерларына авыру шагыйрь Габдулла Тукайны карарга чакыралар. Шул чакларны искә төшереп, Әбүбәкер абзый болай диде (аның сүзләрен тулырак бирү нияте белән, русча язганмын, чөнки ул русча сөйләде. Хәзер татарча бирәм):

— Тукай дисәм, иң элек аның күзләре искә төшә, кара күзләр, ялтырап тора, акыллы карыйлар. Ул вакыттан ярты гасыр үтте инде. Ә мин аларны хәзер дә күрәм кебек, еллар тирәнлегеннән алар якты йолдызлардай җемелдиләр. Бер нәрсәне дөрес аңлагыз: мин Тукай янына бөек шагыйрь янына барам, дип чыкмадым, ул чакта мин аның шигырьләрен аз беләдер идем. Күп булса, унбиш-егерме минут сөйләшкәнмендер. Шуңа карамастан, мин, шигъряттән шактый ерак бер кеше, ярты гасырдан соң да аның күзләрендәге ялтырауны һәм акылны хәтерлим икән, аларда нинди көч булганлыгы сезгә аңлашылырдыр дип уйлыйм. Йөзе исә кайгылы иде — бераз уйлап торгач үзе үк төзәтеп тә куйды,— юк, кайгылы түгел, моңлы, сагышлы иде. Акыллы да иде. Безнең художниклар әле дә чын Тукайны ясаганнары юк. Беләсезме, тагын аның менә монда,— ул бармагы белән борын яфракларына күрсәтте,— бик үзенчәлекле сызыклар бар иде. Менә шул сызыкларны мин хәзергә Тукайның бер рәсемендә дә, бер бюстында да күргәнем юк. Ихтимал, опера театры янындагы скульптурада гына Тукайга беркадәр охшашлык бардыр, ә Кольцодагы һәйкәл...— Әбүбәкер абзый кулын селтәде,— барып чыкмаган... Аннары мине, беләсезме, тагын нәрсә рәнҗетә? Художниклар Тукайны малай сымак, хәтта юләрсетеп күрсәтергә тырышалар. Ә Тукай зур, укымышлы һәм гаҗәп акыллы кеше иде. Фикер иясе, туганкай, уйлануччы шагыйрь. Русча әйтсәк, властелин дум народных! Аны менә шулай итеп ясарга да кирәк! Халык күңелендә дә ул шундый килеш саклана.

Шуннан соң мин Тукайны тагын берничә күрдем, ләкин узып барышлый гына. Тулырак итеп Әминә Ибраһимовна[1] сөйли алыр иде. Ул чакта Әминә Ибраһимовна татар хыялларына якын тора, хәтта һәвәскәр театрда да уйный иде.

Тукайдан соң Әбүбәкер абзый Хөсәен Ямашев турында сөйләп китте.

— Ямашев та бик акыллы, бик матур кеше иде. Мин аны күбрәк белә идем, безнең гаиләләр аралаша иде. Хөсәеннең иң яхшы рәсеме дә безнең гаилә архивында саклана иде. Соңыннан без аны академиягә бирдек. Гафур Коләхметовны да белә идем. Хөсәен белән сөйләшеп утырулары күңелле, ул телгә бай, кыю. Гафур исә аз сүзле, күбрәк тыңлап утыра, үзе бик тыйнак. Мин аның революционер булуын башыма да китерми идем. Октябрьдан соң гына белдем. Хәер, аларның икесенә дә бер сыйфат хас иде: алар тел бистәләре түгел иде. Үзләренең партия эшләре турында хәтта гаилә эчендә дә сөйләмиләр иде. Гаҗәеп тотнаклы кешеләр!

Укып бетергәч, Әбүбәкер абзыйны Дим станциясенә врач итеп җибәрәләр. Дим станциясе Уфа белән янәшә генә. Яхшылап урнашырга да өлгерми, аны утыз чакрымдагы бер авылга чакыралар. Тройка кырлар, авыллар буйлап чаба. Балаларын җитәкләгән хатынкызлар, каз-үрдәкләр, куркып, читкә тайпыла. Атларның авызларыннан күбекләр генә оча.

Чакырылган авылда аларны өлкән земский врач үзе каршы ала. Бу авылда тиф эпидемиясе башланган икән. Өлкән земский врач яшь коллегасы белән әдәпле, әмма коры итеп исәнләшә дә каты итеп кисәтеп куя:

— Тиз килеп җитүегез яхшы. Моның өчен мактыйм. Әмма тройкагыз өчен, гафу итәсез, егеткәем, ачуланырга тиешмен. Һәр вакыт исегездә тотыгыз: крестьяннар барчукларны яратмыйлар!

Күчер, әлбәттә, бу сөйләшүне ишетми, кайтканда тагын да кызурак кайталар, каршы очраган олауларны, борылып өлгермәсәләр, бәреп егалар. Әбүбәкер абзый тройкадан баш тарта.

— Мин тройкада чабарга түгел, авыруларны дәваларга килдем. Миңа кешеләрне таптамый, олауларны бәреп китми торган атлар бирегез,— ди ул үзенең җитәкчеләренә.

Күчер итеп Вәлиулла дигән кешене ала. Бу Вәлиулла озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, йомшак холыклы бер агай була. Соңыннан, аерылганда — Әбүбәкер абзый Казанга китә — Вәлиулла елап җибәрә:

— Нигә бездән китәсең? Шулай начар булдымыни бездә? Ярат-мадыңмыни? — ди ул. Кулына чыбыркысын тотып, Вәлиулла әле байтак вакыт пар аты янында басып тора һәм күз яшьләрен сөртә. Әбүбәкер абзыйның да күзенә яшь килә. Китеп барган вагон тәрәзәсеннән ул соң мәртәбә кул болгый...

Әбүбәкер абзыйның истәлекләре моның белән генә бетми. Ул туган якларына әле тагын ике мәртәбә кайта һәм шул турыда бик тәфсилләп сөйли. Аннары Кама буйларында ауга йөрүләрен искә ала. Ау турында ул бик шагыйрәнә итеп сөйли. Мин аларның барысын язып алганмын...

Әбүбәкер абзый ике кулын баш астына куйган да түшәмгә карап уйга чумган. Әле яңа гына парикмахер килеп киткән, сакалын кырган, мыегын төзәткән, одеколон бөркегән. Кәефе шәп чакта ул иренмичә сөйли. Мин аның янында урындыкта утырам, тыңлыйм. Кулым-

---

[1] Әминә Ибраһимовна — Әбүбәкер абзыйның тормыш иптәше.

да, билгеле, кәгазь-фәлән юк. Бары тик Әбүбәкер абзый йокыга киткәч кенә сызгалыйм. Әбүбәкер абзыйның Себер хикәяләрен, алтын елгалар турындагы әкиятләрен барысын язганмын. Л. Толстой, С. Цвейг турында гүя поэма укыды. Кайчак ул җәһәт итеп кулы белән ишарәләр ясап ала. Аннары иреннәрен нык итеп кыса. Шулай бер секунд чамасы тора да «һы-һы» дип куя, ап-ак башын кызык кына итеп боргалап ала һәм кыска ак мыегы астыннан бик ягымлы итеп елмая. Аннары Казан байлары турында сөйләп китә...

Бүген Әбүбәкер абзый янына аның хатыны Әминә апа килде. Олы яшьләрдәге хатын, күзләре начар күрә. Миңа аларның үзара сөйләшүләрен тыңлау кызык. Бер-берсенә «сез», «туганкай» дип кенә эндәшәләр.

Әминә апа Әбүбәкер абзыйның Хөсәен Ямашев турында сөйләгәннәрен раслады. Аннары болай дип өстәде:

— Өфедә Кәримовлар аны киногa төшерткәннәр иде. Болында, сәйранда йөргән чагында. Хөсәен бик яхшы төшкән дип күп сөйләделәр ул чакта. Үземә карарга туры килмәде. Бәлки ул кинолента Кәримовлар нәселендә бүген дә саклана торгандыр.

Саубуллашканда Әминә апа иренә:

— Мин сезне яткырыйм да, туганкай, кайтып китим,— диде.

Әбүбәкер абзыйның еш кабатлый торган сүзләре бар иде. Берсе болай:

— Алла тәгаләнең кодрәте зур, ул мине ир иткән, хатын итмәгән!

Көннәрдән бер көнне Әбүбәкер абзыйларның квартирасына бер татар карчыгы килеп керә.

— Әбүбәкергә күренергә килдем, ди. И, әнә үзе дә өйдә икән, рәхмәт төшкере. Карасана, син, Әбүбәкер балам, һаман элеккечә икән, тырнак очы кадәр дә үзгәрмәгәнсең... Хәтерем бутамый торган булса, мин моннан утыз еллар элек сиңа бер күренгән идем. Ашказаным авырта дип. Даруың бик килешкән иде. Бүтән бер дохторга да бармадым. Әбүбәкерем биргән даруны гына эчәм дидем. Күз карасы кебек саклап тотсам да, бетте шул сихәтле даруым. Зинһарлап сорыйм, тагын шундый шифалы дару биреп җибәр үземә. Гомер буе теләк теләрмен...

— Әдрәс бишмәт, теләсәң нишләт,— дип, Әбүбәкер абзый яңадан үзенең Чишмәсенә кайта, бетмәс истәлекләрен сөйли башлый. Аннары Казанга кайтып, Әдик белән (Әбүбәкер абзыйлар үстергән малай) булган вакыйгаларны актара башлый...

Күп вакыт ул Казем-бек турында сагынып сөйли.

Җәүдәт Фәйзинең хәлен белә кердем. Ул һаман җиденче палатада ята. Кәефе яхшырган, йөрәге сызламый, күп йоклый. Кайсыдыр врач: йокы — җиһан туенда иң яхшы сый ул,— дип әйткән ди.

Сөйләшеп киттек.

— Менә хикәя өчен бик әйбәт тема,— диде ул.— Уйлап яттым әле. Берәүне, носилкага салып, больницага китерәләр. Өстенә ак җәймә япканнар. Караватка яткыралар. Ул һушсыз, берни белми. Төнлә аңына килә. Ут сүндерелгән, стенада күләгәләр уйный. Кайдадыр электросварщик эшлиме: стена бер яктырып китә, бер караңгылана. Яктылык тигез түгел, дерелдәвек. Яктырып киткәндә стенада тәрәзә рамнарының, пәрдәләрнең күләгәсе күренә. Пәрдәләр күләгәсе тибрәнә һәм ниндидер бер мизгелдә ул шул хәтле зурая, бөтен стенаны каплап ала. Мондый чакта стенада диңгез дулкыннары хасил була кебек.

Кеше уйлый: стенада тормыш бар. Зиһене әкренләп ачыла, ул үзенең кызганыч хәлен аңлый, йөрәгенә кулын куя: күпме тибәрлек хәле калган икән? Ә стенада диңгез чайкала, кайчак урамдагы куш фонарьлар күләгәсе күренә. Юк, тормыш дәвам итә. Авыруда яшәргә дәрт туа башлый...

Бәйрәм ашы кара каршы дигәндәй, икенче көнне Җәүдәткә, опера өчен «шәп тема» дип, Надежда Дурова турында сөйләдем. Дөрес, кавалеристка кыз турында опера бар барын, ләкин бездә аны бөтенләй икенче яктан ачарга мөмкин. Дурованың татарлар турында язган хикәясе ни тора! Аннары Алабугадагы пәриләр шәһәре турындагы легендалар, рус, татар җырлары, француз бәете, Казан губернаторы белән очрашулары. Толстойның «Балдан соң» хикәясендәге вакыйгаларны да шуңа китереп бәйләсәң, гаҗәп әйбер килеп чыгар иде. Иң мөһиме: рус-татар дуслыгының күптәннән килүен күрсәтергә булыр иде...

— Бу идея турында уйларга ярый,— диде Фәйзи.

16. 1. 1961 ел. Иртәгә чыгам инде. Бераз аруландым шикелле. Әбүбәкер абзый да бер-ике көннән чыга. Без аның белән нык дуслаштык. Озак ятканга аның аяклары йөрми башлаган иде. Мин аны култыклап коридорга алып чыга идем. Башта озын коридорның яртысына кадәр генә бара идек, аннары ахырына кадәр. Соңгы көннәрдә баскычтан да төшеп менгәләдек.

Күнегелгән шифаханәдән чыгып китү моңсу икән!

*Чехов урамы, 2 нче йорт,*
*Республика шифаханәсе. 16. 1. 1961.*

Менә икенче дәфтәр дә бетте. Икенче дәфтәр — иҗат лабораториясенең икенче бүлмәсе дидем. Ләкин иҗат лабораториясе ике бүлмәдән генә тормый, аның әле өченче, дүртенче, бишенче... бүлмәләре дә, бихисап подваллары да җитәрлек. Бу икенче бүлмәдә төп геройлардан берсенең прообразы күренә. Сүз романдагы профессор Әбүзәр образы турында бара.

Вакытында кайбер иптәшләр мине прообраздан «мең чакрымга ераклашкан» дип гаепләп карадылар. Нидән гыйбарәт соң образ белән прообразның үзара мөнәсәбәте? Мин профессор Әбүбәкер Терегулов турында махсус китап язмадым. Мин аны фәкать прообраз итеп алдым. Ләкин прообраз ул әле тулы образ түгел. Язучы шул нигездә бөтенләй яңа әдәби шәхес иҗат итәргә тиеш. Аны исә фотография юлы белән иҗат итеп булмый. Монда иҗат фантазиясенең катнашуы шарт. Гомумиләштерү кирәк. Әдәби образдан тормышчанлык таләп ителсә дә, аның төгәл копия булуы мәҗбүри түгел. Копия әдәби образның җанын ала, аны тоныкландыра, философик мәгънәсен җуя. Киңрәк күләмдә әйтсәк, язучыны һөнәрче итә. Язучы исә иҗатчы булганда гына үз исемен аклый ала.

Болар инде иҗат лабораториясенең өченче һәм аннан соңгы бүлмәләрендә эшләнә торгандыр. Бу эшнең нинди дә булса закончалыгын яки тәртибен күрсәтергә бер язучы да алынмастыр шикелле. Һәр язучы үзенчә, фәкать үзенчә генә яза. Көнбатыш әдәбиятларда теге яки бу классик язучының ничек язганлыгы турында, сәер гадәтләренә кадәр, кызыклы китаплар бар. Кайберләре хәтта анекдоттай яңгырый. Мәсәлән, берсе язган чакта хәтсез күп кофе эчкән, тәрәзәләрен каплаткан, икенчесе аягын җылы суга тыккач кына яза ал-

ган... Татар әдипләреннән фәкать төнлә генә язучылар һәм язган чакта кайнар чәй эчүчеләр билгеле.

Образларны чарлау, әсәрнең сюжетын камилләштерү, телне шомарту кебек эшләр, шулай ук, һәммә язучыга хас ниндидер бер схема яки тәртип буенча башкарылмый. Берәүләр күп нәрсәне уйда тудыра, бүтәннәр кәгазьдә. Мин үзем тегесеннән дә, монысыннан да файдаланам. Ничек? Моны караламаларны тикшерүчеләр генә әйтсә әйтә алыр. Кайчак үзем шуны чамалап карыйм да ихтыярсыздан куркып калам: бу коточкыч эш! Моның очына чыгу гомумән мөмкинме? Теге-бу уй язучының башында кайчан, нинди сәбәпләр аркасында туган? Бер җөмләне яза башлаган да бозган, чөнки яшен тизлеге белән башына икенче уй килгән. Язучының уе, фикере, җанлы сыман, кан тамыры шикелле тибеп тора. Ә кайчакта ул шул ук нәрсәне шактый вакыт үткәч эшли. Ник? Ихтимал, беренче язганда җанлы уй әле өлгереп җитмәгән булгандыр, йомылып яткандыр. Язучы моны әйтми, әйтә дә алмый.

Кайчагында «төзәтүләр» телгә генә карый, җөмлә җыйнаклана, матурая. Кайчагында шул бер сүз, бер җөмлә әсәрнең бөтен сюжет агышын үзгәртеп җибәрә, эчтәлегенә дә кагыла. Игътибарлы һәм... талантлы тикшерүче — әдәбият галиме, һичшиксез, талантлы һәм эчкерсез булырга тиеш — моны күрә, күрми кала алмый, чөнки ул да иҗатчы, иҗат минутларында ул язучының икенче җаны булып әверелә. Мондый тикшерүчедән гаҗәп зур ачышлар көтәргә була. Кызганычка каршы, бездә мондый әдәбиятчылар азрак шул. Бездә язучыдан акыллырак булып күренергә тырышкан, югары баскычтан торып акыл саткан, язучыларны үз манарасыннан карап кына талантлыларга һәм талантсызларга бүлгән тәнкыйтьчеләр күбәеп бара...

Кайбер язучылар кульязма өстендә эшләгәндә, бигрәк тә телне шомартканда, берничә төрле кара кулланалар: кызыл, яшел, зәңгәр... Мин үзем алай итмәскә тырышам, күчерергә туры килсә дә, бер генә төрле кара кулланам.

Башка романнарымның язылу «тарихларын» кәгазьгә теркәп бармаганмын. Кираксенмәгәнгәме, хәтергә артык ышангангамы (әйтерсең ул үзгәрми тора!), белмим, нәрсәдер булган. Әмма «Ак чәчәкләр»нең ничек язылуын кәгазьгә беркадәр теркәгәнмен. Хәзер шуларны, кыскартып, күчерә башлыйм.

25. 8. 1962 ел. Инфаркттан соң (1958 ел) аякка баскач, мине «Мәңгелек кеше» мавыктырып алды. Күрәсең, ул өлгергән булган, бик тиз язылды. Ә медицина һаман калып торды. Чөнки ул өлгермәгән иде.

1960 елның ахырында янадан больницага кереп яттым. Бу юлы профессор Әбүбәкер абзый Терегулов белән икәү бер палатага туры килдек. Шунда мин әсәремнең төп геройларыннан берсенең прообразын таптым. Хәзер инде күп нәрсә ачыкланды. Беренче һәм икенче бүлектән аерым главаларны язып та ташладым. Ләкин озакламый килеп «тәртелдем». Һаман нәрсәдер җитми иде кебек. Әллә «Мәңгелек кеше»дән соң арыган идем — зур әсәрне тәмамлагач, «бушап калгач», гомумән үзеңне беркадәр авыру сизәсең. «Мәңгелек кеше» кебек авыр фаҗигаләргә корылган (Бухенвальд!) әсәрне язгач бигрәк тә. Бер вакытны якыннары Бальзакны язу өстәле янында һушсыз килеш табалар. Бик борчылалар, аннары аңардан: ни булды, дип сорыйлар. «Әле яңа гына отец Горио үлде», дип җавап бирә

язучы. Шуңа якын хәлләрнең башка язучылар белән дә булуы бик ихтимал. «Мәңгелек кеше»дә бер генә үлми, ун меңнәрчә тоткыннар үлә, дөресрәге, үтереләләр.

Ни генә булмасын, врачлар мине бөтенләй диярлек эштән тыя башладылар. Вак-төяк мәкаләләр, хикәяләр генә язгаладым. Әмма «Ак чәчәкләр»не бер генә минутка да оныта алмадым. Күңелдә эшләү һаман дәвам итте.

1962 елның 30 июнендә язучыларның санаторий тибындагы иҗат йорты — Малеевкага (Мәскәү янында) килеп төштем һәм шул ук көнне язарга утырдым. Шуннан соң бер генә көнгә дә бүленмәдем. Иртәдән кичкә кадәр яздым да яздым. Ял да, дәвалану да, прогулкалар да — барысы да онытылды. Мин фәкать ашарга гына барам, бер сәгать, ярты сәгать һава сулыйм да тагын язарга утырам. Малеевкада олы гына бер сестра бар иде, ул элегрәк Склифасовский больницасында операция сестрасы булып эшләгән. Бик күп нәрсә сөйләде. Төрле хирургларны күргән, инструментларны атып бәрә торганнары да булган. Беләгендәге яра эзен дә күрсәтте. Янгура һәм операция сестрасы образларын ачыклауга ул күп ярдәм итте.

1962 елның 22 июлендә романның соңгы главасын язып бетердем. Соңыннан үзем дә шаккаттым: 24 көн эчендә романның беренче караламасы әзер! Эврика!

Малеевкада мин шундый хис белән яшәдем: гүя иҗат савытларым тулган, ташый, гизрәк-тизрәк, югыйсә, түгелә, җиргә агып китә. Ничек кенә булса да сулышны өзмичә, күңелне сүрелдермичә барысын кәгазьгә төшерергә кирәк иде.

Бу вакытта Малеевкада Әхмәт абый Ерикәй хатыны белән ял итә иде. Ул минем ничек эшләүне бераз күрде. Аннары Мәхмүт Максуд бар иде. Ул да бик күп эшлисең, дип әйткәләде. Чөнки аның янына да бик азга гына кереп чыга идем.

Путевканың срогын берничә көнгә озайттым.

23 июльдә үк романның беренче кисәген укырга, төзәтергә керештем. Бу эш 31 июльгә кадәр дәвам итте. 1 августта Малеевкадан икенче иҗат йорты — Переделкинога күчтем.

Переделкино башта ук миңа ошамады. Малеевкадагы юан имән янындагы ярым караңгы бүлмәмнән аерылгач (7 нче бүлмә), яңасына ничектер тиз генә ияләшә алмадым. Югыйсә, мондагы бүлмә иркенрәк тә, яктырак та иде. Начар ягы да бар, бүлмәне яңа гына ремонтлаганнар, мин килеп кергәндә буявы да яхшылап кибеп җитмәгән иде. (2 флигель, 54 бүлмә.) Тәрәзәне ачсаң, поезд, самолет тавышлары, япсаң — буяу исе башка каба.

Переделкинога килүемнең төп сәбәбе — «Мәңгелек кеше»нең русчага тәрҗемәсен тәгалләү иде. (Тәрҗемәчем Кузьма Яковлевич Горбунов күрше Баковкада, үз дачасында тора. Тәрҗемәче белән нибары ике тапкыр очраштык. Аның замечаниеләре аз иде. Ләкин Горбунов зур рус язучысы — Горький мактаган «Ледолом» романының авторы, мин аның кечкенә генә күрсәтмәләрен дә игътибарсыз калдырмадым.)

Төп эшем һаман «Ак чәчәкләр» булды. 25 августта беренче бүлекне күчереп бетердем. Кульязма белән 210 бит булды. Ә роман биш бүлектән тора.

Иртәгә путевканың соңгы көне. Казанга кайтам. Анда эшләр ничек барыр — алдан әйтүе кыен.

Романның эше бик күп әле, ел ярымнарга сузылырдыр. Иң мөһиме врачларны (ягъни геройларны) «дипломлы» итәсе бар. Хәзергә

алар күбрәк матбугат конференциясендәге космонавтларча сөйләшәләр (һәм эшлиләр дә): Җиһанга очтыкмы? Очтык. Ничек очтык — анысы сер. Минем врачлар да шулай: авыруларны сәламәтләндерәме? Сәламәтләндерә. Ничек сәламәтләндерә, анысы сер. Халыкара пресс-конференцияләрдә әйтеп бетермәү — урынлы, ә матур әдәбиятта болай эшләү һич ярамый, чөнки укучы ышанмый башлый. Ә укучыны ышандырмый торган «әсәр» — макулатура гына.

Кыскасы, эш муеннан әле. Ләкин төп баганалар утыртылган, төп образлар ачык (һәрхәлдә, күңелдә, кәгазьдә эшлисе бар).

Романның исеме — «Ак чәчәкләр» — шулай калырмы, үзгәрерме — белмим. Әсәрнең исеме эчтәлегеннән кечкенәрәк булырга тиеш. Укучыга зур нәрсә вәгъдә итеп тә бәләкәйне бирсәң, яратмый. Киресенчә булганда, күңеленә хушрак килә.

*Переделкино. 25. 8. 1962 ел, кичке сәгать сигез.*

* * *

13. 2. 1963 ел. Бүген «Ак чәчәкләр»не күчереп бетердем. Кульязмада 898 бит булды. Роман әзрәк киртәгә керде, геройларның язмышлары ачыклана төште, сюжет сызыгы да бераз рәтләнде. Ләкин эшлисе эш күп әле, бик күп. Беренче чиратта медицина ягына игътибар. Характерларны тулыландырасы, чарлыйсы бар. Аннары җыйнакландыру һәм тел мәсьәләсе. Беренче караламаны ертып ташладым.

* * *

5. 6. 1963 ел. Бүген «Ак чәчәкләр»не икенче тапкыр күчереп бетердем. (Бу юлы машинкада.) Күзгә күренеп яхшыра төште, ләкин эшлисе тагын да күбәйде кебек. Медицина ягына һәм телгә аз тидем әле. Образлар да әле канәгатьләндереп бетерми. Бик озын. Кыскартырга. Башта бик җиңел кыскартырмын дигән идем дә, алай булмый икән.

* * *

22. 6. 1963 ел. Бүген «Чәчәкләр»не укып бетердем (төзәтә-төзәтә). Нәтиҗә: йөрәк белән эшләү шунда туктарга тиеш. Хәзер салкын акыл белән сукалый башларга кирәк:

1. Сюжетны камилләштерергә. Бигрәк тә башта.
2. Кыскартырга.
3. Вакытка игътибар. Инфаркт белән авыручылар больницада озак яталар. Гадәттә 2,5—3 ай.
4. Медицина мәсьәләләре (диплом!).
5. Тел.

Шуларны эшләгәннән соң гына берәр врачка консультациягә бирергә мөмкин булыр.

2. 9. 1963 ел. «Ак чәчәкләр»нең яртысын карап, төзәтеп чыктым. Байтак үзгәрде, сюжет ягы да төзекләнә төште.

Алда салкын акыл белән генә эшләргә кирәк дип ашыгыбрак язганмын. Акыл һәм йөрәк әле һаман бергә эшли.

Бүген Ялтага, иҗат йортына китәм. Романны да, машинканы да алам. Исәп — икенче яртысын төгәлләү. Кайткач, медицина ягына керешермен. Анысы күпме вакыт сорар — чамаларга да мөмкин түгел. Дөресен әйткәндә, врачлардан шүрлим. Юкка чыгармасалар ярар иде. Аңлы рәвештә эрну-сызлануларга азрак урын бирергә тырыштым. Авыруларны кызгандырасым, укучыларны елатасым килми, оптимистик әсәр булсын иде. Больница тормышының ямьсез яклары да аңлы рәвештә йөгереп үтелә. Сәнгать әсәрендә алар кирәкми. Шулай ук медицина «производствосыннан» да качарга тырышам. Укучы аңламаслык терминнар тутыруда мәгънә юк. Матур әдәбият әсәрендә иң уртада кеше, бу очракта врачлар һәм авырулар торырга тиеш. Аларның күңел тибрәнүләрен бирә алсам, шунда гына бурычымны үтәдем дип санар идем.

* * *

5. 10. 1963 ел. Бүген Ялтадан Казанга кайтып төштем. Ялтада «Чәчәкләр»нең икенче яртысын карап чыктым, ягъни төзәттем. 25 көн буе иртәдән кичкә кадәр эшләдем. Диңгезгә су керергә дә әллә нигә бер генә бардым. Күп кенә урыннарын машинкада күчердем, яңа битләр яздым. 30 сентябрьдә икенче бүлекне карап чыгам, аңа яңа бер глава яздым (12 глава).

Бүген, 6 октябрьда, инде Казанда, өченче бүлекне карарга утырдым.

* * *

19. 10. 1963 ел. Өченче-бишенче кисәкләрне карадым. Башта һаман яңадан-яңа фикерләр туа. Искеләре канәгатьләндерми. Гөлшәһидәнең эше азрак, аңа эш бирергә кирәк, эш, эш!

* * *

11. 1. 1964. Берөзлексез «Ак чәчәкләр»не эшлим. Моннан ике-өч көн элек машинкадан соң укып чыктым. Тагын әллә нихәтле яңа уйлар. Бик күп кыскарткан идем кебек, тагын машинкада 876 бит булган (минем машинка ваграк хәрефле икән). Кысарга, һичшиксез кысарга кирәк. Шулай да, тәвәккәлләп, кулъязманың бер данәсен хөрмәтле Афзал абый Шамовка укырга бирдем. Беренче укучы, ни дияр?!

25. 3. 1964. «Ак чәчәкләр»нең икенче данәсен январь аенда ук врач-терапевт Зөмәррә Зариповага укырга биргән идем (тимер юл

больницасы). Ул аны бик тиз укып та кайтарды. Шулай итеп, романны беренче укып чыгучы шул ак халатлы кеше булды. Бик кызыксынып укыганлыгын әйтте. Терапевт буларак үзенең киңәшләрен бирде. Алар әллә ни зур төзәтүләр сорамый иде. Тик Асия мәсьәләсендә башкачарак язарга кирәклеген әйтте. (Йөрәк парогы.) Шундый авыруларның «тарихларын» китереп бирде. Алар миңа әйтеп бетергесез ярдәм итте. Гомумән Зөмәррә ханымга чиксез зур рәхмәт. Минем аяк астымда җир ныгый төшкәндәй булды.

7 февральдә Афзал абый Шамов та романны укып кайтарды. 19 битлек рецензия язган! Ул да романга уңай бәя бирде һәм шуның белән бергә җитди генә кимчелекләрен дә күрсәткән. Ул бит гади укучы гына түгел, зур язучы да. Аның фикерләре минем өчен бик кыйбат булды.

Мин инде үземнең каты авыруымны сизә һәм бер кемгә дә әйтмичә йөри идем. 9 февральдә больницага салдылар. Тагын роман өчен кирәкле детальләр җыю башланды. Ул арада икенче врач-терапевт Диләрә Кадыйровна Ходжаева романны укып чыкты. Ул минем янга больницага ике тапкыр килеп китте (хәзер ул поликлиникада эшли иде). Бик җентекләп укыган, байтак кыйммәтле киңәшләр бирде. Романны кызыксынып укыганлыгын әйтте. Аның белән бергә романны аның дәү әнисе дә — шулай ук күренекле врач! — укыган икән. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә романны өч врач укып чыкты. Хәзер Әхмәт абый Айдаровка (романда Чалдаев) укытып, хирургның киңәшен беләсе калды.

19. 8. 1964 ел. Иҗат эше никадәр авыр, газаплы булмасын, ул бер вакытта да арытмый, туйдырмый. Аның сүз белән әйтеп биреп булмый торган бер ләззәте — вакытны оныттыра торган сихри көче бар. Мондый чакта җан тыныч, күңел күтәренке, гүя бәхет кошы — койгырыш синең кулыңда. Үзеңне җәмгыятькә кирәкле бер кеше итеп сизәсең.

Инде әсәр язылып беткән, син иптәшләреңнең гадел хөкемен көтәсең! Ибраһим Гази романны атна-ун көн эчендә укып бирде. Аның тәнкыйть фикерләренең байтагын мин инде төзәтеп тә өлгергән идем. Аннары «Ак чәчәкләр»нең байтак өлешен Габдрахман Минский да укып чыгып фатиха бирде. Бераздан «Совет әдәбияты» журналы редколлегиясенең өченче кешесе — Сибгат Хәким дә мине куандырды.

Билгеле, барысы да шулай шома гына бармады, бәхәсләр дә булып алды. Алары кайсы гына әсәргә карата булмый икән? Әдәби зәвыклар, әдәби әсәрләргә карашлар бер төрле түгел бит.

10. 10. 1964 ел. Соңгы ике айны тагын «Ак чәчәкләр» белән утырдым. Редколлегия кешеләренең гомуми искәрмәләре әллә ни күп булмады. Ләкин мин үземә кыскарту бурычын куйган идем. Журнал варианты дигән нәрсәне гомумән кире кактым. Безнең укучыбыз бер — аңа «вариантлар» кирәкми.

Инде ни булса да булгандыр, бүген бу зур эшне дә тәгәлләдем. Билгеле, бу актык нокта түгел. Журнал укучылар кулына кергәч, тагын бик күп фикерләр әйтелер. Аларын да карамый булмас. Ни хәл итәсең, эшебез шундый безнең.

1965 ел. «Ак чәчәкләр» романы башта «Казан утлары» журналында (1—5 саннар), аннары шул ук елны аерым китап булып басылды. 1968 елда икенче басмасы чыкты. Шул ук елда Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында, 1970 елда «Роман-газета»да (2.200.000 тираж белән), 1972 елда «Современник» нәшриятында «Библиотека российского романа» сериясендә русча тәрҗемәсе басылып чыкты.

Менә сез иҗат лабораториясенең икенче бүлмәсендә дә булдыгыз, аннан соңгы бүлмәләрнең дә ишекләрен ачып, башыгызны сузып эчкә карадыгыз. Үзегезгә файдалы берәр нәрсә таба алдыгызмы? Таба алган булсагыз, мин бик шат, димәк, бушка утырмаганмын. Тагын бер тапкыр басым ясап әйтәм: бу язмаларга катгый бер закон итеп карамагыз, болай да була икән дисәгез, шул җиткән. Тик аларның тирәнлегендә, күзгә күренмичә, автор тарафыннан сүз белән ачыкган-ачык әйтелмәгән «иҗат серләре» ята. Вакыты килгәч, иҗат һәм тормыш тәҗрибәсе туплагач, аларын да беркадәр төшенерсез дип ышанам.

Матур әдәбият белән гомумән кызыксынучы меңләгән иптәшләргә сүзем шул: сез язучы эшенең никадәр кыен, катлаулы һәм авыр икәнен күрдегез. Ул тормыштан бер нәрсәне дә әзер көенчә алмый, тагын да ачыграк әйтсәк, тормыш матур әдәбият әсәрләре язмый һәм аларны язучылар йөргән юлларга яшереп куймый. Бары тик күчермә мәгънәсендә генә язучы, алтын эзләүче кебек, гаҗәеп бай материалга юлыккан дип әйтә алабыз. Шунысы да бар тагын, берәүләре шул хәзинәнең өстеннән йөри, ләкин берни күрми, икенчеләре шуны махсус эзли. Табамы? Һәр очракта да уңай җавап биреп булмый. Бу бүтән күп нәрсәләргә бәйләнгән...

Сизеп торам, тел очыгызда бер сорау кыймылдап тора: барысын яздыгыз, карт буын геройларның прообразларын да күрсәттегез, ул кешеләр хәзер дөньяда юк икәнен дә төшендердегез, ләкин безне Гөлшәһидә һәм Мансурның прообразлары кызыксындыра, дисез сез.

Хөрмәтле укучыларым, язучы үзенең геройларын күктән алмый, аларның кайчакта бер түгел, берничә прообразлары була. Кайчакта хәтта бөтенләй булмаганны да тагалар. «Ак чәчәкләр» чыккач, казанлылардан берничә кеше миңа: «Гөлшәһидәңне фәлән врачтан алып язгансың икән, үзе әйтте, дөресме?» — диделәр. Мин көлемсерәдем.

— Үзе әйткәч, дөрестер инде,— дидем.

Ләкин, минемчә, бер врач та, Гөлшәһидәне ошаткан хәлдә дә, мин Гөлшәһидә, дип әйтмәс. Әдәби образ даны нәрсәгә аңа? Үз даны, чын дан, Гөлшәһидәнең шөһрәтеннән югарырак лабаса!

Гөлшәһидәне, шулай ук Мансурны иҗат иткәндә дә, мин бер генә прообразга ябышып ятмадым. Алар әле яшьләр, аларда Әбүбәкер абзый Терегуловтагы яки Николай Иванович Якушенкодагы тормыш тәҗрибәсе, акыл һәм хикмәт юк. Шуңа күрә Гөлшәһидә, Мансурларны күбрәк гомумиләштерелгән әдәби образлар итәргә тырыштым. Аларның атап әйтерлек адреслары да юк, аларга хатлар язсагыз да барып җитмәс.

Беләм, хатлар күп вакытта гади кызыксыну аркасында гына язылмыйлар. Кешенең яшисе килә! Ул инде врачларда да булган, больницаларда да ятып чыккан, матур әдәбият әсәре кулына эләккәч, өмете уянып, язучыга да хат салган. Ул барысына да ябыша. Моны барлык авырулар диярлек эшли. Шуңа күрә авырулардан врачларның адресын сорап хатлар килүе дә гаҗәп түгел.

Бервакыт, «Казан утлары» журналында бугай, бер мәкалә укыдым. Автор, «Ак чәчәкләр»гә кагылып, загслардан сорашып белдем, яшь ата-аналар яңа туган кызларына Гөлшәһидә исемен куштыралар икән, ди.

Балага исем бирү — зур нәрсә. Ул гомерлек. Моны уйламыйча гына эшләмиләр. Бер заман, үскәч, бала әнисеннән: кайдан миңа шундый исем таптыгыз? дип сорар. Ана әйтеп бирер. Яшь кызда шул китапны табып уку теләге туар...

Шундый хәл чыннан да була калса, бу минем барлык иҗади борчылуларым, газапларым һәм хезмәтем өчен бирелгән әйтеп бетергесез зур бүләк булыр иде. Моны мин кояш тотылганда тапкан хәзинәм өчен дип кабул итәр идем.

1973 ел

Таҗи Гыйззәт

# ЧОРДАШЛАР, КАЛӘМДӘШЛӘР

*Үзенең утыз елдан артык иҗат гомерендә драматург Таҗи Гыйззәт бай һәм күпкырлы мирас калдырды. Язучының шәхси архивында (ул хәзер Татарстан дәүләт музеенда саклана), башланып та тәмамланып җитмәгән сәхнә әсәрләре белән бергә, моңа хәтле матбугатка чыкмаган күп кенә мәкаләләр, истәлекләр һәм кульъязмалар бар.*

*Журналның бу санында укучыларга шундый ике истәлек тәкъдим ителә. Берсе күренекле драматург Кәрим Тинчурин, ә икенчесе татар халкының сөекле шагыйре Һади Такташ турында. Чама белән һәр икесе утызынчы елларның беренче яртысында язылган дип әйтергә була. Һади Такташ турындагы соңгы истәлек, иң кызыклы җирендә өзелеп, тәмамланмый калган. Автор исән булса, матбугатка бирер алдыннан аларны, һичшиксез, яңадан бер карап чыгып, төзәткән, камилләштергән булыр иде.*

*Без исә укучыларга ул истәлекләрне үз вакытында ничек язылган булсалар, шул хәлләрендә тәкъдим итәргә булдык. Аерым урыннардагы вак-төяк кыскартуларны искә алмаганда, истәлекләргә үзгәреш кертелмәде.*

*КАЗБЕК ГЫЙЗЗӘТОВ.*

## Кәрим Тинчурин

1920 нче ел май аеның ахыргы көннәре.

Бу вакытларда Колчак, Деникиннарның сатлык армияләре, данлы Кызыл Армиябез тарафыннан тар-мар ителеп туздырылса да, шул ук дөнья капиталистларының акчасына сатып алынган Польша паннары, барон Врангель гаскәрләре, иң соңгы техника белән коралланган хәлдә, Советлар өстенә ахыргы мәртәбә коточкыч рәвештә һөҗүм иткән чаклар иде. Менә шундый авыр көннәрдә Совет хөкүмәте Самара шәһәрендә Идел арты хәрби округының политик управлениесе каршында татар хезмәт ияләренең аң-белемнәрен күтәрү, милли культура кадрларын хәзерләү максаты белән 150 кешелек укытучылар курсы, 400 кешелек политшкола, 120 кешелек драма һәм 60 кешелек музыка студияләре ачып җибәрә. Заманында шул драма студиясенең гади бер укучысы буларак, студияне оештыруда якыннан торып катнашучы һәм аның белән җитәкчелек итүче Кәрим ага Тинчурин турында булган кайбер истәлекләремне язып китмәкче булам.

Мин Казанда татар батальонында кызылармеец идем. Безнең батальонны бүген-иртәгә Польша фронтына җибәрергә торганда, беркөнне иртә белән барлау вакытында рота командиры иптәш Зарипов: «Гыйззәтов, Батыршин, ике адым алга», дип команда бирә һәм батальон комиссарына барырга куша. Бүлмәгә барып кергәч, комиссар, үзе янәшәннан безгә урын күрсәтеп, сүзгә башлады: «Менә нәрсә, егетләр! Без сезне икегезне дә Самара шәһәрендә ачылган татар драма студиясенә укырга командировать итмәкче булабыз», ди. Без, әлбәттә, бу командировканы үзебезгә зур шәрәф санап, шул көнне үк пароходка утырып, Самара шәһәренә киттек.

Җәйнең иң матур чаклары, Волга пароходы, кичке дымлы һаваны ерып, матур яр буйларын, ямьле, яшел болыннарны бер-бер артлы артта калдырып, алга омтыла иде. Без, ике кызылармеец, соры шинельләребезне беренче класс палубасының идәненә җәеп яткан килеш җырлап бара идек. Тәтеш тирәсендәге матур урманнар, күңелле таулар башлану белән каюталарда баручы кешеләр дә безнең янга чыктылар. Соклана-соклана табигатьнең матур күренешләрен мактыйлар. Ә без һаман җырлыйбыз. Кисәктән чиста гына киенгән ачык чырайлы бер кеше безнең аяк очыбызга килеп туктады һәм кая баруыбыз турында сораштыра башлады. Без, әлбәттә, Самарага баруыбыз турында җавап кайтардык. Ул бездән кайсы яктан, нинди мәктәптә укуларыбыз, моңарчы сәхнәдә уйнавыбыз турында сорашканнан соң, үзенең студиягә укытучы булып баруын белдерде. Бу кеше Кәрим абый Тинчурин иде.

Кәрим ага, студиядә берничә дәрес алып бару белән бергә, ...«Актерның, режиссерның эше» дигән дәресләрнең тәрҗемәчесе дә иде. Кәрим аганың кеше белән яхшы мөгамәләдә, сабыр табигатьле, ачык чырайлы булуы укучыларны үзенә бик тиз җәлеп итте. Шуңа күрә дә Тинчурин студиядә иң авторитетлы, иң зур кеше итеп санала иде. Өч айдан соң практик эшкә керешеп, репетицияләр башлану белән ул үзен укучыларга тагын да якынайтты. Чөнки театр эшендә тәҗрибәсез, белемсез яшь көчләрдән артистлар хәзерләү бурычы бөтен килеше белән Тинчурин җилкәсендә иде. Шушы бурычны ул, бик күп авырлыкларга карамыйча, намуслы рәвештә үтәде. Алты ай вакыт эчендә тотнаклы яхшы артистлар хәзерләп чыгарды. Тинчурин студия беткәннән соң да үз укучыларыннан аерылмады. Шуларны үстерү, таркатмый саклап калу максаты белән «Пролетар коммунистлар труппасы» исемендә илле кешелек зур труппа оештырып, Оренбург шәһәренә күчте. Бу труппа, артистлар арасында яшәп килгән искелек калдыкларына рәхимсез көрәш ачып, «Сәнгать хезмәт ияләре өчен», «Формасы белән милли, эчтәлеге белән пролетар сәнгать өчен» дигән лозунгларны күтәреп, шул заманның бөек идеаллары белән мәйданга ташланды.

Безнең Академия театрында суфлерсыз уйнау мәсьәләсе моннан ике-өч ел гына элек тормышка ашырылган булса, «Пролетар труппасы» моннан уналты ел элек инде суфлерсыз уйный иде. Артистлар үз рольләрен генә түгел, хәтта уйнала торган бөтен пьесаны күңелдән белерлек итеп өйрәнәләр, ятлыйлар иде.

Рольләр уйнау да, дублерлык системасын тормышка ашыру да заманына күрә бик зур проблемалардан иде. Шулай ук бу труппада, гасырлар буенча яшәгән театр традицияләре җимерелеп, баш рольләрне уйнаучы артист белән кечкенә рольләрне уйнаучы артист арасында аерма берничә сумнар белән генә аерыла иде. Бу, әлбәттә, асылда дөрес булмаган тигезләүчелек принципы булса да, Тинчурин кебек үзе драматург, үзе режиссер, үзе баш рольләрне уйнаучы артист, үзе театрның җитәкчесе булган бер кешенең яңа гына мәктәп эскәмиясеннән чыккан артистлар белән бертигез жалованье алуы труппаның гомуми интереслары өчен үз интересларын корбан итүе иде. Шуның белән бергә, труппаның барлык артистлары Кызыл Армия сафларыннан җыйналган шинельле артистлар булганга, куела торган әсәрләрне уйнау өчен Тинчуринның барлык көчен безнең өстә була иде.

Кәрим аганың Самара студиясенә яшь кадрлар үстерүгә куйган көче, «Пролетар труппасы»на иткән хезмәтләре егерме биш еллык хезмәт бәйрәмен үткәргәндә аеруча искә төшереп үтелергә тиеш.

# Һади Такташ

I

1920 нче елның май башларында, яшь Совет дәүләте яңа гына Колчак, Деникин бандаларын тар-мар итеп, илне яңабаштан төзи башларга торганда, чит ил империалистларының ярдәме белән ак поляк паннары, барон Врангельның сатлык армияләре безгә каршы җинаятьчел походларын башлыйлар. Ләкин инде сугышларда чыныккан, зур көрәшләрдә җиңеп чыккан илебезнең халыклары аптырап калмадылар, большевиклар партиясенең җитәкчелегендә яңадан коралларын кулга алып, Көньяк фронтларына ташландылар. Менә шушындый авыр көннәрдә безнең большевиклар партиясе, чит ил империалистларының бу походларында да тиздән тар-мар ителәчәкләренә тәмам ышанган хәлдә, яңа культура, сәнгать көчләрен җитештерү теләге белән, май аенда Самара шәһәрендә Идел арты хәрби округы каршында татарлар өчен политшкола, педучилище, драма һәм музыка студияләре оештыра. Менә шушы драма студиясен тәмам иткән яшь көчләрдән бер труппаны яңа гына төзелеп килгән яшь Казагыстан республикасына җибәрәләр. 1920 нче елның декабрь айлары иде. Без илле кешелек артистлар составы, аерым вагоннарга төяләп, Оренбург шәһәренә киттек.

Безнең Оренбургка килү хәбәребез партия-совет җәмәгатьчелегенә һәм культура өлкәсендә эшләүчеләргә, әлбәттә, билгеле булган. Без Оренбург вокзалына килеп туктар-туктамас, тәбәнәгрәк буйлы, киң күкрәкле, җиткән куе чәчен артка тараган, су шикелле зәңгәр күзле бер егет безнең вагонга сикереп менде. Һәм шунда ук көләч ачык чырай белән «шагыйрь Һади Такташ» дип безнең белән күрешә башлады. Аның артыннан мәгариф эшчеләре, башка культура көчләре безнең янга кереп тулдылар. Әйберләребезне кулларыбыздан алып, вокзалның бер бүлмәсенә алып керделәр. Ул елларның гадәтенчә, митинг ачып, Оренбург губкомы, губерна мәгариф комитеты исеменнән яшь артистлар коллективын котлаулар башланды. Ахыргы сүз «Юксыллар» газетасы исеменнән әлеге ялангач башлы яшь егеткә бирелде. Ул үзенең мишәрчәрәк, кыска гына ялкынлы котлау рече белән бөтен тыңлаучыларны үзенә җәлеп итеп, безнең мәхәббәтебезне үзенә туплады.

Шуннан безне алдан билгеләнгән гомуми торак йортына алып киттеләр. Бу шагыйрь квартирага урынлашкач та безнең яннан китмәде. Безгә Оренбург хәлләрен, андагы культура көчләрен, нинди газеталар, театр артистлары барын сөйләде. Кыскасы, шул бер көн эчендә безнең барыбыз белән дә якыннан танышып, «үз кеше» булып китте. Һәм үзенең бик күп кенә шигырьләрен укып күрсәтте. Без барганда анда зур составлы театр труппасы эшли иде. Һадиның тәкъдиме буенча «Хезмәткә мәдхия» дигән спектакльне карадык. Шулай итеп, кич буена да ул безнең белән бергә булып, кызларыбызны торак йортыбызга кадәр озата килде.

Бу яшь шагыйрьнең безгә якынлыгы моның белән генә бетмәде, ул һәр көнне иртә белән эшкә барышлый безгә керә иде һәм эштән соң буш вакытларын безнең янда уздыра иде. Хәтта кайвакытларда бер йокы йоклап уянганнан соң да, кызлар бүлмәсендә сөйләшеп утыруын, яисә нинди дә булса мишәрчә кызык вакыйгалар сөйләвен, яисә шигырьләрен укуын ишетергә туры килә иде.

Безнең спектакльләр башлангач, ул, әлбәттә, бер генә спектаклебезне калдырмый караучы кешеләрнең берсе иде. Гадәтенчә, һәр вакытта алдан килеп, сәхнә артына кереп, барыбыз белән дә күрешә, сөйләшә иде. Антракт араларында да ул безнең янга кереп уйнаган рольләребез турында фикерләрен әйтә, ошаган җирләре булса, мактый, ошамаса, үзенең замечаниеләрен әйтә иде.

Шулай итеп, ул егерме беренче елның май ахырларына кадәр безнең белән бик якын бәйләнештә булып яшәде. Май ахырында без, ялга чыгып, һәркайсыбыз үз туган җирләребезгә таралган чакта да ул безне озатырга вокзалга төште. Шулай итеп, без Самарага таба кузгалып киттек, ул исә күздән югалганчы кулын болгап перронда калды.

## II

Без отпускадан килгәндә ул инде Оренбургта юк иде. Оренбург шәһәре 21 нче елның ачлык дәһшәтенең иң күңелсез вакыйгаларын үзенә туплаган бер шәһәр иде. Ачлык фаҗигасеннән котылырга теләп, Ташкент, Төркстан ягына бөтен Идел буе авылларыннан вагон түбәләренә сырышкан кешеләр белән поездлар үтеп китәләр. Атлы арбалар, тәссез-чырайсыз балаларын җитәкләгән ирле-хатынлы кешеләр. Урамнар, базар мәйданнары эчке Россиядән килгән шундый кешеләр белән тула иде. Бу фаҗига безнең труппадан да корбаннар ала башлады. Хакимуллин белән Хәмитов дигән артистларыбыз холерадан үләләр. Шуннан соң без, ничек кенә булса да китәргә карар итеп, 7 нче августта аерым вагонга төялеп, Ташкент шәһәренә юл тоттык. Ундүрт көн барганнан соң, ниһаять, Ташкент шәһәренә килеп төштек. Ни күзләребез белән күрик, перронда үзбәк түбәтәе кигән, ак күлмәк, ак чалбардан Такташ басып тора. Без вагоннан кычкыруга, йокысыннан уянган кебек айнып китә дә безнең янга йөгереп керә. Кочаклашып күрешәбез. «Син ничек монда?» дибез. «Мин өйгә кайткан идем дә рәт булмагач монда сыптырдым», ди. Кызык кына очраклы вакыйга. Оренбургка килеп төшкәндә беренче танышкан кешебез Һади Такташ булса, Ташкент шәһәрендә каршылаучы да ул булды. Ташкентта без аның белән озак була алмадык. Безнең труппаны монда, таратып, Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызстан авылларына мәгариф эшләренә тараттылар.

Шулай да мин, Ташкентка еш кына баргалавым сәбәпле, Һадины очрата торган идем. Чөнки ул безнең труппадагы Ташкентта калган Әсгат Мәҗит, Гумәр Терегуловлар белән бер квартирада тора иде. Билгеле, миңа да инде Ташкентка бару белән үземнең артист иптәшләрем белән очрашырга, яннарына барырга туры килә иде. Исемдә: бервакыт мин аның белән «Ирек йорты»на бардым. Анда аларның Зариф Бәшири белән араларында булган ниндидер низаг каралды. (Ялгышмасам, Такташ Зариф Бәширине (үзенең) «Тау кызы» исемле шигыреннән урлап язуын һәм аны бастырып чыгаруын фаш иткән иде.) Озак кына фикер алышулар Такташ файдасына булып, аның соңгы сүзе белән бетте. Чыннан да ул оратор булуы белән дә, үзенең хокукын яклавы белән дә бөтен залны кабындырды: сөйләгән сүзләре көчле алкышлар белән барды.

## III

1922 нче елның сентябрендә беренче Татар дәүләт театры үз бинасында (хәзерге Яшь тамашачылар театрында) эшли башлагач, октябрь айларында Һади Такташ Ташкенттан Казанга кайтып төште. Казанда, әлбәттә, бездән башка аны белүче юк иде. Һәм ул үзе дә Казанга килү белән безне эзләп тапты.

Хәзергедәй хәтеремдә, кич белән без, Октябрь бәйрәменә театрны ачу өчен, генераль репетиция ясый идек. Әсгат Мәҗит минем янга килеп: «Такташ кайткан», ди. «Кая?» мин әйтәм. «Әнә, залда утыра», ди. Чыннан да, беренче рәттә, ак тешләрен күрсәтеп, көлеп, ул утыра. Репетициядән бушау белән без аның янына төштек. Озак кына Ташкент хәбәрләрен аңардан сораштык. Һәм аның киләчәге турында киңәштек. Казанда, әлбәттә, аның башка танышлары юк иде. Тормышны алып барырга нинди булса да бер хезмәт кирәк иде. Без аңа шул хезмәтне табып бирергә булыштык.

Ул болай булды. Театрның штатында ике генә суфлер булуына карамастан, аны өченче суфлер итеп алуны сорадык. Бик шәп укучы дип, дирекциягә тәкъдим иттек. Аны суфлер итеп алдылар. Һәм шунда ук аңа Чернышевский урамындагы театр карамагында булган Европейск гостиницасыннан бүлмә дә бирделәр. Шулай итеп, Такташ театр эшчесе булды. Суфлер өч кеше булганда, алар чиратлап репетициядә утыралар иде. Шунлыктан буш вакыты күп булгандыр, ләкин аның суфлерлык таланты бик чамалы иде. Ул вакытларда машинкалар юк, басылган китаплар да юк. Суфлерларга авторларның кульъязмаларын укырга туры килә иде. Гарәп әлифбасы белән язылган кульъязмаларга тиз генә төшенү ифрат кыен булгандыр. Ул чакларда артистларда хәзерге кебек рольләрне ятлап уйнау гадәте юк иде. Спектакльнең, гомумән

артистның язмышы күбесенчә суфлерның тәҗрибәле, сәләтле булуына бәйләнгән иде. Ә ул мәсьәләдә, әйткәнемчә, Һадиның сәләте бик чамалы булып чыкты. Бервакытны шулай, ниндидер бер комедия уйнаганда онытылып китә дә суфлер будкасы эчендә рәхәтләнеп көләргә керешә. Шул вакытны алдындагы китабы аска төшеп китә. Сәхнәдә хәрәкәт туктый. Такташ аста китап эзләп йөри. Ахырда пәрдәне ябарга мәҗбүр булалар. Гомумән ул шатлык-кайгыны хис белән кабул итүчән иде. Җитдирәк чакта кашларын җыера, тавышына калтыравыклы ноткалар керә иде. Ә инде шатлык булганда зур авызын колагына кадәр ерып кычкырып көлүчән иде. Театрда ул озак эшләмәде. Шигырьләре газета, журналларда басыла башлау белән, тиз арада үзенә мәхәббәт казанды. «Кызыл байрак» газетасыннан секретарьлык хезмәтенә чакырдылар. Театр штатыннан чыкса да, квартира тормышы безнең белән бергә булганга, ул безгә, без аңа йөрешә идек. Бигрәк тә «Җир уллары» трагедиясе язып, якын дусты Әсгат Мәҗит бенефисенә биргәч, репетиция вакытларында һаман ул театрда булды. Хәтерем алдамаса, «Җир уллары» март айларында куелды. Газазил ролен уйнаучы артист кисәктән авырып китү сәбәпле, ул үзе чыгып башкарды, һәм ул аны начар уйнамады. Ләкин «Җир уллары» әсәре уңыш казана алмады. Чөнки инде Такташның дингә каршы протест рәвешендә язылган бу әсәре дин йогынтысында булган кешеләр өчен зур борчылу тудырган иде. Икенчедән, «Җир уллары» әсәренең беренче куелышы ничектер бәйрәм көннәренә туры килде (ураза, корбан гаете көннәре иде. Кайсы икәнен хәтерләмим). Бу әсәрнең куелу уңае белән мәчетләрдә һәм агай-энеләр арасында күп кенә сүзләр булган. Театрда куйдырмауны сорап ультиматум белән вәкилләр килә икән дигән хәбәр дә чыккан иде. Ләкин ни сәбәптәндер килмәделәр.

## IV

Һади Такташ белән минем дүртенче очрашуым 1929 нчы елның ноябрь айларында «Яңалиф» редакциясендә булды. Мин Казаннан китеп, биш ел Ульянов, Алабуга һәм Мәскәү шәһәрләрендә эшләп йөргәннән соң Казанга кайтып, яңадан Татар дәүләт академия театрына эшкә кердем. Бу вакытларда инде Һади иҗат ягыннан бик нык үсеп, иң популяр татар шагыйре булу дәрәҗәсенә ирешү белән, ул инде үзен тотышы белән дә бик нык үзгәргән иде. Анда хәзер элекке яшьлек уенчаклыклары сүнгән иде.

Менә ул 30 нчы елны «Камил» әсәрен язып, театр коллективына укырга килде. Сүз Такташка бирелде, укырга кереште. Беренче пәрдәсе шахтерларның гомуми торак бүлмәсендә бара. Яшь шахтерлар тормышындагы уен-көлкеләр, кызыклы күренешләр. Кызыклы моментлар килеп җиткәндә артистларга караганда үзе эче катып көлә. Бервакытны укый торган җиреннән туктады да «сезгә ошамыймы әллә» дип сорады.

— Ни өчен?

— Көлмисез,— ди.

*(Шунда истәлек өзелә.)*

Азат Әхмәдуллин

# ЗАМАН ГЕРОЕН ЭЗЛӘҮ ЮЛЫНДА

Татарстан язучыларының ике съезды арасында драматургларыбыз бик күп сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр. Әгәр театрларда куелган яки төрле җыентыкларда басылып чыккан пьесаларның һәммәсен бергә җыйсаң, аларның гомуми саны йөзгә якынлашыр иде. Бездә елына кимендә 10—15 яңа пьеса иҗат ителә.

Соңгы еллар драматургиясе хакында байтак язылды. Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда һәм матбугатта чыккан аерым мәкаләләрдә драматургларыбыз иҗатына төпле бәя бирелә, татар драматургиясенең үсеш тенденцияләре гомумиләштерелә барды. Шуны искә алып, мин укучыларның игътибарын соңгы ике елда дөнья күргән сәхнә әсәрләренә юнәлтмәкче булам.

Шикләнми әйтергә була: соңгы елларда идея-эстетик кыйммәте ягыннан да һәм жанр үзенчәлекләре ноктасыннан карагандa да шактый кызыклы, игътибарга лаеклы пьесалар иҗат ителде. Ул әсәрләр бүгенге драматургиябез үсешенә хас күп кенә үзенчәлекле якларны ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

Бүгенге драматургларыбыз иҗатына нәрсә характерлы соң? Бу сорауга драматургларыбыз кешенең тормыш белән, чынбарлык белән йөзгә-йөз килеп очрашуын сурәтли торган конфликтлар эзләүне көчәйттеләр дип җавап бирергә мөмкин.

Соңгы еллар драматургиясенең тагын бер үзенчәлеге шунда, турыдан-туры драма жанрына караган әсәрләр (тагын да аныклаштыра төшеп әйткәндә, психологик драма төрендәге пьесалар) башка төрләргә караганда күбрәк иҗат ителде. Театрларда комедия жанры хакимлек итә башлаган иде.

Хәзер исә саф драма төренә караган уңышлы әсәрләр дә торган саен ешрак күренә. Әдәбият өчен дә, театрларыбыз өчен дә күңелле хәл бу. Моннан, әлбәттә, комедия түбәнрәк сортлы сәхнә әсәре икән дигән фикер аңлашылмаска тиеш. Кимчелекләрне фаш итүдә аның белән бер жанр да тиңләшә алмый. Әмма шул кадәресен дә истән чыгармаска кирәк, сәнгатьчә тирән эшләнгән, тормышчан һәм ышандыра торган характерлар иҗат итәргә, совет кешесенең бай эчке дөньясын, аның хисләрен һәм фәлсәфи уйлануларын ачарга, чынбарлыкның алга үсешен тиешенчә сурәтләргә киң мөмкинлекләрне иң әүвәл драма бирә.

Гадәттә, драма әсәрендә бер яки берничә шәхеснең драматик хәле күрсәтелә, бу хәлгә китергән эчке һәм тышкы сәбәпләр ачып бирелә. Ә шәхес драмасы, ягъни драматизм төрле сәбәпләр аркасында туарга һәм күп төрле булырга мөмкин. Аны пьесада чагылдыруның берничә алымы бар. Әйтик, берсе менә мондый. Моңа кадәр без әйбәт кеше дип, яхшы иптәш, акыллы дус дип ышанып

йөргән бер кеше була. Кеннәрдән бер көнне әлеге кешенең эчке дөньясы, асыл мәгънәсе ачыла башлый. Вакыйгалар агышыннан килеп туган ниндидер ситуация бу персонажның эчке дөньясы белән тышкы кыяфәте арасында зур аерма, хәтта каршылык барлыгын ачып сала. Шушы ачыш пьесада катнашучы башка персонажларда эчке кичерешләр тудыра, бу геройлар характерында үсеш китереп чыгара. Шуның белән әсәрнең эчке динамикасы һәм хәрәкәте барлыкка килә. Бу — бездә күп кабатланган һәм әле дә очрап торган, инде күнегелгән, шактый «чарланган» һәм шомарган алым. Бигрәк тә якын кешесенең (мәсәлән, ире яки хатынының, әтисе яки әнисенең, сөйгән кешесенең һ. б.) үткәндә эшләгән берәр әшәкелеген белү, начар гадәтләрен күрә башлау, җәмгыять өчен зарарлы икәнен аңлау пьеса геройларында тирән кичерешләр кузгата. Бу алымга нигезләп иҗат ителгән әсәрләрнең берсе төсендә Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасын күрсәтергә була. Ул — уңышлы мисалларның берсе.

Ләкин бу алымга гына ябышып яту драматургияне ярлыландыруга китерер иде. Чөнки драматизм үзенең табигате белән үк кешенең үз эчке дөньясында туып үсүне һәм ачылуны да таләп итә. Ягъни, шәхеснең үз хаталарын яки кимчелекләрен аңлаудан, тормыш серләрен төшенүдән, авыр ситуацияләргә, еш кына хәтта фаҗигале хәлләргә эләгүдән туган эчке кичерешләр тирән дә, мәгънәле дә, көчле дә була. Драматик кичерешләр никадәр үткен булса, эчке тетрәнү һәм яңарыш кичергән характерның үсешен, алга китешен күрү һәм аңлау да шул кадәр үк гыйбрәтле төс ала.

Мондый төр драмалар бездә элек-электән аз языла. Драматизмның бу тирәнә яраклы конфликт табу һәм шуны әсәрнең нигезенә сала белү — авыр һәм зур осталык сорый торган эш, күрәсең. Соңгы вакытта драматургларыбыз, шундый төр пьесалар биреп, бу жанрның сизелерлек алга китүенә булыштылар.

Яшь драматург Диас Вәлиевнең «Дәвам» драмасы конфликтның менә шул төренә нигезләнгән. Бу аның олы сәхнәгә менгән икенче пьесасы. «Намус хөкеме» исемле беренче драмасы Татар дәүләт академия театрында барган иде. Ә «Дәвам» Казанда Рус зур драма театрында һәм «Сиңа тормыш бүләк итәм» дигән исем астында Мәскәүнең Ермолова исемендәге театрында зур уңыш белән бара. Бу драманың мөһим үзенчәлеге шунда, автор материалны бүгенге тормыштан алган, бүгенгә хас булган конфликт җирлегендә заман геройларын сурәтләп, җәмгыятебез үсешенең безнең көннәрдә туган актуаль мәсьәләләрен күтәргән. «Намус хөкеме»ндә проблематика мораль-этик мәсьәләләрне үз эченә ала иде. «Дәвам» драмасында исә социаль-политик, хезмәт һәм әхлак проблемаларының үзара тыгыз бәйләнештә алынуын күрергә мөмкин.

Драмага автор материалны яңа зур төзелештән алган. Ул атаклы КамАЗ төзелеше дип кабул ителә. Хикмәт, әлбәттә, драмадагы вакыйгаларның тарихи һәм географик урынын билгеләүдә түгел. Шулай да республикабыздагы һәр яңалык һәм һәрбер хезмәт казанышы белән горурлана торган патриотлар өчен монысы да бөтенләй үк әһәмиятсез дип әйтеп булмый.

Үзәк конфликт төзелештә яңа, прогрессив методларны тормышка ашыру өчен алып барылган көрәш төсендә оеша. Бу көрәштә партиянең шәһәр комитеты секретаре Саттаров, инженер Сатынский, эшче кыз Алсу, баш механик Дунаев, директор урынбасары Дания Әхмәдуллина һ. б. алдынгы көчләрне гәүдәләндерәләр. Гоголев, Саликова кебекләр кайберәүләрнең йомшаклыкларыннан, вакытлы кыенлыклардан оста файдаланып, тормышта үз мәнфәгатьләре өчен генә яшәргә омтылалар.

Әсәрнең үзәгендә Байков һәм Саттаров образлары тора. Гәрчә пьеса нигездә Байков драмасы буларак уйланылган булса да, сюжет сызыгында боларның кайсына булса да өстенлекне бирү кыен. Гигант төзелеш җитәкчесе Байков — купчелек сыйфатлары белән уңай тәэсир калдыра торган кеше. Үзенә ышанып тапшырылган эшне ул һәрнәрсәдән югары саный, мөкатдәс бер нәрсә итеп карый. Юк, ул гади бер карьерист кына түгел. Үз тормышын һәм талантын яңа тормыш төзүгә багышлаган акыллы, каты куллы бу кеше мондагы төзелешне үзенең хезмәт баскычындагы иң югары басма дип, үзе өчен «соңгы тургай җыры» дип атый. Бу төзелештә ул фидакарьләрчә эшли, бүтәннәрдән дә шундый ук фидакарьлек таләп итә. Шул ягы белән ул соклангыч, шул ягы белән уңай герой. Ләкин тиңе булмаган гигант масштаблы төзелеш күп кенә

мәсьәләләрне яңача хәл итә белүне сорый. Менә бу яктан инде Байков характерында консерватив сыйфатлар калкып чыгалар. Төзелешне ул искечә, күнегелгән методларга таянып оештырырга ниятли. Мондый зур эшкә һич ни дә кызганыч булмаска тиеш дип уйлап, ул хөкүмәттән өстәмә рәвештә зур-зур суммалар сорап ала. Кайбер очракларда, төзелешнең көндәлек мәшәкатьләре, вагы-төяге белән мавыгып, төп мәсьәләләрне дә күздән ычкындыра. Тагын да бер җитешсезлеге шунда, Байков производствога җитәкчелек итүнең прогрессив алымнарын, алдынгы методларын күреп бетерә алмый, аларны дөрес бәяли белми. Сатынскийның беркадәр тәвәккәллек сорый торган, аның каравы, киләчәге зур булган техник тәкъдименә ул игътибар биреп җиткерми. Менә шулар җирлегендә ул Саттаров белән, Дунаев һәм Әхмәдуллиналар белән каршылыкка керә.

Саттаровның язмышы көтелмәгән үлем белән бетә. Шулай булуга да карамастан, ул — пьесадагы иң якты фигуралардан берсе. Аның характерына хезмәт иясенең тормышын яхшырту, коммунизм идеалларын тизрәк якынайту өчен көрәшкә ахыргача бирелгәнлек хас. Шәхси тормышына кул селтәү, үз мәнфәгатьләре турында кайгыртмау, ягъни аскетлык Саттаровны образ буларак көчсезләтми, киресенчә, аның характер бөтенлеген тулырак күрсәтү өчен хезмәт итә. Партиянең шәһәр комитеты секретаре Саттаров драматургиябез өчен яңа, оригиналь образ.

Бу образны сурәтләү алымнары ягыннан да яшь драматург үзенчәлекле эш йөртә. Саттаров баштарак әле ничектер вакыйгалардан читтәрәк торган шикелле тәэсир туа. Сатынскийның тәкъдимен күңеле белән кабул итсә дә әле ул мәсьәләне өйрәнә, төрле якларын ачыклый. Иң беренче, аңар Байковның мөнәсәбәтен көтеп тора. Бу табигый дә, чөнки Саттаров белеме буенча инженер түгел, ахыргы сүзне ашыгып әйтү аңар килешми. Ләкин инде төзелеш процессында үзенең, ягъни партия оешмасының катнашы кирәк моментны күреп-аңлап алгач, Саттаров бөтен темпераменты һәм принципиальлеге, кыюлыгы белән көрәшкә ташлана. Бу — якынча пьесаның икенче яртысыннан гына башлана. Аның каравы, вакыйгаларның бу өлешендә Саттаров гаять актив, ул үзәктә тора, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт җепләренең күпчелеге аңар килеп бәйләнә. Төп конфликт та шунда гына тәмам оешып бетә.

Ләкин драманың беренче яртысын да хәрәкәт үсеше ягыннан сүлпән дип әйтеп булмый. Арткы пландарак булып күренгән, әмма асылда төп конфликтның оешуында зур роль уйнаган образлар һәм коллизияләр ярдәмендә автор тамашачыны олы конфликтны кабул итәргә хәзерли. Инженер Сатынскийның төзелешне күп мәртәбәләр тизләтәчәк һәм арзанайтачак проекты, тар ведомствочылык интереслары күзлегеннән карап аңар Гоголевның каршы чыгуы, бу бәхәстә һәм бәрелештә Качаеваның урталыкта калуы, шуннан туган эчке киеренкелек ышандырырлык сурәтләнеш тапкан.

«Дәвам» — асылда Байков драмасы, җитәкчелек итүнең, хезмәтне оештыруның яңа методларын, заман таләпләрен тиз генә аңлый алмыйча хата җибәргән, Саттаровның фидакарьлеге һәм үлеме нәтиҗәсендә дөрес юлга басарга тиешле кеше драмасы булып чыга. Бу әсәрнең төп идея-художество көче һәм новаторлыгы менә шунда.

Шушы уңай белән А. П. Авдеевның «Советская Татария» (1972 ел, 15 декабрь) газетасында чыккан рецензиясенә тукталып үтәсе килә. Рецензент әсәрдәге конфликтны Байков белән Саттаров арасындагы бәрелешкә, субайлар мәсьәләсенә кайтарып калдыра. Бу — проблеманы бик тә гадиләштереп һәм тарайтып аңлату. Конфликт монда, алда әйтелгәнчә, тирәнрәк тә, киңрәк тә. Ул пьесаның буеннан-буена бара.

«Дәвам» драмасы һәртөрле кимчелекләрдән азат булган әсәр түгел, билгеле. Шул ук рецензиядә бу пьеса буенча куелган спектакльгә беркадәр пессимизм, минорный тон хас булуы әйтелгән. Чыннан да шулай, бу драматургик материалда ук бар. Ул хәтта пьесаның жанр үзенчәлегенә дә зыян китермиме икән әле?! Автор әсәрен «героик драма» дип атаган. Һәм күпчелек урында бу жанрга хас югары стиль сакланган да. Гомумән алганда, пьесага эпик киңлек, масштаблылык хас, фикер тирән, сюжет үстерелешендә дә, диалогларда да киеренкелек сизелә. Уңай геройларның гомуми эшкә, дәүләт һәм халык эшенә ахыргача бирелгәнлеген төрле характерлар ярдәмендә, төрле планда ачу уңышлы чыккан. Шул ук вакытта героик драмага хас булырга тиеш-

ле стильнең ахыргача сакланмавын да таныырга кирәк.

Соңгы елларда сәхнәгә менгән һәм уңыш казанган әсәрләр арасында Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» дип аталган драмасы да бар. Алынган проблемасы белән дә, темасы ягыннан да пьеса актуаль. Ул укытучыларга багышланган. Бу мактаулы, җаваплы һәм авыр профессия кешеләренә дан җырлау нияте белән язылган. Драманың проблемасын — гаделлек һәм хакыйкатькә тугрылык дип билгеләргә мөмкин. Сүз хезмәттә дә, үзара мөнәсәбәттә дә, балалар тәрбияләүдә дә, мәхәббәт мәсьәләләрендә дә намуслы һәм гадел булу турында бара. Тормышта ялган урын алмасын, тәрбия эшендә фальшьның эзе дә булмасын, сөешүдә риялану булмасын — тәҗрибәле укытучы Хәят Газизовна да, яшь кыз Мәршидә дә менә нәрсә өчен көрәш алып баралар. Бу көрәштә олы яшьтәге Хәят Газизовна яшьләргә хас романтик омтылыш, активлык үрнәкләре күрсәтә. Мәсәлән, аның сугыш батырларына куелган һәйкәл янында факель кабызу өчен утны шәһәрдәге олы факельдән, изге уттан кабызып алып кайтырга тәкъдим итүе шул хакта сөйли. Вакыт-вакыт хәтта аңар яшьләрчә җиңеллек, наянлык та хас (аның мәктәп директорын бүлмәсенә бикләп куюы күренешен мисалга алырга мөмкин). Болар нигездә ышандыра, болар образны җанландыра һәм аның уңай сыйфатларын үтемлерәк итеп чагылдыра торган детальләр һәм табышлар.

Ә асылда самимилеге белән сокландыра торган, яшьлекнең гүзәл якларын, сафлыкны үзендә туплаган Мәршидә исә урыны-урыны белән җитди һәм акыллы була белә. Аның үз эшенә мөнәсәбәте, коллегаларына һәм балаларга, тәрбия мәсьәләләренә карашы өлгерә барган саен, образ тулылана, характер бөтенәя.

Х. Вахит драматургиясенә бер үзенчәлек хас. Аның иҗаты мажор тоннарга, якты буяуларга бай. Автор моңар ирешү өчен һәр вакыт дип әйтерлек мәхәббәт темасына мөрәҗәгать итә, пьесаларында үзәккә яшьләр образларын куя. Ләкин драматург бервакытта да диярлек мәхәббәтне ялгыз гына, үзен генә алмый. Ягъни, ул мәхәббәт вакыйгаларыннан сюжет кору, коллизияләр тудыру өчен файдаланса да, бу аның асыл теләге дә, төп максаты да түгел. Ул мәхәббәт ситуацияләре ярдәмендә алдынгы хезмәткә, матур мөнәсәбәтләргә, тормышыбыздагы яңалыкларга, уңай геройларга дан җырларга омтыла. (Бу омтылышы ни дәрәҗәдә сәнгатьчә камиллек табадыр, анысы икенче мәсьәлә.)

Без тикшерә торган әсәрдә дә шуны ук күрергә мөмкин. Драматург хаклык, гаделлек, дәреслек өчен көрәш темасын мәхәббәт проблемасы белән органик бәйләнештә бирергә тырыша. Мәхәббәт проблемасы, дидем. Чыннан да, ул драмада проблема дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әсәрнең исеме үк шуңар ишарә ясый. «Мәхәббәтең чын булса» дигән исем, мина калса, Мәршидә һәм Таһирның бер-берсенә булган көчле мәхәббәтләрен генә түгел, ә Хәят Газизовна, Нурислам, Мәршидә һәм Мәликәләрнең үз профессияләренә, балаларга булган олы ярату хисен дә аңлата.

Гаҗәп хәл, ләкин нәкъ менә шушы проблеманы хәл итүдә әсәргә ачыклык җитеп бетми. Драманың, аның буенча куелган спектакльнең гомуми уңышын һәм популярлыгын тулаем һич тә кире какмаган хәлдә, бу кимчелек хакында да ачык итеп әйтергә кирәк. Мәсьәлә шунда: драманың соңгы күренешләрендә ике хис: шәхси интереслар һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр кирәкмәгән төстә үзара каршылыкка кертелә. Дөрес, драматург белән бер мәсьәләдә килешергә кирәк: совет кешеләренең гүзәл сыйфатларыннан берсе дә шунда, алар кирәк булган вакытта гомуми эш өчен, югары идеаллар өчен шәхси теләкләрен йөгәнли дә, корбан итә дә беләләр. Әйе, кирәк булган вакытта! Ләкин безнең җәмгыятебездә шәхси теләкләр белән иҗтимагый интересларның ярашуы өчен мөмкинлекләр гаять күп. Шуңа күрә дә андый үзара бәрелеш булган очракның сәбәпләрен, конкрет чагылышын бик ныклап нигезләргә кирәк. Бу драмага менә шул җитми. Драматургның теләгән аңлау кыен түгел. Ул укытучы һөнәренең авыр һәм җаваплы булуын, шул ук вакытта мавыктыргыч һәм мактаулы һөнәр икәнен тамашачыга тулырак җиткерергә тели. Хәят Газизовна һәм Нурислам кебек, яшь буынны тәрбияләү эшенә гомерләрен һәм талантларын багышлаган кешеләрнең фидакарь хезмәтен үтемле итеп күрсәтергә тели. Кабатлап әйтәм, көчле мәхәббәт һәм җәмгыять каршындагы бурычның үзара конфликтка керү очраклары да булырга бик мөмкин. Ләкин безнең җәмгыятебездә мондый конфликт-

ның да шәхеснең үз интересларына зарар китермәслек, шул ук вакытта җәмгыять каршында, халык алдында бурычларын намус белән үтәрлек төстә хәл ителү мөмкинлекләре гаять зур. Автор менә шул мөмкинлекләрне исәпкә алып бетермәгән. Драмадагы логика буенча барсаң, нәрсә килеп чыга? Яхшы укытучы һәм үз профессиясенең серләренә төшенеп җиткән тәрбияче булыйм дисәң, үз тормышыңа игътибар итмә, шәхси тойгыларыңны йөгәнлә, янәсе. Нәтиҗәдә, әнә, Хәят Газизовна кебек, кияүгә чыкмыйча, гаилә рәхәте күрмичә, аның каравы, халык мәхәббәтен һәм игътибарын тоеп, үз укучыларыңнан хатлар алып, аларның уңышлары белән горурланып яшәрсең. Яки батыр фронтовик Нурислам кебек, балалар белән булу, аларга дәрес бирү рәхәтен тату өчен, һәр көн җиде километр араны үтеп күрше авылга йөрерсең. Мәликә шикелле, ир-ат иркәләвенә сусап гомер кичерерсең. Шәхси интереслар һәм профессиягә мәхәббәт хисен капма-каршы куеп, Хәят Газизовна, Мәликә, Мөршидәләрне гаилә рәхәтлекләреннән ваз кичкән кешеләр ясап, автор, үзе телимеюкмы, укытучы эшен берьяклы күрсәтә, аны авыр хезмәт төсендә генә тәкъдим итә. Ахыр чиктә, укытучы хезмәтендә шәхси интересларны тулы канәгатьләндерү өчен мөмкинлекләр аз икән дигән ялгыш фикергә илтә торган бәхәсле концепция туа.

Шунысы да гыйбрәтле: проблеманы болай хәл иткәндә уңай геройларның характер бөтенлегенә дә зыян килә. Таһирның тәкъдименнән баш тарту күренешләрендә Мөршидәнең үз-үзен тотышында ясалмалылык көчле. Ә Таһирны карагыз инде! Сөйгән кызы алдына нинди таләп куя ул: я бүген мин сине алып китәм, яки беркайчан да без бергә була алмаячакбыз (?!). Ни өчен? Чөнки Таһир үзалдына хәзер үк өйләнергә дигән максат куйган. Һәм ул моны эшләячәк, Мөршидәне булмаса, бүтән кыз алачак. Ә бит үзе, имеш, Мөршидәне шашып сөя. Шулай итеп, пьесаның соңгы күренешләрендә тотнаксыз бер егет күз алдына килеп баса. Гаҗәбе шунда, Таһирның анасы урынында калган, аны тәрбияләп, кеше иткән Хәят Газизовнага, аның үз профессиясенә булган мөнәсәбәтенә һөҗүм ясап сөйләгән сүзләре әсәрдә тиешле отпор алмый. Яки Мөршидәнең Таһирдан баш тартуының сәбәбен карагыз. Имеш, Таһир хезмәткә бара торган җирдә татар мәктәбе юк икән, Мөршидә татар телен һәм әдәбиятын укыта алмаячак. Димәк, укытучы буларак ул үз-үзен югалтачак. Шактый ясалма киртә!

Шәхси тормышта уңайсызлыклар һәм бәхетсезлекләр, җәмгыять интереслары өчен шәхси теләкләрен корбан итәргә әзер булу алда карап узган «Дәвам» драмасындагы кайбер геройларга да хас дигән идек. Мәсәлән, Әхмәдуллина, Саттаров образларында шул күренә. Ләкин бу персонажларның аскетлыгы аклана һәм ышандыра. Аннары ул вакытлы бер күренеш итеп сурәтләнә. Аскетлык геройларның характерын бөтенәйтә, аларны бизи. Ә Мөршидә характерын бизәргә тиеш дип уйланылган аскетизм хакыйкатькә зыян китерә, уңай геройларның эш-хәрәкәтендә ясалмалылык тудыра. Театрда бу тенденция тагын да көчәйтелгән.

Х. Вахит — актив һәм эзләнүчән драматург. Ул тормышның төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, мораль-этик проблемаларның яңадан-яңа якларын күтәрә. Драматург тагын бер әсәр өлгертте. «Давыл» исемле бу драмадагы вакыйгалар водолазлар тормышыннан алынган. 3—4 ел элек салган кабель өзелеп электр тогы килми башлагач, зур завод эштән туктала. Шунда менә әсәр геройлары мораль сынау алдында калалар. Бу эшне үз вакытында тиешенчә эшләмәгән Мостафа һәм Нәдирләр генә түгел, өзелгән кабельгә катнашлары булмаган яшь инженер Заман да, студентка Солтания дә, водолазларның хәзерге старшинасы Мансур да намуслылык һәм батырлык сынавын үтәргә тиеш булалар. Сынаудан соң берәүләр (Нәдир, Мостафа, Мансур, Солтания) гражданин буларак үсеш баскычыннан югары күтәрелсәләр, икенчеләргә бу эш тормыш юлындагы үтеп чыга алмаслык киртәгә әйләнә. Бигрәк тә Нәдиргә бу сынау тирән газаплар, икеләнүләр аша совет кешесенең, коммунистның яшәү принципларын, мораль кагыйдәләрен тирәнрәк аңлап үзләштерергә ярдәм итә. Геройларның настроениесен һәм характер үзенчәлекләрен бирүдә, психологик кичерешләрне, эчке кичерешләр агышын чагылдыруда драмага җентекләп эшләнү хас. «Давыл» — драма жанрында һәм бүгенге теманы, көн геройларын үзләштерүдә Х. Вахитның чираттагы уңышы.

Актуаль темага багышланган булуы һәм характерлар тирәнлеге белән Аяз

Гыйләҗевнең әлегә кульязма хәлендәге «Җан җылысы» дип аталган драмасы да аерылып тора. Вакыйгалар нефтьчеләр тормышыннан алынган, шундагы кешеләрнең образларын чагылдыра. Ситуациясе беркадәр Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары» пьесасын хәтерләтә: ата-ана йортына балалары җыйнала (һәр ике әсәрдә дә болар — дүртәр ир туган). Шунда хезмәт һәм яшәү принципларын аңлау тирәсендә конфликт-бәхәс куба. Бераүләрнең хата карашлары кире кагыла, дөрес принциплар раслана. Ләкин А. Гыйләҗев һич тә кабатлау юлыннан бармый. Аның материалы да бүтән, конфликтны хәл итү алымнары да шактый үзгә. Хезмәткә һәм халык байлыгына дөрес мөнәсәбәт, хуҗаларча караш булдыру, социалистик производствога акыллы җитәкчелек итү, әхлак нормаларын саклый белү кебек мәсьәләләр драмада урынлы куелган. Персонажларның күпчелеге үзенчәлекле. Таймас карт белән Сабира әбидән башлап, аларның һәр улы, хәтта кечкенә оныклары Лилия хакында да, образ буларак, билгеле бер төшенчә туа, аларның характер үзенчәлекләре төсмерләнә. Эре масштабтагы җитәкче Госман Шабановның шәхес буларак үсә-үзгәрә башлавы, Мирхәтнең тормышка җиңелчә караштан котыла һәм җитдиләнә баруы шулай ук ышандыра. Драматургның табышы да асылда шушы ике образга кайтып кала түгелме икән әле. Чөнки драма Госманны, ул таяна торган принципларның хаталыгын фаш итүгә юнәлтелгән. Шушы яктан әсәрдә алда искә алынган «Дәвам» драмасы белән яңгыраш моментлар да бар.

Тагын да бер образны сурәтләү принциплары ягыннан А. Гыйләҗев әсәре Д. Вәлиевнеке белән аваздаш. Сүз партком секретаре Урал Шабанов образы турында бара. А. Гыйләҗевнең партия җитәкчесе образын сурәтләүгә алынуын хупларга кирәк. Чөнки, бердән, безнең сәхнәгә нәкъ менә шундый геройлар җитми. Икенчедән, мондый олы һәм җитди эшкә тотынуы драматургның үз иҗатында тагын да җитлегә, тирәнәя баруы турында сөйли.

Сүз уңаенда, драматургларның һәм, гомумән, язучыларның игътибарын бер нәрсәгә юнәлтәсе килә. Соңгы елларда язылган әсәрләрдә бер коллизия бик тә еш кабатлана башлады. Сүз табигатьне саклау турында бара. Бу бик аңлашыла торган нәрсә. Табигатьне саклау эшен партиябез дәүләт интересы дәрәҗәсенә күтәрде, һәммәбезнең бурычы итеп куйды. Һәм бу проблеманың сәнгать әсәрләрендә чагылуы бик тә табигый. Безне мәсьәләнең икенче ягы борчый. Бу көрәштә (сүз әсәрләрдә чагылган көрәш турында бара) нефть эше җитәкчеләре һәм производство кешеләре тискәре позициядә торучылар итеп, ә колхоз кешеләре уңай геройлар итеп кенә сурәтләнә. А. Гыйләҗев әсәрләрендә, дөрес, уңай геройлар да шул ук нефтьчеләр («Җан җылысы»нда, мәсәлән, шулай). Ләкин күпчелек очракта, әйткәнемчә, нефтьчеләр — тискәре, крестьяннар уңай герой итеп бирелә. Р. Төхфәтуллинның асылда кызыклы эшләнгән «Тургай» пьесасында бу бигрәк тә ачык куелган. Мондый коллизияне кат-кат һәм бертөрле генә формада кабатлау, бердән, үзе үк шәп түгел. Чөнки кабатлау сәнгатьне баетмый. Икенчедән, тарихи хакыйкатьне тулы чагылдыруга да зыян килә. Ә бит нефть промышленностеның кызу темплар белән үсүе республикабыз экономикасын тамырдан үзгәртү белән генә калмады. Шул ук районнарда яшәүче кешеләрнең көнкүрешен, яшәү шартларын үзгәртү белән генә дә чикләнмәде. Ул кешеләр психологиясенә зур йогынты ясады. Колхозларның хуҗалык итү практикасына, хезмәтне оештыру традицияләренә көчле тәэсир итте. Боларны югарыда әйтелгән коллизия ярдәмендә генә чагылдырып булмый. Димәк, яңа конфликтлар, яңа коллизияләр эзләргә кирәк. Яңа геройлар кирәк.

Соңгы елларда Туфан Миңнуллин ифрат нәтиҗәле эшли. Академия театрында аның «Диләфрүзгә дүрт кияү» исемле водевиле, Республика күчмә театрында «Уйланып чак» исемле һәм әле күптән түгел генә «Үзебез сайлаган язмыш» дигән пьесалары куелды. Татарстан китап нәшрияты драматургның ике пьесасын аерым китап итеп бастырып чыгарды. 1972 елда «Казан утлары» журналында аның «Ир егетләр» драмасы басылды. Тематик яктан да, материал эзләп, тормышның яңадан-яңа өлкәләренә мөрәҗәгать итүе ягыннан да, Т. Миңнуллин үзүзен кабатлый дип булмый. Ул иҗат иткән әсәрләр арасында комсомол работникларының тынгысыз хезмәтен үзәккә куеп сурәтләнгән пьеса да, яңа әхлак нормаларының ничек итеп үзләренә юл яруларын күрсәткән әсәр дә, укытучыларның тын-

гысыз эшчәнлегенә багышланган драматик хикәя дә, бүгенге колхоз яшьләрен якты буяуларда тасвирлаган, кайбер кимчелекләрдән күңелле итеп көлгән водевиль дә бар.

Т. Миңнуллин сәхнәне сизгер тоя, ул характерлар тудырырга оста. Болар бигрәк тә аның комедияләрендә ачык күренә. Драмаларында да ул комик һәм сатирик типларны тормышчан һәм җанлы итеп, шактый тапкыр сурәтли. Мәсәлән, аның «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиле шаянлыкка, уен-көлкегә, җорлыкка байлыгы, характерлары ачык беленеп торуы, кызыклыгы белән укучының һәм тамашачының игътибарын яулап алды. Шул ук вакытта Т. Миңнуллин драматик характерлар иҗат итү өлкәсендә дә эзләнүләр алып бара. Бигрәк тә аны заманыбызның үзәк геройлары, әйдәүче геройлар, алдынгы кешеләрне гәүдәләндерүче образлар кызыксындыра. Дөрес, монда аңар бөтенесе дә ансат кына бирелми. Уңышлар аерым кыенлыклар белән аралашып килә, барысы да автор уйлаганча килеп чыкмый. Мәсәлән, бу яктан аның «Ир егетләр» кебек, вакытында матбугат битләрендә мактау мәкаләләре һәм рецензияләр күргән пьесасы шактый гыйбрәтле. Сүз дә юк, әсәр нигездә уңышлы язылган, аның буенча куелган спектакль һәм драманың «Казан утлары»нда (1972 ел, 9 сан) басылган әдәби варианты тамашачыларны һәм укучыларны тәрбияләүдә уңай роль уйный. Ләкин зур сәнгать югарылыгыннан торып караганда, пьесага кайбер кимчелекләр дә хас булуын күрмәү мөмкин түгел. Заман каһарманының гүзәл образын күрсәтү максаты белән язылган драмада Мәрвән образы тиешенчә ачылып бетмәгән. Ул, гомумән алганда, декларатив һәм статик. Чыннан да, әсәрдә Мәрвән үзенең эчке рухи көче, оештыру сәләте, әхлак принципларының гүзәллеге белән ачылып китәрлек күренеш бармы? Асылда геройның уңай сыйфатлары электәге фронтовик дусты, эчкече Әхтәмне дөрес юлга бастыруда гына күренә түгелме? Ә бу, үз чиратында, вакыйгаларда Әхтәм образының кирәкмәгән дәрәҗәдә урын алуыннан килә. Әйе, болай да булырга мөмкин: әгәр дә автор Әхтәмнең җәмгыятькә файдалы юлдан тайпылып, эчкечелек сукмагыннан кереп китүен, шуның аяныч нәтиҗәсен, эчке фаҗигасен, драматизмын күрсәтүне максат итсә һәм күрсәтә алса, ифрат та шәп булыр иде. Ләкин бу эшләнмәгән. Шуның аркасында бер исерек баш белән кирәкмәгән төстә артык булашу, аны игътибар үзәгендә кирәгеннән артык тоту килеп чыга. Мин үзем сәхнәдә һәртөрле исерекләрне, бушбугазларны, кеше исәбенә рәхәт яшәргә омтылучыларны, хезмәттән читләшүчеләрне үзәккә куеп, шуларны төзәтү белән вакыт уздыруга, уңай геройларның күркәм якларын шул җирлектә генә ачарга тырышуга шикләнеп карыйм.

Ә менә драматургның соңгы әсәре — «Үзебез сайлаган язмыш» бу яктан, ягъни уңай геройны сурәтләү ягыннан, җитди уңыш дип каралырга хаклы. Бу драмадагы вакыйгалар үзәгенә омтылышлары һәм яшәү принциплары һәркем өчен аңлаешлы һәм ачык булган, олы максат хакына көрәшкә атлыгып торган герой образы куелган. Ул — мәктәп директоры Илгиз Туктаров. Нурия кебек намуслы укытучылар ярдәмендә Илгиз Кәримович мәктәп тормышындагы иске тәртипләргә каршы көрәш ача. Әмма традицияләр көчле, аны яклаучылар һәртөрле әшәкелектән дә баш тартмыйлар. Бу көрәш юлында мәктәп директоры алдына күп киртәләр корыла. Аны хәтта директорлыктан алалар, ул моннан күчеп китәргә мәҗбүр була. Шулай да мораль җиңү Илгиз Кәримович ягында кала.

Соңгы елларда водевиль жанрында да әһәмиятле әсәрләр барлыкка килде. Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» исемле алда искә алынган водевиле Академия театрында уңыш белән бара. Х. Вахитның аннан алда сәхнә күргән «Күк капусы ачылса» водевиле дә репертуарда уңышлы саклана. Болар басылып та чыктылар. 1972 елда тагын да бер водевиль — Илдар Юзеевның «Бөркетләр кыяга оялый» дип аталган әсәре «Безнең сәхнә» җыентыгында басылды. Ул аңарчы Республика күчмә театрында уңыш белән барган иде. Шулай итеп, водевиль жанры соңгы вакытта сизелерлек баеды. Х. Вахит, водевиль авторы буларак, сюжет үстерелешен көтелмәгәнчә борып җибәреп, вакыйгаларны кызыклы төзеп яза. Т. Миңнуллин, алда әйтелгәнчә, үз әсәрендә тапкырлык, җорлык, шаянлыкка киң урын бирә, характерларны җанлы сурәтли, шуның белән уңышка ирешә. И. Юзеев исә водевильгә романтик картиналар кушып җибәреп, үз фикерен тулырак әйтеп бирергә омтыла. Дөрес, И. Юзеев әсәрендә әле романтика һәм реальлек үзара

йомшаграк бәйләнгән. Гөлүс белән Нәзиненең тормышка мөстәкыйль сукмак салу уена килүләрендә логик эзлеклелек җитенкерәми. Вакыйгалар агышы да, җанлы ситуацияләр дә түгел, ә авторның романтик омтылышы аларны күбрәк шушы фикергә китерә. Шулай да мондый эзләнүләрдән баш тартмаска кирәк. Бәлкем И. Юзеевка эзләнүләрен башка жанрларда да алып барыргадыр?! Мәгълүм булганча, ул — романтикага һәм драматизмга бай поэмалар авторы. Шагыйрь каләмен романтик драмалар һәм трагедияләр өлкәсендә дә сынап караса, сәхнә сәнгатенең яңа мөмкинлекләреннән файдалану осталыгы белән дә куандырырга бик мөмкин.

Романтик драма димәктән, бу жанрда әсәрләр бездә гаять сирәк иҗат ителә. Ә бит романтика сәхнә сәнгатен баетуда гаять әһәмиятле роль уйный ала. Әлбәттә, сүз революцион романтика турында бара. Олы фикерләрне, зур идеяләрне тамашачыга җиткерүдә романтик драманың үз чаралары һәм алымнары бар, мөмкинлекләре зур. Рухландыргыч патетика, гүзәл пафос сәхнә өчен гаять кыйммәтле, андый пафосны, патетиканы, романтик күтәренкелекне тамашачы бик тә уңай кабул итә. Моның ачык мисалы итеп соңгы еллар романтик драматургиясенең казанышларыннан санала алырлык әсәрне — Әхсән Баяновның «Һәйкәл» драматик повестен күрсәтергә була. Ул менә ничә ел инде Минзәлә театрының репертуарын бизи. «Казан утлары»ның 1973 елгы 10—11 саннарында әсәр басылып та чыкты. Автор белән аның жанрын билгеләү мәсьәләсендә бәхәсләшергә, «ул күбрәк драматик поэма дип аталырга тиеш түгелме» дигән характерда сүзләр куертырга да мөмкин булыр иде. Ләкин төп хикмәт анда түгел. Әсәр үзенчәлекле булуы, романтик характерлы, катлаулы фикерләргә байлыгы, мәсьәләне тирән куя белүе белән игътибарга лаек.

Әгәр дә инсценировкалар турында бер сүз дә әйтелмәсә, мәкалә тулы булмас иде. Соңгы еллар драматургиясе һәм театры бу жанр исәбенә шактый баеды. Һәм сыйфаты, һәм хәтта формасы ягыннан да. Бу бер бездәге күренеш кенә дә түгел. Танылган театр белгече А. Бояджиев, мәсәлән, бу күренешнең үз закончалыкларын ачарга омтылыш ясап, инсценировкаларга актив мөрәҗәгать итүне хәзерге сәхнәнең уңай бер үзенчәлеге төсендә билгеле («Театр» журналының 1973 елгы 7 санында басылган «В чем новая сила сцены?» исемле мәкалә). Проза әсәрләрен (бигрәк тә повестьларны) сәхнәләштерүнең активлашуын һәм милли театрыбыз өчен уңай йогынтысы барлыгын без дә шикләнмичә әйтә алабыз. Соңгы ике-өч елда гына да Г. Камал исемендәге театрда куелган һәм уңыш казанган өч инсценировканы атап китәргә мөмкин. Болар — Ш. Камалның «Акчарлаклар» (инсценировка авторы Г. Ахунов), М. Әмирнең «Агыйдел» (сәхнә вариантын автор үзе үк язган) һәм Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» (инсценировканы авторның якыннан булышлыгы белән Ә. Зарипов һәм Р. Хаҗиәхмәтов эшләгән) исемле повестьлары. Бигрәк тә соңгы икесе тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Шул ук вакытта аерата «Чикләвек төше» спектакленә һәм аның нигезенә салынган инсценировкага төрле, вакыты белән хәтта каршылыклы фикерләр дә әйтелде. Шушы уңай белән сәхнә әсәренең һәм спектакльнең гомуми әһәмиятен тикшергәндә һәркем өчен дә ачык булган бер хакыйкатькә игътибар итеп бетермәү күзгә ташланды. Ул да булса, анализны әсәрнең төп героен ахыргача билгеләмичә башлау. Чыннан да, «Чикләвек төше» спектаклендә үзәк геройның кем булуы ачык шикелле. Ул — Рокыя. Әгәр дә шуны таныйбыз икән, спектакльдәге соңгы күренешләрнең киләклеге турындагы бәхәсләр үзеннән-үзе төшеп кала. Спектакль Рокыяның мещанлык баткагыннан акрынлап котылуы һәм актив тормышка яраклы кеше булып җитешүе турында сөйли. Игътибар иткәнсездер: беренче күренешләрдә сәхнәдә сары бәрхет материал тугланып йөри. Бу — алтынны гәүдәләндерә, зиннәткә чумган мещанлыкны гәүдәләндерә торган деталь. Сары бәрхет башта күзләрнең явын алып өстәлгә килеп кунаклый, тора-бара Рокыяның гәүдәсенә сылана башлый. Бәрхеттән күзен ала алмыйча көзге алдында күпме бөтерелмәсен, Рокыя үзендә аны бер як читкә алып ташларлык көч таба, ягъни әти-әнисе үгетләгән тормышка кул селти. Бу деталь режиссер тарафыннан бик оста эшкә җигелгән, спектакльнең төп фикерен тамашачыга тулырак җиткерүгә ярдәм итә. Әлбәттә, бәрхеттән баш тарту гына әле мещанлыкның бөтен начарлыкларыннан да котылдым дигән сүз түгел. Рокыяга тормыш сукмагыннан лаеклы төстә атлап китәрлек дәрәҗәгә җиту өчен күп кенә

сынаулар үтәргә туры килә. Монда аңар һәлиткеч тәэсирне Халикъ Саматов ясый. Соңгы күренешләр авторларга Рокыяның кешe буларак өлгерүен күрсәтү өчен кирәк. Электәге битараф Рокыя, тормышка үз гаиләсе тәрәзәсеннән генә карап өйрәнгән хатын, кристаллдай саф кеше һәм чын коммунист Саматовның үз гомерендә беренче кат ялгышуын аңларлык кеше булып җитешә.

Ә повестьта үзәк герой Саматов бит, диярләр. Әйе, шулай. Жанр мөмкинлекләреннән оста файдаланып, язучы Г. Ахунов нык характерлы, идеалына турылыклы, авырлыклардан курыкмый торган, партия кая җибәрсә, шунда эш үрнәкләре күрсәтә алган уңай геройны тулы сурәтли, аны үзәк персонаж итеп алып, повестьтагы вакыйгаларның үзәгендә тотып тасвирлый. Ә инсценировка авторлары уртага икенче персонажны чыгарганнар. Бу аларга повестьтагы төп фикерне, үзәк идеяне сәхнә чаралары ярдәмендә әйтеп бирергә ни дәрәҗәдә ярдәм итә — бу хакта бәхәсләшергә дә, теләкләр әйтергә дә мөмкиндер. Анысы икенче мәсьәлә. Инсценировканы икенче берәү эшләсә, бәлкем үзәктә нәкъ менә Саматов торыр иде. Ә бәлкем хәзерге авторлар драманың үзәгенә драматизм һәм үсеш кичергән персонажны куйганда, үрнәк уңай геройны да тулы һәм ышандырырлык итеп сурәтләп була, дип уйлап эш иткәннәрдер? Бәлкем сәхнә сәнгатенең үз кануннары бу очракта шундый юлга басарга мәҗбүр иткәндер?! Бәлкем, бәлкем... Ләкин инде инсценировка эшләнгән, спектакль куелган һәм сүзне хәзер шушы конкрет сәнгать әсәре хакында алып барырга кирәк. Ә спектакльдә үзәк герой — Рокыя. Шул ук вакытта Саматовның да роле гаять зур. Нәкъ менә Рокыяның үсеш процессы ышандырырлык һәм тулы ачылганга күрә дә, Саматов образы тормышчан да, әһәмиятле дә булып чыккан. Халикъның тормыш киртәләренә каршы, яшәү кыенлыклары белән алып барган көрәше Рокыяның үз-үзе белән көрәше яктылыгында чагылып, сәнгатьчә ышандырырлык һәм социаль яктан тирән мәгънәле төс ала.

Уңай геройны сурәтләү принциплары ягыннан «Чикләвек төше» инсценировкасын «Ир егетләр» пьесасы белән үзара чагыштырып карыйсы килә. Чыннан да, Т. Миңнуллин әсәрендә дә Мәрвән уңай герой буларак Әхтәмнең үсеш юлы яктылыгында ачылырга тиеш дип уйланылган бит. Карый китсәң, Мәрвән кайсыдыр яклары белән Халикъ Саматовка да нык охшаган. Шулай да ул, образ буларак, Саматов кебек үк тулы ачылып, тамашачы күңелен үзендәге уңай сыйфатлар белән ахыргача яулап бетерә алмый. Ни өчен? Чөнки, алда әйтелгәнчә, үзәк герой роленә дәгъва иткән Әхтәм тулы үк ачылмаган, аның кеше буларак үсеш сызыгы ахыргача ышандырырлык сурәтләнмәгән. Ә «Чикләвек төше»ндә, киресенчә, Саматов тормышчан авырлыклар белән көрәшә, төп юлыннан читкә тайпылмый торган булып күренерлек ситуацияләрдә хәрәкәт итә. Ул хатынын артык иркәләми дә, аны артык үгетләми дә шикелле. Ләкин Рокыя аңар тартыла, аңар хатын-кыз буларак та, иптәш буларак та, гомумән, кеше буларак ошарга тырыша. Чөнки көчле мәхәббәте аны шулай тотып тора, үстерә, кеше итә. Шул җирлектә Саматов та җанлы образ булып ачыла. Бу — бик тә әһәмиятле момент. Аерым бер инсценировканың яки пьесаның әһәмиятен билгеләүдә генә түгел, ә уңай герой иҗат итүдә конкрет драматургик принципларның үзенчәлеген, драматургия алымнарының закончалыкларын аңлау өчен дә ул гаять мөһим.

Сүз җае туры килгәч, шул ук нәрсәнең «Агыйдел» спектаклен бәяләүдә дә зур әһәмияте барлыгын әйтергә кирәк. Монда үзәк герой итеп Гаязны таныганда гына (ә ул — нәкъ шулай!) спектакльнең төп фикере дә, композицион үзенчәлекләре дә, образлар системасы да тиешенчә бәяләнәчәк. Ә инде үзәккә Ильясны куеп анализлаганда, спектакль шактый ук берьяклы бәяләнгән булыр.

Татарстан китап нәшрияты пьесаларны бастырып чыгару эшенә җитди игътибар бирә. Хәзер, кагыйдә буларак, яңа әсәрләр сәхнәдә уйналганнан соң артык озак та үтмичә, укучылар кулына килеп керәләр. Соңгы бер-ике елда гына да күпчелек драматургларыбызның яңа әсәрләре дөнья күрде: Х. Вахитның «Күк капусы ачылса», Т. Миңнуллинның «Йөрәк янар өчен бирелгән», Р. Ишморатның «Гүзәл син, Хәят», Ш. Зәйниненең «Пьесалар», Ю. Әминевнең «Гөлҗәннәтнең җәннәте», С. Кальметовның «Шулай да була», Г. Рәхимнең «Яңа ел шатлыгы», «Безнең сәхнә» исемле пьесалар җыентыклары һ. б. Өлкән драматург Н. Исәнбәт яңа җыентыгын төзеп нәшриятка тапшырды. Димәк, авторларыбыз иҗат иткән күпчелек сәхнә әсәрләре үз вакытында басылып чыга баш-

лады дип әйтә алабыз. Бу, әлбәттә, бик куанычлы хәл. Шуның белән бергә сүз уңаеннан бер теләк тә белдерәсе килә.

Бездә электәрәк матур бер традиция бар иде. Сүз СССР халыкларының иң яхшы драма әсәрләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгару турында бара. Шулай ук бөтен дөнья драматургиясенең иң матур үрнәкләрен вакыт-вакыт татар укучысына бирү. Соңгы елларда бу изге эш онытылып бара. Дөрес, проза һәм бигрәк тә поэзиядә ул билгеле бер күләмдә дәвам иттерелә. Ә менә драматургиядә алай түгел. Ә бит бөтен Союз тамашачысының һәм укучысының игътибарын җәлеп иткән иң яхшы драма әсәрләрен системалы төстә туган телебездә бастырып чыгару бик тә кирәк эш. Аларның безгә яңа образлар һәм яңа идеяләр алып киләчәге, башка халыклар тормышы белән таныштырачагы турында әйтеп тә торасы юк. Алар татар укучысында сәхнә әдәбиятына югары зәвык тәрбияләшәчәк. Аннан тыш бит бу эш үз милли драматургиябез үсешенә дә уңай йогынты ясар иде.

Драматургиябезнең уңышлары, үсеш юнәлеше күз алдында. Хәлнең шулай торышында драматургия буенча 1968 елда КПСС өлкә комитеты уздырган киңәшмәнең тәэсире дә, көннең өлгергән мәсьәләләрен үзләштерү юлында драматургларыбызның армый-талмый эзләнүләре һәм профессиональ osталыклары үсә баруы да, театрларыбызның бәрәкәтле эшчәнлеге дә, нәшрият һәм журнал редакцияләренең драматургиягә игътибарлары артуы да роль уйный. Иң мөһиме, партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары, Татарстан өлкә комитетының шул карар нигезендә билгеләгән чаралары бу юнәлештә җитәкче кулланма булып торалар. Карар әдәби әсәрләрне бәяләүдә марксистик-ленинчыл принципларны кыюрак кулланырга, объектив һәм таләпчән булырга өйрәтә. Ә принципиальлек һәм таләпчәнлек драматургиянең һәм, димәк, театрның да сыйфатын күтәрергә булыша. Бүгенге көндә татар әдәбияты югары сәнгать позицияләреннән торып куелган таләпләргә җавап бирерлек драматургларга да, идея-эстетик дәрәҗәсе югары булган пьесаларга да ия. Алар киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешеләчәк дигән ныклы өмет уяталар.

# Фәрит Хатипов

# ҖАВАПЛЫЛЫК

*«Казан утлары» журналында басылган тәнкыйть мәкаләләренә күзәтү*

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарыннан соң бездә бүгенге тәнкыйтьнең торышы хакында байтак мәкаләләр, күзәтүләр басылып чыкты. Авторларның һәркайсы диярлек әдәби тәнкыйтьнең беркадәр җанлана төшүен, партия карарының моңа шифалы йогынты ясаганлыгын билгеләп үттеләр. Моңа кадәр күбесенчә тиргәү объекты булып йөргән өлкәнең хәзер ил-көз алдында иҗтимагый абруе күтәрелә бара, башка тармаклардагы кебек, тәнкыйть иҗатына да кайгыртучан сак мөнәсәбәт кирәклеге аңлашыла. Уңай йогынты барыннан да бигрәк әнә шунда чагыла.

Үсеш, җанлану тенденциясе 1973 ел тәнкыйтендә дә дәвам итте. Аның офыклары, тематикасы, жанрлары киңәя төште, күтәргән мәсьәләләре тирәнрәк, җитдирәк төс алды. Иҗади активлыкны арттыруда Язучылар союзы идарәсенең дә роле ачык күренде. Традицион әдәби ел йомгакларыннан тыш әле ел арасында ул оештырган журнал күзәтүләр конкрет жанрлар буенча тәнкыйть хезмәтләрен барлыкка китерделәр, һәм алар «Казан утлары»нда басылып чыктылар.

## I

Тикшерелә торган вакыт эчендәге мөһим күренешләрдән бүгенге проза турындагы дискуссиягә тукталып китәсе килә. Бу сөйләшү турыдан-туры «Казан утлары» инициативасы белән уздырыла. 1972 елда Рафаэль Мостафин кузгатып җибәргән фикер алышуга 1973 елда тәнкыйтьчеләрдән И. Нуруллин, М. Вәлиев, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, язучылардан Ф. Хөсни, А. Гыйләҗев кушылып, үз тавышларын, уй-теләкләрен ишеттерделәр. Сөйләшү хәзерге әдәбият алдына куела торган зур бурычлар югарылыгында алып барыла. Авторларның чыгышында проза үсеше турында ихлас кайгыртучанлык белән олы таләпчәнлек аралаша. Фатих Хөсни, гадәтенчә, көн кадагына суга торган мөһим мәсьәләләрне күтәрә дә аларның ни дәрәҗәдә актуаль булуын дәртләнеп, кыза-кыза исбатлап бирә. «Без китмәскә килдек!» дип өндәү билгесе белән исемләнгән мәкаләсендә (2 сан) ул зур темага лаеклы сәнгатьчә камиллек таләбен куя, чиле-пешле, чырайсыз-төссез әсәрләр белән кирәкле теманың кадерен ямен җибәрүгә каршы чыга. Игътибарга лаеклы искәртү бу. Зирәк художник әдәби хуҗалыгыбызда тышкы ялтыравыкларга урын бирмәү, мәһабәт, масштаблы образлар өчен көрәшә. Менә шушы художество таләпчәнлегендә язучының гражданлык активлыгы, әдәби-иҗтимагый бурычны тою дәрәҗәсе гәүдәләнә.

Ф. Хөсни соңгы ун еллар дәвамында прозабыздагы искә алырдай уңай якларның берсе итеп «кеше-герой психологиясенә тирәнрәк керүне» (173 бит), «эчке драма»ның үрелеп баруын (174 бит) саный, ягъни чынбарлыкның, кеше тормышының үзенчәлекле бер ягын яктыртудан туа торган психологизмга уңай бәя бирә. Ләкин нишләптер бу дөрес караш ахырга

кадәр эзлекле сакланмый, аерым әсәрләргә бәя бирә башлау белән бөтән төс ала. Автор болай ди: «Аяз Гыйләҗевнең исенә төшерергә һәм вакытында иптәшләрчә кисәтергә кирәк: әгәр ул... гел аерым шәхесләр җанында казыну юлы белән китсә, аның иҗатының чор иҗатыннан аерылу куркынычы бар» (179 бит). Ягъни кеше күңелен тирәнтен ачарга омтылу язучыны читкә алып китә булып чыга.

Биредә Фатих ага Хөсни мәкаләләренә ят булган янау тонын игътибарсыз калдырган хәлдә дә әлеге психологизм мәсьәләсенә кагылмыйча китеп булмый. Күңел дөньясы бит ул язучыны юлдан яздыра торган яман бер күренеш түгел, бәлки, Хәсән Туфан әйтмешли, уйлый, хис итә торган материянең даими бер сыйфаты. Инде «чор иҗатыннан аерылу» мәсьәләсенә килсәк, мондый аерылу кешенең тик тышкы эш-хәрәкәтләрен генә сурәтләү нәтиҗәсендә дә барлыкка килергә мөмкин. Монда яшәешнең бер өлкәсе булган күңел дөньясы гаепле түгел. Хикмәт нинди күңел дөньясы алынуында һәм аның ничек сурәтләнүендә. Достоевский кеше психикасын актырту дәвамында мөһим гуманистик мәсьәләләр күтәрә. Үзебезнең әдәбиятта Әмирхан Еникинең һәр әсәре безне тормыш турында тирән уйландыручан була. Шулай булгач, гомумән кешенең тышкы эш-хәрәкәтләрен сурәтләүгә каршы чыгу дөрес булмаган кебек, аның гомумән күңел дөньясына киртә кору да ярап бетмәстер. Тышкы вакыйгалар арасында әһәмиятлеләре белән беррәттән вaклары, әһәмиятсезләре булган кебек, рухи дөньяда да әһәмиятле элементлар белән бергә әһәмиятсезләре дә тулып ята. Димәк, дифференциаль караш кирәк.

Аяз Гыйләҗевнең «Урталыкта» повесте төрле укучыга төрле тәэсир ясаган. Мин үзем Аяз Гыйләҗев иҗатын тирән ихтирам итәм. Ләкин шулай булган хәлдә дә «Урталыкта» повесте күңелдә беркадәр канәгатьсезлек хисе калдырды. Чөнки монда негатив як кына, ягъни баш герой Сәгыйт күңелендә иҗат дәрте сүнүе генә ышандырырлык тасвирланган, ә уңай рухи үзгәреше җитәрлек нигезләнмәгән. Психологик процесс гүя ки башланмаган килеш бетеп куя. Димәк, язучының кимчелеге, минем карашка, гомумән күңел хәрәкәтен сурәтләргә омтылуында түгел, бәлки яхшы ниятнең сәнгатьчә хәл ителеп җиткерелмәвендә.

Мин биредә Фатих Хөсни мәкаләсендәге юл арасында гына әйтелеп киткән мәсьәләгә вәземләп тукталдым. Кабат әйтәм, мәкалә тулысы белән бик кызыклы, тирән эчтәлекле, кайнар хисле. Ләкин шул ук вакытта юл арасында гына кузгатылып куелган мәсьәләнең дә әдәбиятыбыз үсеше өчен принципиаль әһәмияте бар.

Бу мәгънәдә Мансур Вәлиевнең «Безнең заман геройлары» (3 сан) дигән мәкаләсе игътибарга лаеклы. Биредә ул, байтак тәнкыйтьчеләребездән аермалы буларак, рухи дөньяны сәнгатьчә сурәтләү осталыгына бик югары бәя бирә һәм нигездә яхшы дип табылган әсәрләребездә дә психологик төгәллек, сәнгатьчәлек җитмәүне тәнкыйтьли. Бу яшь авторның анализында конкретлык, әдәби зирәклек, фикер масштаблылыгы күзгә ташлана.

Ибраһим Нуруллинның шул ук өченче санда басылган «Аяк белән йөрүгә ни җитә?» дигән мәкаләсенең төп пафосы реалистик казанышларның бүгенге әдәбият өчен әһәмиятен раслауга, формалистик күнегүләрнең нәтиҗәсез булуын дәлилләүгә юнәлгән.

Флүн Мусинның бүгенге проза турындагы сөйләшүгә кушылып язган һәм алтынчы санда басылып чыккан мәкаләсе «Югары сәнгатьлелек өчен» дип атала. Исеменнән үк күренгәнчә, сүз проза әсәрләренең идея-эстетик кыйммәтен күтәрү мәсьәләләре тирәсендә бара. Автор соңгы вакытта язылган романнарның кайбер кимчелекләрен тәнкыйтьли. Әмма кимчелекләрне эзләү азарты кайчак авторны ялгыш нәтиҗәләргә китереп куйгалый. Флүн Мусин урта кул әсәрләрдә дә, бүгенге көннең күренекле романнарында да бердәй кимчелекләр күрә яки аларны бердәй итеп күрсәтергә тырыша. Миңа, мәсәлән, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы турында, газета-журналларда басылган рецензияләрдән тыш, күп санлы укучыларның, студентларның, укытучыларның һәм гомумән әдәбият сөючеләрнең фикерен ишетергә туры килде. Алар бер сө дә әсәр турында салкын сүз әйтмәде, киресенчә, һәркайсы мактап, сокланып телгә алды. Чөнки әсәр чыннан да талантлы язылуы белән аерылып тора. Ф. Мусин исә шуны урта кул роман төсендә такъдим итә, әсәр турында рецензия язып чыккан Ф. Хөсни, Т. Галиуллин, Ф. Урманчиевларның фикерен нигезсез итеп күрсәтергә тырыша.

Минем аңлавымча, тәнкыйтьнең төп бурычы һәм изге максаты да — яхшыны яманнан, әйбәтне уртачадан аера белү, аеруда сизгерлек, гаделлек, объективлык күрсәтү. Укучыны ул барыннан да бигрәк нәә шул зирәклеге белән тәрбияли. Әсәрләрне объектив дөрес, квалификацияле анализлау — үзе үк укучыларны эстетик тәрбияләү чарасы ул, ягъни тәнкыйть үзенең иҗтимагый бурычын әдәби күренешләргә биргән дөрес бәясе аркылы башкара, иҗади уңышларны күрә белергә, аларны ныгытып, беркетеп куярга, кимчелекләрдән арынырга булыша, яхшыны яманнан аерырга өйрәтә. Әдәби әсәрләр әдипнең күпьеллык хезмәт җимеше генә түгел, ул — җәмгыять байлыгы. Тәнкыйть әнә шул байлык белән эш итә. Ул укучыда тулы ышаныч, авторитет яулап алганда гына укучы аның гадел сүзенә колак сала, рецензия, мәкалә тәкъдим иткән әсәрләрне кулына ала. Әгәр инде бәя бирүдәге сизгерлеген югалтса, әйбәт әсәрләрне дә уртачалар түбәнлегенә төшереп калдыра торган булса, укучыга «югары сәнгатьлелек өчен!» лозунгысының мәгънәсе аңлашылып җитми башлый.

Флүн Мусин — актив тәнкыйтьчеләребезнең берсе. Бүгенге проза тәнкыйтен үстерүгә ул зур гына өлеш кертте. Ләкин шулай да аның хезмәтләрендә фикер кыюлыгы һәр вакытта да фикер төгәллеге белән кушылып җитми. Теоретик гомумиләштерүләр ясаганда бигрәк тә. Ул, мәсәлән, әлеге мәкаләсендә болай ди: «Роман әдәбиятның иң камил һәм синтетик формасы» (149 бит). Роман турында масштаблы, эпик колачлы, күп геройлы, катлаулы, дәвамлы процессларны чагылдыруга сәләтле жанр диярга була, әмма «иң камил форма» дип булмый. Кайсы жанр камил түгел? Лирикамы? Поэмамы? Алайга китсә, роман башка кайбер жанрлардан соңрак туган һәм, димәк, азрак традицияле жанр әле ул. һәм төрле таркаулыклар да еш кына шушы жанрда күренгәли. Кыскасы, бер жанр формасын күтәрү өчен икенчесен түбәнәйтү һич тә шарт түгел. Икенчедән, синкретизм, укмашканлык — бер дә җитлегү билгесе түгел, бәлки сәнгатьнең башлангыч чоры өчен хас күренеш. Безгә теоретик карашларның дәлилле, кире кагылмаслык нигезле булуына омтылырга кирәк.

Инде гомумән проза турындагы сөйләшүләрнең кайбер кимчелекле якларына килсәк, монда сөйләшүне башлап җибәргән мәкаләнең дискуссия объектын бер еллык проза белән генә чикләвен, башка авторларның да шуннан әллә ни читкә чыкмавын, нигездә, кузгатылган проблемалар тирәсендә генә йөрүен, мәсьәләнең яңа якларны күтәрелмәвен, авторлар даирәсенең таррак булуын, күренекле галимнәребезнең, әдипләребезнең читтәрәк торуын, фикер алышуларның аерым саннарда өзелеп-өзелеп калуын күрсәтеп үтәсе килә. Ләкин шундый җитешсезлекләре булуга да карамастан, дискуссиянең уңай нәтиҗәләре булыр дип уйлыйм.

## II

Соңгы вакытта, әдәби ел йомгаклары белән беррәттән, Татарстан язучылар союзының төп әдәби органы «Казан утлары»нда басылган әсәрләргә күзәтүләр оештыру популярлашып бара. Бу җитди журналда иң яхшы әсәрләр басылганлыктан, әлеге сөйләшүләр дә бүгенге әдәбиятның мөһим тенденцияләре турында фикер уртаклашу төсен ала. Әдәби күренешләргә карата җәмәгатьчелек игътибары туплана. Бу күзәтүләр үзләренең оперәтив, конкрет булулары белән аерылып торалар.

1973 елда идарәнең киңәйтелгән утырышында ясаган докладлар нигезендә «Казан утлары»нда Шамил Бикчуринның «Очеркның асылы» (3 сан), Фатих Урманчиевның «Бүгенге тәнкыйть мәсьәләләре» (5 сан), Роберт Әхмәтҗановның «Заман утлары» (6 сан) дигән кызыклы, шактый тирән эчтәлекле мәкаләләре басылып чыкты. Аларның берсе дә гади күзәтү генә булып калмаган. Авторлар үзләре тикшерә торган өлкәнең җитди мәсьәләләрен күтәрәләр, уңайны яклыйлар, тискәрене камчылыйлар. Менә, мәсәлән, Роберт Әхмәтҗановның мәкаләсе. Бирелә сүз «Казан утлары»ның 1972 елгы 1—8 саннарында басылган шигырьләр турында бара. Җыелышта без аның докладын да кызыксынып тыңлаган идек, журналдагы мәкалә варианты да җылы тәэсир калдыра. Монда без фикерле күзәтү үрнәген күрәбез. Шагыйрь-тәнкыйтьче бүгенге поэзияне нечкә тоя, поэтик казанышлар турында бар тавышка дәртләнеп, куанып сөйли, кимчелекләрне дә, шагыйрьләрнең олысына-кечесенә карамыйча, хәтер саклауны төп максат итеп алмыйча, туры карап әйтә. Кыскасы, бөтен мәкаләнең

рухын олы поэзия турында җитди кайгыртучанлык билгеле. Бу җәһәттән өстәп тик шунысын гына әйтәсе килә. Әдәби әсәрләр, «Казан утлары»ннан тыш, тагын бик күп альманах-журналларда («Идел», «Азат хатын», «Чаян», «Ялкын»), республика газеталарында басылып килә. Аларның тиражы берничә йөз меңнәрне узып китә. Әсәрләрне гаять киң массалар укый. Алар укучыга нинди әсәрләр тәкъдим итәләр? Газета-журнал битләрендәге әсәрләргә дә күзәтүләр ясалып торса, без бу сорауга да ачык җавап алыр идек.

Аның каравы, ел йомгаклары әдәби байлыгыбызны мөмкин кадәр тулырак иңләргә омтылалар, укучыларга әдәби күренешләрне бәйнә-бәйнә аңлатып бирәләр. Былтыр «Казан утлары» журналында Флорид Әгъзамовның 1972 елгы очерклар турында «Чорның елъязмасы» дигән мәкаләсе (7 сан), Нил Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика — хәрәкәттә» (8 сан), Фарваз Миңнуллинның «Прозаның гражданлык йөзе» (9 сан) исемле күләмле хезмәтләре басылып чыкты. Н. Юзиевның киң карашлы мәкаләсендә энциклопедик белешмәләрдән, рецензияләрдән башлап җитди монографияләргә һәм диссертацияләргә кадәр һәрберсе конкрет анализлана, тәнкыйть, әдәбият тарихы һәм теориясе алдында торган мөһим реаль проблемалар күтәрелә. Фарваз Миңнуллин мәкаләсе үткен тешле булуы белән аерылып тора. Проза әсәрләрен тикшерүдә тәнкыйтьле мөнәсәбәт өстенлек итә.

Җитди гыйльми тикшеренүләр рәвешендәге күзәтүләрнең беришесе әдәбиятыбыз тарихының аерым чорларына карыйлар. Шунлыйлардан, мәсәлән, Зәет Мәҗитовның «Тимерче сугышта» дигән хезмәтендә (2 сан) Фатих Кәрим поэзиясендә солдат образының поэтик гәүдәләнеше тикшерелә, әсәрләрнең вариантларын, караламаларын чагыштырып, моңа килү юллары, поэтик энҗеләр табылу тарихы уңышлы яктыртыла. Мондый мәкаләләр яшь язучыларга шигъри мәктәп ролен үтиләр. Нур Гыйззәтуллин «Яңа герой эзләгәндә» дигән мәкаләсендә (5 сан) утызынчы еллар башындагы прозаны, Кави Нәҗми, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмирләрнең яңа кеше образын иҗат итү тәҗрибәсен, бу юлдагы уңышларны һәм кимчелекләрне чагылдыра.

Бүгенге язучыларыбызның иҗат портретлары — журналда сирәк кунак. Ел әйләнәсенә алар күп булса бер-ике тапкыр күренеп калалар. Тәлгат Галиуллинның «Матурлыкка бай ул безнең заман...» (10 сан) дигән мәкаләсе икенче төрле «И. Юзеевның иҗат портретына эскизлар» дип исемләнгән. Бу эскизлар Илдар Юзеев поэзиясенең мөһим үзенчәлекләрен, традицияләрен, яңалыкларын, романтик-психологик характерын, проблематикасын шактый ачык итеп күз алдына китереп бастыралар. Тәнкыйтьче хронологик эзлеклелек үзеннән генә бармый. Язучы иҗаты, аның мөһим яклары төп проблемалар тирәсенә төркемләп аңлатыла. Нәтиҗәдә автор төп тенденцияләрне җыйнак, ләкин шул ук вакытта калку итеп, ерактан күренеп торырлык итеп исбатлап бирүгә ирешә. Өлкән шагыйребез Хәсән Туфанның Мостай Кәрим иҗаты турындагы, язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең халык җырлары хакындагы мәкаләләре дә күңелдә җылы тәэсир калдыра.

Фатих Хөсни белән Хәсән Туфанның бер матур гадәтләре бар: алар, берсе — проза, икенчесе — поэзия өлкәсендә, берәр талантлы әсәр язылдымы, шуннан туган шатлыкларын тизрәк җәмәгатьчелек белән уртаклашырга, үз мөнәсәбәтләрен белдерергә омтылалар. Бу очракта Хәсән Туфанның «Минутларның бөек чагы» дигән мәкаләсе журналда Башкортстан халык шагыйренең «Көзге шигырьләр»е басылу уңае белән бирелгән. Автор Мостай Кәрим поэзиясенә бик югары бәя бирә, аның фәлсәфи-поэтик асылын ачып күрсәтергә омтыла. Шушы ук рәттән мин Мостафа Ногманның икенче бер күренекле башкорт шагыйре Нәҗар Нәҗмигә «Социалистик Татарстан» газетасы аркылы җибәргән ачык хатын да күрсәтеп китәр идем. Алар һәр икесе дә — халыклар дуслыгы хәбәрчеләре.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк...» дигән язмасы, бик җанлы, образлы итеп, билгеле бер сюжетка салып, халык җырларының нинди шартларда туую яктырта. Язучыларның хезмәтләрендә гыйльми дәлилләрдән дә бигрәк хисләр өстенлек ала, ягъни авторлар теге яки бу әсәрне укудан алган тәэсирләрен уртаклашалар.

«Казан утлары»нда төрле характердагы җыентыкларга ясалган күзәтүләр дә зур гына урын алып тора. Былтыр, мәсәлән, журналда Шәрәф Әхмәдуллин, Мансур Вәлиев, Рәшит Гәрәй, Мөхәммәт Мәһдиев, Илдус Ахунҗанов, Гариф Ахунов, Фатих Урманчиев, Н. Гамбәров,

Л. Гаделшин, Р. Абдуллина, М. Рәфыйков, И. Кадыйров иптәшләр Локман Бадыйкшанның, Тәуфыйк Камалиевның, Рәшит Әхмәтҗановның, Нонна Орешинаның, Нәби Дәүлинең, Клара Булатованың, Сибгат Хәкимнең, Зиннур Насыйбуллинның хикәя, шигырь китапларына, кыргыз хикәяләренә, Марс Шабаев поэзиясенә, Илбарис Надиров төзегән «Җырлар китабы»на, Мәхмүт Нигъмәтҗанов чыгарган «Татар халык җырлары»на анализ ясыйлар. Фатих Урманчиев журналның 6 нчы санында, яңа җыентыкны төзүдәге, һичшиксез, уңай яклар белән беррәттән, соңгы вакытта җыр текстлары иҗат итүдәге моңа кадәр ничектер игътибар итеп җиткерелмәгән җитди кимчелекләрне дә ачып сала (бер үк поэтик образларның җырданҗырга сәяхәт итеп йөрүе, темаларның, формаларның бер үк рәвештә кабатлануы, гади информация, декларация, барлык шагыйрьләр дә, лирик геройлар да берьюлы Татарстан туфрагыннан күчеп киткәндәй, һәрберсенең җырына да уртак сагыну-саргаю мотивларының килеп керүе, поэтик ярлылык h. б.). Рецензия шагыйрьләр игътибарын җырлар иҗат итүдәге мөһим мәсьәләләргә юнәлтә.

Соңгы вакытта талантлы тәнкыйтьче Илдус Ахунҗановның кабат әдәбиятка кайтуы безнең һәммәбезне дә ихлас куандырды. Илдус Ахунҗанов рус, татар һәм башка әдәбиятларны яхшы белүче, сәнгатьлелекне нечкә тоючы тәнкыйтьче. Үткән елда аның татар шагыйрьләрен рус теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсен анализлаган мәкаләләре басылып чыккан иде. Быел «Тормыш белән танышканда» дигән мәкалә белән катнаша (4 сан). Ул биредә Нонна Орешина повестьларын анализлый.

Рецензиягә юлыккан китаплар арасында моңа һичшиксез лаеклы булганнары да бар. («Татар халык җырлары», «Җырлар китабы», «Кыргыз хикәяләре», С. Хәким, Н. Дәүли, М. Шабаев, З. Насыйбуллин җыентыклары.) Әмма шуның белән бергә рецензияләрнең үзләренең гомум рухыннан ук күпчелек җыентыкларның артык югары художестволылыкка дәгъва итмәгәнлекләре аңлашыла. Сорау туа: ни өчен рецензия өчен әдәбият үсешенең югары ноктасын билгеләгән әсәрләр алынмый да, бары урта кул җыентыклар гына сайлана? Әле урталыкка каршы көрәш байрагы күтәрелсә икән. Юк бит, тәнкыйтьчеләребез моның белән килешү тонында язалар. Моннан күреп кайбер талантлы гына әдипләребез дә тора-бара урта кул әсәрләр тудыруга җайлашып, көнегеп китәләр, әсәргә көчне дә уртача гына салалар, тормыш эченә дә әллә ни тирән үтеп кермиләр, художестволылык та бер чамадан артмый. Шулай бер әсәр, ике, өч... ун әсәр дөньяга килә. Ә шунда өч әсәргә салган көчне бер әсәргә салса, нәтиҗәсе нихәтле яхшырак булыр иде.

Тәнкыйтьнең бурычы — тоташтан барлык әсәрләрнең дә итен иткә, сөяген сөяккә аерып бару түгел. Тәнкыйть хезмәтләрендә тәнкыйтькә лаеклы әсәрләр анализлана. Кимчелекләрне кыю фаш иткән хәлдә дә ул укучыларны башлыча яхшы әсәрләр үрнәгендә тәрбияли. Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан тәнкыйтьтән түбән торган әсәрләрнең җитди мәкаләләргә үтеп керməвен яки сирәк кенә телгә алынуын табигый күренеш дип санарга кирәк. Художество иҗатындагы кебек, монда да сайлап алу принцибы әдәбияттагы мөһим тенденцияләрне ачыграк итеп яктыртырга ярдәм итә. Бездә исә моның икенче ягы белән дә очрашырга мөмкин: урта кул әсәрләр турында язабыз, әйбәтләрен күрмәмешкә салышабыз.

Романнарны гына алып карыйк. Яхшы роман туу — теләсә кайсы әдәбият өчен зур вакыйга ул. Соңгы елларда бездә «Әтил суы ака торур», «Фронтовиклар» кебек теләсә кайсы телгә тәрҗемә иткәндә дә йөз кызартмаслык, әдәбиятның горурлыгы булып торырлык, йотлыгып укырлык, җентекле анализга лаеклы җитди романнар иҗат ителде. Ләкин журналда аларның берсе хакында да аерым рецензия, аларның поэтик табигатен бөртекләп, тирәнтен ачкан мәкалә басылып чыкмады. Күп булса газета рецензиясе яки узып барышлый әсәрнең тегеяки бу почмагына кагылып киткән репликалар белән чикләнеп калдык. Минемчә, безгә яхшысы турында да, яманы турында да дәшми узу практикасыннан никадәр тизрәк арынсак, шул кадәр яхшырак булачак.

Киң эрудицияле, иң актив профессиональ тәнкыйтьчеләребездән Рафаэль Мостафин «Проблемалар, аларның чишелеше» (7 сан) дигән кызыклы мәкаләсендә Атилла Расихның «Каһарманнар юлы» романын тикшерә, әсәрнең проблематикасын җентекле яктырта. Проблематикага махсус игътибар туплау, һичшиксез, уңай күренеш. Бу җәһәттән Мирсәй Әмирнең дә «Социалистик Татарстан»да басылып чык-

кан бер мәкаләсен искә алып үтәсе килә. Анда ул Х. Хәйруллин повестенда күтәрелгән проблемаларга туктала.

Һәр ике автор да кыю проблемалар күтәрелүен иҗтимагый активлык билгесе дип карыйлар. Шуның белән бергә, Р. Мостафин мәкаләсендә проблемаларның художестволы хәл ителеше турындагы фикерләрне дә ишетәсе килә. Кызганычка каршы, әсәрнең башка компонентлары җитәрлек яктыртылмаган. Бу хәлендә мәкалә зур хезмәтнең кереше кебегрәк кабул ителә. Хәлбуки, сәнгатьчә камиллек мәсьәләсе яшь язучылар өчен генә түгел, өлкән буын әдипләр өчен дә иң үткен, актуаль проблемаларның берсе булып кала. Сәнгатьчә эшләнеш ягыннан кайбер әсәрләрдә язучыларыбыз үзләре ирешкән югарылыкка да күтәрелеп җитмиләр, иҗтимагый мөһим тематика художество камиллеге белән тиешенчә кушылмый.

III

Матур әдәбият дип йөртелә торган зур байлык аерым әсәрләрдән төзелә. Сәнгать әсәре — әдәбиятның иң мөһим берәмлеге. Башка бертөрле чаралар да язучы өстәл янына утырып иҗат иткән сәнгать әсәрен алыштыра алмый. Ләкин, шуның белән бергә, һәрбер зур әдәбиятның олылыгын билгеләүгә җитди теоретик хезмәтләр дә катнаша. Зур гомумиләштерү сыйфатына ия булган кайбер күренекле теоретик хезмәтләр әдәби әсәрләргә караганда да озынрак гомерле булалар. Гыйльми тирән әдәбият теориясе — ул язучының һәм укучының акыллы киңәшчесе, сүз сәнгатенең серләрен аңлатучы, юл күрсәтүче. Укучы, сәнгать әсәрен укып, аның эмоциональ эчтәлеген кабул итә, теоретик хезмәт укып, әсәрнең гыйльми эчтәлегенә төшенә.

1973 елда журналда басылган мәкаләләр безнең әдәбиятта да интенсив гыйльми-теоретик эзләнүләр алып барылганлыгын күрсәтәләр. Алар характерлары буенча да төрлеләр. Мансур Хәсәнов «Интернационализмның данлы традицияләре» исемле, фактик материалга бай, тирән эчтәлекле мәкаләсендә (5 сан) татар әдәбиятындагы интернационализм традицияләрен тикшерә, бу юнәлештә билгеле бер теоретик гомумиләштерүләр ясый. Сәлим Шәйдуллин өченче санда басылган мәкаләсендә борынгы, урта гасыр, XIX йөз татар әдәбиятларында романтизм элементларының нинди урын билгеләвен күздән кичерә. Мондый хезмәтләрдән беркадәр аермалы буларак, Нурмөхәммәт Хисамов «Гасырлар тирәнлегеннән» дигән мәкаләсендә (4 сан) бик конкрет рәвештә аерым поэтик сурәтләү чараларының эволюциясен яктырта. Шәрәф Әхмәдуллин «Шигърият мәйданында — сонетлар» дигән мәкаләсендә (1 сан) сонетларның килеп чыгу тарихын, бу форманың безнең әдәбиятка килеп керүен, аның уңышлы һәм уңышсыз куллану очраклары турында сөйли, сонетның асылын ачып бирә. Бу кызыклы мәкаләдә тик кайбер терминнарның гына гомум кабул ителгәнчә бирелмәве аптырашта калдыра. Автор «билләүле рифма» дип атаган рифма төре (175 бит) гадәттә «әйләнмә рифма» дип йөртелә, ә «алгарыш», «аркылы рифма» сүзләре гомумән аңлашылмый. Соңгысын «арадаш рифма»ның бер төсмере яки синоним мәгънәсендә кулланамы, шулай булганда термин төрлелеге үзен аклыймы икән? — диясе килә.

Инде килеп, тәнкыйть турындагы тәнкыйть хакында берничә сүз. Дөресен әйткәндә, «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карар кузгатып җибәргән иҗади активлык барыннан да бигрәк тәнкыйть турындагы тәнкыйтьнең җанлануында чагыла. Бу җанлылык бигрәк тә 5 санда бер фокуска туплап бирелгән. Монда тәнкыйть мәсьәләләре хакындагы мәкалә дә, теоретик китапларга рецензияләр дә, хәтта тәнкыйтьче хакындагы махсус мәкалә дә урын ала. Рафаэль Мостафин гадәти юбилей мәкаләсе язып кына калмаган, Ибраһим Нуруллин тәнкыйтенең эченә үтеп кергән, аңа хас сыйфатларны — яңа үсентеләрне яклап чыгу, мәкаләләренең теоретик һәм эстетик яктан тыгыз, композицион төгәл, фикер ягыннан эзлекле булуы, кимчелекләрне кыю тәнкыйтьләү сыйфатларын күрсәтеп китә.

Рафаэль Мостафин Ибраһим Нуруллинның нигездә тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген, ягъни башлыча эш арасында язган әсәрләрен тикшерә, ә зур, теоретик хезмәтләр бер читтә торып кала. Бәхеткә каршы, бу бушлык шул ук 5 санда басылган икенче бер рецензиядә — Гали Халитның «Әдәбиятның төп үзәнен һәм үзенчәлеген күреп» дигән мәкаләсендә беркадәр тутырыла. Автор биредә Казан университеты профессорлары Йолдыз Нигъмәтуллина һәм Ибраһим Нуруллинның

соңгы елларда басылып чыккан китапларын анализлый һәм шул уңайдан эстетик идеал һәм иҗат методы кебек әдәбият теориясенең үзәгендә тора торган мөһим мәсьәләләрне яктырта, әлеге китапларга нигезләнеп, кайбер яңа мәсьәләләр күтәрә.

Мәгълүм булганча, сугыштан соңгы елларда Казан университетының әдәбият кафедрасында Хатип Госман җитәкчелегендә татар поэзиясе мәсьәләләрен өйрәнү шактый киң колач алды. Моның ачык мисалы Хатип Госманның «Шигырь төзелеше» (Казан. 1973), Нил Юзиевның «Шигырь гармониясе» дигән китабы (Казан. 1972). 5 санда Марсель Бакировның соңгы китапка карата язылган рецензиясе урнаштырылган. «Нил Юзиевның бу китабы татар шигырь поэтикасын өйрәнүгә багышланган,— дип яза рецензент.— Хезмәттә мәсьәләнең куелышы да һәм аның тематик юнәлеше дә яңа. Әйтик, моннан алда чыккан «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» (Казан. 1969) дигән китабында автор поэзиянең тышкы бәйләнешләрен, ягъни кино, театр, музыка кебек башка сәнгать төрләре белән элемтәләрен күрсәткән булса, монда инде игътибарын шигырь структурасындагы эчке бәйләнешләргә юнәлтә. Аерым алганда, шигырьнең «алтын багана»лары булган ритм, рифманың үзара һәм шигъри фикер белән нинди мөнәсәбәтләргә керүен тикшерү яңа хезмәтнең максатын һәм бөтен эчтәлеген тәшкил итә» (173 бит). Бу китап үзенең темасы, проблемасы белән яңа булган кебек, тикшерү алымнары ягыннан да үзенчәлекле. Шигырь төзелеше җанлы иҗат процессына, шагыйрьләрнең иҗат лабораториясенә бәйләп тикшерелә. Рецензент укучыга шушы китапның төп мәсьәләләрен җыйнак төстә аңлатып бирә.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, чагыштырмача тарраk өлкәдә дәвамлы тикшеренүләр алып бару җитдирәк теоретик ачышлар ясарга мөмкинлек бирә. Моңа галимнең таланты һәм фикер тирәнлеге дә кушылса бигрәк тә.

Менә шулай: бөртекләп җыела алтын дигәндәй, теоретик фикер энҗеләре дә акрынлап туплана, ул энҗеләрне эзләп табуда күп буыннар, күп авторлар катнаша. Ләкин шулай да эзләнүләр темпы, колачы, тирәнлеге безне һәр вакытта да канәгатьләндереп житкерә алмый әле. Гәрчә әдәбиятыбызның тарихы, аерым язучылар иҗаты, әдәби методлар, шигырь теориясе буенча байтак казанышлар булса да, проза, драма, фольклор, художество әсәре теориясе буенча җитди ачышларны, зур гомумиләштерүләрне күрсәтә алмыйбыз. Әдәбият теориясе, татар халык иҗаты буенча вузлар өчен дәреслек булмавы да теория өлкәсенең бездә иң артта калган тармакларның берсе булганлыгы турында сөйли. Бу өлкәгә иң әүвәл мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Безне шулай ук сәнгатьнең күрше тармаклары буенча да фундаменталь теоретик хезмәтләр язылмавы, музыка теориясе, рәсем теориясе буенча җитди дәреслекләр булмавы борчый. Югыйсә бит, байтак гыйльми көчләр бар (консерватория, пединститутның музыкаль-педагогика факультеты, культура институты һ. б.). Тиешенчә оештырганда, бу эшләрне дә уңышлы башкарып чыгарга була.

Аннары тәнкыйть теориясе турында да уйлый башларга вакыт инде. Бездә киң эрудицияле, әдәбиятны нечкә сизүче бик күп могтәбәр галимнәр, тәнкыйтьчеләр бар. Аларның берише, чәчәкләрдән нектар җыеп бал ясаган эшчән бал кортлары кебек, яңа әсәрләр табып әдәбиятыбызны баеталар, икенчеләрнең хезмәтендә фактик ачышларга галимнең тирән фикер нуры төшерелә, өченчеләре сәнгать әсәрләренең табигатен зирәк тоеп, нечкәлекләрен укучыга аңлатып бирәләр, гомумиләштерүләр ясыйлар. Әдәби күренешләр, әсәрләр хакында фикер йөрткәндә алар барыннан да бигрәк үзләренең тирән белемнәренә таянып эш итәләр. Шушы хәл тәнкыйтьнең авторитетын билгели. Ләкин һәр галим, тәнкыйтьче әдәби күренешләрне үзенең шәхси таланты, аңлау, тою дәрәҗәсенә карап тикшерә. Тәнкыйть теориясен яктырткан хезмәтләр юк бездә. Тәнкыйть осталыгы турында сүз йөртү гомумән гадәткә кермәгән. Хәлбуки, тәнкыйть хезмәте — ул, бер яктан, фән булса, икенче яктан, гүзәллек турында сөйли торган, киң массаларга адресланган шактый демократик фән. Бу мәгънәдә ул фән белән әдәбият арасында уртадарак тора, үзенә тегесенең дә, монысының да мөмкинлекләрен туплаган. Болай дигәндә мин, әлбәттә, тәнкыйть хезмәтен иллюстратив материаллар белән тутыруны күздә тотмыйм. Сәнгать әсәреннән алынган эмоциональ яңгырашлы, поэтик бизәкле мисаллар мәкаләне җанлы, кызыклы, экспрессив йогынтылы итә, билгеле. Әмма тәнкыйть мәкаләсе шулай да иллюстратив

хрестоматия түгел бит ул. Болай итәргә аның күләме дә мөмкинлек бирми. Яхшы тәнкыйть мәкаләсе укучыны үз артыннан барыннан да бигрәк мисаллар белән ныгытылган фикернең яңалыгы, тирәнлеге, эзлеклелеге белән җәлеп итә. Фикернең үсә баруы — ул үзенә күрә мәкаләнең сюжеты ролен үти. Аерма тик шунда — художество әсәрендә динамиканы вакыйгалар хәрәкәте тудырса, тәнкыйть мәкаләсендә фикер хәрәкәте мавыктыра. Нәкъ менә фикердә гомумиләштерүгә ирешелә.

Без, әлбәттә, тәнкыйть мәкаләләренең җиңел укылырдай булуына омтылырга тиешбез. Әмма җиңел укылучанлык — тәнкыйтьнең төп уңай күрсәткече түгел. Биредә матур әдәбиятка куела торган таләпне механик рәвештә тәнкыйтькә күчерү мөмкин түгел. Тәнкыйть хезмәте, әдәби әсәр хакында сөйләсә дә, образлы фикер йөртү нигезендә түгел, гыйльми фикер йөртү нигезендә, ягъни әдәби әсәрләрне гыйльми анализлау җирлегендә туа. Җиңел укыла торган кайбер мәкаләләрнең фикерләре дә шактый җиңел була, укып чыгу белән оча да бетә, парга әйләнеп юк була, ә билгеле бер хәзерлекне, аңлау, төшенү өчен беркадәр көч салуны, тырышлыкны сорый торган җитди, тирән фикерле мәкаләләр әдәбият тарихында урын алып калалар.

Һәрбер әдәби әсәр — ул гомум законлылыкның чагылышы гына түгел, шул ук вакытта ул индивидуаль күренеш тә. Шуңа күрә һәрбер әдәби әсәрне идея-эстетик яктан анализлау өчен үзенең ачкычын таба белү сорала. Әле тәҗрибә җитмәгән чакта тәнкыйтьчеләр мәсьәләне бик җиңел хәл итәләр: сюжет вакыйгаларын яки күп булса сурәтләнгән геройның биографик эпизодларын сөйләп чыгалар. Бу рәвешле анализның аерым мисалларын без тикшерелә торган саннарда да очратабыз. Әмма җитди тәнкыйть ким дигәндә өч сорауга җавап бирергә бурычлы: нәрсә? Ничек? Ни өчен? Ягъни әсәрдә нәрсә турында сүз баруын сөйләү генә җитми, аның ничек һәм ни өчен сурәтләнүен дә укучыга аңлатып бирергә кирәк. Аеруча соңгы ике сорауга җавап биргәндә әсәрнең идея-поэтик кыйммәте тирәнтен ачыла. «Ни өчен» соравына җавап эзләү теләсә нинди фәндә күп уйлануны, баш ватуны, күренешнең эчке пружиналарын, ерак бәйләнешләрен, гади күзгә күренеп тормаган якларын капшап карауны, төбенә, асылына төшеп җитүне таләп итә. Эстетикада исә моңа җавап эзләү дәвамында әсәрнең, әдәби күренешләрнең тормыш белән катлаулы бәйләнешләре, сәнгать закончалыгының мөһим чагылышлары, кыскасы, сәнгать дип йөртелә торган катлаулы өлкәнең яңа серләре ачыла.

Безнең теоретик тирәнлек белән критик анализ осталыгын кушу юнәлешендә, тәнкыйтьнең идея-художество дәрәҗәсен күтәрү өлкәсендә байтак тырышасыбыз бар әле. Һәрбер иҗат әсәре кебек, тәнкыйть хезмәте дә даими камилләштерүне, каткат эшкәртүне, күчереп язуны сорый. Җилгәргән саен кибәкләр очып китә, көшелдә эре бөртекләр торып кала, фикер ачыклана.

Моннан тыш әле тагын һәр жанр тәнкыйтенең үзенең спецификасы бар. Бу җәһәттән тәнкыйтьчеләребезнең билгеле бер жанрларны басымлап өйрәнүләрен, бу өлкәдәге специальләшүне уңай күренеш дип санарга кирәк.

Бу урында бүгенге тәнкыйть мәкаләләрендә еш кына очрый торган фикерне бертөрле раслау рәвешенә тукталып узасы килә. Флүн Мусин болай ди: «Әдипләребез заман тормышына, аның яңа күренешләренә активрак мөрәҗәгать иткән саен алар иҗатының сәнгатьлелеге кими бара шикелле». (6 сан. 149 бит.) Шактый җаваплы белдерү, дөрес бит! Ләкин куелган положениенең бик җитди, кискен булуыннан үзе үк сискәнеп булса кирәк, аны «шикелле» бәйлеге белән бераз йомшартып, җаваплылыкны киметеп куясы иткән. Минемчә, монда эш стильдә генә түгел, бәлки авторның үзе куйган положениенең дөреслегенә, дәлилле, нигезле булуына җитәрлек ышанып җитмәвендә, иманы камил булмавында. «Кебек», «шикелле», «бугай» сүзләре — алар раслауның ныклы булмавын күрсәтеп тора торган чаралар. Әгәр шулай икән, чак кына шигең бар икән, мәйданга фикер ташламый тору хәерле.

Инде мәсьәләнең асылына килсәк, минем аңлавымча, замандаш тематика белән сәнгатьлелек бер-берсен кире кага торган капма-каршы төшенчәләр түгел, киресенчә, күңелләрен күрә белгәндә, бер-берсен тирән аңлый, тату, дус яши торган күренешләр алар. Әгәр дә әдип тормышны художник һәм философ буларак өйрәнсә, урта кулдагы өч әсәргә төшә торган көч һәм талантын бер әсәргә салса, замандаш тематика гына нишләп үзенең сәнгатьчә

яңгырашын тапмас икән? Әдәбият тарихында мисаллары хәтсез бит.

Без теоретик яктан бөек әсәрләрнең художник сәләте белән философ фикере кушылуы җирлегендә туганын яхшы беләбез. Әмма практикада художниклык ягына гына басым ясыйбыз да, җәмгыятьне фикер иясе, философ буларак өйрәнү таләбен куймыйбыз. Бу ике башлангычны һәр әсәрдә кушарга, үреп җибәрергә омтылырга кирәк. Фикердән башка рухи азыкның кыйммәте әллә ни югары йөрмәс. Димәк, кайбер әсәрләрдә сәнгатьлелек кимүенең төп сәбәбе бүгенге тормыш күренешләрен алып сурәтләүдә түгел, бәлки аны нинди тирәнлектә, нинди художество көче белән яктыртуда. Бер үк язучының бүгенге таныш чынбарлыкны уңышлы чагылдырып та җитди генә тарихи теманы йомшак тасвирлау очраклары да бар бит.

* * *

Матур әдәбият сәнгатьнең башка бик күп тармаклары белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә дә әдәби журналда сәнгатьнең башка өлкәләре буенча да мәкаләләр басыла килүен хупламыйча мөмкин түгел. Журнал битләрендә драма, эстрада артистлары, композиторлар, художниклар, архитектура мәсьәләләре турында кызыклы мәкаләләр басылган. Бу хәл журналның диапазоны киңәя баруы хакында сөйли. Ләкин шуның белән бергә ул үзе белән яңа проблемалар да алып килә. «Казан утлары» — әдәби журнал. Шуңа күрә аның редакциясе дә сәнгатьнең барлык төрләре буенча да җитәрлек дәрәҗәдә компетенцияле була алмый. Чөнки һәр тармакның үзенең үзенчәлекләре бар. Икенчедән, бу материаллар әдәби әсәрләрне кысрыклау хисабына басылалар. Шулай итеп, көн тәртибенә сәнгатьнең башка тармаклары буенча махсус журнал булдыру кирәклеге мәсьәләсе килеп баса.

Партия Үзәк Комитеты безнең алга тәнкыйтьнең фәлсәфи тирәнлеген арттыру бурычын куйды. Философик гомумиләштерү — ул философия курсларындагы положениеләрне урынлы куллана белү генә түгел. Һәр өлкәнең үз философиясе бар. Еш кына безнең фикер йөртүдә берьяклылык өстенлек алып китә. Фәлсәфи тирәнлек — ул күренешнең асылына төшенү, аның күпьяклы, катлаулы бәйләнешләрен күрә белү, нәтиҗә ясау дигән сүз.

Тәнкыйтьнең өйрәнү предметы — матур әдәбият һәм җәмгыять тормышы, аның кешеләре. Ягъни ул матур әдәбиятны җәмгыять тормышы яктылыгына куеп өйрәнә. Без хаклы рәвештә әдәбият фәнендәге вульгар социологизмны тәнкыйтьләп чыгабыз. Ләкин моңа карап тәнкыйтьнең иҗтимагый тормышка игътибары һич тә кимергә тиеш түгел. Киресенчә, партия Үзәк Комитеты карарында социаль анализны тирәнәйтү бурычы куела. Тәнкыйтьче — әдәбият һәм җәмгыять хакында фикер йөртүче философ ул. Ягъни иҗтимагый тормышны әдәбиятка бәйләп тикшерә.

Массаларны идея-эстетик тәрбияләүдә тәнкыйть бик үтемле булган эмоциональ сүз сәнгатен файдалана. Прогрессив тәнкыйть фикер үсешенә үзеннән өлеш кертә килгән. Безнең көннәрдә тәнкыйтьнең гражданлык бурычы чагыштыргысыз зурайды, яңа җәмгыять төзүгә булышу таләпләре куелды. Олы максат яңа иҗади ашкыну тудырыр дип уйлыйм.

Флера Сафиуллина

# ТЕЛ БАЙЛЫГЫ— ХАЛЫКТА

Әдәби тел гомум халык теленә нигезләнеп туа, үсә, камилләшә, чәчәк ата. Башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки әдәби тел шушы халыкка хезмәт итә, шушы халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Халыкның җанлы сөйләме, гомум халык теле әдәби тел өчен һәр вакыт бетмәс-төкәнмәс чыганак булып тора. Шушы чыганактан ераклашса, әдәби тел яңа тормыш, яңа иҗтимагый шартлар алып килгән үзгәрешләрне белдерә алырлык чаралар табуда зур кыенлык сизәр иде.

Хәзерге әдәби телебез төрки халыклар арасында зур үсеш алган телләрдән исәпләнә. Ул — халык теленнән кергән сүзләр, гыйбарәләр, тезмәләр исәбенә дә үскәннән-үсә бара. Телебездәге зур байлык — гасырлар буе тупланган сүз байлыгы телчеләребез тарафыннан төрле сүзлекләргә һаман теркәлә бара. Соңгы елларда чыккан «Татарча-русча сүзлек» (Мәскәү. 1966), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (Казан. 1969) әдәби телдә һәм халыкның җанлы сөйләм телендә кулланышта йөргән сүзләрне туплауда зур адым булдылар. Тиздән басылып чыгачак аңлатмалы сүзлек телебезнең байлыгын тагын да тулырак чагылдырыр.

Иге-чиге булмаган бу тел хәзинәсен җыеп бетерү бик кыен эш. Язучыларыбызның әсәрләрендә берниндн сүзлекләргә дә теркәлмәгән, әмма әдәби телгә кереп китә алырдай әллә никадәр сүзләр очратырга була. Алар халыкта киң кулланылышта йөриләр. Әдәби телдә бу төшенчәләрне белдерә торган сүзләр юклыгын яисә ул төшенчәләрнең берничә сүздән торган сүз тезмәсе рәвешендә, тасвирлама юл белән бирелүләрен исәпкә алсак, аларның кайберләрен әдәби телгә дә кертеп җибәрергә мөмкин булыр иде. Мәсәлән, Кыз чуерташ алды да аны ачу белән Ык өстенә **бәпчетеп** җибәрде. (Г. Мөхәммәтшин. Дулкыннар.) **Бәпчетү** сүзе юка ташны су өстеннән сикертеп җибәреп, йөгерек дулкыннар ясау мәгънәсендә кулланыла. Әдәби телдә бу сүзнең синонимы юк, бу төшенчәне белдерү өчен сүз дә юк. Шуны искә алсак, бу төшенчә, әлбәттә, сүзлекләрдә урын алыр дип уйларга нигез бар. Тагын берничә мисал китерик.

**Тупчын** кебек киенгән кешеләр әзрак баргач юл көенә ойыйлар. (А. Гыйләҗев. Зәй энҗеләре.) **Тупчын** сүзе кат-кат киенгән, түгәрәкләнеп беткән төшенчәсендә кулланыла. Матур сүз бит! Бу сүз шулай ук сүзлекләргә әле теркәлмәгән. **Болгавыр** сүзе дә буталчыклык төшенчәсен белдерү өчен бик тә кулай булыр иде, җитмәсә, ул әйтер өчен дә уңай, төшенчәне дә төгәл белдерә:

— Алай да ярый,— диде Идрис, алдында яткан кәгазьләргә күз төшереп,— минем мәшәкатьле, **болгавыр** көннәрем. (А. Гыйләҗев.)

Анның очлы башлы яңа кара ботинкасы астында калын **бакакыйлар** шытыр-шытыр изеләләр. (А. Гыйләҗев. Зәй энҗеләре.) Бака кабыгы, бака кашыгы диюгә караган-

да, бакакый сүзе аһәңлерәк тә, кыскарак та. Янсә менә тагын бер мисал: Малаекызы — һәммәсе бергә тау шуып, боз өстендә **кәшәтаяк** уйнап, бергә аунап үскән балалар. (Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек.) Урта диалектның аерым сөйләшләрендә **кәшәкәле уйнау** сүз тезмәсе дә актив. Бу сүзне хәтта хоккей сүзе урынына да кулланып булыр иде. Язучыларыбыз беркайда да теркәлмәгән яңа сүзләрне әдәби телгә күпләп алып киләләр. Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Г. Мөхәммәтшин, Г. Ахунов һ. б. теле моңа үрнәк була ала.

Мәсәлән, Менә юл өстенә ак битле, кара түшле **сиртмә койрык** килеп кунды. (И. Гази. Онытылмас еллар.) Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, яр буенда саргылт **тал пипиләре** өзделәр. (Н. Фәттах. Бала күңеле далада.) Мансур күзләрен **мөлтәйтеп** аңа бераз карап торды да, артка чигеп, караватка утырды. (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр.) Теге **быткычны** шул утыртып җибәрде бит. (А. Гыйләҗев. Зәй энҗеләре.) Урындык ясыйсы каенны ул әллә кайдагы ерак урманнан, түбән җирдә үскәне, **могылсызы** булсын дип, үзе сайлап алып кайтты. (Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек.) Гаҗәпкә каршы, чирәм өстенә кармакны бик сирәк ала торган кашык буе **чурагай** килеп төште. (Г. Мөхәммәтшин. Дулкыннар.)

Бу мисаллар әдәби тел сүзлекләренә дә, диалектологик сүзлекләргә дә теркәлмәгән. Алар арасында үзенең җыйнаклыгы, аһәңлелеге, төшенчәләрне төгәл белдерә алуы белән аерылып торганнары шактый күп. Без монда сүзлекләрнең берниндн төрендә дә теркәлмәгән, әмма әдәби телдә үзенә урын алырдай сүзләрнең кайберләренә генә тукталдык. Диалекталь лексиканың матур әдәбиятта кулланылышы үзе зур бер мәсьәлә булып тора[1].

Шул ук вакытта, әдәби телне баетам дип, халыктан теләсә кайсы сүзне әдәби телгә кертергә тырышу да җавапсызлык булыр иде. Мәсәлән, түбәндәге җөмләләрдәге аерым сүзләрнең әдәби телне баетулары шактый шикле. Караңгыда Исламның әле кулында, әле битендә **калтыранган** дымлы чәч бөртекләре тиеп китте (Н. Фәттах).— Без пассажирлар йөртмибез ич,— диде Илбарис, аны **дүндермәкче** булып (С. Сабиров). Төрлесе төрле **дәүмәлектәге** кылдый-былдый тәгәрмәчләр... (А. Гыйләҗев). Шөкер, ярый **берчәк** (Ш. Маннур).

Соңгы елларда әдәби телебез җанлы халык сөйләменнән кергән сүзләр исәбенә шактый баеды. Урта диалектның җайдак, әрфия, тәүге, тымызык, күләвек, тоҗым, аҗаган, кондырак кебек сүзләре аларны алып керүче әдипләр телендә генә түгел, башка тел осталарыбыз тарафыннан да яратып кулланыла.

Әдәби телебез халык теленнән аерым сүзләр алу белән генә чикләнми. Халык сөйләм теленең җанлылыгын, эмоциональлеген, йөгереклеген бирү өчен, әдәби телгә җанлы сөйләм әйләнмәләре дә килеп керә. Халык сөйләмендә үзеннән-үзе, табигый рәвештә, уйламыйча гына әйтелгән бу төзелмәләр, әлбәттә, әдәби телдә язучыларыбыз, шагыйрьләребез тарафыннан аңлы рәвештә кулланылалар. Мәсәлән, самолетлар гүләве бүтән уйлар уйлата. Күктә самолетлар... Алар югарыдан күбрәк күрәләр, күбрәк беләләр. **Куркынычын да, киләчәк матурлыкны да.** (Ә. Баянов. Яшьлегемне эзлим.) Сез бит, доктор, гаҗәеп эш эшләп ташладыгыз. **Газетага басып чыгарырлык.** (Г. Минский. Язның беренче көне.) Барыбер аның абыйсы Рәйсәне яратмаска тиеш. **Аның эше әләкчене.** (Р. Төхфәтуллин.)

Мондый төзелеш бары җанлы сөйләмдә генә туарга мөмкин. Сөйләм процессында кеше җөмләнең бөтен кисәкләрен дә төгәл, логик эзлекле, бик тәртипле итеп урнаштырып җиткерә алмый. Инде формалашып җиткән фразага сөйләүченең аңында онытылып калган, истән чыгып киткән кисәкләр килеп ялганалар, өстәләләр. Табигый сөйләмнең бу үзенчәлеге өстәлмә конструкцияләр барлыкка китерә. Тел белемендә аны парцелляция күренеше дип тә атаучылар бар.

Өстәлмә конструкцияләр телдә бүген генә тумаганнар, әлбәттә. Җанлы сөйләмнең бу үзенчәлеге халык иҗаты әсәрләрендә, татар халкының язма истәлекләрендә сакланып калган. «Йосыф вә Зөләйха»да (XIII йөз) мондый юллар бар:

**Бер хәбәши кол вар иде, Кылыч атлы.**

---

[1] Мәхмүтова Л. Т. Хәзерге татар әдәби теле һәм диалектлар. Татар теле һәм әдәбияты. 4 нче китап. Казан. 1969.

Монда, әлбәттә, ритм, рифма таләбе дә роль уйнаган булуы мөмкин. «Тәварихы Болгария» дә (XVII йөз) мондый алым еш кулланыла:

Вә дәхи ул атауда сычканнар вардыр, **мышыктан олу...**
Вә дәхи ул диңгездә нурдан кошлар вардыр, **киекә биңзәр...**
Вә дәхи ул диңгездә бакалар вардыр, **егерме карыш, биеклеге...**
Өстендә төкләре вардыр, ак мамык кеби...[1]

К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Коләхметов, Г. Камал, М. Фәйзи, Г. Ибраһимов, Ш. Камал әсәрләрендә өстәлмә конструкцияләр ара-тирә кулланылып килөләр, ә М. Гафури, Ф. Әмирхан иҗатында алар бөтенләй диярлек очрамыйлар. Эш, әлбәттә, һәр әдипнең индивидуаль стилендә. Салмаклык, эпиклык бу алым белән һич тә килешә алмас иде.

Олы буын әдипләребез Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Шамов, Г. Бәширов, Г. Гобәй әсәрләрендә өстәлмә конструкцияләрне куллану арта төшә. Кайбер язучылар, мәсәлән, Г. Әпсәләмов, С. Хәким, Ф. Хөсни, Х. Туфан һ. б. аларны аеруча яратып кулланалар.

Мәсәлән, Аннары без сөйләшеп утырдык. **Озак түгел.** (Ф. Хөсни. Язмыш шуклыгы.) Әйтергә көне килеп җитте дип уйлыйм. **Самый көне.** (Ф. Хөсни. Утызынчы ел.)

Менә, алла теләсә, совет кайткач, яңа өй сорарбыз. **Зурны, биекне...** (Г. Гобәй. Маякчы кызы.) Посттагы солдат мылтыгын кешегә бирергә тиеш түгел, аңладыңмы? **Иң зур командиргә да.** (Г. Гобәй. Каланча.) Бер көн эчендә атлы-туплы, йортлыҗирле булдың бит, Әбделхәй, ди. **Нәкъ әкияттәге шикелле.** (Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек.)

Хәзерге татар прозасында бу алым бик киң кулланыла. Өстәлмә конструкцияләр дип йөртелгән бу алым бик күп стилистик функцияләрне башкара ала. Ул юмор, ирония, сатира, комизм алымы буларак та, сөйләм телен, бигрәк тә балалар һәм картлар телен стилизацияләү алымы буларак та кулланыла. Мәсәлән, Т. Гыйззәт персонажларыннан берсе болай ди:

Колтау мулласы өстеннән дәгъва кылып йөргән өчен сыер хакын биреп җибәр...

Укучы яки тамашачы бу бай ничек итеп шундый яхшылыкка бара соң әле? дип уйларга өлгерми, бай тагын берничә сүз өстәп куя: **Камчы белән.** Үлгәнче онытмаслык булсын.

Яисә менә Ш. Маннурның «Муса» романында фашист майоры Краузе Җәлилгә ауга барырга тәкъдим ясый. Шунда мондый юллар бар:

Муса ауны яратмыймы соң? Үлеп китә инде ул ауда йөрер өчен! — Бусы чыннан да дөрес булгандыр. Әмма шул юллар янына иронияле тагын берничә сүз өстәлеп әйтелә: **Бигрәк тә майор Краузе белән.**

Телебездә аларның күпләп кулланыла башлавы Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» лирик повесте белән бәйле түгелме икән? Романтик шәхес авызыннан сөйләнә торган бу лирик монологта яңа интонация ишетелеп куйды. Шуннан соң ук Н. Фәттахның «Мөдир Саҗидә»се дөнья күрде. Монда да шәхес монологы. Монда да җөмләләрнең төзелеше нәкъ сөйләм телендәгечә. Шуннан соңгы әсәрләрдә бу конструкцияләрне бик күпләп очратырга була. Сөйләмнең җанлылыгы, табигыйлеге эчкерсезлеге Ә. Баяновның менә бу юлларында бигрәк тә ачык сизелә.

Яз көне, сары яфраклар, былтыргы үләннәр түшәген аралап, ямь-яшел үлән шыта... **Аксыл гына, көчсез генә...** Безнең икебезнең дә аерыласы килми. **Бер генә минутка да...** Кечкенәрәк күзләре дә очраклы түгел — **өлгергән иген кырын бизәп торган зәңгәр чәчәк төсле...** Алардан шундый тәмле ис килә, өлгергән иген исе... («Яшьлегемне эзлим».)

Кеше сөйләменең табигый интонациясен бирү өчен, сөйләмнең табигыйлеген күрсәтү өчен кулланылган сурәтләр бит болар! Кеше белән якын итеп сөйләшеп утырганда гына, үз «күңел хисләреңне аның алдына сибеп салганда» гына мөмкин булган интонация барлыкка килә.

Әйтелгәннәргә нисбәтән Сибгат ага Хәкимнең «Социалистик Татарстан» газетасының 4 ноябрь 1971 ел санында Әхсән Баянов иҗатына багышлап язган «Гел яктыга

[1] Мисаллар «Борынгы татар әдәбияты»ндагы (Казан. 1963.) текстлардан алынды. 109 бит, 458—59 битләр.

таба» мәкаләсенең беренче юлларын китереп китәсе килә: «Шигырьдән түгел, поэмалардан башлап китте Әхсән Баян. Ун ел элек, 1959—60 елларда. Ике буын уртасында... «Шәүкәт Галиевләр белән Равил Фәйзуллиннар буыны уртасында...» С. Хәкимнең язу алымындагы бу үзенчәлекне, ирексездән, Ә. Баяновның лирик повестеның стиле белән чагыштырып карыйсы килә башлый.

Әмма бер үк стилистик чараны күп тапкырлар куллану әсәрнең бераз түбән җибәрә, кайчак өтек-өтек җөмләләр ясалуга китерә.

Күренекле тел осталарыбыз тарафыннан бик сайлап кына, чамасын белеп кенә кулланылганда, бу алым бик күп төрле стилистик бизәкләр тудыра ала. Шунысы кызык: өстәлмә конструкцияләр проза телендә генә калмыйча, поэзия телендә дә күпләп үтеп керәләр. Мәсәлән, С. Хәким иҗатында ул аның индивидуаль стилен билгеләр дәрәҗәдә характерлы. Халыкның җанлы сөйләм телен сурәтләү өчен, авторның тирән кичерешләрен, уйлануларын сурәтләү өчен ул бик кулай:

**Түбәтәйдән, ләкин ялан аяк,**<br>**Чыбыркысы сүстән, кыл очлы.**<br>*(«Баһавиның моңы».)*

**Базарга күптәнге сукмактан**<br>**Икенче карт килә, оныклы.**<br>*(«Васыятьләр».)*

**Ир затына, беләм, күбрәк төшә**<br>**Семьяда һәм эштә... Судта да.**<br>*(«Әулия».)*

Бу турыда шагыйрь үзе дә болай яза: «Мин алдынгы татар поэзиясе һәм рус демократик поэзиясе традицияләрендә тәрбияләнгән шагыйрь. Халыкчан тел, сөйләү теле якын... Ничектер, халыкчан телдә гадилек белән хакыйкать, гражданлык хисләре әйбәтрәк кушыла. Мин шул традиция кешесе...»[1].

С. Хәкимнең бу алымны кулланып язуы аның индивидуаль стиль үзенчәлеген тудыруда зур роль уйный. Шагыйрьдәге киң күңеллелекне, тыйнаклыкны, олы җанлылыкны, зур гражданлык тойгысын күрсәтү алардан башка мөмкин булмас иде. Түбәндәге юлларда өстәлеп килгән кисәк нинди зур мәгънәви вазифа үти:

**Ярлар, ярлар, халык күңеле кебек,**<br>**Сез катлаулы, тордым оялып.**<br>**Җырларыма минем сездә урын**<br>**Табылыр микән! Тик бер оялык.**<br>*(«Ярлар, ярлар...»)*

Х. Туфан иҗатында да бу алым шактый актив кулланыла:

**Сөйләшәбез.**<br>**Сорыйм:**<br>**— Ә син кайдан!**<br>**— Усиядән... Ватык лодкадан.**<br>*(«Зәңгәр бүре».)*

**Әйдә, агай, чабатаңны сиплик,**<br>**Кичәгенәк**<br>**Без бит әйбәт юкә урладык,**<br>**Пешә юкә.**<br>*(«Ике чор арасында».)*

**— Сезнең бала!**<br>**— Әйе, безнеке,—**<br>**Безнең колхозныкы.**<br>**Әнә теге**<br>**Тәрәзәсе гөлле өйнеке.**<br>*(«Тәрәзәсе гөлле өйнеке».)*

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1969. 48 бит.

Х. Туфан иҗатында өстәлмә конструкцияләр персонаж теленең сөйләм үзенчәлеге бирү өчен хезмәт итсә, С. Хәкимдә ул лирик геройның кичерешләре, уй-фикерләренең эчкерсезлеген күрсәтү өчен кирәк.

Хәзерге татар поэзиясеннән яңадан-яңа үрнәкләр китерергә булыр иде. Соңгы еллар татар совет әдәбиятын күз алдыннан кичергәндә, бу алымның активлаша баруын күрергә була. Әдипләр аны тоеп алдылар, заман сулышына туры килердәй алым икәнен сизделәр. Халыкның җанлы сөйләм теле өчен иң характерлы булган бу алымны куллануның, әлбәттә, чамасы һәм чиге булырга тиеш. Югыйсә, бу төзелмәләр берсе икенчесе өстенә еш-еш кабатланып килеп, әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, эмоциональ тәэсир итү көчен киметергә мөмкин.

Без бер сорауга җавап бирергә тырышып карыйк: бу алымның хәзерге матур әдәбият телендә киң таралуының сәбәбе нәрсәдә соң? Әдәби тел шушы телдә сөйләшүче халык теле белән бик тыгыз бәйләнгән. Гомум халык телендәге үзгәрешләр әдәби телгә дә тәэсир итә, әмма ул әдәби телне баетучы иң зур чыганак буларак кала бирә.

Чорның катлаулылыгы, динамикасы, тормыштагы күп санлы үзгәрешләр, аларның бер-берсен бик тиз алыштырып килүләре авторның сөйләү манерасына да тәэсир итми калмый, билгеле. Тормышта хәзер салмаклыкка, монотонлыкка урын юк. Чор тизлеккә мохтаҗ, дулкынландыргыч вакыйгаларга бик бай. Менә шундый динамизмны бирү өчен язучы эзләнергә мәҗбүр. Аны элеккеге формалар канәгатьләндерми, яңа сулышны бирә алырдай башка, яңа формалар эзли һәм аларны халыкның җанлы сөйләм теленнән таба да. Җанлы сөйләм телендәге табигый бу чара автор сөйләменә, аның әсәренә килеп кергәч, билгеле бер стилистик максатлардан чыгып кулланыла башлый. Бу — яшьләр мавыгуы, мода гына түгелдер дип уйларга нигез бар, чөнки Ә. Еники, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, И. Гази һ. б. тел осталары аны чит күрмиләр.

Бу алымны шулай ук рус теленең тәэсире дип исәпләргә дә мөмкин түгел. Чөнки язма истәлекләрдә һәм бик күптәннән теркәлгән әкиятләрдә һ. б. аларны күпләп очратырга була. Димәк, өстәлмә конструкцияләр активлашуы телнең үз потенциаль мөмкинлекләре нигезендә булган икән.

Әдәби телебездә, һичшиксез, сөйләм теле белән бәйләнешле рәвештә активлашып бара торган тагын бер төзелеш турында да бернична сүз әйтеп китмичә булмый. Традицион синтаксиста аларга атау җөмләләр дигән исем бирелгән. Әмма үзеннән соң килгән җөмлә белән үзенчәлекле бәйләнүе аның башка төрле синтаксик төзелмә булуын дәлилли. Мәсәлән:

**Хыялның да бик җилкенгән, эзләнгән, очынган чагы!** Нәкъ менә **шушы чакларда** миңа курайны еш кына ишетергә туры килде. (Ә. Еники.) Ипи карточкасы... Ник аңа тия бу завхоз, ә? (М. Мәһдиев.)

**Агыйдел буйлары. Ямьле Агыйдел буйлары.**

Мин **аларның** ямансу матурлыгы, яшьлек белән генә чагыштырырга мөмкин булган гүзәллеге турында бер сүз дә әйтә алмыйм, чөнки ул сүздән файда юк. (Ә. Баянов.)

**Үсмер чакның татлы һәм тынгысыз, борчулы һәм ашкынулы** уй-хыяллары! Иге дә, чиге дә юк аларның. (Р. Төхфәтуллин.)

Бу — шагыйрьләрнең яраткан алымнарыннан берсе. Аларны С. Хәким бик яратып куллана.

**Ватан сугышы... аның** йөрәкләрдә җыелып килгән сагыш, моңнары шул көенчә. («Якын дуслар».)

**Дуслык юлы... Инеш кенәме ул!**
**Тап шулай да очын син аның.**
*(«Урләр аша».)*

**Нигезем... шул иске нигезне,**
**Син, шагыйрь, үлгәч тә кил эзләп.**
*(«Васыятьләр».)*

Х. Туфан, Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, З. Маликов һ. б. өчен дә бу алым ят түгел.

Бу алым теге яки бу предметны-төшенчәне күз алдына китереп бастырып, аны сурәтләү мөмкинлеген бирә. Шигъри сөйләмдә, прозаның эмоциональ төрендә әдипләр аны яратып кулланалар. Бу алымның нигезе табышмакларга барып тоташа кебек. Табышмакларда да бит башта ниндидер бер предмет, билге атала, күз алдына китереп бастырыла, шуннан соң гына аңа хас билгеләр әйтелә. Мәсәлән:

**Кечкенә генә таш пулат,**
**Эче тулы алтын да көмеш.**

**Тау башында җиз төймә,**
**Җиргә төшсә, җир көлә,**
**Суга төшсә, су кибә.**

**Биек-биек буралар,**
**Сандугачлар оялар,**
**Тышы хәрам, эче хәләл,**
**Ул ни булыр, муллалар!** [1]

Әдәби телебездә, матур әдәбият стилендә күзгә ташланган тагын бер үзенчәлекле әйләнмә бар — бу керетмә җөмләләр, яисә керетмәләр. Алар синтаксиста моңарчы кереш яисә аныклагыч җөмләләр дип йөртелгән җөмләләрдән структурмәгънәви һәм стилистик яктан бик нык аерылып торалар. Керетмәләр төп хикәяләү стиленә өстәмә мәгълүматлар өстиләр, сөйләү моментында искә төшкән мәгълүматларны белдерәләр. Алар бер дә икенчел дәрәҗәдә түгел, автор, аларны җөяләр эченә алып, аларга укучының игътибарын юнәлтмәкче була. Керетмәләрдә күп төрле мәгънәләр белдерелә ала: билгеле бер шәхес, предмет турында логик бәяләү, портрет, профессия, персонажның кул-йөз хәрәкәтләре, кешенең сөйләү үзенчәлеге һ. б. Мәсәлән: Шактый күп еллар узгач, мин үзебезнең радиокомитетта (**фронттан кайтып шунда эшли башлаган чагым**) бер курайчы белән таныштым. (Ә. Еники.)

Иртәгесен мин Кәүсәрияне алып кайттым (**теге врач кызның исеме шулай иде**). (И. Гази.)

Пианинода уйнаучы яңарак кына балалыктан чыккан нечкә билле (**андыйларны бездә шөпшә билле диләр**) оялчан бер кыз иде. (И. Гази.)

— Ник булмасын, бар иде, кеше күп иде,— дип, тизрәк әйтеп бирергә ашыктым. (Андый чакта җавапны кыска, ачык һәм атылган ук кебек тиз чыгарырга тиешлеген мин инде белә идем.) (Ф. Хөсни.)

Шулай авыл өстендәге биеклекне үз кулыбызда тотуның ләззәтен җитәрлек татыгач — **чаманы да белергә кирәк бит** — малайларга да өләшә башладык. (Р. Төхфәтуллин.)

Безнең күзәтүебезчә, мондый төр әйләнмәләр искә төшерү, хатирәләр планында язылган әсәрләрдә аеруча күп кулланыла. Әллә кая еракка китмичә, Ә. Еникинең «Без дә солдатлар идек» дигән әсәрен генә карап чыгыйк. («Казан утлары», 9 сан. 1972 ел.) Язучы, теге яки бу вакыйганы искә төшергәндә, юл уңаенда искәрмәләр бирә бара: «Шундыйлардан менә Хафиз Акшелов, Дурду Ходайбирдин (икесе дә казакълар), минем якташлардан Төхфәт абзый белән чуваш Емелькин — боларны инде чын солдатлар дияргә була... Шулай, кырык икенче елның кышында Баталино дигән станциядә торабыз (ул чагында әле мин ротада писарь булып утыра идем)... Ләкин соңгы ике-өч көн эчендә алар күренмәс булдылар, ахрысы, хатын бу хәтәр җирдән кызын тынычрак урынга алып киткәндер дип уйладым (чөнки безнең хуҗаның да аны, кит, торма монда, тиле, дип куганын ничектер ишетеп калган идем)...»

Мондый төзелешле әйләнмәләр шигырьләр теленә дә үтеп керә:

**Көлә-көлә кызлар атлап килә,**
**(Кызлар холкы көлү бит инде!)**
**Күзләрендә күрәм яшьлегемне,—**
**Яңа җырым туа шикелле.**

*(Фәния Чанышева.)*

---

[1] Татар халык табышмаклары. Җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. Казан. 1970.

**Урманнар, таулар үттем,**
**Энә буе җир киттем.**
**(Юк, әкият сөйләмим,**
**Алдарга да теләмим.)**
**Шул арада Европадан**
**Азиягә дә җиттем.**
(*И. Юзеев.*)

Рәдиф Гатауллин бу алымны шигырьнең структур-композицион билгесе буларак куллана:

**Безнең якларда яши ул.**
**Син ул кызны беләсеңме!!**
**«Юк» дисеңме!**
**Зур күзләрен бер дә күрмәдеңме! —**
**(Димәк, зәңгәр күкне аңлыйм димә!)**
**— Күрмәдеңме җилгә чәчен таратканын!**
**(Дулкын уйнаклавын күргәнем бар димә!)**
**— Буй-буй матроскадан иде — әллә**
**күзеңә чалынмады!**
**(Яшьлекнең давыл белән көрәшүен**
**күзәтмәдең, димәк!)**
**— Син белмисең аны!!**
**(Җирдә иң матур диңгезне беләм димә!)** [1]

Әлбәттә, без югарыда күрсәтелгән конструкцияләрне идеаллаштырудан ерак торабыз. Аларның әдәби әсәрләрдә күп кулланылуы күпмедер күләмдә әсәрнең таркаулыгы, эшкәртелеп җитмәве турында да сөйләмиме икән?! Әмма тел факты буларак, алар, һичшиксез, өйрәнүне сорыйлар. Сөйләм телендә аерым искәрмәләрне сөйләүче түбәнрәк интонация һәм кызурак темп белән әйтеп куя һәм бу искәрмәләр төп фраза эченә кереп урнашалар. Мондый калыплар әдәби әсәрләр теленә үтеп керәләр икән, димәк, юкка гына түгел. Әмма аларга объектив бәя һәм характеристика бирелергә тиеш.

Халык сөйләм теленең әдәби телгә тәэсире әйтелгәннәр белән генә чикләнми, билгеле. Әмма бер нәрсә ачык: әдәби тел чоры-чоры белән халык теленә мөрәҗәгать итеп, аннан заман таләбенә туры килерлек сурәтләү чаралары эзли. Әдипләр сөйләм теленнән төрле-төрле сурәтләү чаралары эзләп табып, үзләренең әсәрләре аша халыкка яңадан кире кайтарып бирәләр. Иҗат процессында бу сурәтләү алымнары, язучының осталыгына карап, төрлечә бизәкләр алып, үзгәрәләр. Әмма нихәтле генә үзгәрсәләр дә, җанлы сөйләм теленең үзенчәлекләрен үзләрендә саклыйлар.

---

[1] Р. Гатауллин. Кояшлы утраулар. Казан. 1967. 35 бит.

# СӘХНӘДӘ БҮГЕНГЕ КӨН ТЕМАСЫ

Тамашачының уй-хисләрен дөрес аңлаганда, аның рухи тормышын һәр даим баетырга тырышканда, узган көннәр героикасын, бүгенге тормыш матурлыгын, киләчәк көннәр яктылыгын сәхнә телендә дөрес итеп сөйли алганда гына бүгенге көн темасын дөрес чагылдырырга мөмкин.

Спектакльләрне өйрәнәләр, куялар. һәм, әлбәттә, вакытлар узу белән алар репертуардан төшеп кала. Ләкин һәрбер спектакль театр коллективы тормышында, режиссерлар һәм актерлар язмышында нинди дә эз калдыра, тамашачының театрга карата булган мөнәсәбәтенә азмыкүпме йогынты ясый, аның эстетик зәвыгын тәрбияли.

Иҗат коллективының нинди уй-тойгылар белән янып яшәвен белергә теләсәк, театр репертуарына күз салырга кирәк. Репертуар театрның бүгенге тормышка мөнәсәбәтен, коллективның иҗади мөмкинлекләрен, аның ни дәрәҗәдә өлгергәнлеген күрсәтә. Репертуар турында сүз барганда театр, беренче чиратта, бүгенге көн темасын күздә тотарга тиеш.

Драма әсәренең уңышлы яки уңышсыз булуы барыннан да элек авторның, кеше буларак, шәхес буларак, заманны ни дәрәҗәдә аңлавына бәйле. Минемчә, художник бүгенге тормыштан, чынбарлыктан халык өчен иң әһәмиятле вакыйгаларны сайлап ала белсә генә уңышка ирешә.

Безнең заман драматургтан кеше тормышын, көнкүрешебезне мөмкин кадәр киңрәк яктыртуны сорый.

Бүгенге драматургия фикер ягыннан тирәнәю, тематик яктан киңәю бәрабәренә үсәргә тиеш. Ләкин әле бүгенге көн вакыйгаларына мөрәҗәгать итү белән генә бу мөһим мәсьәләне хәл итеп булмый. Бүгенге көн темасына багышланган спектакльләр заманның иң мөһим күренешләрен чагылдырырга тиеш. Шул чакта гына театрның тәрбияви роле үсәчәк.

Г. Ахуновның «Чикләвек төше» повесте буенча эшләнгән һәм Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры куйган шул исемдәге спектакль бүгенге көн темасына багышланган. Театр әлеге әсәрнең фикерен, эчтәлеген бөтен тулылыгы белән тамашачыга җиткерә алганмы соң? Безне иң элек әнә шул сорау борчый һәм бу сорау, минемчә, бик урынлы. Чөнки инсценировка — театрдан күп көч, шуның белән бергә аеруча сак эш итүне сорый торган катлаулы жанр. Шулай бервакыт патша Николай Беренче Пушкинга «Борис Годунов» трагедиясен Вальтер Скотт романнары рухында үзгәртеп язарга киңәш итә. Ә Пушкин моңа каршы нәфрәтләнеп: «Трагедия булып туган әсәрдән һич тә роман ясап булмый»,— ди. Шулай булгач, без үз алдыбызга: «Роман я повесть формасында язылган проза әсәре сәхнәдә ничегрәк яңгырар?» дигән сорау куя алабыз лабаса. Бу, минемчә, шулай ук урынлы, әһәмиятле сорау. Ни өчен дигәндә, театрлар инсценировкаларга көннән-көн ешрак мөрәҗәгать итәләр. Бәлки моның сәбәбе яхшы проза әсәрләренең яхшы пьесаларга караганда күбрәк иҗат ителүендәдер. Хәер, ни генә булса да, инсценировкаларның театрларда зур шау-шу тудырган очраклары көннән-көн арта, инсценировканы кире кагучылар азая бара.

Сәхнә сәнгатенең магистраль юнәлешен билгели торган төп жанр драматургия булуы, әлбәттә, бәхәссез. Ләкин бүген, театр тормышының иң тирән катламнарына үтеп керергә омтылган дәвердә, репертуарның башка чыганаклар бәрабәренә баюын хупларга гына кирәк.

Проза әсәрләренең сәхнәдә яңа тормыш башлап җибәрү очраклары санап

бетергесез. Әйтик, «Чапаев», «Виринея», «Мятеж», «Бронепоезд 14-69»... Әле бүген дә үзләренең тәэсир итү көчен, актуальлеген җуймаган революцион рухтагы әнә шундый әсәрләр яшь совет театрларына героик романтика белән сугарылган традицияләр урнаштыруда зур булышлык күрсәттеләр.

Тик мәсьәләнең шул ягы да бар: роман яки повесть сәхнәдә күпмедер дәрәҗәдә югалтуларга дучар була. Гадәттә зур әсәрләрнең фикерләре, эчтәлекләре саега, характерлардагы кайбер үзенчәлекле сыйфатлар югала.

Инсценировка авторына һәр вакыт диярлек сәхнә законнары турында уйларга туры килә. Зур күләмле әсәрне бернничә сәгатьлек спектакльгә сыйдырып бетерү — һич тә мөмкин булмаган эш. Шуңа күрә инсценировка авторы да, театр да һәркайчан әсәрнең нинди өлешләрен, сюжетның кайсы сызыкларын сәхнә рамкаларына кертү турында бик ныгытып уйларга тиеш.

Әлбәттә, инсценировканың уңышлы яки уңышсыз булуында сәхнәләштерергә алынган әсәрнең заман таләпләренә ничегрәк җавап бирүе, аның идеясе зур роль уйный.

«Чикләвек төше» мисалында фикеребезгә ачыклык кертеп үтик.

Ил кайгысы өчен кайгырып, дәүләт эше өчен янып-көеп йөргән Халикъ Саматов белән мещан семьясында тәрбияләнгән Рокыяның дөньяга карашлары ике төрле. Шул карашларның бер-берсе белән бәрелешүе әсәрнең төп конфликтын тәшкил итә.

Тамашачы инде күптән сәхнәдә Халикъ Саматов кебек коммунист образын күрергә тели иде. Миңа калса, бу образ нәкъ менә бүгенге тормыштан, безнең әйләнәтирәбездән алып язылган. Халикъ Саматов һәр вакыт заман сулышын тоеп, партия күрсәткән юлдан читкә тайпылмыйча яши торган саф йөрәкле коммунист. «Чит кеше» спектаклендәге Алексей Чешков кебек үк, Халикъ Саматов та сәләтле оештыручы. Халикъ Саматов белән Алексей Чешков — Погодинның «Минем дустым» пьесасыннан Григорий Гай, Кочетковның «Бертуган Ершовлар»ыннан Дмитрий Ершов, Лаврентьевның «Әтиең мин синең» әсәреннән Трофим Кичигин эстафетасын дәвам иттерүчеләр.

Спектакльнең беренче ике пәрдәсе повесть стиленә тулысынча туры килә. Бу пәрдәләрдә конфликт кискен итеп, ышандырырлык итеп күрсәтелгән. Әмма өченче пәрдәдә без Халикъ Саматовның колхозчылар арасында булуын сурәтләгән конкрет вакыйгаларны күрмибез. Кешеләрне үз артыннан ияртеп бара торган сәләтле җитәкче Халикъ Саматов бу пәрдәдә характер буларак ничектер сүлпәнрәк чыккан. Сүз дә юк, артист И. Йомагулов үз ролен ышандырырлык итеп уйный. Беренче карашка актерның тышкы кыяфәте ничектер үзгәрешсез сыман, тик тамашачы һәр вакыт диярлек аның эчке тормыш белән янып-ялкынланып яшәвен сизеп, күреп утыра. Кыскасы, И. Йомагулов үзенең эчке кичерешләрен, уй-хисләрен тамашачыга җиткерә ала. Ә бу актер өчен, әлбәттә, бик мөһим сыйфат.

Спектакльдә иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе — мещанлыкның чын йөзен фаш итү. Без сәхнәдә мещанлыкның төрле формаларын күрәбез. Ул — дәүләт хисабына яшәргә тырышу, квартираны кирәксез әйберләр белән тутыру, үз профессияңә салкын карау, җәмгыять алдындагы бурычларны оныту кебек фактларда чагыла.

Татарстанның халык артисткасы М. Миңлебаева, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Г. Шамуков мещанлыкны артык көчәнмичә генә сатирик планда күрсәтәләр. Алар, үз рольләрен сәнгатьчә итеп башкару белән бергә, тискәре персонажларга хөкем дә чыгаралар. Ә тамашачының ихлас күңелдән көлүе әлеге хөкемнең дөрес булуын раслый.

Артистка Н. Ихсанова авыр язмышлы хатын-кыз образын иҗат иткән. Ул героиняның психологик халәтен дөрес аңлый, үзенең ролен оста башкара.

Спектакльдә аеруча әһәмиятле, истә кала торган күренешләрнең берсе — Саматовның Маркиз атавында Рокыядан сорау алу күренеше. Бу күренеш режиссерның зур казанышы дисәк тә хата булмастыр. Монда табигать үзе кешеләрнең саф күңелле булуларын таләп итә шикелле. «Киттек, Рокыя туташ,— ди Саматов күк күкрәү авазлары астында,— яшенле яңгыр булачак». Рокыя, ниндидер бер кискен карарга килгәндәй, алга талпынып куя. Аннары кыю гына: «Булсын»,— дип җавап бирә һәм Саматовка барып сыена. Яшен яшьни, күк күкри. Гүя табигать Рокыяга мещанлык тойгыларыннан арынырга, сафланырга булыша. Рокыя яшенле яңгырга каршы бара. Үзенең язмышын Саматов

белән бәйләргә тәвәккәлләве була бу аның.

Рим шагыйре Овидий «сәнгатьнең сәнгать икәнлеге сизелмәсен» дигән шикелләрәк фикер әйткән. РСФСРның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Ш. Биктимиров уйнавында без моның ачык мисалын күрәбез. Актер вакыт буенча артык зур булмаган эпизодта обком секретаре Саттаровның якты образын тудырган. Саттаров — кеше күңеленең бөтен нечкәлекләрен аңлый торган, эчкерсез, кешелекле җитәкче. Рокыяны мещанлык баткагыннан тартып алуда аның ярдәме аеруча зур була.

Тулаем алганда, режиссерлар Ә. Зарипов һәм Р. Хаҗиәхмәтов спектакльдә фәлсәфи проблемаларны да, әхлак мәсьәләләрен дә уңышлы хәл иткәннәр. Тыгызлыгы, психологик тирәнлеге, лирик буяуларның куелыгы, заман таләпләренә җавап бирә алуы белән «Чикләвек төше» күңелдә якты эз калдыра.

Әлбәттә, һәрбер иҗади эш кебек үк, бу спектакль дә кимчелекләрдән тулысынча азат түгел. Кайбер эпизодларда көнкүреш детальләренең кирәгеннән артык ишәеп китүе әнә шул хакта сөйли.

«Чикләвек төше» хакында әйтәсе килгән соңгы фикерем шул: бу очракта инсценировка жанрына мөрәҗәгать итеп, театр тамашачы өчен дә, үзе өчен дә отышлы һәм файдалы эш эшләгән; киләчәктә дә бу юнәлештә эзләнүләр дәвам иттерелсен иде.

Инде В. Качалов исемендәге зур драма театрының соңгы спектакльләреннән берсе «Саша Белова» (И. Дворецкий) турында берничә сүз.

Бу спектакль техник вузларда укучы студентларның, фәнни-тикшеренү учреждениеләре хезмәткәрләренең тормышын яктырта һәм кешенең җәмгыятьтә тоткан роле турында сөйли. Кешенең гармоник камиллеккә омтылуы җәмгыятьне дә үзгәртә, матурландыра. Без еш кына гармоник камиллекне ничектер берьяклырак аңлыйбыз. Янәсе, физик яктан сәламәт, белемле, югары эстетик зәвыкка ия булган кеше бөтен яктан камил була. Ләкин гармоник камиллек өчен болар гына җитми. Әлеге сыйфатларның барысына ия булып та күңелләре, җаннары белән мещан булып калган кешеләр юкмыни?..

Әлеге спектакльдә төп персонаж Саша Белова чын мәгънәсендә бөтен яктан килгән, ягъни гармоник камиллеккә ирешкән, укымышлы, акыллы, итагатьле, намуслы, эчкерсез кеше итеп бирелгән. Ул һәр минутта фән өчен, кеше бәхете өчен үзүзен корбан итәргә әзер. Аның бөтен уйлары ничек кенә булса да кешеләргә күбрәк файда китерү турында. Тик тормыш юлында Саша Беловага очраган кешеләр аны аңламыйлар, я булмаса аның эчкерсезлеген үзләренең шәхси максатлары өчен файдаланырга тырышалар.

Әлбәттә, Саша характерындагы күп кенә сыйфатлар гипербола дәрәҗәсенә җиткерелеп күпертелгән. Пьеса авторы һәм театр моны куелган проблеманың әһәмиятен тамашачыга бөтен тулылыгы белән җиткерү, аны уйландыру йөзеннән эшләгәннәр булса кирәк.

Саша Белова — катлаулы образ. Сәләтле актриса С. Кузьминаның бу образны тагын да камилрәк итү өчен байтак тырышасы бар әле. Чөнки кайчагында Сашаның саф күңеллелеге, эчкерсезлеге беркатлылык булып күренә башлый.

Әлегә спектакльдә киңлек, ритмик төгәллек җитенкерәми. һәм режиссер Н. Бабенкога бу хакта шактый уйланырга кирәк.

Безнең заман, замандаш темасы Казанның Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачы театрында куелган «Яз көне, 30 апрель» (А. Зак һәм И. Кузнецов) дигән спектакльдә дә ярыйсы ук тулы чагылыш тапты. Бу спектакль (режиссеры Л. Верзуб) Бөек Ватан сугышы тәмамланыр алдыннан булган героик вакыйгаларны яктырта, яшь совет сугышчыларының батырлыгына дан җырлый. «Яз көне, 30 апрель» — автор фикерен төкми-чәчми тамашачыга китереп җиткерүе, яшь буын өчен тәрбияви роле зур булуы белән кыйммәтле.

«Актер бүгенге кешеләрне дулкынландырган сорауларга җавап бирергә, үз чорының алдынгы кешесе булырга тиеш»,— дигән бөек режиссер К. Станиславский. Ул һәр вакыт фикер театрын, идея-художество позициясе ачык һәм төгәл театрны яклаган. Бүгенге тамашачының да өметләре һәм уйлары шундый театр турында.

**А. ШАПИРО,**
**Казан театр училищесы директоры.**

# ҖИЛКӘННӘР БИРЕШМӘС ӘЛЕ

Фәнис Яруллинның узган ел дөнья күргән «Җилкәннәр җилдә сынала» [1] исемле повесте яшәү өчен, тормышта үз урынын раслар өчен көрәшкән кеше язмышын сурәтләүгә багышланган.

Баштан ук искәртеп куйыйк: әсәр югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткән икән, ул инде гади тормыш материалыннан бер башка югары күтәрелгән дигән сүз. Шуның өчен дә без бу әсәрне Ф. Яруллинның гади автобиографиясе генә дип карый алмыйбыз. Фәнияр — әдәби образ, ул — язучының фантазиясе белән баетылган, үстерелгән, гомумиләштерелгән образ. Фәнияр, бәхетсезлеккә очрап, яшьли гарип кала, очраклы шул хәл аркасында гомер буе урын өстендә ятарга мәҗбүр була. Бу — аның физик хәле. Әмма образның рухи халәте, эчке хасияте тирән һәм кискен каршылыкларда бирелә, ягъни гомумиләштерелә. Мин моны тән һәм җан көрәше дип атар идем.

«Берәүләрне тормыш гомергә бер тапкыр сыный. Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыеп килгән гайрәтен, ана сөте белән кереп тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкларны бер селтәнүдә юкка чыгара, шул мизгелдә каушап калмаганнарны батыр диләр. Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный...»

Әсәрнең үзәге, фокуска җыелган нурлар төенләнеше нәкъ менә шушы сүзләрдә. Фәниярнең алдагы тормышына күз салыйк. Укчы-радистлар мәктәбе, очучы булырга хыяллану. Беренче тапкыр парашюттан сикергән көн. Егетнең канатлы хисләре:

«Шунда ул үзенең бары тик очар өчен генә яратылуын, моңарчы яшәгән егерме еллык гомеренең шушы очыш өчен хәзерлек икәнлеген аңлады, үзеңне тапкан көн — кеше гомерендә иң бәхетле көннәрнең берсе буладыр...»

Фәниярнең олы максаты бар, ул очарга, очучы булырга тели. Моның өчен исә физик яктан нык, сәламәт кеше булырга кирәк. Спортзалда Фәнияр ялгызы гына, турникта ул авыр гимнастик күнегүләр башкара, «кояш» ясый. Бер, ике әйләнә. Кыюланып, куанып тагын, тагын һәм... очар күгеннән егылып төшә егет... Шул кадәр очраклы, көтелмәгән һәлакәт бит бу. Әгәр берәр батырлык эшләгәндә Фәнияр шушы хәлгә дучар булса, үзен юата, аклый алыр иде. Фәнияр Островский язмышын күз алдына китерә. һәм тарихта якты исемен калдырган бөек шәхес алдында үзен бик кечкенә итеп тоя. Сызлана, ачына.

Башта ул терелермен дигән тирән өмет белән яши, әмма өметләре акланмый — ул беркайчан да аякка баса алмаячак икән. Бу аның беренче мәхәббәте Фәүрияне дә тетрәндереп ала. Калын китапларны ахырына кадәр укып чыгарга да түземе җитмәгән, бераз җилбәзәк, язмышның мондый борылышларына түзәргә әзерләнмәгән кыз берьюлы югалып кала. Фәниярне больницадан алып кайткан вакытта, Фәүрия станцияләрнең берсендә поездан төшеп кала. Әйтмичә, сиздермичә генә. Ул әнә эшләгән җиренә —

[1] Ф. Яруллин. Җилкәннәр җилдә сынала. Повесть һәм хикәяләр. Казан, 1973 ел.

Фәниярнең туган авылына да кайтып тормый, читенсенә, документларын хат аша гына соратып ала. Бу адымы өчен ул үз-үзен кичерерме? Намус хөкеме аны гомер буе эзәрлекләмәсме? Язучы Фәүрияне гаепләми. Аны хөкем итүне ул укучы ихтыярына калдыра.

Фәнияр алдында яңадан-яңа кыенлыклар туа тора. Автор герой күңелендә барган көрәш-каршылыкларны гаять эзлекле, нечкә итеп сурәтләп килә. Куллары-ның хәрәкәтләнә башлавы, зур тырышлык белән яңадан язарга өйрәнүе... Бу, әлбәттә, физик күнегүләрнең нәтиҗәсе генә түгел, ә ышанычы, көчле омтылыш, ихтыяр көче бәрабәренә яуланган җиңү!

Фәниярнең үзен башкаларга кирәкле кеше итеп күрәсе килә, аңарда шул теләгән тормышка ашыру омтылышы көчәя. Ул үз теләгенә ирешә дә. Әйе, ул ялгыз түгел. Фәнияр чын йөрәктән ярдәм кулы сузарга әзер торучы гади кешеләр арасында. Үзенә дә әйтеп тормыйча, Фәниярнең беренче шигырьләрен район газетасында чыгарган, шәфкать туташы Нәсимә, искиткеч олы җанлы һәм туры сүзле шагыйрь Илдус Гаделшин, рус теле укытучысы Мария Викторовна, мәктәп укучылары совет кешеләренең туганлыклы матур сыйфатларын ачыклыйлар. Җәмгыятьнең гуманистик чынбарлыгы әнә шулар йөзендә чагыла.

Язучы тарафыннан яратылып, кадерләп сурәтләнгән иң мөлаем кешеләрнең берсе — ана образы.

«Аналарның бөтен мәхәббәте, бөтен җылысы ярдәмгә мохтаҗ балаларына тиючән. Язмыш ныграк кыерсыткан саен, әнкәсенең якынлыгын күбрәк тоя ул. Ананы дөньяда һични алыштыра алмый, ул — кешелекне тотып торучы алтын багана...»

Гөлсәйдә түти олы кайгыны ирләрчә сабырлык белән каршылый. Ул һәр вакыт Фәнияр янында. Аны терелтү, тәрбияләү өчен бөтенесен эшләргә әзер. Әйтергә генә ансат: урта мәктәп, ВУЗ бетерү, беренче шигырьләр җыентыгын чыгару өчен, күпме әзерлек, йокысыз төннәр, физик киеренкелек аша үткән Фәнияр. Ана — боларның шаһите, ярдәмчесе.

Гөлсәйдә образын язучы конкрет тормыш җирлегендә, кечкенә генә детальләр аша типиклаштыра.

«Купега билетлар беткән иде. Фәүрия:
— Гөлсәйдә түти, купега билет юк икән, общийга булса да ярыймы? — дип сорады.

— Купе дигәне тизрәк барамыни, кызым? — диде Гөлсәйдә».

Ерак җирләргә чыгып йөрмәгән беркатлы татар хатынының самимилеген шушы бер диалог ачып бирә.

Больницада улын саклап тәмам йончыган ананы эшче кызлар үзләренең тулай торакларына алып кайтырга булалар. Анда исә тәртип бик коры. Чит кешене алып керү мөмкин дә түгел. Шулай да, кызлар бик кыстагач, ул риза була, кайта. Иртән, кызлар эшкә киткәч, комендант килеп керә.

«— Сез бу кызларның кайсысына әни буласыз соң?

— Эһем, эһем... Ләбибә минем кыз,— ди ана аптырап кына.

— Үзем дә шулайдыр дип уйлаган идем,— ди комендант,— күзләрегез, кашларыгыз охшаган. Юлда килгәндә бик алҗытмадымы соң?

— Юк,— диде Гөлсәйдә,— самолет бик уңай нәрсә бит ул...

— Сезгә шулай самолет та оча башладымыни? — диде комендант.

— Рәхмәт төшкере, авылга самолет җибәргәннәр, икебезне тиң утыртып апкитте,— диде Гөлсәйдә, кем белән сөйләшүен онытып.

— Ничек икегезгә? Кем белән килдегез соң сез?

Ана үзенең ялгышлык җибәрүен аңлап алды, ләкин хатаны төзәтү чарасын белмәде».

Шушы мәкерсез ялганны ерып чыгарга да җөрьәт итә алмаган Гөлсәйдә түти гомер буе изгелеккә табынган, тыйнак, эчкерсез авыл хатыны булып күз алдына килеп баса, аңа ышанасың, аны ярата башлыйсың.

Фәниярнең бер канаты әнисе Гөлсәйдә булса, икенче канаты — Илсөя. Фәнияр янына килеп йөрүче, шигырьләрен яратып укып баручы эшче кызларның берсе. Фәнияр хәрби хезмәткә киткәндә военкомат янында очрашкан да булганнар икән. Аннан соң инде күп вакыт үткән, еллар икесен дә нык үзгәрткән.

Төскә-биткә чибәр, җор телле, эрудициясе, үзенең яхшы мөгамәләсе белән авыру икәнен дә онытгыра ала торган Фәниярга кызның йөрәгендә якынлык, мәхәббәт хисе уянуы ышандыра. Юк, бу һич тә кызгану аша туганярату түгел,

Фәнияр кызганудан өстен. Ул үзен беркемнән дә ким санамый. Ф. Яруллин үз героеның мәхәббәткә, сөелүгә лаек икәнен, хакы барлыгын кыю рәвештә яклый, дәлилли.

Илсөянең югары хисләре каршылыклар аша җитлегә. Аның күңел диалектикасын язучы сак һәм тормышчан итеп ачкан. Илсөя шагыйрьнең киләчәк иҗаты өчен таяныч, терәк булуын, аны назлау, рухын күтәрү өчен кирәклеген тоя, аңлый. Әсәрнең эчке конфликты шушында чишелә. Илсөя белән Фәнияр арасын кешелекле, физик һәм материаль мөнәсәбәтләрдән өстен булган рухи, изге мәхәббәт бәйли.

Фәнис Яруллинның бу повесте яктылыгы, оптимистик рухы белән яшәргә димли, матурлыкка, ныклылыкка өнди. Әсәрнең тел тукымасында шагыйрь җаны сизелеп тора, Фәнискә генә хас ачышлар, бизәкләр, кабатланмас чагыштырулар күп очрый. Стиль үзенчәлегенә дә игътибар итми мөмкин түгел. Язучы бер вакыйганы күчемле икенче вакыйга белән янәшә куя, фәлсәфи уйлануга корылган янсә кыска эчтәлекле хәл белән беренче вакыйганы ачыклый. Ачыкламаса, тел төбен яшерә, укучыга уйланырга, бәя бирергә урын калдыра.

Дөрес, дөньяда һәр яктан килгән, бөтен җире камил эшләнгән әсәрләр сирәк очрый. Кимчелекләр «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда да бар. Кай урында Фәниярнең уйлану-фикер йөртүләре публицистик риторикага әйләнеп китә. Алгы планга язучы калкып чыга. Әсәрнең соңы да кискен аккорд белән тәмамланмаган кебек.

Китапка, повестьтан тыш, кыска хикәяләр кертелгән. «Тарту көче» дип исемләнгән хикәягә киңрәк тукталып үтик.

Солдат радиодан җыр ишетә, җырчының моңлы тавышы аның хисләрен кузгатып җибәрә. Егет тавышка гашыйк була. Ул җырчының адресын, фамилиясен белеп ала. Тик менә исеменең баш хәрефе генә хәтердә калган икән. Егет хат язып сала. Хат авылда нәкъ шундый ук фамилияле икенче бер кызга эләгә. һәм ул солдат белән үзе язышa башлый. Була торган хәл.

Бервакыт егет армиядән кайта. Очрашалар. Егет кызны, кыз егетне охшата. Ләкин... клубка чыгарга җыенып торганда гына, кечке тынлыкны ярып, урамнан әлеге җыр, моңлы тавыш яңгырап китә. Икесе дә тын калалар. Кыз үзенең ялганын ачып сала. Әлбәттә, ул аны барыбер яшереп калмас иде, бер әйтер иде. Шик юк, бу психологик моментта егетнең кызга карата вакытлы гына булса да күңеле төшәр иде, хикәядә язылганча чыгып та китәр иде. Әмма укучы күңелендә, теләгәндә кире борылып килер иде. Язучы бу юлны бикләп куя. Автор хикәянең азагын тормыш логикасына туры килмәгәнчә чишә шикелле.

« — Мин сине яраттым, Вилсур,— диде Иркә.

— Мин дә,— диде Вилсур,— ләкин мәхәбббәт ялган белән башланырга тиеш түгел. Ул изге нәрсә, хуш!»

Ялганның объектив нәтиҗәсе матур бит, нигә кызга бу кадәр кискен гаеп ташларга?

Язучы хикәяләрендә тематиканы төрләндерергә омтыла. Бүгенге хезмәт кешесе, яшьләрнең үзара мөнәсәбәте. Сугыштан соңгы балалар дөньясы. Ләкин аерым хикәяләренә тирәнлек, психологик төгәллек җитенкерәми. Тышкы хәрәкәткә буйсындырылган тормыш фактлы өстенлек итә. Фәнискә йөгерек тел белән күзгә чалынмастай «яфрак асты» детальләрен шигъриләштереп, кечкенә вакыйганы таркатып, калку итеп бирә белү хас. Уңышлы хикәяләре шуның белән җылы тойгы тудыралар, шуның белән укучыны җәлеп итәләр.

«Җилкәннәр җилдә сынала» китабы Фәнис Яруллинның сыналу чорында тагын бер адымын, күтәрелешен раслый. Укучылар аны яратып кабул итәрләр дип ышанабыз.

**Марсель ГАЛИЕВ,**
**Казан дәүләт университеты студенты.**

# УЧАК УРЫННАРЫ

Үткәннең ачысын,
Үткәннең кайгысын
Исенә төшереп,
Яхшыдан яхшыга,
Яктыдан яктыга
Атласын кешелек.

Китап киштәләрендә Мөдәррис Әгъләмовның яңа шигырь җыентыгы урын алды: «Учак урыннары»[1]. Ничектер, исеме үк үзенә җәлеп итә һәм аны кулына алган мизгелдән башлап укучы уйланырга мәҗбүр. «Учак урыннары». Укучы күңелен әзер учак урыны итеп, шигырьләре белән анда ялкын дөрләтмәкчеме шагыйрь? Әллә инде кайчандыр ялкынланып, хәзер салкын көле генә калган учак урыннары аның үз күңелен кузгаткanмы? Күңел тизрәк җыентыкка исем биргән әлеге шигырьне эзли.

Бер караганда, шигырьдә гап-гади учак урыннары хакында сүз бара кебек. Көз. Лирик герой болында йөри. Көзнең соңгы гүзәллеге белән саубуллашу теләге дә, мәхәббәт газаплары кебек нечкә хисләр дә алып килмәгән аны бирегә. Атларын эзләп йөри герой. Көне дә гади хезмәт көне. Тирә-якта көтүчеләрме, балыкчылармы яккан учаклар...

Ләкин, учак дигәч тә, ялкынланып, дөрләп янып торган учаклар түгел. Сүнгәннәренә әллә ни гомердер инде: көлләрен, уйнаклап, шаян җил еракларга очереп бетергән — такыр урыннары гына торып калган. Шагыйрьнең уйлары еракта. Бу учак урыннары аңа «ләхете иңеп төшкән кабер»ләрне, Болгар һәм Суарны, Орадур һәм Сонгмины хәтерләтә. Шушы урында шагыйрь күңелләрне тетрәтерлек ачыш ясый.

Учак урынына
Тишелмәгән курпы,—
Минем яшь йөрәгем
Урыныннан купты:
Тишелмәгән курпы, тишелмәгән курпы...

Учак урыннары... Орадур һәм Сонгми... Шигырьнең соңгы юллары ләгънәт, рәнҗү, каргыш һәм кинәт ясалган куркыныч ачыштан туган шомлы аваз булып яңгырый. Орадурларның, Хатыньнарның ярасы сызлаудан туктамаган, Сонгми дигән авыр җәрәхәт ясалды кешелеккә. Әледән-әле кабатланып торган шундый учаклар әрнетә шагыйрь йөрәген. Алгарак китеп булса да, шуны әйтү кирәк: Тукайлар кабызган учакларның һаман көчәя баруына да ишарә ясый бу шигъри исем.

Кулыбызда Мөдәррис Әгъләмовның икенче шигырь җыентыгы, анда шагыйрьнең сигез еллык иҗат җимеше. Шагыйрь өчен сигез ел аз вакыт түгел. Димәк, безгә хәзер «Учак урыннары» авторының шагыйрь буларак үсеш юлы турында фикер йөртергә дә мөмкинлек туа. Иҗатының нинди сыйфатлары, нинди үзенчәлекләре Мөдәррисне Мөдәррис итә соң? Аны тормышның нинди мәсьәләләре борчый?

Күп нәрсә борчый шагыйрь җанын.

Төн йокыларын калдырып, күңелен тынгысызлап, кан тамырлары буйлап бер сорау йөгерә:

Карадыңмы үткән көнгә,
Лаекмы син бүгенгегә?

Юктан гына мондый сорау куймый шагыйрь үзалдына, чөнки чоры шундый, «чаганнар түгел, заманнар аягүрә» баскан дәвер. Шунлыктан шагыйрь үзе яшәгән төбәк белән генә чикләнми, тагын да тегәлрәк итеп әйтсәк, үз казанында гына кайнамый — аны ил язмышы, халык язмышы, дөнья язмышы ут йотарга мәҗбүр итә.

Шагыйрь Урал тауларында йөри, аның урманнарында үз эзен калдыра. Тик туган ягын, туган халкын бер даим дә истән чыгармый. Вакытлыча ул калдырып киткән яклардан искән җил дә, ул тарафтан килгән яңгыр да бик якын аңарга. Бәлки бу яңгыр тамчылары монда Идел, Кама, Ык суларыннан күчкәндер... Таш кыя өстендә тамыр җибәргән имән дә күңелен

[1] М. Әгъләмов. Учак урыннары. Шигырьләр. Казан. 1973 ел.

кузгата аның фәлсәфи уйлануларга этәрә.

— Шагыйрьнең көче гомумиләштерүдә,— ди җыентыкка язган сүз башында Сибгат ага Хәким. Мөдәрриснең җыентыкка кертелгән һәр шигыре Сибгат аганың фикерен раслый.

Көтүче җырлый. Уралдан да кадерлерәк җир юк аның өчен.

Көтүче җырлый...
— Уралым, Уралым...
Иң матур җиредер
Син бу дөньяның.

Ләкин матурлыктан гына тормый шул дөнья. Бәхет бар, бәхетсезлек бар, шатлык бар, кайгы бар, тынычлык бар, сугыш дигән афәт бар җирдә — аны үзләренең лозунгысы иткән бәндәләр бар җирдә.

Тауларның да үзәгенә үтә сугыш...

Көтүче җырлый. Һәр туган яңа көнне сугыш белән башларга хыялланучы бурзайлар бар җир йөзендә. Шуңа күрә дә күпме ачы нәфрәт аның тавышында, нихәтле моң. Бу инде бер көтүче авазы гына түгел, меңнәр, миллионнар хоры. Шуларны уйлап тынгылык таба алмый шагыйрь йөрәге.

Җыентыкта шигырьләр хронология тәртибендә урнаштырылган. Әлбәттә, без авторның теге яки бу елларда язылган барлык шигырьләре дә монда кертелгәндер дигән фикердән ерак торабыз. Шагыйрь иҗатын айсберг белән чагыштыру ни дәрәҗәдә төгәлдер, ләкин шул рәвешле чагыштыра калганда, җыентык — айсбергның судан калыккан өлеше генә. Шулай да ул Мөдәрриснең шагыйрь буларак үсешен күзалларга мөмкинлек бирә.

Шагыйрь үсә, һаман саен югарырак күтәрелә — офыклар киңәя төшә. Әлегә чаклы үзен зәгыйфьрәк сиздергән тема Мөдәррис иҗатында үзәк темага әверелә. Бу — халыклар язмышы темасы. Мөдәррис үзен үз халкы — татар халкы язмышы белән ныграк бәйли һәм гомум кешелекнең үткәне, киләчәге турында уйлана.

... Үз халкының киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен;
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара!

«Халкының киләчәген, үткәнен, бүгенгесен» һәм «кайгысының, шатлыгының зурлыгын» шигъри тасвирлауга алыну иҗади кыюлык һәм көч сорый, әлбәттә. Әмма шагыйрь инде җитәрлек тәҗрибә туплаган, иң әһәмиятлесе, эзләнергә иренми, уйлана белә — еллар катламы аша халкыбызның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә карый ала. Мөдәрриснең бер нәрсәдә иманы нык: халкының тарихи үткәнен онытырга мөмкин түгел, шуннан башка бүгенгесен (киләчәк турында әйткән дә юк) аңлап булмаячак.

Шагыйрь үзе үсә барган саен, лирик герой да үсә, җанлана — укучы алдында әле бер, әле икенче ягы белән ачыла төшә. Шуңа күрә шигырьләрдә я «мин» дип, я «без» дип бирелгән ул затка торган саен ышанасың, аның белән киңәшәсе, уй-хисләреңне уртаклашасы килү теләге һаман көчәя. Алай гына да түгел, алга таба укый барган саен, лирик геройның характеры катлаулана, аны характерлый торган сыйфатлар тирәнәя. Мөдәррисне кабат-кабат укыйсы килүнең серен шуның белән аңлатырга мөмкин.

Мөдәрриснең лирик герое — бөтен барлыгы белән җир кешесе. Аның уйлары җирдән, кешеләрдән аерылмаган. Ни генә күрмәсен, кайда гына булмасын, гел шул хакта уйлана ул.

Һәр шагыйрь, әгәр ул чын шагыйрь икән, традицияләрне дәвам итә. Мөдәррис эстафета таягын Тукайлардан, Такташлардан, Туфаннардан алган. Ләкин барыннан да элек, минемчә, Дәрдмәндкә якын ул. Рухы белән якын, стиле белән якын. Билгеле, берәү дә Дәрдмәнд һәм Мөдәррис арасында тигезлек билгесе куярга җыенмый. Сүз ул турыда бармый. Шагыйрьләрнең бер төре поэтик чаралар ярдәмендә сурәт, күренеш тудыра. Шуның аша үзен чолгаган мохитка мөнәсәбәтен белдерә. Мөдәррис турында моны әйтеп булмый. Ни турында гына язмасын — табигатьме ул, мәхәббәтме, батырлыкмы, я булмаса ана турындамы — шагыйрь фикер әйтә һәм һәрнәрсәгә үз мөнәсәбәтен белдерә. Татар әдәбияты тарихында андый үрнәк бирүче шагыйрьләр бар. Шуларның берсе — Дәрдмәнд. Ләкин Мөдәррис Әгъләмов, уйлана белү белән бергә, Дәрдмәндтән сагыш, хәсрәт, моңны да кабул иткән. Җыентыкта мондый юллар бар:

Сагышларны күбрәк йөртә,
Күбрәк саклый картлар җаны.

Бит шагыйребез әлегә өченче дистәне дә ваклап бетерергә өлгермәгән. Шуңа да карамастан, Мөдәррис моң, сагыш, моңсулык, хәсрәт кебек сүзләрне шактый күп куллана.

Үзәннәрдә чәчәк бәйрәмнәре,
Йөрәгемдә сагыш бәйләмнәре.
Офыклардан ары бу киңлекләр,
Бу киңлекләр — безнең мөмкинлекләр.
Тамырларда яшь кан сулык-сулык,
Күкрәгемдә сәер бер моңсулык.

Бу килеш шагыйрь сабый чырайлы аксакалны хәтерләтә. Дәрдмәндтәге сагыш, өметсезлек аның социаль хәле белән аңлатыла. Ул башкача яза да алмас иде. Ә ни өчен Мөдәррис йөрәгендә «сагыш бәйләмнәре», күкрәгендә «сәер бер моңсулык?..»

Шагыйрь — үзе яшәгән заманның елъязмачысы ул. Берни дә аның игътибарыннан читтә кала алмый. Мөдәррискә килсәк, аның иҗатында заман сулышы азрак сизелә. Ә бит шагыйрьнең сигез еллык хезмәте бу җыентык. Сигез ел эчендә безнең илебездә һәркайсы тарих битенә җуелмас сүзләр белән язылырлык нинди генә вакыйгалар булып үтмәде. Ә дөнья күләмендә? Аларның берсе дә шагыйрь йөрәген кузгата алмаганмы икәнни? Кирәк иде. Кирәк иде генә түгел, шуннан башка шагыйрь шагыйрьлеген югалта.

Мөдәррис иҗаты сагыш, моң белән генә чикләнә дип, аның башка шигырьләренә күз йому, әлбәттә, гаделлек булмас иде. Чын мәгънәсендә оптимизм бөркелеп торган шигырьләре дә байтак аның. Сүзне озакка сузмый, «Студент кунагы» дигән шаян шигырен үрнәккә китерү дә җитә.

Сүз сәнгате нечкәлекләрен белеп эш итү — Мөдәрриснең иң зур уңышларыннан берсе. Шагыйрьнең әдәби теле йөгерек, һәр сүзе үз урынында. Кулына кәгазь-каләм алганчы ук туган булалар, күрәсең, шигъри юллар.

Дулкыннарны тимер чылбыр
Ыргыта телеп-телеп;
Башыңны комга салырсың
Бәйләнгән көймә кебек,
Сагындырганда ирек.

Күрәсез: искитәрлек катлаулы тасвир чаралары юк монда — барысы да көндәлек тормышта кулланыла торган иң гади сүзләр. Ләкин Мөдәррис каләме аларны берсе артыннан берсен бик белеп кенә тезеп куйган, нәтиҗәдә музыкаль яңгыраш, Мөдәррисчә яңгыраш барлыкка килгән. Мөдәррис көндәлек сүзләр белән тирән фикер әйтергә омтыла, баш әйләндергеч чагыштырулар эзләп газапланмый. Шуңадыр, күрәсең, аның шигъри теле гаҗәеп матур, ювелир төгәллеге белән «шомартылган». Дөрес, аңарда да:

Ләкмәсә дә майлы каз ботлары,
Егет кеше ләкте аягы...
Качып-посып кызлар күзләгәндә
Ләккәләде картлар таягы...

кебек юллар очраштыргалый, ләкин сирәк.

Мөдәррис — эпиграфлар остасы. Эпиграфның эчтәлек ачудагы роле турында сөйләп тормастан, шуны әйтергә кирәк: аларны ул башка шагыйрьләр әсәрләреннән эзләп интекми, я халык җырларыннан ала, я булмаса, үзе иҗат итә. Үз иҗаты булган эпиграфларда да халык авыз иҗаты әсәрләренә хас җыйнаклык, үткенлек, тирән фәлсәфә ярылып ята.

Тауларның да үзәгенә үтә сугыш,
Бары тарих өчен генә бетә сугыш.
Ничә буын килеп китә, белеп китә,
Бары алар белән бергә китә сугыш.

Яки:

Сабан туйларда да алга карый халык,
Көрәштерә башлый нәнилардән алып.

Болар комментарий таләп итмиләр кебек. Гадәттә, 2—4 юл белән чикләнгән бу эпиграфларны һич икеләнмичә мөстәкыйль әсәр итеп кабул итәргә мөмкин. Ләкин шигырьләр алардан башка төссезләнә төшәрләр иде. Беренче карашка шигырьнең эчтәлеге белән әллә ни бәйләнештә булмаган кебек күренсәләр дә, шигырьнең тәэсир көчен бермә-бер арттыручылар — шулар. Шуннан башка Мөдәррис Мөдәррис булмас иде.

Шагыйрь юлда.

Бер-бер артлы артта кала
Баганалар...
Баганалар...

Шагыйрьгә инде егерме сигез яшь, аңа нибары егерме сигез яшь... Алда тынгысыз эзләнүләр, иҗат газаплары һәм шигъри ачышлар көтә шагыйрьне.

**Әмир ДӘМИНОВ.**

# САМАТ ШАКИРГА 50 ЯШЬ

## ҺАМАН ДА ТЫНГЫСЫЗ

**«Зөбәрҗәт», «Бормалы сукмак», «Өченче очрашу», «Чәчәкләр сөйләшә» кебек җылы хис белән сугарылган дистәләрчә шигырь китаплары авторы Самат Шакир 1924 елның 15 апрелендә дөньяга килә. Аның туган җире — Арча районының Күәм авылы.**

**С. Шакир Арча педагогия училищесында читтән торып белем ала.**

**1943—1945 елларда хәрәкәттәге армиядә хезмәт итә. Сугыштан соң район газеталарында эшли, мәктәпләрдә балалар укыта. Читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый. Берничә ел Татарстан китап нәшриятында редактор була.**

**С. Шакир төрле рухтагы, төрле характердагы шигырьләр язу белән беррәттән балалар әдәбияты һәм публицистика өлкәсендә дә актив эшли. Бөек Ватан сугышыннан кайта алмаган язучыларның иҗатын өйрәнә, аларның тормышы һәм иҗаты хакында очерклар яза.**

**С. Шакирның «Легенда егетләре» дигән повесте Сталинград сугышы каһарманнарына дан җырлый, төрле милләт вәкилләренең фашист илбасарларына каршы аяусыз көрәше турында художестволы итеп сөйли. «Үлемсезлек», «Солдат хатлары» кебек китаплар шулай ук Бөек Ватан сугышы геройлары хакында. «Сугыш елъязмасы» әсәрендә фронтовик-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең үлемсез батырлыгы тасвирлана.**

**Тынгысыз шагыйрь, язучы Самат Шакирга шушы язда 50 яшь тулды. Ул бүген дә янып, ялкынланып яши. Ерак җирләргә, дәһшәтле сугыш булган урыннарга сәфәр чыга. Яңа геройлар эзләп таба. Алар турында дулкынландыргыч әсәрләр иҗат итә.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Татарстан язучыларының февраль аенда үткәрелгән партия җыелышында төп сүз тәрҗемәче хезмәте, тәрҗемә (проза) әсәрләре һәм аларның сыйфаты хакында иде.

Башка телләрдән татарчага тәрҗемә итү буенча доклад белән тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе Кыям Миңлебаев чыкты. Ул тәрҗемә әсәрләренең сыйфаты елданел яхшыра баруын һәм шул ук вакытта әлегә тәрҗемә эшенә игътибар җитеп бетмәвен искәртеп үтте.

Татар язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү турында тәрҗемәчеләр секциясе бюросы члены Азалия Бадюгина сөйләде. Филология фәннәре кандидаты Рүзәл Йосыповның чыгышы политик әдәбиятны һәм В. И. Ленин хакындагы әсәрләрне татарчага тәрҗемә итү мәсьәләләренә багышланган иде.

Докладлар буенча фикер алышуларда язучылардан тәҗрибәле тәрҗемәчеләр С. Әдһәмова, А. Шамов тәрҗемә эшен киң яктыртып, яшь тәрҗемәчеләргә эшлекле киңәшләр бирделәр.

З. Нури, Г. Ахунов, М. Рәфыйков, Т. Нурмөхәмматовларның да чыгышлары шулай ук кызыклы, тирән мәгънәле булып нигездә бүгенге тәрҗемә әсәрләренең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән иде.

## ИСТӘЛЕКЛЕ СӘЯХӘТ

СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури белән СССР Язучылар союзы идарәсенең чит ил эшләре комиссиясе председателе, тәрҗемәче Г. Васин Монголиядә булды. Монголия Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Лодонгийн Тудэв, идарәнең секретаре, «Цог» журналы редакторы Далантайн Тарва һәм башка культура эшлеклеләре кунакларны җылы каршыладылар.

Совет һәм Монголия язучылары ике ил өчен дә әһәмиятле иҗат мәсьәләләре, оешыру эшләре буенча зур сөйләшү алып бардылар. З. Нури һәм Г. Васин «Правда» газетасының Монголиядәге үз корреспонденты В. Шаров, ТАСС корреспонденты К. Балдаханов, Совет илчелегенең культура бүлеге мөдире Б. Савинов белән очраштылар, «Сухэ-Батыр юлы» исемендәге авыл хуҗалыгы берләшмәсендә булдылар.

СССР Язучылар союзы һәм Монголия Язучылар союзы арасында 1974—1975 елларга хезмәттәшлек килешүенә кул кую тантанасына Монголия Халык революцион партиясе Үзәк Комитетының культура бүлеге һәм секторы мөдирләре, Монголия Чит ил эшләре министрлыгының культура бүлеге мөдире, Совет илчелегенең культура бүлеге мөдире, матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре катнашты.

1974—1975 елларда кырыкка якын СССР язучысы — Монголиядә һәм шуның кадәр үк монгол язучылары Совет илендә булачаклар.

## ТАТАР МУЗЫКАСЫ — БЕЛОРУССИЯДӘ

Белоруссия дәүләт филармониясенең концерт залында татар симфоник музыкасы концертлары зур уңыш белән узды. Бу истәлекле һәм ике республика өчен дә әһәмиятле очрашуга композиторларыбыздан А. Монасыйпов, М. Яруллин, Р. Еникеев, музыка белгече П. Исәнбәт һәм дирижер, профессор Н. Рахлин катнашты. Композиторлар Минск тамашачыларын үзләре иҗат иткән әсәрләр һәм, гомумән, бай тарихлы татар музыкасы белән таныштырдылар.

Н. Җиһановның «Сабан туе» симфониясен, Р. Еникеевнең фортепиано концертын, М. Яруллинның балалар өчен язылган сюитасын, А. Монасыйповның «Муса Җәлил» исемле поэма-симфониясен белорус дуслар аеруча дулкынланып тыңладылар.

## КОМПОЗИТОРНЫ ИСКӘ АЛУ

М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Г. Тукай бүләге лауреаты, композитор Фәрит Яруллинның туума 60 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне СССР халык артисты, Татарстан композиторлар союзы идарәсе председателе Н. Җиһанов ачты. Сәнгать фәннәре кандидаты Ч. Бәхтиярова композиторның тормыш юлы һәм иҗаты турында доклад сөйләде.

Соныннан Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетыннан өзекләр күрсәтелде, ул иҗат иткән җырлар һәм инструменталь әсәрләр башкарылды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Январь, февраль айларында Татарстан язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләре аеруча әйбәт эшләде.

Шагыйрьләр секциясе членнары яшь шагыйрь Ә. Гадел иҗатына анализ ясадылар, әдәбият галиме Н. Юзиевның «Шигырь гармониясе», «Хәзерге татар поэтикасы» дигән китабы буенча фикер алыштылар.

Проза секциясендә Ә. Гаффаров, А. Вергазов, Р. Фәизов һәм башка яшь прозаикларның яңа әсәрләре укып тикшерелде.

Драма секциясендә С. Шәкүревнең яңа пьесасы, балалар әдәбияты секциясендә Җ. Дәрзамановның әкиятләр китабы, тәнкыйтьчеләр секциясендә бүгенге әдәби рецензияләр хакында зур, житди сөйләшүләр булды. Секция утырышларына Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә Еники кебек тәҗрибәле өлкән әдипләр катнашып, яшь авторларның иҗатларына кагылышлы фикерләр әйттеләр, киңәшләр бирделәр.

## БҮЛӘККӘ ЛАЕК БУЛДЫЛАР

Узган ел «Дружба народов» журналында Р. Мостафинның тәнкыйть мәкаләсе, Р. Фәйзуллинның шигырьләр циклы басылып чыккан иде. Бу әсәрләр «Дружба народов»та 1973 елны басылган иң яхшы әсәрләр рәтенә кертелде һәм журналның бүләгенә лаек булды.

* * *

1973 елның 30 январенда КПСС өлкә комитеты секретариаты кабул иткән карар нигезендә промышленность һәм авыл хуҗалыгы коллективлары хезмәт кешеләре турындагы әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә смотр-конкурслар игълан иттеләр. Питрәч районының Вахитов исемендәге колхозы уздырган конкурста В. Нуруллинның «Күпер чыкканда», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» әсәрләренә югары бәя бирелде. Авторлар (В. Нуруллин — I дәрәҗә, Х. Хәйруллин — II дәрәҗә) дипломнар белән бүләкләнделәр.

* * *

«Азат хатын» журналы профессиональ белем алган эшче хатын-кызларның фидакарь хезмәтен, рухи тормышын чагылдырган иң яхшы хикәяләргә конкурс уздырды.

Конкурска алтмышка якын автор катнашты. Жюри беренче бүләкне «Туй бүләге» хикәясе өчен Г. Сабитовка, икенче бүләкне «Нәселләре шундый» хикәясе өчен В. Монасыйповка бирергә карар чыгарды. М. Маликовага кызыксындыру бүләге бирелде.

* * *

Язучы һәм журналист Самат Шакирның хәрби-патриотик темага дистәгә якын китабы бар. Шушы әһәмиятле өлкәдә актив эшләвен искә алып, ДОСААФ Үзәк Комитеты Самат Шакирны СССР ДОСААФының «Почет билгесе» значогы белән бүләкләде.

## МУЗЕЙ ЗАЛЛАРЫНДА

Сынлы сәнгать музеенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнәс Тумашевка 50 яшь тулу уңае белән аның иҗатына багышланган күргәзмә оештырылган иде.

Рәссамның төрле елларда, төрле спектакльләр өчен эшләнгән декорацияләрен, республикабыз табигатен, эшчеләр һәм колхозчыларның даңлы хезмәтен чагылдырган картиналарын, этюдларын тамашачылар зур соклану белән карадылар.

* * *

Сынлы сәнгать музеенда оештырылган күргәзмәләрнең берсе Гайшә Рахманкулова иҗатына багышланган иде. Тамашачылар үзенчәлекле рәссамның йөздән артык әсәре белән таныштылар. Замандашларыбыз портретлары, туган җиребез пейзажлары, Казан шәһәре күренешләре һәм авторның иң яраткан жанры — натюрмортлар бик күпләрнең күңелендә якты эз калдырды.

## РЕСПУБЛИКАБЫЗ БУЙЛАП

Татарстанның атказанган артисты Габдулла Рәхимкулов житәкчелегендәге эстрада бригадасы Түбән Кама, Бөгелмә, Азнакай, Әлмәт шәһәрләре хезмәт ияләре, КамАЗ төзүчеләре каршында йөзгә якын концерт бирде.

Г. Рахимкулов һәм Ф. Сөләйманова башкаруында татар халык җырларын, конферансье Н. Низамиева, баянчы Р. Курамшин чыгышларын тамашачылар аеруча җылы кабул иттеләр.

* * *

ТАССРның атказанган артисты, Тукай бүләге лауреаты Айрат Арсланов КамАЗ төзүчеләре белән еш очраша. Әле күптән түгел генә А. Арсланов КамАЗда 200 нче чыгышын ясады.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ «ИДЕЛ»

Татарстан язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышында «Идел» альманахын тикшерү булды. Язучы А. Гыйләҗев «Идел»нең моңа кадәр чыккан саннарына тулы анализ ясады, альманахның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтеп китте. Фикер алышуларда Х. Туфан, З. Нури, Г. Ахунов, Ә. Баянов, М. Шабаев, Х. Сарьян һәм башкалар катнашты. Ул чыгышларда яшьләр альманахының сыйфатын яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәр әйтелде. Соңыннан «Идел»гә яңа редколлегия составы сайланды.

## КИРӘКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

Арчада республика күләмендә халык авыз иҗатына багышланган семинар-киңәшмә үткәрелде. Анда һәр районнан культура йортларының художество җитәкчеләре катнашты. Авылларда үзешчән сәнгатьне үстерүдә халык авыз иҗатының роле турындагы докладны ТАССР Культура министры урынбасары М. Низамиев сөйләде. Фән кандидатлары М. Нигъмәтҗанов, И. Надыйров, Х. Гобәйдуллин, язучы һәм әдәбият белгече М. Мәһдиев чыгышлары да кызыклы һәм эчтәлекле булды. Киңәшмәгә катнашучылар үзара тәҗрибә алмаштылар.

## ШЕФЛАР ЯРДӘМЕ

Казан дәүләт курчак театры Мамадыш районы мәктәпләренә шефлык күрсәтә. Шефлар инициативасы белән Түбән Сөн, Югары Ушма, Тәкәнеш, Усали кебек зур авылларда пионер курчак театрлары эшли башлады.

Әле күптән түгел генә район үзәгендә пионер курчак театрлары җитәкчеләре һәм пионер вожатыйларының берләштерелгән семинары булып узды. Семинарга катнашучылар Ушма курчак театрының «Үги кыз», Казан дәүләт курчак театрының «Энҗеле үрдәк» спектакльләрен карадылар. Соңыннан фикер алышулар, тәҗрибә уртаклашулар булды. Семинарда Казан дәүләт курчак театры җитәкчеләре — директор Ә. Хөсәенов, режиссер Л. Рабинович, рәссам М. Эльберг, педагог Л. Имаева, драматург Р. Батуллин курчак театрына кагылышлы мөһим мәсьәләләргә тукталдылар, һәвәскәр артистлар белән теоретик һәм практик дәресләр уздырдылар.

## ШӘРИФ КАМАЛ УРАМЫ

Шәриф Камалның тууына 90 ел тулу уңае белән хезмәт ияләре депутатларының Рузаевка район Советы язучының туган авылы Пешләдәге бер урамга Шәриф Камал исемен бирү турында карар кабул итте.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Күренекле татар язучысы Шәриф Камалның тууына 90 ел тулу уңае белән язучының туган авылы Пешләдә (Мордва АССР) зур тантана булды. Бу олы бәйрәмгә Татарстаннан Тукай бүләге лауреаты, шагыйрь Х. Туфан, прозаик Г. Минский, шагыйрь Зөлфәт барган иде.

Тантаналы җыелышта партия һәм профсоюз вәкилләре, укытучылар, колхозчылар, Ш. Камалны күреп белгән ветераннар, Татарстан язучылары исеменнән Г. Минский, Мордва АССР язучылары исеменнән Ф. Адрианов чыгыш ясады.

Соңыннан Х. Туфан белән Зөлфәт шигырьләр укыдылар. Авылның үзешчән сәнгать көчләре Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен куйдылар.

* * *

Тәнкыйтьче Р. Мостафин Биектау районының Ленин исемендәге колхозында укучы балалар һәм колхозчылар белән очрашты, үзе эзләп тапкан материаллар буенча герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында сөйләде.

* * *

Февраль аенда язучы А. Гыйләҗев Казанның 94 нче мәктәбендә уздырылган сорау һәм җавап кичәсенә катнашты. Кичәдә А. Гыйләҗевнең Мәскәүдә басылып чыккан китаплары игътибар үзәгендә булып, автор укучыларны кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап бирде.

Шул ук айда А. Гыйләҗев татар театр училищесында да булды. Ул студентлар

белән бүгенге драматургия, республикабыздагы культура һәм сәнгать яңалыклары турында кызыклы әңгәмә үткәрде.

* * *

Казанның 74 нче мәктәбендә язучы Л. Ихсанова һәм шагыйрь И. Юзеев катнашында әдәби кичә булды. Кунакларның чыгышын тыңлаганнан соң укучылар үзләре дә төрле буын татар шагыйрьләренең шигырьләрен укыдылар, язучылар хөрмәтенә концерт куйдылар.

* * *


Казан медицина училищесы студентлары шагыйрь И. Юзеев иҗатына багышланган әдәби кичә оештырдылар. И. Юзеев студентларга яңа әсәрләрен укыды, бүгенге поэзия турында сөйләде. Кичәгә композитор Ф. Әхмәтов та катнашты. Аның И. Юзеев сүзләренә язылган көйләрен җырчылар К. Хәйретдинова һәм З. Җаббаров башкарды.

* * *

Прозаиклар М. Хәсәнов һәм Х. Хәйруллин, драматурглар С. Кальметов һәм Ю. Әминов, шагыйрь Р. Мингалимов, нәфис сүз остасы М. Шиһапов Сарман районы колхозларында булып, культура сарайларында, клубларда, фермаларда, мәктәпләрдә чыгышлар ясадылар, әдәби кичәләр үткәрделәр.

## ЗӘҢГӘР ЭКРАНДА

Р. Төхфәтуллинга 50 яшь тулуга багышланган телевизион тапшыруда Р. Мостафин, Ф. Миңнуллин, М. Мәһдиев кебек күренекле тәнкыйтьчеләр катнашты. Алар сәләтле прозаик Р. Төхфәтуллин иҗаты хакында кызыклы әңгәмә алып бардылар. Соңыннан тамашачыларга төрле буын артистлары башкаруында Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым», «Акбүз ат» кебек күләмле әсәрләреннән өзекләр тәкъдим ителде.



Композитор НӘҖИП ҖИҺАНОВ
Ф. ӘМИНЕВ рәсеме

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210